# Казан утлары

АПРЕЛЬ
№ 4
1966

*„Казан утлары“ журналы, нигездә, подписчиклар санынча тираж белән генә басыла. Бу ел аның киоскларда сатыла торган саны бик нык кимеде. Журналга ярты елга гына язылган иптәшләрдән, әгәр киләсе ярты елда да „Казан утлары“н укырга теләкләре булса, подпискаларын 15 майдан да соңга калмыйча яңартуларын үтенәбез.*

ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ:

ярты елга — 2 сум 40 тиен.

*РЕДАКЦИЯ.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

4

АПРЕЛЬ

1966

## Бу санда:

**Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Ж. Сыздыков. Син Жаекта канат кактың. Шигырь. 3
Х. Туфан. Чәчәкләр китерегез Тукайга; Юл. Шигырьләр. 3

**ПОВЕСТЬ, ШИГЪРИ РОМАН, ХИКӘЯ, ПОЭМА**

И. Гази. Канатланыр чак. Повесть. Ахыры. 5
С. Баттал. Чирмешән якларында. Шигъри роман. 51
А. Хәсәнов. Гомер иткән нигез. Хикәя. 62
С. Сөләйманова. Язылмаган җырлар. Поэма. 66

**Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Г. Халит. Бәхәссез һәм бәхәсле хакыйкатьләр 75
Р. Ганиева. Уртак кояшыбыз. 87
Г. Сәгъдеваккасов. Уйгур әдәбиятына Г. Тукайның тәэсире. 93

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Г. Гобәй. Коръән серләре. Дәвамы. 95

**СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА**

Я. Румянцев. Ильич белән бергә 121

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Н. Исәнбәт. Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре . . . . . . . 124
Г. Халит. Г. Тукай хаты . . . . . . . . . . . . 127
С. Исәнбаев. Архив актарганда . . . . . . . . 127

1965 ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

М. Әмир. Җыелышны ачу алдыннан . . . . . . . 129
Р. Мостафин. Киң колачлы, тирән фикерле . . . . 132

Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Н. Ханзафаров. «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» һәм хәмсә, назирә традициясе . . . . . . . . 140
Х. Хәсәнов. Шагыйрь һәм патша цензурасы . . . . 142

К. БАСЫЙРОВНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Н. Гыйззәтуллин. Язучы истәлегенә . . . . . . 145

Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Б. Бикбай. Беренче укыган шагыйрем . . . . . . 147
Г. Кайбицкая. Ул минем туган абыем кебек иде . . 148
Ш. Әхмеров. Тукай һәм Сәйдәш . . . . . . . . 150
З. Бикбаев. Минһаҗ кем иде? . . . . . . . . . 151

ТЕАТР

Ә. Җәләлиев. Тамашачы сүзе . . . . . . . . . 152
«Казан утлары»н балкытучылар . . . . . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . 156

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый.*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары.*

Жакан Сыздыков

Казакъ шагыйре.

## Син Җаекта канат кактың

Бала чактан сөйдем сине,
Сөйде сине казакъ иле;
Иркәләде тал, тирәге,
Үзең сөйгән казакъ җире.

Сөйде сине якты Җаек,
Йөзде анда синең каек.
Дулкыннары чайкалдылар
«Апушым» дип кочак җәеп.

Җырлап үттең Җаек буйлап,
Җаек ярларында уйнап.
Бүген синең туган көнне
Җаек каршы ала туйлап.

«Без күктә өч йолдыз» дидең,
Яңгырады җырың синең:
«Пар ат»ыңны, «Туган тел»не
Сөйде илең, сөенде илең.

Казакъ җирен, бөдрә талын,
Казакъ халкын син мактадың, —
«Киң күңелле, риясыз» дип,
Үз иттең син казакъ җанын.

Син Уралда чәчәк аттың,
Казакъ ризыгы тәмен татыдың:
Җанга шифа, тәнгә дәва —
Сары кымыз, ак каймакның...

Мин өйрәндем синнән җырга,
Синнән илһам аламын мин.
Бар җырчылар арасында
Сине остаз санадым мин.

Йөрәкләрдә синең ялкын!
Син Җаекта канат кактың.
Җырларыңнан биек күктә
Син мәңгелек йолдыз яктың.

Алма-Ата, 1966 ел.

*Нури Арсланов* тәрҗемәсе.

Хәсән Туфан

## Чәчәкләр китерегез Тукайга

Әйләнәндә — гөлләр...
Сүзен, гүя,
Шулар аша әйтә күңелләр:
— Туган көнең белән! — дигән сыман,
Елмаялар кебек бу гөлләр.

Килә, килә... Язлар саен сиңа
Илең килә туган көнеңдә,
Бетми торган гомерен кушкан сыман
Синең бөек, кыска гомергә.

Ераклардан, йөзләп сукмаклардан
Килеп меңнәр һәйкәл каршына,
Еллар саен арта бара торган
Сәламнәрен сиңа тапшыра.

Әбиләр дә килә синең янга,
Ил улының хәлен белергә:

«Еллар үткән... Ләкин син һаман яшь,
Син һаман сау безнең күңелдә...»

Туган илнең тирән ихтирамын
Әверелдереп гөлгә, чәчәккә,
Туган көнең белән котлап килү
Керсен иде гомум гадәткә.

Без чәчәкләр аша тапшырырга
Тиеш тә бит сиңа сәламне...
Ел буена тик бер генә тапкыр
Күрәсең син, Тукай, аларны.

Ник кырларда чәчкә өзгән чакта
«Тукай өчен бусы» димәскә?
Ник кырлардан кайтып килгән чакта
Синең янга керә китмәскә?

Ял көнендә кырлар-болыннардан,
Урманнардан кайткан уңайда,
Ел эчендә тик бер генә тапкыр
Килеп китсә һәркем Тукайга,
Синең янда — яздан кышка кадәр
Гөлләр балкыр иде көн саен...
Әйтер иде илләр: — Күрче, ничек
Сөя халык үзенең Тукаен...

Килер илең
меңләп сукмаклардан,
Килер иртән, килер кичләрдә,
Сәламнәрен чәчкәләре аша,
Гөлләр аша тәкъдим итәргә.

## Юл

Тарихның төнле, сөремле,
Томанлы җирләре бар,
Таңнарга таба дәшүче
Тынгысыз ирләре бар.

Бөекләр дәшкән тарафка
Бергәләп җитү өчен,
Булырга тиеш сафында
Быргычы — җырчы кешең.

Талантлы илнең — Киевның
Тарасы [1] — шигъри ире,
Татарның тиңсез баласы —
Тукае шундый иде.

Барасы юлны буталмый,
Бүленми үтәр өчен,
Булырга тиеш, күрәсең,
Байрагың кебек кешең.

[1] Тарас Шевченко.

*Ибраһим Гази*

# Канатланыр чак



*Повесть* [1]

Сыер дуласа, аттан яман дигәннәр. Ноябрь дулап декабрьдан уздырып җибәрде. Җәйге пальтодан гына йөри торган Хәлим (кышкысы әле кибеттә), куырылып институттан кайтып килешли, аста, швейцар өстәлендә, үзенә хат тапты. «Анатолийдан» икән дип уйласа, алай булып чыкмады. Махсус стипендия бирә торган комиссариаттан язганнар. Керәп чыгуны үтенәләр.

Икенче көнне политэкономия дәресеннән качып, Хәлим шунда китте. Мине генә дәшкәннәрме дип уйласа, коридорда бүтән студентлар да өелешеп тора иде. Хәлимгә бөтенләй таныш булмаган чырайлар күренә. Техникумнардан, ахрысы.

«Нигә чакырганнар?» дигән уй һәркайсының күз карашыннан сизелеп тора иде. Кайберәүләр әйтә: «Стипендиядән төшерәләр икән», ди. Икенчеләре: «Төшерсәләр, чакырмаслар иде», диләр.

Коридорда байтак көттереп торганнан соң, эчкә чакырып керттеләр. Өстәл артында язлый институтка килгән пенснеле арык агай басып тора иде. Бүлмәсенә яшьләр килеп тулгач, Дәүләтьяровның коры салкын чыраена елмаю нуры чыкты. Яшьләрнең кайбер сүзләреннән хәтта көлеп тә җибәргәләде. Студент иптәшләрнең рәхим итеп утырышуларын үтенде. Бу юлы Хәлимгә ул хәтта ошады. Чыраеның аклыгы, ябыклыгы белән булса кирәк, Хәлимгә ул мәктәптә математика укыткан Вәли агайны хәтерләтте.

Дәүләтьяров җәй көне кемнең кайда эшләгән булуын сораша башлады. Хәлимнең Т. кантонында исполкомда тылмачлык итүен ишеткәч, бик җанланып китте. «Кемнәр эшли хәзер анда?» — дип кызыксынды.

Чакырылган махсус стипендиатлар арасыннан бер Хәлимне генә шулай якын итеп сорашып утыргач, Хәлимгә иптәшләре алдында күңелле булды. «Исполкомда хәзер председатель булып безнең авылныкы Шәрифҗан Заһиров эшли», дип әйткәч, Дәүләтьяров, нидер исенә төшергән кебек, беркавым дәшми торды, өстәлдәге кәгазьләрен күчергәләде, шуннан соң янә җанланып китеп, урындыгында кыймылдап алды да арык аякларын чалып куйды.

— Башлыйк булмаса, иптәшләр, — диде, ягымлы җылы тон белән башлап җибәрде:

---

[1] Ахыры. Башы журналыбызның 3 санында.

— Коммунистлар партиясе, дип әйтергә кирәк, без татарларга республика бирде. Тик шунысы кызганыч: без үз йортыбызда үзебез хуҗа булып бетә алганыбыз юк әле, чөнки дип әйтергә кирәк, гасырлар буе изелү сәбәпле татарларда дәүләт эше белән идарә итәрлек укымышлы кешеләр бик аз.

Ул өстәл тирәсенә сырышып утырган кайсы ак йөзле, кайсы ал битле, кайсы матур, кайсы ямьсез егетләргә, әйткән бер сүзне йотып утыручы шушы авыл малайларына куанып карый-карый сөйләвендә булды. Янәсе, менә хәзер дә, үз республикабыз вежүткә ашканнан соң да, татар егетенә югары уку йортын тәмамлау ансат түгел. Стипендияләр кечкенә. Күбегезнең ата-аналарыгыз сезгә ярдәм итә алмый, чөнки дип әйтик, эти-әниләрегез иген сатып сезнең өс-башыгызны карасыннармы, налог түләсеннәрме, чәй-шикәр алсыннармы — барысына да ничек иген төткәзмәк кирәк? Керәстиән ала торган шәһәр тавbooksарларының бәяләре бик кыйбат...

Ул өстәлдәге кәгазьләр арасыннан берсен кулына алды.

— Менә, — диде ул, кәгазьне җиңелчә селкеп, — өч ел эчендә тиреяры техникумын бары бер татар бетереп чыккан, химия техникумын ике елда ике татар, ә индустриаль техникумнан бер генә татар да чыкмаган.

Укырга керүчеләр байтак булса да, бетереп чыгучылар шулай гына икән. Сәбәп? Әлеге дә баягы, татар керәстиәне ярлы, — диде Дәүләтьяров, — Казанда укып йөрүче кызына, улына ярдәм итә алмый, тегеләр техникумны ташларга мәҗбүр. Рус керәстиәне бай, аның баласы тынычлап укый, бетереп чыга...

— Юк акчаны бар итеп, без татар студентларына булышабыз. Дәүләт биргән стипендиягә өстәп, тагын үзебездән стипендия бирәбез, — диде ул һәм яхшы укучыларга алда да стипендия бирелеп торачагын әйтте. Тырышып укырга чакырды һәм, зур уңышлар теләп, яшьләр белән саубуллашты. Студентлар, урыннарыннан кубып, барысы да ишеккә таба киттеләр.

— Галиуллин, — дигән тавышка Хәлим, чыгып барган җиреннән туктап, кире борылды. Дәүләтьяров аның бераз сабыр итүен үтенә иде. Кара-каршы утырышкач, Хәлим тегенең текәлүле салкын күз карашлары астында башта үзен бик уңайсыз сизсә дә, Дәүләтьяровның юка иреннәренә әзрәк елмаю кагылганнан соң җиңелрәк сулый башлады. Бу чандыр агайның Т. шәһәрен төпченеп сорашуына Хәлим сәерсенеп утырды. Әти-әниләренең исәнме-юкмы икәнлеген сорагач, үзенең балалар йортында үскән булуын әйтте.

— Күрәм, өс-башыгыз бик юка икән, — диде Дәүләтьяров, егетнең җәйге пальтосына ымлап. — Мин сезгә менә бер язу язып бирим әле... — һәм, өстәлгә иелеп, яза башлый.

«Сау булыгыз» сүзен ишеткәч, Хәлим, иркен сулап җибәреп, тизрәк урамга чыкты. Шул көнне үк кышкы пальтоны алып киде.

Әле кайчан гына Хәлим газетадан укыган иде: ике рус агай обкомга хат язган, Татарстанда русларга юл бирмиләр, кая карама анда татар, эшкә иң әүвәле татарны алалар, уку йортына — тагын татарны, стипендия гел татарларга гына дип зарланганнар иде. Газетада аларның хатларына җавап басылган иде. Ә бу тотты да татарлар үз йортларында үзләре хуҗа түгел дип сөйләде. Хәлимдә сәеррәк тәэсир калды: гүя хөкүмәт татар студентларын кайгыртуны ташлаган, Дәүләтьяров эшли торган комиссариат кына аларны кайгырта булып чыга...

Кайтышлый трамвайда Айдаров белән очраштылар. Дөнья күргән, утны-суны кичкән дип, райком аны частный фабрикага эшчеләр арасында эшләргә дип беркеткән иде. Шуннан кайтып килүе икән. Абзагызның сөмсере коелган. Күрәсең, гадәтенчә, фабрика хуҗасы белән әләгешкәндер. Хәлимнең шулай дип әйтүенә каршы Броневик трамвайда кайтучы

апайларга карап алды да, авызын егетнең колагына китереп, сүгенеп куйды. НЭП дуңгызы (фабрика хуҗасы була инде) партия ячейкасының бюро членнары хезмәтләреннән куып чыгарган. Янәсе, алар эшчеләрне котырталар, забастовкалар мәтәштерәләр. Чыгару гына житмәгән, кара исемлеккә теркәп, Казандагы бүтән частный фабрика хуҗаларына тараткан. Егетләрне бер җиргә эшкә алмыйлар икән.

— Бүген көн буе шуның артыннан чаптым, — диде Броневик, — профсоюзда хуҗа тигәнәсеннән ашаучы дуңгызлар утыра. Коммунистларны яклап алып калмаганнар. Барысының да койрыкларына басам әле мин аларның!..

## 12

Кышкы каникулга шәһәрдә калучы студентларны фабрикаларга, заводларга җибәрәләр иде. Хәлим дә быел авылга бармаска, берәр заводкамы, фабрикагамы беркетүне сорарга булды. Укулар туктар алдыннан утырып гариза язды да Бишбалта райкомолына китте.

Трамвай бистәгә килеп җиткәч, вагон ишегендә чибәр бер татар кызы күренде. Аның маңгаена төшкән чәч алкалары суыктан бәсәреп агарган, битләре алланган иде. Вагонга кыз сыйфатында яшьлек һәм матурлык үзе килеп кергәч, пассажирларның күзе аңа таба юнәлде. Ирләр тураебрак утырдылар. Яшьләр, елмаешып, юри кычкырып сөйләшә башладылар.

Хәлим астыртын гына кызга күз төшергәли иде. Трамвай кузгалгач, кыз, баскан урынында чайкалып китеп, кемнеңдер җиңенә ябышты да уңайсызланудан кып-кызыл булды. Хәлим, үз уйларына үзе үк сәерсенеп: «Матур булса да инерция законына буйсынмый булдыра алмый икән», дип уйлап куйды. Хәлимгә матур кешеләр бөтенләй икенче камырдан ясалганнардыр кебек тоела иде. Битләре матур булган кебек, эчке сыйфатлары да матурдыр, кешеләргә хас кимчелекләрнең берсе дә аларда юктыр кебек иде. Менә бу кызның кем белән булса да әрләшүен яки кешегә берәр тупас сүз әйтүен Хәлим һич күз алдына китерә алмас иде.

Матур кыз тыныч кына басып торган кебек күренсә дә, әллә нихәтле ирләрнең кызыксынучан күз карашлары астында тыныч тору аңа бик кыен булуын Хәлим аңлый иде, әлбәттә. Әнә бит, чибәрегез, матур күзләрен кая итәргә белмичә, әле идәнгә карый, әле бозлы тәрәзәгә карап тора, ул да түгел, көлешеп барган егетләр ягына да күзләрен кыегайтып ала иде. Тыштан караганда, яшьләрнең сүзләренә бөтенләй игътибар итмәгән кебек тоелса да, кара тутлы бит очларының кинәт алланып китүеннән кызның бер генә сүзне дә ычкындырмыйча колагына җыеп баруын Хәлим сизә иде. Ниһаять, егетләрнең нindидер сүзләре аны елмаерга мәҗбүр итте. «Елмайганда бу бөтенләй икенче чибәрлек белән чибәр икән» дип, Хәлим кызның бу үзенчәлеген дә күреп өлгерде. «Бу каһәрең ачуланганда да бик матурдыр», дигән кызык уй башына килде.

Кара тутлы кешеләрнең бик каралары була, бу исә андый түгел, битләре ал кара, ияге бөтенләй ак диярлек иде. Хәлим аны кайсыдыр художникның рәсемендә күргән бер бик матур кызга охшатты, кайсы художникта икәнен исенә төшерә алмый аптырады.

Яңа пассажирлар тукталыш саен керә, искеләре төшеп калырга ашыкмыйлар әле. Хәлим үзенең төшәсе җирен ике тукталышка узып киткән булуын әле генә сизде. Шуннан соң, үзеннән үзе көлеп, тиз генә төшеп калды.

— Матурлыкның көче! — дип, ул райкомолга җиткәнче матурлык турында уйланып барды. — Постауга ышкыгач көмеш тәңкә ничек балкыса, матурлык белән очрашкач, кешеләр дә яхшы яклары белән

ялтырый башлыйлар. «Матурлык арасында мин дә үземне матур сизәм» дип, Лев Толстой әйткән бугай. Хәлимнең үзенең дә сынаганы бар: матурлык янында аның күңелендәге керләре юылып төшә, җаны пакьләнә...

Рәссамнарга бу тойгы таныш бит инде, ни өчен соң алар гарип сурәтләр төшерәләр? Гинзбург әйткәч барган теге күргәзмәдән Хәлим тәмам боегып кайткан иде бит. Шакмак йөзле, сыңар күзле кеше рәсемнәрен күргәннән соң аптырады да калды. Хәлим аңлатып торучы абзыйдан: «Яшел чәчле кеше буламыни?» дип сорагач, аңлатучы агай бик җитди кыяфәт белән бик озак итеп сөйләгән иде: янәсе, табигатьтә төсләр минут саен үзгәреп тора. Кояшлы көндә төс бер төрле булса, кояшсыз көндә шул ук төс икенче төрле булып күренә. Димәк, табигатьтә даими төсләр юк, шартларына карап, төсләр гел үзгәрүчән. Шулай булгач, кара чәчнең мәгълүм бер шартта яшел булып күренүе дә гаҗәп түгел. Балалар гына ул агачны яшел, чәчне кара, кояшны кызыл итеп ясыйлар, ә художник күзе... Кыскасы, аңлатучы абзый зәңгәр һәм яшел чәчләрне яклап сөйләгән иде. «Бөтен кеше сокланып карый торган әлеге матур кызның чәчләрен яшел, битләрен зәңгәр итеп ясасак? — дип уйлады Хәлим, — кыз безгә нәрсә дип әйтер иде икән? Һәрхәлдә, рәхмәт әйтмәс иде. Ә бит мәгълүм шартларда ул кызның да бите зәңгәр булып күренүе ихтимал...»

Райкомол Хәлимне Ягодныйдагы Текстилькомбинатка билгеләде. Икенче көнне Хәлим, комбинатка барырга дип, тагын иртүк урамга чыкты. Көн шактый суык иде. Егет якасын күтәрде.

Бистәгә җитәрәк Хәлим вагон ишегеннән күзләрен алмыйча көтте: теге кыз бүген дә килеп керер кебек тоела иде. Әгәр ул кыз шушы трамвай белән көн саен йөри торган булса, гаҗәп түгел, бер көнне тагын очрашулары мөмкин ич.

Текстилькомбинатның партколлектив секретаре Клочков, маңгай чәче коелып беткән зур башлы, калын җилкәле түгәрәк кеше, Хәлимне ошатты: «Симпатичный студент» дип йөртә башлады. Хәлим цехларда стена газеталары чыгарыша, эшчеләр белән сәяси темаларга гәпләшә, кычкырып газеталар укый, эшчеләрнең зарларын тыңлап, кирәкле тапканнарын фабкомга яисә Клочков агайга сөйли, аннары бергәләп администрацияне «кысалар» иде.

Хәлим беренче көннәрне эшчеләр белән бик базмый гына аралашты. Интеллигент кисәге дип ят итүләреннән курыкты. Дәүләтьяров бирдергән әйбәт пальтосын фабрикага киеп барырга тартына иде. Чатнама январь суыкларында иске юка пальтосын киеп йөрде. Цехларга кергәндә, бигрәк тә йон тетү цехына кергәч, юри йонга буялып чыга иде: янәсе, эшчеләр үз кеше итеп санасыннар. Буялудан курка торган ак сөяк интеллигент түгел, ә эшчеләр белән бер камырдан ясалган кеше, ягъни...

Бер шулай гел диярлек хатын-кызлардан гына торган туку цехына барып керде. Аның студент икәнен, стена газеталары чыгаруын беләләр иде. Хатыннар администрациядән зарландылар: ашханә туку цехыннан җир тишегендә, әллә ничә цехны узып барасы, аннары ашханәнең үзендә әллә ни гомер чират торасы... Ашап өлгерә алмыйча, кире кайткан чаклары да була икән. Кайнар ашны цехның үзенә китереп булмасмы? Аларның үтенече менә шул иде. Фабкомның вәгъдәсе дә бар, имеш. Ашханә работниклары ни өчендер һаман киреләнәләр икән. Хәлим сөйләшеп карарга сүз бирде дә цехның аргы башына таба китте.

Бер туку станогы янында өч-дүрт ир кеше басып тора иде. Хәлим алар катына да туктыйсы итте. Нindидер кыз станокта эшләп утыра, ә егетләр, авызларын җыя алмыйча, аңа карап торалар. Кыз ара-тирә иңбашы аркылы тегеләргә ачулы гына нидер әйткәләп куя иде. Барып туктагач, Хәлим кинәт каушап калды: бу шул трамвайда очрашкан

чибәр кыз үзе иде ләбаса!.. Тик бирелә ул зәңгәр сатиннан тегелгән эш киеме киеп, җиңнәрен терсәктән сызганып, станокта киндер тукый иде. Матурлыкка да трамвайдагыча күз явын ала торган түгел, икенче төрле: эш өсте матурлыгы белән матур иде. Өстәвенә ачулы матур иде. Кыз студентка күзләренең агы белән генә карап алды да, һич көтмәгәндә:

— Карагыз әле, гәҗит абый, — диде. — Язып чыгарыгыз әле, зинһар, сурәтләре-ниләре белән шушыларны гәҗитегезгә! Керәләр дә, күзләре белән мине ашап, эшемә комачау ясап торалар.

— Матур булмаең шул хәтле, без бинават түгел, — диде егетләрнең берсе.

Икенчесе, Хәлимгә күз кысып:

— Студент үзе дә сине карарга кергән, — дип көлеп җибәрде. — Студент халкы кызлар тирәсендә махы бирми ул...

Кыз Хәлимгә бер акаеп карап алды да үзенекен эшләвендә булды.

Комбинатта бик чибәр бер кыз бар дип Хәлим байтактан ишетеп йөри иде. Имеш, фабрикага экскурсиягә килүче яшь-җилкенчәкләр шул кыз эшли торган станок янына өелешеп, юкны-барны сорашкан булып, кызны туйдырып бетерәләр икән, шуңа күрә администрация аны, юл өстендәге станоктан алып, бер почмакка тыгып куйган. Хәлим үзе дә шул кызны күреп чыгарга җыенып йөри иде. Ул кыз әнә кем булып чыкты.

— Ярый, язармын, — диде егет, елмаергамы, җитдилек сакларгамы белмичә. — Сурәтләре-ниләре белән язып чыгармын.

Кайнар аш турысында сөйләшергә ашханәгә кереп караса да, Хәлим ашханә мөдирен очрата алмады. Аны күрим дисәң, иртүк килергә кирәк икән. Шулай да фамилиясен белеп чыкты: Ползунов Федор икән.

— Ползунов кына булса да гел чабып йөри ул,— диделәр Хәлимгә.

Хәлим икенче көнне иртүк йөгереп килде, шулай да «дядя Федяны» инде ашханәдә очрата алмады. «Яңа гына чыгып китте, фабкомда түгел микән», диделәр. Хәлим фабкомга керде. «Яңарак кына чыкты, дирекциядә түгел микән», диделәр. Хәлим дирекциягә йөгерде. «Бу Ползунов артыннан чабып та җитеп булмый», дип, егет күңеленнән көлә иде. Ул аны дирекциядә дә тота алмады. «Гаражда түгелме» дип, Хәлимгә гаражны ничек табарга өйрәтеп чыгардылар.

Хәлим фабрика территориясенә йөгереп чыкты. Хәлимнең әле бер тапкыр да Ползуновны күргәне юк иде, шулай да фабрика ишек алдыннан чабып баручы кешене күргәч, «шул!» дип, тизрәк аның артыннан йөгерде.

Ползуновның ни өчен шулай ашыгып йөрүен ул соңыннан гына аңлады. Ашханәдә көн саен нидер ашатырга кирәк, продукт җитми, шәһәр складларына соңарып барсаң, вермишель белән тары ярмасыннан бүтән бернәрсә булмый. Өстәвенә, ашханәнең үз машинасы юк, гел дирекциядән теләнергә туры килә. Ун елдан артык ашханәләрдә эшләү гомерендә ул әнә шулай кабаланып яшәргә күнегеп киткән икән.

Әйткәнебезчә, Хәлим моны әле соңыннан гына белде, хәзер исә ул кыршылып беткән сары портфель кыстырган, бүреге арткарак киткән, кырык километр чапкан ат кебек тирләп, мышнап чыккан Ползуновның артыннан куып җитте дә җиңеннән тотты.

— Сезгә нәрсә? — диде теге, йөрешен бераз гына да әкренәйтмичә. — Ни кирәк? Дөге сорамагыз, бетте. Шикәр дә юк, кесәлгә салырга да җитми. Туктатмагыз мине, ашыгам.

Хәлимнең һаман ияреп баруын күргәч:

— Сез кем? — дип сорады.

Студент дип әйтә алмый бит инде.

— Мин партколлективтан. — диде Хәлим.

— Бер кило дөге бирә алам, артык сорамагыз. Эшчеләр дә гарнирга гел вермишель ашыйлар.

Хәлим үзенең йомышын, ниһаять, аңлатып биргәч, Ползунов егеткә гаҗәпләнгән кыяфәт белән күтәрелеп карады да:

— Ә мин цехка ашны бүрегем белән ташырмынмы? — дип, баш чүмечендә көчкә эләгеп торган бүреген тартып алып, Хәлимгә таба сузды. — Бүрегем беләнме? Минем кулда аш термослары юк бит!

Хәлим хатыннарның ашап өлгерә алмауларын кабат-кабат әйткәч, фабкомның вәгъдәсе барлыгын һәм колдоговорда да ерак цехларга ашны ташып ашату хакында пункт барлыгын сөйләгәч, дядя Федя:

— Карарбыз, уйларбыз, — дип, тизрәк Хәлимнән котылу ягын карады.

— Кайчанрак? — диде Хәлим төпченеп. — Алар бит ач кала, барып-кайтып өлгерә алмыйлар...

— Ә мин өлгерә аламмы? — диде дядя Федя. — Менә мине сез тотып торасыз, чыгып киткәнче тагын биш кеше тотачак. Ә мин трестка соңга калсам, иртәгә нәрсә ашатырмын? Тагы вермишельме? Уйларбыз, җаен, может, табарбыз...

Хәлим партколлектив секретаре Клочков агайга керде дә хәлне сөйләп бирде. Клочков ялтырап торган маңгай турысын сыпырып-сыпырып куйды. Аның бу җире шундый шомарган, шундый ялтырый, тәрәзәдән төшкән кышкы кояш нуры көзгедәге кебек чагыла иде. Хәлим ирексездән үз маңгаен сыпырып куйды.

Егетнең сүзләрен тыңлап бетергәннән соң, Клочков агай колдоговорның үтәлеше турында фабкомның отчеты озакламый бюрога куелачагын әйтте.

— Менә шунда инде без мәсьәләне үткен почмагы белән китереп куярбыз, — диде.

Хәлимгә бу бик озак булып тоелды. Телефон трубкасын алырга да фабком председателе белән партийный телдә әйбәтләп бер сөйләшергә. Бетте китте! Колдоговорда махсус пункт булгач, фабком белән дирекция аны үтәргә мәҗбүр ич!

...Хәлим, комбинат капкасыннан чыгып, бүреген басыбрак киде дә трамвай тукталышына таба китте. Хәлим бит әле теге чибәрнең исемен дә белми. Икенче баргач, берәрсеннән сорарга кирәк булыр: ни атлы икән?

## 13

Инде күпме вакыт үтте, «дядя Федя» туку цехына кайнар аш бирә алганы юк. Бюро карары һавада асылынып тора. Имеш, махсус аш бидоннары ясатырга заказ бирелгән. Бидоннар өлгерүгә кайнар аш булачак.

Каникул күптән беткән, лекцияләр башланган булса да, Хәлим комбинатка барып чыгарга ара таба. Кайнар аш артыннан йөрим, шуны булдырмыйча туктамыйм, дип уйлый. Туку цехына керергә туры килгәндә, теге чибәр кыз утырган ерак почмакка бармаска тырыша. Уйламасыннар әле, башкаларны стена газетасына язып чыгарды, ә үзе шул кыз тирәсендә сырпаланып йөри дип... Гомумән ул кыз Хәлимгә бик ошамый: шактый усал күренә...

Шул кыз аркасында ямьсез вакыйгалар килеп чыга язды. Эш вакытында кыз тирәсенә җыелучылар стена газетасындагы карикатурадан үзләрен таныганнар. Берсе Хәлимгә пычак күрсәтеп китте: «Кара аны, студент, безнең кызлар янында бик чуалсаң, кызыл күлмәк кидертербез!» дип, пычагы белән мәгънәле генә селтәнде. Безнең егеткә хәзер револьвер тыгып йөрергә туры килә.

Ул комсомоллардан җиңел кавалерия отряды оештырды. Комбинатның ишек алдында кар астыннан чыккан, тирес кебек өелеп яткан әйберләрне актарып карадылар, берничә тонна йон һәм житен сүсе табылды. Ә кыш көне йон тетү машиналары ике атна тик торган иделәр, йон булмаган иде. Көтмәгәндә ишек алдыннан йон табылгач, эшчеләр: «Менә бит!» дип шаулаша башладылар. «Кем гаепле моңа? Җавапка тарттырыгыз!»

Тукучы хатыннар да бик каты чәпчеде: «Аркау җебе минут саен өзелгәч, инженер Палевский безне гаепли, янәсе, без эшли белмибез, лодырьлар, ялкаулар! Кар астында кышлаган черек сүстән эрләгән җеп ничек минут саен өзелмәсен! Бер быел гына чертүләре түгел, узган кышны да черттеләр!»

Шулай дип, стена газетасы тирәсендә хатын-кыз шау-гөр килде. Газетага язганга дирекциянең кәефе кырылган иде. Имеш, эшчеләрне администрациягә каршы котырту булып чыккан. Дирекция тирәсендә Хәлимгә, гаепле кешегә караган кебек, дошманый күз белән карый башладылар. «Студентның администрация эшенә тыгылып йөрергә ни хакы бар?» — дип әйткән, имеш, директор Кальсенсон.

Хәлим борчылып партколлектив секретарена керде. Клочков агай, гадәтенчә, ялтыр маңгаен сыпырып куеп, егеткә:

— Продолжай, старина, в том же духе. Поддержим! — дип канат куеп чыгарды.

Шушы канатта Хәлим байтак вакыт очып йөрде. Җитте бер көн, йөгерә-йөгерә фабрика ишек алдыннан узып баручы дядя Федя үзенә каршы очраган «бәйләнчек студентка»:

— Бидоннар кайтты! — дип кычкырып китте.

Хәлим, фабкомда аунаган бер плакатны алып, бармагын карага манды да плакатның ак ягына:

«Тукучы иптәшләр!

Бүген сезнең цехка кайнар аш килә!» дип калын-калын хәрефләр белән язды һәм, Ползунов кебек үк тиз булмаса да, шактый үк кызу йөгереп, туку цехына кереп китте.

Хатын-кызлар Хәлим элгән язу каршына өелештеләр.

— Булмас! — диделәр өметләре өзелгәннәре.

Хәлим читкәрәк китеп баскан иде. Ул, карамаган шикелле булса да, плакат янына кемнәр килгәнне карап, күзәтеп, чибәр кыз Галимә килеп укыр микән дип көтә иде. Кыз күренмәде.

Ашау сәгате җитәрәк, Хәлим үзе ашханәгә чапты, бидоннарны кызулатты. Ике тәгәрмәчле кечкенә арбага утыртылган ике ак бидон цех ишегендә күренгәч, хатыннар «ах!» иттеләр. Хәлим хатыннардан бигрәк үзе куанды. Бидоннарны ишек бусагасыннан кертергә булышты.

Кечкенә арба артыннан ук, сары портфелен култыгына кыстырып, дядя Федя йөгереп килеп керде. Моннан бер ай, бер атна элек кереп карасын иде ул, карчыгага ташланган яр карлыгачлары кебек дәррәү кубып, хатыннар аның кирәген биргән булырлар иде. Бүген исә «рәхмәт» сүзләре белән бергә ашханә мөдиренең өлешенә матур-матур елмаюлар да эләкте.

— Менә кемгә рәхмәт әйтегез! — дип, ул «рәхмәтләрне» Хәлимгә биреп, елмаюларны үзенә җыйды да, «Ашыгам!» дигән булып, тиз генә чыгып китте.

Хәер, елмаюлар Хәлим өлешенә дә калган иде әле. Бигрәк тә берсенең елмаюы егетнең күңеленә хуш килде. Аш тәлинкәсе тотып, бидоннар янына баскан Галимә кап-кара күзләре белән Хәлимгә елмаеп карап тора иде.

...Бер көнне егет столярлар цехына бара иде, һич көтмәгәндә Галимә белән кара-каршы очрашты. Галимә, кызгылт күлмәктән ялкындай җилфердәп, исәнләшеп узып китте. Кинәт очрашканга Хәлим исәнлә-

шергә өлгермәде. Бер сүз дәшмичә шулай узып киткәч, үзенең артында: «Гәҗит абый, әллә телеңне йоттыңмы?» дигән, инде бөтенләй дә көтелмәгән сүзләрне ишетте.

Борылып караудан үзен чак-чак тыеп кала алды.

Абый... Хәлим шулай ук абый да булды микәнни инде!.. «Гәҗит абый, әллә син телеңне йоттыңмы?» Бөтен кешене үзенә табындырып та, чибәр яшь студентның салкын гына йөрүенә чыдаша алмаудан, тагын берәүне табындырырга ашкынудан гына әйтелгән сүзләр түгел микән бу? Әллә чынлап та бу матур дошманның йөрәгенә очкын төштеме?

Шулай уйланып, егет столярныйга барып керде. Аяк асты гел йомычка. «Тәмәкече! Ут чыкса синнән генә!» дип, күзгә кадалырлык итеп, стенага язу язылган. Хәлим сораган ящикларны ясап куйганнар иде. Аннары комсомоллар ящикларны цехларга элделәр. Барлык кеше дә әйтәсен җыелышта әйтә алмый бит. Кайсы сөйләүдән тартына, кайсы мастердан курка. Ящикка язып салганда исемеңне куймаска да мөмкин. Җаваплар стена газетасында басылачак.

Хәлим атна саен цехлардан берәр кепка язулы кәгазь алып чыга башлады. «Работница» дип кул куйган берәү яза: «Мельникова Галина дигән хатынны эшкә алдылар, ире дә эшли, үзе дә эшли, нигә бер семьядан ике кеше аласыз? Бөтенләй эш таба алмаучы семьялар да күп бит».

Икенче, өченче язуларны ачып куйды Хәлим:

«Ипи кибетендә гел чират. Фабком ни карый?»

«Сортировщиклар йонны начар сортлый. Тетү цехына начар кергән йонны тетеп кенә яхшыртып буламы?!»

«Культработагыз шул булыр, чәй кайнатырга чәйнекләр алып бирегез».

«Ашханәдә тәмәке бик тарталар. Ахран труда, күзең кайда?!»

«Дүртенче рәзрәтле эшче сигезенче рәзрәтледән күбрәк ала, тарифный комиссия, йокыңнан уян!»

Шундый язулар рәтеннән менә мондые да килеп очрады:

«Русларны эшләреннән чыгарып бетереп, гел татарларны гына куячаклар дип лыгырдыйлар, шул дөресме? Татреспублика татарлар өчен генә булгач, без кая китик? Куприянов».

Хәлим бу язуны, Клочковка бирергә дип, аерып куйды.

«Ярдәм кассасына кайчан барма, акчалары юк. Ярдәмне гел мастерларга гына бирәләр, эшче агайга шымытыр. Сезнеңчә, шул дөрес палитикамы?»

Бу язу фабкомга китәчәк — өстәлнең уң почмагына барып ятты.

«Станок бозылса, атна буе ремонтламыйлар. Тукучы Бабикинаның станогы бик барахлит итә, шалт-шолт килә, җепне өзә, көн буе тукыганы 12—15 метр. Мастерга әйткәч, минем биш кулым юк, ди».

Бусы өстәлнең сул почмагына барып төште — дирекциягә.

Кулына эләккән чираттагы кәгазьне укыганда, Хәлим көлеп җибәрде:

«Марҗа кызына өйләнергә ярыймы? Татар кызының аягы камыт. Өйләнергә йөрүче».

«Коммунист Камалетдиновның хатыны баланы сөннәткә утыртыйк дип бәйләнә. Ире: «Утыртмыйк!» ди. Көн саен талашалар. Киңәш сорап райкомга баргач, анда: «Хатының кадерлеме, партияме?» дип кайтарганнар. Партия миңа кадерле дип, хатынын сугып үтерсенмени инде? Күршеләре».

Сорауларга җавап язган газетаны халык, гадәттә, минуты белән сарып ала иде. Бу юлы да, смена бетәр алдыннан Хәлим газетаны кертеп элгәч, бөтен цех урыныннан купты. Күрше цехтагы ирләр дә керделәр.

## 14

Җыелышларда сөйләнә торган гадәти генә доклад әзерлим дип керешкән Хәлим, материалның эченә чумгач бик каты мавыгып китеп, кызыклырак доклад әзерләп барырга булды. Әгәр шунда Хәлимгә: «Синең бит матур кыз Галимә алдында бер ялтырыйсың килә, шуңа күрә бик тырышасың, шуңа күрә докладыңа шигырьләрдән өзекләр, әллә нинди канатлы сүзләр тутырасың», дип әйтсәләр, ул кызарыныр иде, «Юк!» дигән булыр иде, ләкин күңеленнән үзе үк: «Чынлап та, шулай бит», дип уйлар иде.

Оста сөйләү турындагы китапларны ул юкка гына китапханәдән ташымады, Броневиклар өйдә юк чакта юкка гына бүлмәдә докладын кат-кат сөйләп карамады — бу доклады белән ул «кайберәүләрнең» исләрен китәрмәкче була.

Түләүсез кино булачак дигәнгәме, клубка яшьләр күп җыелган иде. Комбинатның комсомол секретаре Сыйчугов җыелышны ачты да «иптәш Галиуллинга» сүз бирде. Хәлим, кулына бер төрле язу тотмыйча, зал каршына килеп чыкты. Аның нияте кайчандыр үзе тыңлаган, оста сөйләве белән Хәлимне таңга калдырган бер оратор сыман кәгазьгә бер дә карамыйча сөйләү иде.

Менә ул алгы рәттә утыручыларга елмайды да беренче сүзләрен әйтте. Зал белән оратор арасында якынлык, дуслык җепләре сузар өчен генә әйтелгән бу ярым шаян, ярым җитди сүзләрне ишетеп, алдагы рәтләр көлеп җибәргәч, арттарак утыручылар: «Нәрсә әйтте ул, ә? Нәрсә әйтте?» дип күршеләреннән сорадылар. Маневр уңышлы чыкты. Зал докладчы һәм доклад белән кызыксына башлады. Шушы хәлдән файдаланып, Хәлим партия һәм хөкүмәтнең совет аппаратын яхшыртырга, хезмәт ияләренә якынайтырга тырышуларын сөйләп китте. Аппаратка кереп оялаган бюрократларны, коммунизмга сигездән дүрткә хәтле генә хезмәт итүче түрәләрне, агач җанлы төрле чиновникларны аппараттан «өфертергә» кирәген әйтте.

Әле трибунага чыкканчы ук, Хәлим Галимәнең кызлар арасында залда утыруын күргән иде һәм күргәч, кинәт битләренең кызышуын сизгән иде. Беренче сүзләрне Галимә дә ишетми калды булса кирәк, Хәлим аның кызларга янтаеп нидер соравын күрде. Димәк, матур кыз Галимә дә аның доклады белән кызыксынды.

Газета битләрендә көн саен язылып, колакны «сасытып» бетергән нәрсәләрне Хәлим тиз-тиз генә узды да комбинатның үз тормышына кереп китте. Залда кызыксыну тагын да артты. Ашханәдән тотынып фабкомга, фабкомнан тариф комиссиясенә, аннан «рядовой эшчеләрне кешегә санамаучы» кайбер мастерларга да җитешеп, барысының да өстенә Маяковскийдан, Демьян Бедныйдан алынган шигъри ядрәләрне җибәрде. Ара-тирә бик мавыгып китеп, шигырьләрне цитагалап кына түгел, ә кисәге-кисәге белән умырып алып сөйләргә керешә иде. Зал аңа чатыр-чотыр кул чаба иде.

Бер тапкыр ул Галимәнең күзләрен зур итеп ачып тыңлап утыруын шәйләп калды, икенче тапкыр докладның көлке урынында битләрен каплап көлгәнен күрде. Бу инде безнең егетебезгә бөтен залның кул чабуыннан да гипнозлырак тәэсир итте.

Дирекция турындагын Хәлим юри ахыргарак калдырган иде. Директор Кальсенсонның дөрес тәнкыйтьне күтәрә алмавын күптән әйтәсе килеп йөргәнгә, уңае чыгу белән тачылдатып әйтте. Аннары, гомумән, дирекция аппаратына күчеп, андагы бюрократизм, волокитаны «Горе от ума» афоризмнары белән тунады... Бүтән вакытта һич телгә килмәс ялкынлы, утлы сүзләрне залдагы сихерле күз карашыннан ала иде ул.

Кабынып-кабынып китә торган кул чабулардан, кычкырып көлеп җибәрүләрдән Хәлим үзе дә сизенде: доклад шәп чыкты!

Сыйчугов, өстәл яныннан торып, Хәлимнең кулын кысты да:
— Не доклад, а поэма! — диде.
Тәнәфес вакытында Хәлим тирәсенә таныш тукучы кызлар өелделәр. «Безнең мондый доклад ишеткәнебез юк иде әле» диештеләр. Хәлим кызарынды, елмайды, рәхмәтләр әйткән булды.
Билгеле инде, Галимә дә шунда иде, кап-кара күзләре белән Хәлимне ашап торды.

## 15

Күңеле белән күкләрдә гизеп йөрүче Хәлимгә кинәт кенә жиргә төшәргә туры килде. Бер көнне цехтан чыгып барганда кулын кесәсенә тыкса, кесәсендә — җепле кәтүкләр... Икенчесенә тыгылса — анда да! Башта Хәлим, кызлар шаярткannar икән дип, үз алдына елмаеп куйды. Ләкин шундук: «Кызлар ник шаяртсыннар?» дигән уй башына килде. Мондый нәрсә белән шаярырга ярамаганны алар белмиләрмени? Проходнойда тентеп, кәтүкләрне тапсалар, аны бит караклыкта гаепләячәкләр.
«Карак!» дигән уй Хәлимне эсселе-суыклы итте. Кәтүкләрне илтеп урыннарына салды да, кем эше булыр бу дип, бик аптырап, цехтан чыгып китте.
Артында ашыгып атлаган аяк тавышлары ишетеп, әйләнеп караса, бик борчылган кыяфәттә Галимә йөгереп килә иде. Дулкынланудан тыны беткән кыз егетнең артыннан җитте дә як-ягына каранып алып:
— Кесәләрегезне!.. — дип пышылдады. — Кесәләрегезгә нәрсәдер салдылар...
Кыз үзенең хәбәре белән соңарган булса да, Хәлим рәхмәт йөзеннән аның кулларын кысып тотты.
— Кем? Кемнәр салды? — дип ашыктырды ул Галимәне.
Кызның кара тутлы матур бите комач булып кызарды, башы иелде.
— Мин аны сезгә әйтә алмыйм, — диде. — Хәзергә әйтә алмыйм, — дип, аннары төзәтеп куйды.
Гомер булмаган, проходнойда Михеич аны туктатты, шаярган булып, егетнең кесәләренә шап-шоп сугып карады. Студентның кесәсеннән берни дә чыкмагач, гаҗәпләнгән сыман иңбашларын сикертеп, Хәлимгә сәер генә елмаеп карап торды да:
— Сал әле кепкаңны, — дип, егетнең кепкасына сузылды. Хәлим салып күрсәткәннән соң, Михеич янә иңбашын кыймылдатып куйды.
— Проходи! — диде аннары, мыек астыннан елмаеп...
Проходнойдагы тентү Хәлимне сагайтты. Бу инде очраклы нәрсә түгел, дип уйлады. Кем дә булса, студент кәтүкләр алып чыгып бара дип, әйтеп куйган булса кирәк. Югса Михеич аны бервакытта да тентеми иде. Ярый әле чыгар алдыннан кесәсенә кулын тыкты...
Хәлим, бик дулкынланып, парткомга барып керде, хәлне Клочковка сөйләп бирде. Теге, берни дә булмаган кебек, сабыр гына моның сүзләрен тыңлады да борчылмаска кушты, тикшерербез, белербез, диде.
Клочков белән сөйләшкәннән соң, Хәлим тынычланган кебек булса да, көн буе күңелендә таш утырды. Бу бит инде үч белән эшләнгән эш булырга тиеш. Кем? Ни өчен үч итә? дигән уй аңа һич тынычлык бирми иде.
Күңелне тырнап торган бу вакыйга онытылып өлгермәде, чалт аяз көнне Хәлимнең башы өстендә яңадан яшен яшьнәде.
Вакыйга бик гади генә башланып китте. «Кызыл Татарстан» газетасында ниндидер милләтчеләр турында мәкалә басылып чыккан иде. Татар студентлары укып бер-ике көн шаулашып йөрделәр. Хәлим мәкаләгә әллә ни игътибар бирмәде, чөнки, аның уенча, Хәлимнең милләтчеләргә һичбер катнашы юк иде.

Бер көнне Хәлимне комсомол ячейкасына чакырдылар. Институт ячейкасының секретаре Гыйммранов безнең егетне караңгы чырай белән каршылады.

— Син махсус стипендия аласыңмы?

Бу сорау егетне гаҗәпләндерде, Хәлимнең һәм янә дүрт татар студентының шундый стипендия алганын институт башлыклары беләләр иде.

— Алам, — диде Хәлим.

Гыймрановның чырае тагы да карала төште, авыз почмаклары салынды.

— Беләсеңме, син бит милләтчеләр оешмасыннан стипендия ашап яткансың! Милләтчеләрнең кемнәр икәнен беләсеңме? Контрреволюционерлар! Син, кызыл студент, контрлар акчасына укыгансың.

Хәлим аптырады да калды. Ячейкадан бик кәефсезләнеп чыгып китте. Бер генә юанычы бар, ул да булса Хәлим ялгызы гына алмаган — алар биш кеше.

Уйлану, пошынулар белән берничә көн үтте. Беркая да чакырмадылар. Шуннан чакырып йөдәтә башладылар. Гаепләнүчеләр бишесе биш авыздан: «Без бит үзебез сорап алмадык, безне кемдер исемлеккә керткән, безнең ни гаебебез бар?» дип акланырга тырышкач, бюро членнары: «Милләтче Дәүләтьяров сезне үз янына Кремльгә чакырткан, сезгә барысын да сөйләгән, сез авызыгызны ачып тыңлап торгансыз да риза булгансыз. Кайда сезнең сыйнфый сизгерлегегез?» дип, агарынган, куркынган егетләрне «милләтчеләр кармагына барып кабуда» гаепли башладылар. Дәүләтьяров, имеш, Татарстан татарлар өчен генә дип, руслар РСФСРга күчсеннәр, ә Татарстан җөмһүрияте Федерациядән чыгып, үзенә бер дәүләт булып яшәргә тиеш дип дәгъваләгән, булачак татар дәүләте өчен кадрлар әзерләп йөргән, мөселман студентларына махсус стипендияләр түләткән, акчаны моның өчен Казан нэпманнары арасында җыйган. Сизгерлеге югалмаган кешеләр бу ата милләтчене, аның шайкасындагы мөртәтләрне фаш иткәннәр. Оешмаларын туздырганнар.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Хәлим троцкизм турында дискуссия барган вакытта «Россия шикелле ярлы-фәкыйрь илдә социализм төзеп булырмы?» дигән темага бәхәскә катнашкан иде һәм анда: «Илнең үз эчендәге көчләр социализм корып бетерергә мөмкинлек бирсәләр дә, әле бит чит ил крокодиллары бар, алар безне ашамасклармы?» дип үзенең шиген әйткән иде. Бу сүзләрне хәзер яңадан искә төшерделәр һәм егеткә зур сәяси хата китереп тактылар: янәсе, аның ялгышлары очраклы ялгышлар гына түгел, ул, янәсе, Россия пролетариатының көченә ышанмый, ул, янәсе, троцкизм чире йоктырган һәм башка шуның ише гаепләрне Хәлимнең муенына аса башладылар.

Булмаган җир өчен крестьяннардан налог алалар дип шаулап, обкомга барып, газеталарга язып йөргәнен дә онытмадылар. Түләсәләр соң, диделәр. Николай патшага түләмиләр ич, үз хөкүмәтләренә түлиләр! Крестьянга совет власте Октябрьда ни хәтле җирне бушлай бирде. Акча янчыкларын кыймылдатсыннар хәзер бераз! Вaклана-вaклана шуңа тикле барып җиттеләр, егетне Фатих Әмирханны каберга озата барганы өчен дә, Дәүләтьяров язуы белән алынган кышкы пальтосы өчен дә гаепләргә керештеләр. Хәлим өстенә чүп чүмәләдәй өелде, һәм бу чүмәлә астыннан чыгу кыенайганнан кыеная барды...

Әлбәттә, егет кулыннан килгән дәрәҗәдә үзен якларга тырышты... Ләкин бер үк вакытта троцкизмда да, милләтчелектә дә һәм тагын бүтән бетмәс измнарда да гаепли башлагач, көрәшләрдә чыныгып өлгермәгән яшь кешегә җиңеп чыгу ансат булмады...

Ленинның бер илдә социализм кору хакында әйткәннәрен егет яхшы белә иде. Китапның тиешле битен ачып, Хәлим бюрода укып күрсәтте.

Анда: Россиянең үз эчендәге мөмкинлекләр социализмны корып бетерү өчен җитәрлек булса да, тышкы интервенция куркынычы әле һаман калачак, дип аерым-ачык әйтелгән иде. Хәлим Ленинннан шушы җирне укып күрсәткәннән соң, бюро членнары: «Урынсызга Ленинны китереп кыстырма!» дип, һаман әле гаепләп маташтылар.

Аннары Хәлимнең әдәби дискуссия вакытында әйткән фикерләреннән әллә нинди ялгышлар казып чыгардылар. Имеш, ул, мин Толстойның әнә шул графларын, князьләрен яратам! дип әйткән булган. Кызыл студент авызыннан шундый сүз чыксын әле.

Хәлимгә башын иеп, мин гаепле, мин ялгышкан дип кенә торырга кирәк иде кебек. Ә ул тотты да бөтен бюро алдында әйтте салды:

— Толстойны мин сезнең биш пролетарский язучыгызга алышмыйм!

Бюро членнары ах! иттеләр. Егетне шундук элеп алып селкеп салдылар. Хәлим «пролетарский язучылар» дигәннән әлеге футуристларны, театрда паровоз булып кыланучыларны күздә тоткан иде. Авызыннан «пролетарский» дигән сүз ычкынгач, тегеләргә шул җитә калды, «күгәрмәгән» җирен калдырмыйча тукмадылар. «Дворян ояларын» кылыч һәм штык белән туздырып йөргән кешеләр бюрода утырып торганда, һич тартынмыйча, оятсыз рәвештә чергән дворяннар язучысын, графны яклаган өчен егеткә бик каты эләкте.

Броневиктан Хәлим һич көтмәгән иде: гомуми җыелышта барлык гаепләүләрдән тырышып-тырышып аралаучы ул булды. Хәлимне гимназист дип, мулла малае түгелме син дип мыскыл итеп йөргән Броневик тикшерү вакытында чыкты да:

— Ә менә мин дә Островскийның бер купецын яратам, театрда күреп кайттым, нишләтерсез, яратам, бетте китте! — дип, йодрыгы белән трибуна тактасына сугып, җыелышны көлеп җибәрергә мәҗбүр итте.

Ак-Чернов, әлеге шул институт кызларын үтереп сала торган матур елмаюы белән трибунадан бераз карап торганнан соң, шулай ук Хәлимне яклап речь тотты. Профессор Гинзбург, калын иреннәрен кыймыл-кыймыл китереп, студент Галиуллин Лев Николаевичның мәшһүр романындагы графларны, бароннарны сыйнфый ноктадан алмыйча, бары тик кеше, әдәби образ булу ягыннан гына алып сөйли, ә бу яктан алар арасында бик тә симпатичный личностьлар бар, — дип, Хәлимне әллә яклап, әллә гаепләп сөйләде, җыелыш аңлап бетерә алмады.

Биш студентның бишесен дә, кызыл студент исеменә тап төшергән өчен, институттан кууны (чыгаруны түгел — кууны!) администрациядән сорарга дип карар чыгардылар. Каршы кул күтәрүчеләр әллә ни күп булмады. Шулай итеп, биш егетнең баш өстендә, борынгы Дамокл абыегыз кылычыдай, ычкынып төшәм дә башыгызны чабып өзәм дигән кебек, җыелыш карары эленеп тора башлады.

Кайберәүләр очрашканда инде Хәлим белән исәнләшмиләр. Броневик, егетнең боекканын күреп: «Башыңны югары тот!» дип дәртләндерә, Чернов та уен-көлкеләр белән егетнең күңелен күтәрә. Хәлим уйлый-уйлый да: «Чыгармаслар», дип үзен юата, аннары тагын уйлый да: «Ә чыгарып куйсалар?» дип паникага төшә иде.

Язмышы шулай кыл өстендә торып калды, ә ул, бөтенесенә кул селтәп, Галимә янына комбинатка барып кайтырга ниятләде. Ләкин дамбага су менмәде микән әле? Трамвайлар йөри ала микән? Быел язгы су бик куәтле. Шәһәрнең өч ягы диңгез кебек. Газеталарның язуына караганда, Казанның үзен дә су басу куркынычы бар. Болак, ярларыннан ташып чыгып, су урамнарга керә башлаган инде. Проломный урамын да басмагае дип, кибетләрдәге товарны күчерергә тотындылар. Хәлим беркөннәре Казанка ягына барган иде, суның күплегенә исләре китте: Подлужный урамында көймә белән йөриләр. Бер

мәче, судан качып, багана башына менгән дә диңгез уртасында калган, көймә белән йөрүче малайлар аны алмакчы булалар, мәче төшәргә курка... Су өйләрнең икенче каттагы тәрәзәләренә якынлашып килә иде инде.

Хәлим соңгы лекциягә кереп тә тормады, кеше белән шыгрым тулган трамвайга ничек кирәк алай утырды да комбинатка китте. Трамвайдан төшкәч, чатны борылып, озын тар урам буйлап кызу-кызу атлый башлады. «Хәзер Галимәне күрермен» дигән күңелле уй аны шулай очындырып атлата иде. Барып җитмәс борын ерактан ук Казанка елгасының болганчык сулары комбинат коймасына якынлашып барганны шәйләп алды. Көрәкләр күтәреп чыккан әллә ни хәтле кеше туфрактан вал ясап ята иде.

Көрәк сабына таянып ял итүче Клочковны күреп, Хәлим ерактан ук сәлам бирде. Килеп җиткәч, кем арды — ял итсен! дип, бер карт кешенең кулыннан көрәген алып, вал өешергә тотынды.

Подвалларга кергән суларны насослар белән кудырталар икән, комбинатны ничек тә туктатмаска тырышалар икән. Барлык цехлар да эшлиләр икән әле.

— Менә, эшче сыйныфны субботникка чыгардык, — дип Клочков вал өючеләргә күрсәтте. Калын, юан Клочков авыр сулый иде. Үзле кызыл балчыкны бераз ата да, көрәгенә таянып, ял итеп тора иде. Шулай торган чагында ул кинәт кенә иелде дә су кырыена таяк кадап куйды. Үттеме икән егерме минут вакыт, таяк су эчендә калды. Су, дошман кебек, комбинатны камый иде.

— Ишеттем, әйттеләр, — диде Клочков Хәлимгә, — докладны син бик әйбәт сөйләгәнсең. Хәзер сак бул инде, директорның күзенә чалынма. Миңа жалоба белән керде.

— Ә сез?

— Син нетактичныйрак әйткәнсең, ну, зыян юк.

Укасы коелган икән, дип уйлады Хәлим. Егетнең цехка Галимә янына кереп чыгасы бик килә, эшне ташлап кереп китәргә кешеләрдән генә уңайсызлана. Шулай да аның күзләре еш кына фабриканың проходное ягына авыша иде.

Портфель кыстырган Ползунов проходнойдан чыкты да, гадәтенчә йөгерә-йөгерә шәһәр ягына китте. Тәмәке кабызып азапланган җирән чәчле бер рус егете:

— Әнә безнең тары боткасы чыгып чапты, — дип, кешеләрне көлдереп алды.

Субботниктагы агайлар тәмәке тарткан арада, Хәлим көрәген балчыкка кадады да проходнойга таба йөгерде. Пропусклар тикшереп утыручы Михеич егетне бик салкын каршылады.

— Пропускыгыз! — дип, егетне туктатты.

— Соң бит, Михеич, син мине таныйсың ич!

— Мин таныйм да, приказ танымый. Сине кертмәскә приказ бар.

— Мине кертмәскә приказ!?

Мондый каршылыкка юлыккач, Хәлимнең керергә ашкынуы тагын да арта төште.

— Дядя Михеич, җан кисәгем! — дип ялынды ул.

Михеич — таш, Михеич — агач: приказны бозарга хакы юк, янәсе. Хәлим картны төртеп кереп китәргә җитеште.

— Михеич, бәгырем, — диде ул, нишләргә белмичә, — синең яшь чагың бар идеме?

— Булмыйча!

— Кызлар яраттыңмы?

— Ну, яраттым...

— Мин бер тукучы кызны яратам, күрәсем килә. Кереп чыгыйм, ә?

Михеич мыш-мыш итте. Утырган жирендә кыймыл-кыймыл килеп алды.

— Галяныдыр әле? Өстенә ук бастыммы?

— Бастың, дядя Михеич, ал аягыңны...

Михеичның кашлары салынды, чырае җитдиләнде.

— Галя тирәсендә кайнашкан бер егетнең кабыргасына пычак керде, беләсеңме?

— Минекенә кермәс! Үткәрәсеңме?

Уздырмады бит карт пәри. Хәлим, бик уңайсызланып, проходнойдан кире чыкты. «Кертмәскә приказ бар!» — дип гаҗәпләнде.

Клочков янына борылып килде. Күрәген алды да казый башлады. Байтак вакыт дәшми генә эшләде. Дөрссен генә әйткәндә, аның зарланасы, Клочковка барысын да сөйләп бирәсе килә иде. Ләкин сөйләргә өлгерми калды, аргы башта эшләүчеләр кинәт барысы берьюлы кычкыра, кул болгый башладылар. Клочков белән бер төркем эшче тизрәк шул якка йөгерде. Анда нидер булган иде, күрәсең. Хәлим дә, күрәген күтәреп, шунда китте. Килсә, су валны өзеп, коймага таба сикергән! Каз кауырыйлары йөзеп йөри торган болганчык сары дулкыннар өстенә дистәләрчә күрәктән балчык атыла башлады...

«Мине цехка кертмәскә?.. Көлке!» Хәлим иелде дә күрәгенә сыланган үзле балчыкны йомычка белән кырып төшерде. Турайды. Шул вакыт гүя ниндидер сихерле көч кинәт аның кул-аягын бәйләде... Барлык хәрәкәтләре ясалма чыга иде. Ул элекке табигый хәленә кайтырга, мускулларындагы киеренкелектән котылырга, иркенрәк эшләргә ни тырышса да булдыра алмады. Галимә биредә иде. Хәлим күз кырыйлары белән генә шул якка карап алды. Хатын-кыз барысы бер җирдә кайнаша. Галимәнең күрәге үзеннән зур. Иелә, турая... Яңаклары кызарган. Күрдеме икән әле? «Шундый зур күрәк белән шундый авыр балчыкны...— дип, егет Галимәне кызганды.— Билләре өзелеп чыгарга тора бит үзенең...»

Хәлимнең аркасына кемдер балчык белән бәрде. Кызлардыр дип уйлап, егет әйләнеп карамады. Тагын, тагын аркасына балчык килеп төште. Хәлим борылды. Әмма кызлар барысы да башларын иеп эшлиләр иде.

Бу уен егетнең көлешеп торган кызлар арасына барып керүе белән тәмам булды.

— Гәҗит абый безне күрми дә,— диешкән булдылар кызлар.

Хәлим дә җавапсыз калмады. Каян табыла шундый чакта кирәкле сүзләре... Үткене, көлкесе... Егетнең авызыннан сүзләрнең иң кызыклары сибелеп кенә торды.

Хәлимнең күрәге гел Галимә күрәге янында булды. Күрәкләр юри дә бәрелеште, ялгыш та бәрелеште... Килделе-киттеле сөйләшкән сүзләренең сәнәккә элеп селкерлек кенә дә мәгънәсе юк шикелле тоелса да, үзләре һәр сүздән әллә нинди мәгънәләр чыгарып бетерделәр.

Вакыт барды. Эш эшләнде. Галимә белән Хәлим вакытны сизмәделәр. Читтән кешеләр аларны күзәтеп елмаеша башлады. Тик аларның кешедә эшләре юк иде. Хәлим үзендә гаҗәп күтәренкелек сизә, көч, энергия сизә, күрәктәге авыр балчык мамык кебек кенә булып тоела... Тоташ бер ел шулай котырынып эшләсә дә, тамчы да армас шикелле...

Көн кичкә авышты. Валны сакларга берничә кеше генә кала, бүтәннәргә кайтырга рөхсәт. Хатын-кыз бергә өелешеп трамвайга китте. Галимә дә шулар арасында... «Китте» дип, Хәлим кызның артыннан карап калды. Бөтен кеше күзләрен терәп торганда, Галимә итәгенә тагылу килешмәс иде. Егет, Клочков агай янында бераз юангач, саубуллашып, кызу-кызу трамвай тукталышына таба атлады. Кызларны куып җитәрмен дип өметләнгән иде, ләкин тегеләр китеп өлгергән булып чыкты.

Трамвай никтер бик озак килмәде. Ахрысы, дамбага су менгәндер дә трамвайлар уза алмыйлардыр дип борчылып торганда гына чатта трамвай күренде. Хәлим утырды да китеп барды.

Кояш нуры кешегә ничек сеңсә, Галимә дә Хәлимгә шулай сеңде, һәм егетнең күңеле Галимә белән тулган иде. Игътибар беләнрәк караган кеше трамвайда Хәлимнең токтомалга елмаюларыннан, кашлары чөелү, күзләре ялтыраудан бу егетнең күңелендә нинди шатлык кайтканын, бәлки, сизенер иде. Яисә: «Бу бераз җиңелрәк ахры» дип уйлар иде. Трамвай тыгын булганга, һәр кешенең үз мәшәкате үзенә җиткәнгә, Хәлимнең сәер елмаюларына берәү дә игътибар итмәде.

Әллә күз ияләшеп өлгергәнгә, бу юлы Галимәнең матурлыгы Хәлимгә ул кадәре куркырлык ук булып тоелмады. Гаҗәп әйбәт итеп көлә белә икән. Хәлим аңа: «Я, тагын бер көлегез, сез бик матур көләсез» дигәч, Галимә: «Күп көлгән бер елар, дип әйтә минем әни», диде. «Шулаймыни? — дигән булды Хәлим. — Я, тагын ни дип әйтә сезнең әниегез?» «Минем әниме? — диде елмаеп Галимә. — Әйтә ул минем әни тыңласаң...» Аннары кинәт җитди тонга күчеп: «Сез кем булырга укыйсыз? Инженермы?» дип сорады.

Көтелмәгән бу сораудан соң, Хәлим, бик уңайсызланып, институтта чак-чак кына эләгеп торуын әйтергә мәҗбүр булды. Галимәнең, әлбәттә, беләсе килде: ни өчен шулай? Ни сәбәптән? Хәлимнең җавабы серлерәк килеп чыкты: янәсе, бер сөйләрмен әле...

Бистә белән шәһәр арасында трамвай кызулый төште. Каешка тотынып, чайкала-чайкала аягүрә кайтканда, егет Галимәнең хәзер өйдә нишләп йөрүен күз алдына китерергә тырышып карады. Күлмәкчән һәм оекчан гына өйдә йөридер. Битен-кулын югандыр. (Көзге алдында чүпләмле сөлге белән битен сөртеп торуы Хәлимнең күз алдына килде.) Матур кызлар да ашыйлар микән? (Хәлим тагын елмайды.) Гади кызлар кебек, ялан тәпиләре белән юеш идәнгә чалт-чолт басып, идән дә юалар микән? Аннары Хәлим, сәер генә елмаеп, учын, бармакларын әйләндергәләп карады: аерылышканда Галимә аның шушы кулын тотып торды бит... һәм кинәт күңеленә: «Мин аның турында уйлап кайтам, ә ул минем хакта уйлый микән?» дигән фикер килде.

Трамвай туктады да кузгалып китте. Кояш баеп килә иде инде. Бистә ягына таба узган паровозның морҗасыннан болганып-болганып кызыл төтен чыга иде. Хәлим үзенең институттагы кайгысын бөтенләй онытты. Капка төбенә кайтып җиткәч кенә, кайгысы исенә төшеп, күңеле кысылып куйды. Студентмы әле ул, әллә инде юкмы? Укырга килгәннең беренче көнендә Хәлим, институт бинасының почмагын кочаклап үбеп, кешеләрне көлдергән иде. Менә ул яңадан йөгереп килде дә салкын таш почмакны кочып алды.

## 16

Аларның мәсьәләсен озакка суздылар. Хәлим инде билгесезлеккә ияләшеп килә. Элекке шикелле үк лекцияләргә чаба, китапханә залларында утыра. Иптәшләре дә аның хәленә ияләште. Элекке кебек исәнләшә, сөйләшә башладылар.

Бүген тагы райкомолга чакырып, ике сәгать тотып кайтардылар. Очы-кырые һаман күренми! Кайчан башка китереп кундыралар дигән кебек, һаман муенны җыерып сагаеп яшәргә туры килә...

Галимәне күрмичә ике генә көн чыдады да өченче көн дигәндә тагын комбинатка чыгып чапты. Бу юлы эштән соң кызны өенә озата барды. Галимә талчыккан, битләре агарган иде. Саф һавага чыккач, кызга бик тиз җан керде. Юл буе сөйләшеп, шаярып кайтты.

Эшчеләр клубына җитәрәк егетне туктатты да:

— Шушында аерылыйк, минем белән килгәнегезне күрмәсеннәр,— дип, Хәлимнең артык озатмавын үтенде. Егет кызның сүзләренә ел-майды гына. «Бу кыз белән күренү чынлап та хәтәр микәнни, әллә юри шулай әйтә генәме?» дип уйлады, үзе һаман баруында булды.

Клуб каршына килеп җиттеләр. Багана башыннан төшкән тонык яктыда ике кеше афиша укып тора иде. Хәлим дә иелеп укырга тотынды. «Леонид Гаснецкий производит опыты галлюцинаций, анестезии, каталепсии. Превращает человека в обезьяну по Дарвину».

Егет кычкырып көлеп җибәрде.

— Карагыз әле, Галимә, бу клубта кешедән маймыл ясыйлар икән. Күрәбезме?

— Мин кайтам. Әни ачуланыр.

— Үзеңне маймыл итсәләрме?

Галимә, көлеп җибәреп, Хәлимгә кизәнеп куйды. Аның балаларча уйнап кизәнүе бик матур чыкты. Хәлимгә охшады. «Ник ул күн итек-тән йөри, туфли аякларына бик килешер иде», дип уйлап куйды. Тагын бераз озата барды. Каршыларына очраган кешеләрнең битләренә ка-раган булып:

— Гаснецкий ясаган маймыл килә түгелме? — дип, Галимәне тук-тап-туктап көләргә мәҗбүр итте.

Кинәт Хәлимнең иңбашына арттан шап иттереп уч белән суктылар. Әйләнеп караса, эшчеләрчә киенгән, күлмәк изүен ычкындырган бер татар егете күкрәген киереп, авызын ерып басып тора иде.

— Исәнме, студент?

Хәлим иңбашыннан тегенең кулын алып ташлады.

— Исән. Шуннан?

— Утырган да шуган! Безнең кызларга сыланмасаң, шәһәр кызла-ры беткәнмени сиңа? — Янбашы белән Хәлимнең иягенә кадарга жы-енгандай алдына кырын килеп басты. Бер секунд күзне күзгә терәшеп торганнан соң, Хәлим, аякларын уңайлабрак басу өчен, кыймылдап куйды. Аның нияте Броневиктан откан сугышу алымы белән бу бәйлән-чекне бөтереп ыргыту иде, ләкин шул минутта араларына кыр мәчесе тизлеге белән Галимә килеп керде. Аскы иренен малайларча тешләп, иңбашын тегеңә таба очлайтып:

— Минем кавалерыма тырнагың белән генә кагыласы булсаң да, инженер Исмәгыйл Абрамичка әйтеп, иртәгә үк фабрикадан очырттырам үзеңне! — Шулай дип тезеп салды да эт белән очрашудан ярсыган мәче кыяфәтендә тегенең каршында басып калды.

Теге егет бер адым чигенде, начар итеп елмаеп куйды.

— Аның кавалеры! Инженер Абрашка белән себерелүеңне кавале-рың беләме соң? — Тагын баягыча пычрак итеп елмайды да борылып китеп барды.

Хәлим белән Галимә дә кузгалдылар. Кыз әллә ни гомер бер сүз дәшми барды. Хәлим дә ни дияргә белми бара иде. Кинәт Галимәнең иреннәре тетрәде. Кыз үксеп елап җибәрде. Ул да түгел, йөгерә-йөгерә китеп үк барды. Хәлим, куып җитеп, Галимәнең иңбашларыннан тотты.

— Елама! Әллә мин аның сүзенә ышанам дип беләсеңме?

Хәлим шунда беренче тапкыр Галимәнең яшь тамчылары белән чы-ланган битләреннән үпте. Кулъяулыгын чыгарып, кызның күзләрен сөртте. Борынын да сөртә башлагач, Галимә, егетнең шаяруын аңлап, яшь аралаш елмаеп җибәрде. Хәлим аның кибеп җитмәгән күзләренә карап:

— Сине гел елатып торырлык бар, бик матур елыйсың, — диде, көлеп кызны кочагына кысты.

Аерылышканда Галимә аңа клуб яныннан кайтмаска киңәш бирде. Хәлим «Ярар, кайтмам» дисә дә, үзе клуб урамыннан китте. Качып йөрергә ул хурлана иде. Бу юлы клуб каршында берәү дә очрамады:

күрәсең, барлык кеше Гаснецкийның адәмнән маймыл ясавын карарга кереп киткән булгандыр.

Инженер Абрашка... Хәлимнең күңеленә шушы сүз килеп кадалды. Ә тегенең әйткәне чын булса? Себерелүеңне, диде бит. Нинди жирәнеч сүз. Хәлимнең шулай булыр дип һич ышанасы килми. Кем икән соң ул Исмәгыйл Абрамич? Фабрикадан очыртып чыгара алырлык булгач, кечкенә кеше түгелдер инде. Шундый матур кыз да ялганлый алыр микәнни? Шундый саф күзләр дә алдый алалар микән?

Артыннан куып җиткән трамвайга сикереп менде дә эчкә кереп китте.

## 17

Газета битләрен ачса, гел су ташу хакында...

«...Кабан күле ярларыннан чыкты. «Спартак» фабрикасына су керә...»

«Тукай урамына йөри торган трамвай Болак күпереннән үтә алмый башлады — күпер су астында...»

«Нижний Новгородтан килгән «Страж революции» пароходы Кызыл күпер астыннан уза алмыйча кире кайтып китте».

Газетаны тоткан саен Хәлимнең күзләре комбинат турында хәбәр эзли. Бер көнне «Текстилькомбинат»ның подвалларына су тулды» дигән сүзләрне табып укыды. «Сукно цехы, туку цехлары әлегә эшли», дип язганнар иде.

Хәлим өчен комбинат белән Галимә икесе бер төшенчәгә әйләнгән иде инде. Газета битләреннән ул комбинат турында эзли, ә үзе Галимә хакында уйлый иде. Шушы минутта (Хәлим сәгатенә карап алды) туку цехының экскурсантлар күрми торган аргы почмагында Галимә киндер тукып утыра бит. Шул нәзек-өзек билле чибәр кызны күрергә ашкыну Хәлимнең йөрәген җилкендерә иде. Дөресен генә әйткәндә, кайтканның икенче көнендә үк инде аның йөрәге Галимәне тагын күрәсе килеп ашкына башлады, тик ул үзен авызлыклап тыеп торды.

Михеич цехка кертмәсә, Галимәне ул ничек күрер? Фабрика капкасы төбендә сагалап тормас бит инде. Хәлим исәпли башлады. Үткән атнада Галимә көндезге сменада эшләде бугай. Димәк, хәзер кичке сменада эшли булыр...

Шулай чамалап юлга чыкты. Хәлим Кремль астына төшеп барганда, кичке шәфәкъ ялкыны күк итәгенә сикергән иде инде. Кремль астындагы суда кызыл шәүләләр йөзәләр иде.

Үч иткән шикелле, трамвай йөрми булып чыкты — дамбага су менгән һәм юлны өзгән. Җәяүләп, бәлки, үтеп буладыр әле. Хәлим ашыкты. Чатны борылып, дамба урамына килеп чыккач, алга таба текәлептекәлеп карый башлады.

Дамба авызында винтовкалы кызылармеец басып тора иде. Хәлим үтеп китәргә рөхсәт сорагач, сакчы, Хәлим кебек яшь кенә бер егет, башын уң якка изәп:

— Күрмисеңмени, дамба аркылы шарлап су ага, — диде, штыгын сузып, егетнең юлын бүлде.

Монда хәтле килеп җиткәннән соң, Хәлимнең кире кайтып китәсе килми иде. Юлын су түгел ут киссә дә, ул бүген Галимә янына барырга, кызны күрергә тиеш. Шунсыз йөрәк ашкынуы басылмаячак.

Хәлим бер дамбага, бер кызылармеецка карап тора. Аның күзләре кичке эңгер-меңгер эчендә дамбадагы трамвай платформасын шәйләп алды. Платформа өстендә кешеләр йөри иде.

— Юлны ремонтлыйлар ич? — диде ул кызылармеецка. — Ә мин аларга булышсам? — Һәм сакчыны тәмам ышандырыр өчен, җиңнәрен үк сызганырга тотынды. — Булышыйм, ә?

Кызылармеец Хәлимне күзләре белән бер сүздә дә юлга аркылы сузган штыгын алды. Алай бик эш тансыклагансың икән, әйдә үт! Хәлим дамбага йөгерде.

Трамвай юлы өстенә ургылып ташып чыккан суга кешеләр вагон платформасыннан комлы капчыклар, чыбык-чабык, таш, шлак ыргыталар, котырынган суның юлын бүләргә азапланалар иде.

Йөгереп килгән уңайга Хәлим платформага сикереп менде дә аяк астындагы капчыкның бер почмагыннан китереп тотты, икенче башыннан кемдер бүтән берәү эләктерде. Чайкап торып, капчыкны агымның сыртына ук төшерделәр. Чәчрәп киткән су сәләмәләрен җил күтәреп алып читкә ыргытты. Икенче, өченче капчык та чап-чап барып төште. Су бөтерелеп, айкалып башка җирдән юл эзли башлады. Җәтмәгә эләккән ерткыч җанвар кебек, сикеренергә, ыргылырга тотынды. Аның өстенә чыбык-чабык, эре ташлар ыргыттылар.

Бер җирдә туктатсалар, су икенче җиргә ташлана иде. Трамвай платформасы да тизрәк шунда таба күчә. Котырынган суга яңадан таш, чыбык-чабык, ком чапылт-чопылт сикерә башлый иде.

Хәлим тырнакларын каерта-каерта җен ташыдай авыр капчыкларны атты-атты да, комлы капчыклар беткәч, кулына көрәк алып, шлак ыргытырга тотынды. Кешеләр ардылар, мышкылдап беттеләр. Ә суны туктата алмадылар.

Платформада ыргытыр нәрсә калмады. Тыннарын кысып, кешеләр беркавым су тавышын тыңлап тордылар. Елга шаулый, дулкыннар үкерешеп дамбага ташланалар. Трамвай юлын су һаман баса. Шәһәр белән бистә арасындагы бердән-бер юлны ничек кенә булмасын саклап алып калырга кирәк иде.

Шлак, ком алып килү өчен, платформа яңадан шәһәргә китәргә булды. Ә Хәлим нишли? Кинәт платформадан су эченә сикерде дә, билдән су ярып, бистә ягына таба китеп барды. Аның артыннан «Котырдыңмы әллә?» дип, «Борыл исән чагында!» дип кычкырып калдылар. Ул караңгылык эченә кереп күздән югалды.

Комбинатка килеп җитеп, проходнойны ничек кирәк алай үтте. Цехка керде. Өсте-башы чат су гына... Үзе, гүя берни булмаган, гүя кешеләрне гаҗәпләндереп төн уртасында цехка барып кермәгән, елмаеп, күзләрен тасрайтып, Галимәгә карап тора. Егетне күргәч, Галимә аптырап:

— Гәҗит абый... — дип кенә әйтә алды. Куллары чәбәләнеп җепләре өзелә башлады. Ялгар өчен булса кирәк, ул тизрәк стан артына кереп югалды.

Сменадан чыккач, икәү караңгы урамнарда йөрделәр. Аулак почмакларга сыенып, бер-беренә уралышып басып тордылар. Таң атты, яктырды, ә аларның әле сөйләшеп тә, кочышып та туйганнары юк. Урамда инде берәм-сәрәм кешеләр күренә башлады, бер хатын коега су алырга чыкты, коеның тәгәрмәче шыгыр-шыгыр итә...

Галимә: «Кайтам», дия башлады, Хәлим: «Тагын биш кенә минут!» дип һаман җибәрмәде. Биш минут дигәне ярты сәгатькә сузылды...

— Җибәр, яп-якты ич...

— Сагынганым бетсен инде.

«Озата барма, әни күрер» дигәнгә карамыйча, егет, «анавында хәтле генә», «менә монда хәтле генә», дип, башта бер урам, аннары тагын бер урам озата барды. Кызның терсәген тотып, шулай бара-бара бер тыкрык авызына җиттеләр дә «биш минутны» янә ярты сәгатькә суздылар. Галимәләрнең капка төбенә килеп җиткәч тә әле, Хәлим кызны, җибәрәсе килмичә, кулыннан тотып торды. Ахырда Галимә, егеттән ычкынып, үзләренең капкаларына таба йөгерде.

Өй кыегында бер сыерчык каурыйларын төзәтеп азаплана иде. Хәлим сыерчыкның кыланышларына карап тора башлады. Күрәсең, ул

эле яңа гына уянып чыккандыр. Муенын артка каерып, аркасындагы йоннарын шомарта. Канатын җәеп җибәреп, борынын каурый араларына тыгып-тыгып ала. «Каршында күзгә генә юк» дип, Хәлим рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Ул да булмады, сыерчык, канатларын җилпеп, сайрарга тотынды. Ач карынга сайрау бик барып чыкмады. Менә ул егетләрчә бер сызгырды да кызарып чыгып килгән кояшка таба очып китеп барды.

Хәлимнең иреннәрендә елмаю сүнмәгән әле. Ул урам буйлап әкрен генә атлый. Галимәнең әнкәсе бөтен өметен кызының матурлыгына баглый икән. Бу чибәрлегең белән инженердан түбәнгә чыкма, ди икән. Атаң үлгәннән бирле (әтиләре 1915 елда герман сугышында үлгән) нужа белән талашам, ичмасам син адәм рәтле тормыш белән яшәрсең. Сезнең янгызда мин дә икмәккә ач булмам дип, инженерга чыгу хакында тукый икән. «Кара аны, ни җитте кешегә чыксаң, асылынып үләм» дип куркыта, имеш. Галимә бүген: «Син кем булырга укыйсың?» дип тагын сорады. Кыз ант итә, мин Абрашканы яратмыйм, күрәсем дә килми, бүләкләрен гел кире кайтарам, ди. Тик әнкәсе, чык шуңа, дип каныга икән. Утыз биштә булмагае, әтиең дә миннән олы иде, ә менә нинди матур балабыз туды, дип кызын юмаларга тырыша икән. Галимә елый-елый сөйләде, үлсәм дә мин аңарга чыкмыйм, аңа чыкканчы мин Казанкага ташланам, диде. Хәлим аңа ышана.

Институт торагына ул бары иртән сигездә генә кайтып керде. Төнлә трамвай юлын төзәткәннәр иде.

Лекциягә баргач, ул өч иптәшен институттан чыгарган булуларын стенадагы приказдан укып белде. Хәлимне һәм тагын бер студентны шартлы рәвештә калдырганнар иде.

Бер килсә килә бит. Әллә рухани газаплар аркасында (әле бит комсомолда калу-калмау һаман эленеп тора), әллә теге төнне салкын су ярып йөргәннән булды, Хәлим авырып китте. Температурасы төшкәч, тереләм икән дип куанган иде, кинәт кенә аягы сызлый башлады. Үтәр әле дип, Хәлим лекцияләргә аксаклап булса да йөри бирде. Ахырда бер көнне егетебез таякка калды.

Институтка бара алмый, өйдә генә ята. Бер көн, ике көн шулай аунап ятканнан соң, бер тапкыр лекциядән Айдаров кайтып керде дә караватта аягын тоткалап яткан Хәлимгә:

— Тор, давай! Больницага барабыз! — дип команда бирде.

Хәлимнең үзенең дә больница турында уйлаганы бар иде барын, ләкин бит ул хәзер инде бөтенләй аягына баса алмый, ничек барыр?

— Күп телеңә салынма, давай, тор! — диде Броневик. — Җилкәмә атландырып алып барам.

Броневикны көлә дип уйлаган иде Хәлим, ләкин ни күрсен, теге килеп караватка кырыена чүгәләде. Хәлимне ансат кына күтәреп, бүлмәдән алып чыгып китте.

Урамдагы кешеләр сәерсенеп көлеп кала башладылар. Хәлим, уңайсызланып, каршы очраучыларга елмая-елмая бара иде.

Поликлиниканың халык белән тулы кысан коридорына барып кергәч, Айдаров егеткә: «Ыңгырашкан бул...» дип пышылдады. Хәлим, чыраен сытып, ыңгырашырга тотынды, янәсе сызлана. Броневик, врач кабинеты каршында өелеп торучы авыруларның берсенә бер сүз катмыйча, «Хирург» дип язылган ишеккә Хәлимне алып кереп китте.

Врачлар, «воспаление вен» дигән диагноз куеп, ике атналап урында ятарга кушып, Хәлим белән Айдаровны чыгарып җибәрделәр. Егет яңадан Броневикның җилкәсенә менеп кунаклады.

Кайткач Ак-Чернов белән икәү авыруны караватка сузып салып, аягын караватка башына бау белән астылар, кулына китапларын тоттырдылар: укы, ят! Ике атна кыймылдыйсы булма.

Ике атна! Ә бит Галимә берни белми. Шул инженер аркасында килүдән туктады дип уйлавы бар. Ничек хәбәр итәргә? Өй адресы юк. Цехка язса? Юк, цехка язарга ярамый, уңайсыз, әллә кем кулына килеп керүе мөмкин. Хәлим аптырап баш ватып ятканда, Броневик гадәтенчә шау-гөр килеп кайтып керде дә Хәлимнең сөйләшми ятуын үзенчә юрап:

— Кара әле, профессор, — диде. — Нәрсә син авызыңны туңкайттың? Эчең пошамы? Я күрсәт әле аягыңны, шеше кайта башламаганмы? — Шулай дип егетнең ыштан балагын сыдырды, шомарып, ялтырап торган аягына бармагы белән төрткәләде.

Егетнең йөзе чынлап та бик ачыктан түгел иде. Броневикның башына бик кызык фикер килде: «Иң әйбәт дару шул булыр», дип уйлады. Күзгә каршында төзәтенде дә: «Мин хәзер кайтырмын», дип, тиз генә бүлмәдән чыгып китте.

Броневик Кафияләрнең кайда торганын белә иде. Хәлим өйдә юкта бер килгәч, кызны озатып куйган иде. Ялт кына барып, Кафиягә язу калдырды: шулай-шулай, килеп китегез, егетнең хәле әйбәт түгел.

Кафия кич кенә килеп керде. Хәлим аптырап калды. Кыз киткәннән соң Айдаровка үпкә белдерде. Ни дип чакырдың? Кем синнән сорады?

Броневик, гаепле кешеләрчә елмайгалап:

— Белдеммени мин сезнең арагыздан кара мәче узганны! — дип акланырга тырышты. — Яхшы ният белән эшләгән эш...

— Яхшы ният белән тәмугның юлына асфальт җәелгән ди...

Кафия янә һәм янә килде. Кай көннәрне ул кичнең кич буе утырып китә иде. Әкренләп Хәлим дә аның килеп йөрүләренә ияләште. Экзаменнар беткәч, Кафия көн саен диярлек килеп йөри башлады. Хәлимгә ошый торган күлмәген кия, прическасын да Хәлим яратканча итеп тарый иде.

— Карале, чәчем нихәтле булды инде!

— Элекке шикелле биленә төшеп торсын, яме!

Бүлмәдә үзләреннән башка берәү дә юк чакта, алар уйнашалар, котырышып китәләр, янсә «кем озаграк күзен йоммас» уенын уйный башлыйлар иде.

Шулай уйнап-шаярып утырганда, бер тапкыр Кафия ялкынланып янган ал битләрен учлары белән каплады да:

— Карама миңа шул күзләрең белән! — диде. — Каян алдың шундый сихерле күзләрне?

— Барысы да алладан! Кояш та, ай да, күзләр дә...

Кафия кулларын битеннән алды.

— Карама! Йом күзләреңне...

Хәлим шаярып күзләрен йомды, Кафия, егетне муеныннан кочып, кайнар иреннәре белән Хәлимнең авызыннан котырынып үбә башлады. Аннары кинәт турайды, битләрен учына яшергән килеш тәрәзәгә таба әйләнеп утырды. Кызның иңбашлары елагандагы кебек тирбәлә иде.

Кафия кулларын һаман битләреннән алмыйча пышылдап куйды:

— Оялам...

Утырган урыныннан торып, тәрәзә катына ук барып басты.

— Мин китим... Син инде терелэсең, мин артык килмәм.

Ә үзе тагын килде. Кафия озак утырганда Хәлим бүлмәдәш иптәшләреннән уңайсызлана иде. Аларга йокларга ятарга кирәк, ә бу утыра да утыра. Кайчандыр Кафиянең кинәт кып-кызыл булып кызаруын, битләре ялкынланып януын Хәлим бик ярата иде, хәзер бите белән бергә муены, колаклары да кызаруын күрә дә әллә нинди ямьсез тойгы кичерә...

Аягына басканнан соң, Хәлим Кафиядән качып калгалый башлады. Андый чакта кызны Ак-Чернов озатып куйгалый иде. Ничектер Хәлим мунчага җыенып йөргәндә, тагын Кафия килде. Хәлим аны бу юлы да Чернов кулына калдырып чыгып китте.

Бер көнне бер дә көтмәгәндә Хәлим янына Якуп абзыйсы килеп керде. Ул, Мәскәүдә укуын тәмамлап, Урта Азиягә эшкә барышлый Казанга сугылып чыгасы иткән, Хәлимне эзләп тапкан. Килеп кергәндә Якуп Хәлимгә бик үзгәргән булып тоелса да, күзе ияләшкәч, элекке Якуп абзасы булды да калды. Тик киеме белән генә ул элекке Якуптан бик каты аерыла иде. Кара пинжәк кигән, галстук бәйләгән. Аннары муен астында, битендә җыерчыклар...

— Әллә ни гомер татар театрын күргәнем юк, бик күрәсем килә,— дип, Хәлимне театрга алып китте.

Шул кичне Кафия килгән һәм, Черновның озатыйм дигән тәкъдимен кире кагып, кәефе кырылып чыгып киткән. Театрдан кайткач, Чернов егеткә сөйләде. Кызыңа әллә нәрсә булган, диде. Икенче көнне кич Хәлим Якуп абзасын пароходка озатып йөрде. Якуп авылга да кагылып узасы иткән иде. Озатып кайтып килгәндә, тулай торак капкасына җиткәч, Хәлим капка төбендәге агачка сөялгән Кафияне күрде.

— Нишләп син монда торасың? — диде ул гаҗәпләнеп.

— Сине сагалап тормыйм, уйлама... — диде Кафия шаян тавыш белән. — Синең белән бер бүлмәдә торучы теге ак егет чыгачак, аны көтәм... Кичә театрда кем белән булдың?

Хәлим әйткәч, Кафия ышанмады. Янәсе, ялганлама. Хәлим ирексездән көлеп җибәрде.

— Көнләшү — маймыллык!

— Минме көнләшәм? Фу! — Кафия иңбашларын калтыратып, иреннәрен бүлтәйтеп алды. — Ник чыкмый соң әле минем кавалер?

Хәлим, капкадан сузылып, ишек алдына карады:

— Чыгучы күренми, — диде.

Кафия кинәт егетне култыклап алды да тротуар буйлап алып китте.

— Чыкса, мине шуңа ияртеп җибәрер идең бугай...

Фонарьлар кабынган булса да, урам ярым караңгы иде. Бакчадагы аллея бөтенләй дә караңгы булып чыкты. Алар шушы караңгы аллеядан бик озак йөрделәр. Кафия ничектер кинәт тынып сүзсез калды. Аннары көтмәгәндә башы белән Хәлимнең күкрәгенә төртелде дә мышкылдап еларга тотынды.

— Нишләвең бу? Юләр, ник елыйсың? — диде Хәлим кызның калтыранган аркасыннан кочып. — Я инде, я...

Кафия туктаусыз аккан күз яшьләре белән Хәлимнең битләрен чылатып бетерде.

— Мин сине бик яратам, көнләшәм, үләм!.. — дип, ярсып-ярсып Хәлимгә сарылды. — Син бит минем яшьлек, балалык мәхәббәтем... Кил әле утырыйк.

Утыргач күзләрен сөртте дә Хәлимнең кулларына сузылды.

— Бир әле кулларыңны, тотып утырасым килә. И, кулларың нинди суык. Юк инде,— диде ул кинәт нindidер ят тавыш белән: — Юк инде, — дип кабатлады. — Син мине яратмыйсың. Мин инде моны үткән җәйдә үк сиздем.

Тагын тынды. Бик озак вакыт дәшми утырды. Аннары эскәмиядән күтәрелде дә:

— Озатып куясыңмы мине? — диде.

Бакчадан чыктылар. Бик соң булганга, урамнар бушап калган иде.

Ишек төбендә Кафия егеткә тагын ялкынланып сарылды:

— Ашап бетерәсем килә минем сине! Я, я... Күрәм, туйдың... Күзләрең әнә нинди салкын... Бер үбим инде шул күзләреңнән?.. Бетте. Бар, кайт...

Аерылышкан чакта Хәлимнең кулын салкын гына кысты. Ул әле Хәлим янына тагын берничә кат килде. Аннары килмәс булды. Күпмедер вакыт үткәч, Хәлим аның урамда Ак-Чернов белән узып барганын күреп калды.

## 18

Шәһәрне бер ай буе диярлек камап торган ташу суы, әллә нихәтле хәрабәләр калдырып, май азакларына таба әкренләп кенә чигенде. Трамвайлар йөри башлады. Ерак дамбада ат юлы ачылды. Шәһәрне төзәтү, ямау, күперләрне ремонтлау башланып китте. Ике атнадан артык тынып торган завод гудоклары яңадан кешеләрне хезмәткә чакырды. Эшләрен сагынырга өлгергән завод-фабрика халкы проходнойларга барып тыгылды.

Сигезенче июньдә иртә белән Хәлим, институтка барырга дип, трамвайга чыгып утырды. Вагондагы кешеләр никтер бик дулкынланып сөйләшәләр иде. Хәлим тавышларга колак салды:

— Вокзалда үтергәннәр,— дип сөйли иде кулына газета тоткан күзлекле бер агай, — кемнедер озатыргамы, каршыларгамы барган булган, шунда атканнар.

— Чемберленнар эше, — дип тотынды кайсыдыр бик белдеклесе.

— Польшасын әйтер идем инде, үзендәге дипломатларны да саклый алмый.

— Теләми диген. Бер компания!

— Чемберлен эше, — дип кабатлады күзлекле агай. — Шахтерлар өчен үч кайтаралар.

Хәлим Англия шахтерларының узган елгы забастовкасын хәтерли иде. Җиде-сигез айга сузылган, Англия промышленностен аяктан ега язган бу забастовкага безнең эшче сыйныф акчалата ярдәм итеп торды. Англия хөкүмәтенең рәсми протесты да булган иде. Араны өзү белән дә куркытып караганнар иде. Ләкин кичәге үтерүнең моңа нинди катнашы бар икән?

Хәлим үзе белән янәшә утыручы ак чырайлы бик ябык кешедән:

— Кемне үтергәннәр? — дип сорады.

— Польшадагы безнең илчебезне, Войковны.

Хәлимнең исенә төште. Кышлый газетада басылган иде: Англия белән ара начарая башлагач,ниндидер җыелышта оборона халык комиссары Ворошиловтан: «Сугыш булмасмы?» дип сораган булганнар. Ул: «бик ихтимал» дип җавап биргән иде. Әллә чынлап та башлануымы? Китапларны җиргә бәреп, шинель кияр көннәр җиттеме? Көнбатышта революция кабызыр көннәр?

Хәлим трамвайдан төште. Урамда баручылар барысы да газета тоткан, кайберсе туктап укып тора... Сугыш дигән сүзләр ишетелә иде.

Хәлим институт чатына борылды. Институт бинасы каршында студентлар, студенткалар җыелышканнар. Кычкырып-кычкырып сөйләшәләр. Газеталарны, бер-береннән тартып алып, өелешеп укыйлар. Барысының да авызында: сугыш! Ворошиловның: «Бик ихтимал» дигән сүзләрен искә төшерәләр. Шунда ук кемдер Сталинның: «Сугыш булмый, дошман әле әзер түгел» дип, Ворошиловтан соң бер докладта әйтеп китүен дә телгә алалар. Бар кешенең телендә: Англия, сугыш, Каверда...

Войковны Каверда дигән ак гвардияче үтергән икән. Хәлим дә бер кызның кулындагы газетаны йолкып алып укый башлады. Англия белән ара бозылганнан бирле инглиз матбугаты СССРны травить итә диелгән, ак гвардияче этләрне безнең өскә өстерә, бандитларның кулларына корал тоттыра, дип язылган. Монокль кигән, зәһәрлегеннән ирennәре чалшайган Чемберлен карикатурасына бер эшче агай бармагы белән күрсәтеп тора: ул гаепле!

Аннары Хәлим Войковның соңгы минутлары хакында укырга тотынды. «Ничә кеше атты?» дип сорауга тел белән җавап бирә алмаган. Бер дип, бармагын гына күрсәткән.

Хәлим укып бетерергә өлгермәде, кайсыдыр берсе килеп кулыннан газетаны алып китте.

Лекция вакытында студентлар игътибарсыз утырдылар. Хәлим профессор Гинзбургның калын иреннәре кыймылдаганны күрә, тавышын ишетә, ә сүзләрен аңламый иде. Сугыш... Ә бәлки, бөтен дөнья революциясенең башлануыдыр?..

Икенче лекциядән соң партячейка секретаре Романов кереп барлык студентларны Ирек мәйданына митингыга чакырды. Студентлар өерләре белән аудиториядән чыга башладылар.

Хәлимнәр колоннасы «Войны мы не хотим, но в бой готовы!» дип җырлый-җырлый барды. Тротуарларга өелгән кешеләр, нидер сөйләшә-сөйләшә, карап калалар иде. Ачык тәрәзәдән кызлар студентларга кул изиләр һәм нидер кычкыралар иде.

Хәлим ярсып җырлап бара. Кырыйларына кара креп тоткан кайгылы кызыл байраклар мәйданга таба агылалар. Халык ташкыны трамвайларны туктатты. Вагондагы кешеләр төшеп демонстрациягә кушыла башлады. Чырайлар кырыс, кашлар җыерылган... Пионерларның кулларында Войков портреты — чит-читләре кара ефәк белән бизәлгән зур портретны бик житди чырайлы бер кыз тотып бара...

Колонналарның баш өсләрендә язулы транспарантлар. «Англия империалистлары, бик узынмагыз!» дигән язуны «Спартак» эшчеләре күтәреп баралар. Вахитов заводы киң кызыл комачка: «Ут белән шаярмагыз, әфәнделәр!» дип язган. Хәлим күзләре белән Текстилькомбинат колоннасын эзләде. Бәлки, Галимә шушында якын тирәдә генә барадыр?

Бер төркем яшьләр чүпрәктән ясалган Чемберлен карачкысын таяклар белән кыйный-кыйный киләләр иде. Барлык кеше көлешеп карап калды. Ул да түгел, пан Пилсудскийның озын мыеклы портретын башкадала тотып баручы яшьләр очрады. Янәсе, сугыш чукмары Пилсудскийның башы астына килсен!

Һавада аэроплан гөрләгәне ишетелде. Хәлим күтәрелеп карады: югарыда кечкенә генә У-2 мәтәлчекләр ата-ата оча иде. Ул да булмады, демонстрация өстенә кәгазь яңгыры ява башлады. Малайлар йөгерә-йөгерә листовкаларны җыйдылар. Олылар да аяк асларына төшкәнне алып укый башладылар. Листовка Англия сугыш чукмарларына каршы язылган иде. Дошманнарга җавап итеп һава флотын көчәйтергә, «Чемберленга җавап» фондына акча җыярга чакыра иде.

Мәйдан тамагында торучы атлы милиционер Хәлимнәр колоннасын Державин бакчасына таба борып җибәрде. Мәйдан диңгез кебек чайкала. Митинг әле башланмаган. Студентлар, колонналардан чыгып, өер-өер сөйләшеп тора башладылар.

Кызыл галстуклар таккан ике кыз бала килеп һава флоты значоклары тәкъдим иттеләр. Бер значок илле тиен. Студент абыйларның кесә төпләре такыр. Балаларны юмалап кире борып җибәрделәр.

Хәлим кызып-кызып университет студенты белән сүз көрәштереп торганда, кемдер моның терсәгеннән килеп тотты. Әйләнеп караса — Хәйри... Чәчләрен, гадәттәгечә, сул колагына тарап салган. Белмәгән кеше һич тә колагы юк дип уйларлык түгел. Кафия бит шуңа кияүгә чыкмыйча ялгыш итте, дип уйлап алды.

— Хәлләр әйбәтме? — дип, Хәйри кул биреп, егет белән күреште.

— Менә бәхәсләшәбез әле, — диде Хәлим. — Мин әйтәм, тотынсалар үз башларына тотыналар, бөтен дөнья революциясе кубачак...

— Дөрес әйтәсең, — диде Хәйри. — Без сугыштан курыкмыйбыз. Мировой пролетариат күтәрелергә сигнал булганны гына көтә. Хәтере-

гездәме, — дип ул тавышка килеп туктаган бүтән студентларга да мөрәҗәгать итеп сөйли башлады: — Хәтерегездәме, шахтерлар күтәрелгәч, Англиянең бөтен промышленностен паралич сукты. Домналар туктады, поездлар, пароходлар йөрмәс булды, чөнки күмер кытлыгы... Хәтта трамвайлар да йөрмәде, электростанцияләрдә күмер бетте. Король илдә черезвычайное положение кертергә мәҗбүр булды. Менә пролетариатның көче! Буржуазия безгә каршы ташланса, бөтен дөнья пролетариаты кубачак та Европаның астын өскә китерәчәк. Буржуазия курыксын сугыштан, без курыкмыйбыз!

Баш өстендә биектә-биектә У-2 ниндидер фигуралар ясап йөри иде әле.

Хәйри егетнең култыгыннан алды да читкәрәк тартты.

— Кафияне күргәнең бармы?

Хәлим иңнәрен җыерды. Без бозылыштык, дияргә уңайсызланды. Хәйри мәйдан уртасындагы трибунага таба китеп, халык арасына кереп буталгач, Хәлим уйланып торды: «Обкомда эшләүче кеше ул бит инде үз фикерен генә сөйләми... Сугыштан курыкмыйбыз икән алайса?»

Митинг башлангач, колонналар чуалды. Бөтен кеше трибунага якынрак елышты. Ораторлар сугышка, империализмга каршы сөйләделәр. Хәлимнәр торган арттагы рәтләрдән ораторларның һавага чөелеп-чөелеп киткән йодрыклары гына күренеп кала иде. Кемдер: «Трибунада футуристлар!» — дип кычкыргач, арттагы сафлар кинәт алга сөрлекте, Хәлим дә: «Теге мин күргәннәреме икән?» дип, кызыксынып кысыла-кысыла алга таба узды. Аяк очларына күтәрелеп-күтәрелеп, трибуна ягына карады. Футуристларның кычкырып сөйләгән тавышларын ишетсә дә, үзләрен күрә алмады: әлеге шул һавада айкалган кулларны гына күреп-күреп калды.

— Такташ! Такташ шигырь сөйли! — дигән тавышлар ишетелгәч, Хәлим яңадан бармак очларына күтәрелде. Хәлимнең Такташны күргәне юк иде әле. Ләкин Такташның да саргылт башын гына күреп кала алды.

Митинг кешеләрне бик ярсытты. Бигрәк тә яшьләрне. Трибунага өерләре белән менеп, бүген дисә бүген Польша паннарына каршы корал тотып чыгып китәргә әзер торуларын әйттеләр. Шундук гаризалар язылды. Бүтәннәре төркем-төркем райкомолга киттеләр. Мобилизован санауларын сорап, үтенечләр бирделәр. Хәлим дә язып бирде. Райкомчылар: сәгате житкәч дәштерербез, барыгыз кайтып торыгыз, дип, артык ярсыган яшьләрне тынычландырып кайтара тордылар.

Броневик та гариза биреп кайткан иде. «Недобитыйлар!» дип, ул бик ярсып йөрде. Берничә көн укуларның рәте булмады. Барлык кеше сугыш турында гына сөйли. Китәсе булгач, укуның кирәге юк иде шикелле. Ләкин көн артыннан көн туа, гариза бирүчеләрне райкомол чакырмый. Үзләрен Варшава, Лондон урамнарында революция ясап йөри итеп хыялланган студентларга тагын китапка утырырга туры килде. Экзамен борын төбендә бит.

## 19

Аягы төзәлгәннән соң, Хәлим инде Галимә белән күрешергә өлгергән иде. Бу очрашуда алар тагын бик күп нәрсә турында аңлашканнар иде.

Менә алар бүген тагын очраштылар. Көпә-көндез бистә урамында егет белән йөрүне Галимә уңайсызга чыгарды: бистә тулы танышлары, берәр тишек авызлысы я әнкәсенә ирештерер... Бистәдә йөрмәскә, шәһәр ягына китәргә булдылар.

Трамвайдан төшкәч, Хәлим кызның кулыннан тотты. Балалар кебек житәкләшеп, урамнан киттеләр. Аппак күлмәк кигән Галимә бик

ак, бик чиста иде. Аның матурлыгы бөтен кешенең күзенә ташлана иде. Алар, үз шатлыклары белән бик мәшгуль булганга, каршы очраучыларга, артларыннан карап торучыларга бөтенләй игътибар итмичә бара бирделәр.

Хәлим аны Русская швейцария дигән җиргә алып бара иде. Татар театры каршында ирексездән туктарга туры килде, бөтен урамны буып, халык җыелып тора иде. Ул да булмады, кайгылы музыка елап җибәрде. Театрдан мәет чыгаралар икән. Хәлим ялан башлы кешеләрнең кыймыл-кыймыл иткән җилкәләрен, ялтыраган пеләшләрен генә күрә иде. Гробны машинага куялар иде бугай.

Галимә бармак очларына күтәрелде дә башлар аша алга карады, шулай да гробны күрә алмагач, балалар кебек, сикереп куйды. Хәлим шунда аны биленнән тотып халык өстенә күтәрде. Кызның итәге сыерылды, матур тез аслары ачылды.

— Күрдеңме? — дип сорады Хәлим аңардан, җиргә төшергәч.

— Карт кеше икән, — диде Галимә, аның бу сүзе: «үлеп яхшы иткән» дигәндәйрәк яңгырады.

Халык бер якка сөрлекте, мәет куелган, мәрхүмнең туган-тумачалары утырган машина кузгалды. Кешеләр, урам тутырып, машина артыннан кузгалдылар. Мәет күмгәндә аппак күлмәк белән баруны уңайсызга санап, Галимә белән Хәлим арттарак калдылар. Озатучыларның бер төрлесе дөнья хәлләрен сөйләшеп баралар иде.

— Командировкадан кайтканда пароходта суык тидергәнмен, томау төшкән.

— Салкын сыра күбрәк эчелгән дисән, колакка ятыр иде ичмаса...

— Эчелгән димәктән, бик эчкән диләр мәрхүмне!

— Артист халкы билгеле инде...

Машина, трамвай паркын узып, туганнар каберлегенә таба китте. Галимә белән Хәлим сулга борылдылар да Новиков дачасы дип йөртелгән, качып утырыр өчен аулак урыннары күп булган зур каенлыкка керделәр. Каберлектә җиз литаврларның ачыргаланып кычкырып-кычкырып җибәрүләре монда хәтле ишетелә иде. Хәлим, җилкенеп торып, Галимәне кочагына кысты. Тыннары беткәнче үбештеләр дә, кызарынышып, өзек-өзек сулап, бер-беренә куанышып карап тора башладылар.

Мәетне кабергә төшерәләр иде бугай. Музыка үкереп-үкереп җибәрә башлады. Күмәләрдер, дип уйлады Хәлим. Чукмар-чукмар кызыл балчык гроб капкачына дөбер-дөбер бәреләдер... Ләкин иреннәреннән елмаю китеп тормады.

Вакыт бик тиз үтте. Һәр хәлдә Хәлим белән Галимәгә шулай булып тоелды. Бер караганда кояш байый гына иде, икенче караганда агач ботаклары арасында ай күренде. Бу кичне Хәлим үзенең кызына күктәге йолдызларны, сайрап торган сандугачларны бүләк итте. Ул белмәде, дөньядагы гашыйклар йолдызларны, бу матур айны күптән инде үзләренең сөеклеләренә бүләк итеп биргәннәрдер дип уйламады, беренче мин бүләк итәм дип, беренче мин шулай котырынып сөям дип белде. Бу кичне ул бик бәхетле иде.

...Кайту исләренә төшкәндә, бакча капкасы инде бикле булып чыкты. Койма аркылы төшәргә туры килде. Башта койма башыннан Хәлим сикерде. Аның ачылган кочагына Галимә очып төште.

Кызны озатып куйганнан соң, Хәлим бистәнең караңгы урамыннан ялгыз гына кайтырга чыкты. Ялгыз гынамы? Юк, аның белән бергә урамнарга сыя алмыйча шатлыгы кайта иде. Кайгыны уртаклашу бар, шатлыкны уртаклашу ник юк икән? Ярты шатлыкны кемгә биреп торырга? Әнә чатта милиционер басып тора түгелме?

— Исәнме, иптәш милиционер! Күңелсез түгелме үзеңә генә?

— Булса нишлисең? Хезмәт!

— Ал минем шатлыкның яртысын! Ә?
— Бар, энем, кайтып ят шыпырт кына...
— Иптәш милиционер, җаным... Син Җидегән йолдызны таныйсыңмы? Җидегән йолдыз безне күреп торды, ай да каен артыннан карап торды...
— Бар, энем, юлыңда бул, кайтып ят...
— Җаным, иптәш милиционер...
Милиционер борылды да, сызгырын алап, караңгыга кереп югалды. Хәлим дә көлә-көлә китеп барды. Алда Кремльнең утлары балкый иде. Бистә арасындагы сазлыкта бакалар бакылдашалар иде. Галимә бүген, Хәлимнең сайрауларын бүлдереп: «Синең янда урын юк, әни янында торып булмый ич инде. Кайда торырбыз?» дип сорады. Галимәдән, урыслар әйтмешли, бик практичный хатын чыгачак. Борчылма, Галимәсе, торыр урынга гына калгач табарбыз. Табарбыз бит, иптәш Җидегән йолдыз? Ә?
Караңгы урамда ялгыз аяк тавышы... Бу — Хәлим шулай ялгыз гына кайтып бара. Күңелендә уйлары: «...кабердә беренче төнне үзенә генә... теге кешегә... иялэшмәгән килеш... Каеннарга да төнге караңгыда каберстан куршесендә үзләренә генә шомлыдыр... Ә Галимә хәзер аныкы! Аныкы! Чокыр битендәге теге юан каен бөтенесенә шаһит! Тәлгәшләрен җиргә тикле салындырып, Хәлим белән Галимәне ят күзләрдән яшереп торган теге ак каен... Галимәне хәзер аңардан берәү дә кире ала алмас. Инженерның бай бүләкләре дә, әнкәсенең кирелеге дә... Берәү дә... Галимә аныкы! Сез шаһит бит, иптәш йолдызлар? (Хәлим, башын артка ташлап, йолдызларга мөрәҗәгать итте.) Сез гасырлар буе адәм балаларының җирдәге гамәлләрен күзәтеп торасыз. Сез инде яхшысын да, яманын да күп күрдегез. Сезнең нурларыгыз астында кешеләр бер-берен үтерделәр, бер-беренә гашыйк булдылар. Сезнең күз алдыгызда берәү туа, берәү кабергә керә... Ә бит бүген беренче төнен кабердә ятучы теге кешене дә сөйгәннәрдер... Ул да сөйгәндер... Йолдызлар да үлә, дип язалар. Ә бу шатлыкны кем белән бүлешергә соң? Ә?»
Урамда ялгыз аяк тавышы... Хәлим кайтып килә... Хәлим кайтып җитте.

Җирән кашка талчыкты, ахры. Хуҗа дилбегәне тарткалагач, лырык-лырык юыртып киткән була да озакламый тагын адымлауга күчә. Көн буе чапты шул инде хайван, кич булып бара. Аппак карлы басулар өстенә зәңгәр күләгәләр иңде. Әнә бер йолдыз да чәчрәп килеп чыккан...
Хәлим, ахырда, агайны тел яздырып каты бәхәскә алып керде. Абзыегыз дилбегә очы белән атка кундырып ала да яңадан тотына:
— Калхуз дигәнегез андый оҗмах буласы булгач, ниемә дип халыкны чыбыркылап кертәсез? Кешеләр оҗмахка үзләре дә керерләр иде. Азылдан сөрәбез, аристан ясыйбыз дип куркытып, барыбызны да калхуз иткәннәр иде. Сталинның язуы чыккач, пыртузганнар булдык та беттек. Күрәсеңме моны? — дип, агай куен кесәсеннән газетаның бер кырыен чыгарды да шундук кире тыгып та куйды. — Печән саткан акчаның яртысы кереп китсә китте, тәки алдым. Сталин абзаң, беләсеңме, ни дип әйтә? Көчләп җәннәткә кертеш булмаска тиеш, ди. Ә бездә нишләделәр?
Агай ярсыды, каршы сүз кыстырырга да ирек бирми башлады.
— Әйтмә син миңа! Бездә тикшереп тормадылар. Сине дә, мине дә, Мөхәммәтәминне дә кулачит иттеләр дә алып киттеләр. Кулакка тисеннәр дә ди, ә минем ишегә ник тиярга? Мин гражданскида өч ел йөрдем, беләсеңме син шуны! Ничәмә тапкыр ранный гына булган! Сез мине ышандырыгыз, мин оҗмахка үзем керермен. Вәт!

Агай дилбегәне тарткалады да тагын Хәлимгә таба әйләнде:

— Син әйтәсең, турайтырга барам дисең... Ярый, сынып ук китмәгән җирне турайтырсың, ә сынган җирне нишләтерсең? Алны-артны тикшермичә кулачит иттегез-иттегез дә хәзер ялгыш булган дисез. Кешеләрне киткән җирдән кире кайтарасыз, аларның инде йорты да юк, маллары да җилгә очкан!

— Йорт-җир кайтарып бирелә, — диде Хәлим.

— Дүрт стена бирелә, ә терлек-туар, өй әйберләре? Бар җыеп кара син хәзер...

— Аларына акча түләнә...

— Каян алып? — «Юкны сөйләмә!» дияргә теләгәндәй кулын селтәде. Аннары көлемсерәп болай диде: — Мин сине белмим, син мине белмисең. Сөйлимме бер әкият? — Абзый бияләе белән ияген ышкып алды да сөйләп тә китте: алар авылында мондый хәл булган, имеш: колхозларга куалау бик кызып киткән чакта, мәчет манарасына көн саен карга килеп куна икән дә «Тарала! Тарала!» дип кычкыра башлый икән, ә күгәрчен, карганың болай контр сүз таратуын яратмыйча: «Гпүү! Гпүү!» дип гөрләргә тотына икән.

Икесе дә көлешеп алдылар. Агай дәвам итте:

— Карганыкы да, күгәрченнеке дә дөрескә чыкты бит әй: калхуз таралды, гпү килде... Гпү килсә дә пыртузган тек пыртузган! Юк, энем, көчләп яңа туган бозауны гына имезәләр. Мин, мужет, беразрак карап тормак келимдер. Нишләр бит әле бу калхуз дигәннәре... Нәрсә кырырлар бит...

— Нәрсә син, печән саткан акчаңа Сталин хатын сатып алдыңмыни? — диде Хәлим көлеп. — Юкка акча әрәм иткәнсең, мин сиңа тиген биргән булыр идем. Менә алар миндә! — дип, Хәлим Сталин хаты басылган брошюраларны чыгарып күрсәтте. Агайның чыраенда үкенү кебек нәрсә сизелмәде.

— Казанда басылганмы? — дип сорады. — Казанский миңа тиген дә кирәкми, минеке мәскәүский, Сталинның үз кулыннан чыккан. Сез монда басарсыз, сезгә ышансаң... Ярты чана печән китсә китте, мәскәүскийне төшердем... — Һәм ул кесәсендәге газетаны капшап куйды. Ахрысы, чынлап та, Казанда басылган китапка ул ышанып бетми иде булса кирәк.

Алда җем-җем иткән утлар күренде. Нindидер авылга якынлашып киләләр. Менә бер вакыт чана, кагылмада чалулап, үрәчәсе белән басу капкасы баганасына бәрелде дә капкадан кереп китте.

«Авыл тыштан караганда бик тыныч,— дип уйлап куйды Хәлим.— Ә бит менә бу кар бүреге астына сыенган тып-тын йортларның эчендә хәзер өермәләр өерелә. Хуҗаларның күзләреннән йокы качкан: нишләргә инде бу калхуз белән? дип уйлый-уйлый, мужик агайның башлары чатный. Гәзитәләр көчләмәскә дип әйтеп тора, палнамучныйлар киләләр дә: керәстиянгә калхуздан башка юл юк, керегез, керүчеләргә мондый-мондый льгутлар булачак дип, күңелләргә вәсвәсә салып йөриләр. Баш-күз алырга форсат бирсәләр икән ичмаса, берәзрәк читтән карап торырга... Нинди нәмәрсә килеп чыгар икән ул калхуз дигәннәреннән? Рәте-башы булыр микән? Ир белән хатын гына да тынышып яши алмыйлар, бөтен авыл бер казанга кашык тыга башлагач, сугышып бетмәбезме?

Газаплы сораулар... Тегеякны, бу якны уйлап, икеләнүләр... Аптырап баш кашулар... Бәйләнешеп китүләр — барлык шушы азаплар өйләрнең эчен тузгыта. Кайбер семьяларның уртасыннан ярык узган: бер як әйтә: «Керик!» ди; икенче як: «Кереп кенә кара, мин сине!» дип кисәү агачы күтәрә... Якалардан тотышуларга хәтле барып җитәләр...»

Хәлим шулай дип уйлап бара. Әйе, ярлыга колхоздан бүтән юл

күренми. Юкса кырык талаудан калып та бөлмәгән Маликлар аңа көн күрсәтмәсләр... Маликларны тамырлары белән йолкырга кирәк.

Җирән кашка, дилбегә тартканны да көтмичә, юлдан борылды да кемнәрнеңдер капкасына килеп туктады. Агайның һәрвакыт туктап чәй эчә торган йорты булса кирәк.

— Атны ял иттереп, тамак ялгап алабыз, — диде ул, чанадан төшеп капкага таба атлады.

Барасы җирләренә алар икенче көнне иртән генә барып җиттеләр.

## 20

Яшь уполномоченныйның «турайтып» йөри башлавына икенче атна китте. Ансат булмаячагын ул өйдән чыкканда ук белеп чыккан иде. Һәр төрле кыенлыкларга күңеленнән әзер тора иде. Барып эшкә тотынгач, уйламаган-көтмәгән каршылыкка очрады. Волком секретарьлары Хәлимгә эшләнгән эшне сүтеп йөрүче итеп карадылар һәм егеткә аяк чалдылар. Бер генә секретарь да: «Әйе, без гаепле, чамасыз бөктек, төзәтергә кирәк», димәде. Кантком гаепле, диделәр. Яисә өлкә оешмаларына сылтадылар. Алар ничек кушкан булса, шулай эшләдек, диештеләр. Ни өчен соң, янәсе, йөз процентка куучыларны башта мактадыгыз да хәзер под суд? Юк, уңышлардан безнең баш тамчы да әйләнмәгән иде, ә менә хәзер чынлап та баш катты. Әүвәле процент узыштыру ясадылар. «Куала!» дип, көн саен телеграмм белән дөмбәсләп тордылар, хәзер виноват итәләр.

Хәлим белә иде, аларның сүзләрендә дөреслек бар: чынлап та, бөтен газеталар «Куала!» дип кычкырдылар Кантон белән кантон ярышты: кем тизрәк күмәкләштереп бетерер! Кем алга чыгар! Өлкә комитеты югарыдан шуны хуплап карап торды. Хәзер исә барлык ялгышларны түбәндәге оешмаларга сыптыралар, йөз процент артыннан балакларын сызганып чапкан волком секретарьларын гаепliләр.

Кичә Хәлим барып төшкән Кул Башы волостеның волком секретаре Ногманов, атна буе сакал-мыегына пәке тидермәгән, кабинетында утырганда да башындагы малахай бүреген салмый торган ямь-яшел чырайлы бик талчыккан, нервланып беткән кеше, Хәлимнең кәгазьләрен карады да, кабинетының ишеген бикләп алып, ачкычын өстәлгә куйды.

— Сталин хатын гарәп хәрефләре белән бастырып чыгарып, кантон гына бөтен эшне бозды, — дип тотынды ул, йокы күрмәгән, кан сарган кызыл күзләре белән яшь уполномоченныйга яратмыйча карап. — Яңалиф белән бастырырга кирәк иде, берәү дә рәтләп укый алмаган булыр иде. Кантномның шуңа башы җитмәде. Гарәп хәрефен барлык халык укыды, колхозлар таралды да китте.

Хәлим тыела алмыйча елмаеп куйды: олы кеше, волком секретаре шундый сүз сөйләп утырсын инде. Хәлим сәерсенеп Ногмановның яшел чыраена карап тыңлап утыра, ә Ногманов, шушы сүзләре белән үзен көлкегә калдырганын аңламыйча, (күрәсең, аның башы, чынлап та, бик каткандыр), зарлануын дәвам итте:

— Да иштеләр ишәк чумарын, — диде ул, югары оешмаларны күздә тотып, — астыртын гына безгә әйткән булсалар, «Эшләр шулай-шулай, иптәшләр, тизрәк төзәтегез», дисәләр, без монда иплән кенә турайткан булыр идек тә шуның белән вәссәләм! Эшең бетте, кодагый... Ниемә инде бөтен дөньяга шауларга? Хәзер менә колхоз дип авылга барып кара инде, күрсәтерләр сиңа колхоз... — Һәм ул тәмам өметен өзгән кеше кыяфәтендә кулын селтәп куйды. — Аннары өстәлдәге ачкычны алып шалтыр-шолтыр ишекне ачты да яңадан Хәлим каршына килде: — Менә минем өстәл, минем урын, утыр да командуй! — диде, өстәлен, телефонын Хәлим ихтыярына тапшырганын белдереп. — Мин

колхозлаштырдым, сез сүтегез. Алдан ук әйтәм, мин авылга аяк та атламыйм, бу хәлләрдән соң анда мин күренсәм, тотып авыз-борынымны кан итәчәкләр...

— Юк, — диде Хәлим елмаеп, — команда сезнең кулда кала.

Кул Башы волостенда барлык чиркәүләр, мәчетләр алынган, ун процент хуҗалык раскулачить ителгән иде. Обкомда дүрт процентны да бик зурга санап сөйләүләре Хәлимнең исенә төште. Болар күпме урталарны кулакка чыгарганнар да күпме кешене урынсызга авылдан сөргәннәр. Ногмановның авылга чыгарга куркуы тикмәгә генә түгел икән шул. Ун процентка эләккән кешеләрнең күбесенә малларын кире кайтарып бирергә кирәк булачак, ләкин ул байлык инде күптән тузып беткәндер. Руслар әйтмешли, Ногманов «наломал дров».

— Менә монда исемлекләр, — дип ул Хәлимгә ниндидер кәгазьләр бирде. Хәлим караштыргалады да кәгазьләрне читкәрәк алып куйды. Хәзер үк бюро җыярга тәкъдим итте.

— Бюро членнарының күбесе өйдә юк, — диде Ногманов.

Хәлимгә полномочиесе каты сөйләшергә мөмкинлек бирсә дә, үзенә эти булырлык, өстәвенә күренеп торган авыру кешегә каты бәреләсе килмәгән иде. Инде Ногмановның болай «тәртәне тибеп сындырырга» азаплануын күргәч, урыныннан баш тартырга җыенган кебек, «командуй» дип, барысын Хәлимгә тапшырып, үзе читтә басып калырга теләвен аңлагач, Хәлим сөйләшү тонын кинәт үзгәртте.

— Иптәш Ногманов, — диде, — я сез хәзер үк бюро җыйныйсыз, я мин обком секретарена шалтыратып, сезнең монда паникада ятуыгызны сөйләп бирәм!

Ярты сәгатьтән бюро җыела башлады. Бюро членнары, ят кешеләр сыман, ишек катыннан уза алмыйча, стена буенарак тезелешеп утырдылар. Гүя алар моның белән «без инде монда хуҗа түгел, Казаннан килгән әнә шул малай хуҗа» дип әйтергә телиләр иде. Ногманов та гадәттәге урынына, үзенең өстәле янына, утырмаган, ә бюро членнары белән бергә утыра һәм шундый кыяфәт белән утыра, әйтерсең, ул монда бик яхшы нәрсә эшләгән булган да, уполномоченный аларның «бик яхшы» нәрсәләрен бозып китәргә килгән.

Хәлим бюро членнарының төс-битләренә, чырайларына, үз-үзләрен ничек тотуларына караштыргалап, бер читтәрәк уйланып утыра: болар бит әле кайчан гына монда кешеләрнең язмышларын хәл иткәннәр, теләгән кешеләрен раскулачить иткәннәр, теләгәнен төрмәгә япканнар, ә бүген песием-песием генә утыралар. Бу, ихтимал, үзенә күрә бер протестыр? Чөнки бит алар үзләрен гаепсезгә гаепләнүчеләр итеп исәплиләр...

Бюро членнарының берсе бүтәннәреннән ничектер аерыла иде. Ишектән кергән чагында ук әле ул Хәлимнең күзенә бәрелде. Күн итектән, күкрәк турысына ике каплама кесә ябыштырылган кара френчтан, култык астына кара портфель кыстырып җибәргән салкын чырайлы бу кеше, аерып берәүгә дә сәлам бирмичә, бүлмә эченә гомуми сәлам генә бирде дә тәрәзә янындагы урындыкка ялгыз гына барып утырды. Хәлим, аның кем булуын, кайда эшләвен чамаларга тырышып, «профсоюз — түгел», «кооператор — түгел» дип, волостьтагы җаваплы урыннарны күңеленнән кичерә башлады. Теге дә маңгай астыннан Хәлим ягына караштыргалап ала иде. Икесенең күз карашлары чарпылышкан вакытта, Хәлим бу агайның күзләрендә кешене өтеп ала торган дошманлык сизә иде. «Волостьтагы ГПУ уполномоченные икән, — дип уйлады ул. — «Ун процентны» озата-озата каны тәмам каткан да күзләренә җан өшеткеч дошманлык урнашып калган... Ләкин ни өчен ул миңа да дошманлык белән карый?»

Бюро башлангач беленде, бу кеше волостьта прокурор булып эшли икән.

Хәлим: «Моның кулына эләксән, ай-яй!» дип уйлап алды. Башка бюро членнары шыпырт кына тыңлап утырганда, бу Хәлимнең сүзләренә бәйләнеп китте. Янәсе, менә сез көчләмәскә, ышандырырга кирәк дисез, нинди бер крестьянның: «Мине ожмахка көчләп кумагыз, башта ышандырыгыз, ышансам мин доброволь барып керермен» дигән сүзләрен китердегез... Ә бит ничә ел инде без мужикны ышандырырга тырышабыз, ә ул һаман урманга карый. Маркс әйткән, көчләмичә революция ясап булмый, дигән! Частный хужалыкның тамырына балта чабу шул ук революция ул!

Хәлимнең прокурорны ярсытасы килмәде, каты бәрелмәде. Ленинның, урта крестьянны таяклап социализмга алып барып булмаячак, дигән сүзләрен китерде.

— Факт күз алдыгызда, — диде. — Таяк белән ясалган колхозларыгыз таралганнар да беткәннәр.

— Таралмыйдыр иде ул, — диде прокурор. Беркавым тынып торды. Ногманов кебек, Сталин хаты гаепле дип әйтәсе килде бугай, ләкин әйтмәде, шулай да колхоз таратырга йөрүчеләргә уголовный кодекс статьялары белән яный башлады. Бусы инде бөтенләй урынсыз килеп чыкты, монда бит колхоз таратырга җыенучылар юк иде. Күрәсең, ул Хәлимне шундый кешегә саный иде бугай. Соңыннан Хәлимгә сөйләделәр, бу кеше элек тә бюроларда гел статьялар белән генә сөйләшә торган булган, «шелтә» бирәсе, «на вид» куясы урында гел «фәләненче статья!» дип тотына икән.

Каян килә безгә мондый кешеләр? Һәрхәлдә анасыннан шундый булып тумаган бит инде. Әллә хәрби коммунизм кыйпылчыгымы? Моның кулына зуррак власть тоттырсаң... Ашар иде кешеләрнең башларын! Ә Ногманов җебеде дә төште, властен камыт кебек салып Хәлимгә кигезә башлады. Ә шул кеше бит ни гомер монда секретарьлык иткән, кешеләрнең язмышларын хәл кылып утырган...

Кемне кайсы авылга җибәрү хакында сүз купкач, мин анда бармыйм дип, аяк терәүләр башланды, янәсе, бу авылда ул колхоз оештырган, үзе оештырганны үзе үк таратып йөрисе килми.

— Күренергә куркам дип әйтегез, — диде тегеләрнең күзләренә текәп Хәлим. — Нинди тарату булсын! Саклап калу хакында сүз бара.

Авылларда да Сталин хатын колхозларны тарату дип аңлаганнар иде. Хәлим барган Такта Алачык авылында, колхозны ныгыту хакында сүз чыгаргач, җыелыш ду купты:

— Сталин язган гәҗитне укы, ул анда бик ачык әйткән!

— Ник яшерәсез бездән Сталин язуын!

Хәлим шәһәрдән алып килгән, Сталин хаты басылган брошюраны укый башлаган иде, тагын кычкырып җибәрделәр:

— Палнамучный укымасын, үзебезнең кеше укысын!

— Гарәпчәсен укыгыз, анда бик прабильне әйтелгән!

Шундук аларның үз кешеләре күтәрелде дә гарәп хәрефләре белән басылган, әлеге теге Ногманов зарланган газетадан кычкырып укырга тотынды. Ул укып бетергәч, Хәлим өстәл артыннан күтәрелеп: «Иптәшләр, анда бит менә мондый-мондый сүзләр дә бар» дип, крестьянга колхозлашудан башка бүтән юл юк дигән җирләрне укып күрсәтмәкче булган иде, бөтен җыелыш бер авыздан: «Синекендә, мужет, шулай язылгандыр, безнекендә алай язылмаган!» дип, шау-гәр килеп, уполномоченныйның сүзләрен чутка алмадылар. Волость җитәкчеләре паникада йөргән арада, күрәсең, Сталин хатын кулак үз белдегенчә аңлатып өлгергән иде.

Шундый җыелышларның берсеннән соң, Ногманов Хәлимгә:

— Күрдегезме? — диде. — Хәзер бит арестовать итәргә дә ярамый, нишлибез инде бу кулак агентлары белән?

Шулай диде дә, муены сызлауга зарланып, бүреген басыбрак киде.

Хәлим Аю Көйдергән авылына барырга җыена башлагач, Ногманов андый авылга яшь уполномоченныйның ялгызын гына җибәрәсе килмичә, шул ук вакытта егет белән бергәләп барырга да теләмичә (анда Ногмановны кирәгеннән артык яхшы беләләр иде), Казаннан килгән Ярхәм Ярмухаметов дигән кешене Хәлимгә тагып җибәрде. Ярмухаметов Казандагы партия мәктәбендә укучы бөкре бер студент булып, Хәлимнән ун яшьләргә олырак иде. Бөкресе очлаеп чыккан тәбәнәк буйлы, барлык бөкреләргә хас рәвештә куллары тездән түбән салынган һәм катырак барса сулышы тыгыла башлый торган бу кызыл чырайлы карт студент чанага кереп утыргач, печән эченнән бөкресе белән башы гына күренеп бара башлады.

Дилбегәне Хәлим тотты. Атны бик кызуламый гына бардылар (анда бит бәлешләр белән көтеп торучы юк). Ярмухаметов, бөкресе өстендә башын кыймыл-кыймыл китереп, моңа хәтле кайсы авылларда «турайтып» йөрүен, анда нинди әкәмәтләргә тап булуын мәзәк итеп сөйләп барды. Үзеннән олы кеше, дөнья күргән кеше белән барганга Хәлим тыныч иде. Алларында ике мәчетле зур Аю Көйдергән авылы күренә башлагач, алар «ни өчен Аю Көйдергән кушканнар икән?» дип сөйләшә башладылар.

Март кояшына сыртларын куеп, урамда ике ала сыер рәхәтләнеп күшәп тора иде.

— Авыл советлары кайдарак икән боларның? — диде Ярмухаметов һәм урамда кар бәрешеп уйнап йөргән малайлардан авыл советын сорады. Тегеләр әйттеләр. Хәлим, дилбегәне шул якка тартып, урамнарны күзәтеп бара башлады.

Мәчет катында кешеләр өелешеп торалар иде. Ярмухаметов, терсәге белән Хәлимгә төртеп: «Туктата башласалар, атыңа сыптыр да выж итеп узып кит!» дип егетне өйрәтеп куйды.

Хәлим: «Ярар» дип башта килеште, ләкин зәңгәр койма янында өелеп торган кешеләр арасыннан ике агай чыгып, боларга таба йөгерешеп килә башлагач, атка сукмады һәм чаптырып узып китмәде, «халыктан качып йөрү өчен килмәдек ич без монда», дип уйлады. Ярмухаметов дилбегәне Хәлим кулыннан тартып алмакчы, атка сукмакчы булган иде, алырга һәм сугарга өлгермәде, теге ике кеше, килеп җитеп, атның башыннан тотты. Уполномоченныйлар, сагаешып, нинди ният белән йөриләр икән болар? дип, исләре китмәгәндәй генә чанада утыра бирделәр. Хәлим, күңелле күренергә тырышып, берни булмаган кебек елмаеп:

— Ни бар, агайлар? — диде.

— Сез мәчет чутыннан йөрмисезме?— дип сорады теге ике агайның берсе, тунын җилбәгәйгә җибәргән кара сакаллысы.

— Юк, без мәчет чутыннан түгел, — диде Хәлим.

Кара сакаллы Хәлим белән Ярмухаметовка алмаш-тилмәш карап алды.

— Кайсыгыз сезнең глауный палнамучный?

Тегеләр дәшмәгәч, агай икесенә берьюлы мөрәҗәгать итте:

— Кулакларны сыйныф ясаган чакта мәчеткә җәйгән паласларны алып киттеләр, шуларны таптырасы иде дә аннары муллабызның йорт-җирен үзенә кире кайтарып бирдерәсе иде.

Хәлим: «Мондый хәлдә нишләргә?» дигән сыман, Ярмухаметовка таба борылды.

Болар сөйләшкән арада чананы әллә нихәтле халык сарып алырга өлгергән иде. Ачулы тавышлар, янау сүзләре ишетелә башлады. «Тапсыннар!» «Җибәрмә!» «Өстерәп чыгар чанадан!» дип тавышлана башлаган халыкның янаулы күз карашы астында үзен бик уңайсыз сизгән Хәлим чанага торып басты:

— Җәмәгать, иптәшләр... Мондый мәсьәләне урам уртасында хәл итеп булмый.

— Бик була!

— Язу язып бир, мулланың йорт-җирен кайтарырга рөхсәт диген!

— Андый язу бирергә безнең хакыбыз юк, — диде Ярмухаметов.

— Кайда әле ул бәдбәхетләр, имансызлар? — дип, күзләре-башлары акайган ике хатын, кешеләрне аралый-аралый, боларга таба якыная башлады. «Оятсызлар! Җир битләр!» — дия-дия, чәчләре тузган хатын Ярмухаметовка ташланды, икенчесе, яшьрәге, Хәлимгә килеп ябышты. Хәлим тегене әкрен генә этеп җибәргән иде, хатын чырыйлап торып пычрак кар өстенә чалкан ауды.

— Үтерде! Корсагыма типте! — дип, аһ-ваһ килеп, эчен тотып, җирдә тәгәри башлады.

Аның тавышына ирләр куптылар.

— Күрмисезмени, хатынның корсагына тибеп баласын төшерде бит! Элеп алыгыз үзләрен!

Ярсып, үкерешеп чана өстенә килә башладылар.

Хәлимнең аркасы буйлап чемердәп салкын узды. Галимә белән бистәдә йөргәндә караңгыдан пычак тоткан кеше болар өстенә килеп чыккач Галимә, чырыйлап җибәреп, үзе пычак астына кергән иде... Монда бу котырган халыктан аралаучы булмас. Шулай дип уйлап кына бетерде, бая чананы туктаткан Кара сакал, кулларын болгый-болгый, «Җәмәгать! Сабыр! Агай-эне, сабыр!» дия-дия, халыкны акылга килергә чакыра башлады.

— Җәмәгать! Җәмәгать! — дип кабатлап, агарынган килеш, ике кулын алга таба җәеп, халыкны чана өстенә җибәрмәскә тырыша, ләкин кешеләрнең кысрыклавы астында чанага таба чигенә иде. Чигенәчигенә ул чанага килеп терәлде дә андагы уполномоченныйларга тиз генә әйтте:

— Мулланың йортын кайтарырга дип язу тырнаштырып бирегез дә, мин сезне хәвеф-хәтәрсез генә озатып җибәрәм.

Болар язарга риза булдылар. Ләкин халык тәмам ярсыган, җибәрергә дигән сүзне ишетәсе дә килми. «Бетерегез! Эчәкләрен савыгыз!» дип үк кычкырырга тотындылар.

Дәрәҗәле авыл картлары, эшнең начар бетәчәген күреп, тиз генә Кара сакал ягыннан төштеләр: чанага ташланучы тилергән, күз-башлары акайган хатыннарны таяклары белән кагып-кагып җибәрделәр.

Хәлимнең битен тырнап канатканнар, Ярмухаметовның җиңен тартып өзгәннәр иде. Картлар алардан тагын бер тапкыр: «Язу бирергә ризамы?» дип сорадылар. Тегеләр: «Риза», диделәр.

Урамда гына язып бирмәкче булган иделәр, юк, пичәтле булсын! дип, югары очка авыл советына таба дуылдатып алып менеп киттеләр. Кызык күрергә чыккан бала-чага өере дә шунда чапты. Кыйнамаска! — диелгән булса да, уполномоченныйларның аркаларына тагын шактый гына кундыргаладылар. Ярмухаметов көчкә атлый, аны өстерәп диярлек баралар. Хәлим аягында нык торырга, егылмаска тырыша, җилкәсенә кундырганда сөрлегеп китсәләсә дә, яңадан тураеп, кешеләр арасыннан үзе атлап бара иде.

Язу язып кул куйгач, инде җибәрәләр икән дип торганда, ак сакаллы бабайлар нидер киңәшеп алдылар да үз тирәләрендә айкалган агайларның берсенә атны бире китерергә куштылар. Хәлимнәрнең аты, чанасы килде. Боларны чанага утыртасы урында ни өчендер атны чанадан туардылар. Ул да булмады, кара сакалның аркылы төшүенә карамастан, камытны Ярмухаметовның муенына кигезә башладылар. Аптырап карап торган Хәлим янына да камыт тоткан агайлар йөгерешеп килде. Урам тулы халык көлешеп карап тора иде. Шуннан соң болар-

ның икесен дә үзләре утырып килгән чанага җиктеләр дә: «На! Фють!» дия-дия, баш очларында таяк болгап, каядыр алып киттеләр.

Ярмухаметов сулышы бетеп егылды. Аны тартып торгыздылар да: «Юри мутлана бөкре тәре!» дип, тагын баш очында таяк селки башладылар.

Яшел калай түбәле, яңа урыс капкалы матур йорт каршында икесен дә туктаттылар, бераз сабыр итәргә куштылар. Менә бервакыт йорттан ак чалмалы, түгәрәк ак сакаллы куркынган мулла килеп чыкты, аның артыннан сары чырайлы остабикә һәм мулланың кечкенә балалары күренде. Авыл агайлары мулланы култыклап алдылар.

— Рәхим ит, хәзрәт, чанага, рәхим ит. Өеңә илтеп куябыз, — дип, юл өстендә көтеп торган чанага таба алып китә башладылар.

Ат урынына тәртә арасына кеше җигелгән булуын күргәч, мулла бөтенләй курка калды, ачуланып, аякларын терәде.

— Куегыз килешмәгәнне... Аллам сакласын... Имам башым белән... — дия-дия, җитәкләп килүчеләрдән ычкынды да, кулларын бутап, капкадан кире кереп китте. Аның артыннан остабикә белән балалар да кереп югалдылар.

Ул арада ачык капкадан тимерле зур сандык күтәргән агайлар күренде. Граммофон күтәргән абзый, иләк, ләгән, чиләк тоткан малайлар килеп чыктылар. Сандыкны, сарылы-яшелле граммофон трубасын, тигәнәне һәм ләгәннәрне чанага илтеп куеп, агайлардан берничә кеше үзләре дә менеп утырдылар да, Кара сакалның үгетләвенә, ялынуына колак та салмыйча, тәртә арасында басып торган вәкилләрнең баш очында янә таяк болгадылар. Чана мулла йортына таба юл тотты... Шушындый әкәмәт хәлгә килеп эләгүенә Хәлим бик гарьләнде. «Ногманов кирәк иде монда, — дип уйлап куйды ул чананы бөтен көчкә тартып барганда. — Аның үчен бездән алалар...»

## 21

Ярмухаметовны больницага алып кайтып салырга туры килде. Хәлимне дә берничә көнгә салмакчылар иде, Хәлим: «Мин сәламәт» дип, больницадан баш тартты. Квартирда гына ятып торды. Уполномоченныйларның кыйналуына Ногманов үзен дә җаваплы санады булса кирәк (беренче чиратта обком аңардан сораячак бит), Хәлим янына кергәләп йөрде. Килеп керә дә бүреген салмыйча гына Хәлим янына утыра.

— Врачлар муеннан невралгия таптылар, — ди ул һәм бүреген басыбрак куя. — Бик авырта, муенны борып булмый.

— Муенны бора алмаганда, без ата казга сәлам бирә идек, — ди Хәлим, моны ул шундый итеп әйтә, һич тә шаяра дип белмәссең. Ногманов үпкәләми, тик борынын гына тарткалап куя.

— Нишләтәбез инде бу Аю Көйдергәннәрне? Бер-икесен арестка алсак, санкция бирәсезме?

Хәлим аның ямь-яшел чыраена күзенең очы белән генә карап ала.

— Санкция бирергә мин прокурор түгел, — ди ул коры гына. — Аю Көйдергәннәр кемне кыйнарга икәнен белмәделәр, менә сезне тотып кыйнарга тиеш булганнар алар. Муеныгыз да тизрәк турайган булыр иде.

Ногманов бер кавым тезләренә карап утыра да аннары кинәт башын күтәрә:

— Ансат сезгә, панимаешь, монда килеп, арткы акыл белән судья булып йөрергә... — дип кызып китә. — Центр гаепле, алар куырып тордылар, давай да давай! Фәлән срокка давай йөз процент! Юкса партбилетыңны — өстәлгә! Ә хәзер безне корбан тәкәсе итеп чалалар...

Һәм ул нервланып аяк-өс баса да, ишекле-түрле бераз йөргәч, чыгып ук китә.

Ялгыз калгач, Хәлим почмакка карап, уйланып ята башлый. Чанага җигелеп, мулланы өенә илтеп куюисенә төшә дә, тыела алмыйча, көлеп җибәрә. Кутырлы бите җанлана. Ул да булмый, кычкырып ук көлә... Тиле димәсәң... Теге яктагы хуҗа хатынның әллә ни уйлавы бар. Ярый әле, кара сакаллы агай атны алып килергә өлгерде. Халык мулланы озата кергән арада, атны тиз генә җиктеләр дә авылдан выж чыгарып җибәрделәр.

Обкомда соңгы күрешүдә Хәйри сөйләгән иде. Колхозлар оештырып йөргәндә, бер тапкыр Кафия бик четерек хәлгә эләккән. Шундый четерек, Хәйри сөйләп биргәч, Хәлим ышана алмыйча торды. Әгәр моны Кафия үзе сөйләсә, мактана дип, Хәлим бөтенләй дә чынга алмаган булыр иде. Хәйри авызыннан ишеткәч, ышанмый булдыра алмады. Хәйри моны обкомга килгән рәсми хәбәрдән, ГПУ уполномоченные донесениесеннән укыган иде.

Биштирмән авылында булган бу хәтәр хәл. Боларга хәтле бер-ике тапкыр килеп, колхоз дип, авылны кысып караган булалар инде. Барып чыкмый. Аннан болар киләләр. Халык иләмсез күп җыела. Башлап волком секретаре Галиев сөйли. Бер дә яратмыйлар.

— Сине тыңлый-тыңлый колак сасып бетте инде, Казан кешесе сөйләсен! — дип кычкыралар. Казаннан килгән Макаров сүз ала. Аңа да озак сөйләргә бирмиләр, төрле сүзләр кычкыра башлыйлар. Макаровның ачуы чыга. Җыелышта утыручы кооператив приказчигына карап, бөтен кеше ишетерлек итеп:

— Язып ал кычкыручыларны, аларга кибеттән товар сатма! — дип боера.

— Алайса безнең пайны кайтарыгыз! — дип җавап бирә җыелыш.

Макаров яный ук башлый:

— Җигелгән атлар капка төбендә генә тора, бик бугаз киеручеләрне утыртабыз да хәзер үк Себергә озатабыз, — ди. Колхозга каршы торучыларны иген үсми торган җирләргә күчереп утырту, авылдан сөрү белән куркытырга тотына.

— Син алай бик өркетмә! — дип кычкыралар агайлар. — Аңлат. Нинди рәк тормыш белән торырбыз анда колхозда? Ничегрәк яшәрбез?

— Кергәч ничек яшәргә икәнен өйрәтербез. Исемлекне тавышка куям. Кем дә кем колхозга һәм совет властена каршы — кул күтәрсен!

Берәү дә совет властена каршы күтәрми.

— Барыгыз да бүгеннән колхозда! — дип игълан итә Казан кешесе.

Беркавым җыелыш тын утыра. Аннары кинәт үкереп җибәрә дә, бөтенесе дәррәү кубып, акыра-бакыра президиум өстенә ташланалар. Кафия алгы рәттә утыра икән, җыелыш ажгырып өстенә килә башлагач, эскәмиягә сикереп менеп баса, кулларын баш очында айкап: «Туктагыз! Утырышыгыз!» дип кычкыра. Шунысы бик гаҗәп, — дип сөйләгән иде Хәйри, — туктаганнар. ГПУ кешесе исе китеп яза икән: ниндидер бер кыз ярсыган толпаны кычкырып туктаткан. Туктыйлар! Куркып түгел инде, әлбәттә. Гаҗәпләнеп туктаганнар, ахрысы. Утырыша башлаганнар. Ә бу, эскәмиядән эскәмиягә сикереп, президиум өстәле катына менеп баса да: «Иптәшләр, тынычланыгыз!» — дип әкрен генә әйтә. Үз араларыннан авторитетлы бер кешене җыелышка председатель итеп сайлауларын үтенә. Бер ак сакаллы картны сайлап куялар. «Барыгыз да аңардан рөхсәт алып кына сөйләгез, — ди Кафия. — Мин дә аның рөхсәте белән генә сөйләрмен».

Бая президиумнан чыгып качкан иптәшләр дә берәм-берәм кире керә башлыйлар. Җыелыш бик озак бара. Кафия дә сүз сорый. Бирәләр. Ул хөкүмәтнең колхозларга бирә торган льготаларын сөйли: колхозчы ничә ел налог түләмәячәк, акчалата хөкүмәттән нинди ярдәм

алачак һәм башкалар. Макаров белән Галиев сүз сорагач, җыелыш яңадан ду куба. Аларга сүз бирмиләр. Әлбәттә инде, ул көнне Кафия колхоз оештырып җибәрә алмый. Алмаса алмый, аның каравы халыкны тынычландыра, үзен һәм иптәшләрен коткарып кала.

Хәйридән шушы вакыйга турында ишеткәннән соң, Хәлим: «Безнең Кафиядән булыр аңардан, — дип әйткән иде. — Кафия отчаянный кыз...» Һәм менә бүген, кыйналудан котылып кайтып, ялгыз пошынып ятканда, ул үзен Кафия урынына куеп карады. «Мин аның кебек итә алыр идем микән? — дип уйлады. — Итәр идем. Үзем бетсәм бетәр идем, иптәшләремне ташламас идем».

Ирексездән тик яткан көннәрдә, Хәлим сагыну чире белән авырып алды. Сагыну... Нинди чир соң бу сагыну дигән нәрсә? Әйбәт кенә йөргәндә кешенең күңеле кинәт ашкына-җилкенә башлый. Сагыну белән мәхәббәт бит инде кешеләрне җиде диңгез кичәргә, җиде тау менәргә мәҗбүр иткән нәрсә. Казаннан чыгып киткәндә Хәлим ике генә атнага аерылабыз дип белгән иде. Галимәсенә шулай дип әйткән иде. Ат койрыгына карап чанада чабып йөри башлавына инде айдан ашты. Бер хат алганы юк. Экскурсантлар үзеннән яшереп, цехның ерак почмагына илтеп утыртылган Галимәсен сагынуга чыдый алмый. Халыктагы иң матур җырлар сагыну чиктән ашкан минутларда чыгарылгандыр. Хәлим дә үзеннән чыгарып җырлап йөри. Бер минут тормый кайтып китәр хәлгә җитте. Хәзер йөгереп чыгар иде дә Казан юлы белән чабар иде. Аю Көйдергән агайлары кыйный-кыйный урамнан алып барган чакта ул бер дә курыкмаган иде кебек, ә менә хәзер, сагыну өянәге белән газапланганда, күңеле белән узганга кайтып, үткән өчен курkуга төште... Үтергән булсалар... Әле бит дөньяда яшәгәне дә юк, рәтләп эшләгәне, туйганчы сөйгәне... Галимәнең әнкәсенә: «Хәлим инженерлыкка укый», дип ялганладылар. Ул, мескен, «Кызымның ире инженер була», дип алданып йөри.

Киенде дә обкомга телеграмм сугарга китте. Кайтарсыннар. Укулар да күп кала. Җавап көтә-көтә кичкә хәтле зарыгып бетте. Бер уйлый да: «Кайтармаслар» дип өметсезлеккә төшә, тагын уйлый да, кайтарырга тиешләр кебек тоела башлый. Ике атнага дип кенә җибәргәннәр иде бит... Кайтарырлар. Һәм ул Ногманов янына ат сорарга китә...

Җавап икенче көнне иртән генә килде. Рөхсәт итмәгәннәр иде. Хәлим хат язарга утырды. Бөтен сагыну ялкынын конвертка бикләде. Ә кичкә таба ул инде тагын чанада иде. Көннәр гел кояшлы, җылы торганга, басуда кар иңгән, утырган, чана юллары пыялаланган иде.

## 22

...Чана уңаена тирбәлеп, бер уяна, бер йоклый бара торгач, аяк бармаклары тунудан йокысы ачылып, Хәлим тун якасыннан башын чыгарып карады. Кырлар өстенә караңгы яткан, күктә йолдызлар кабынган иде инде. Менә ул чанадан төште дә, тун чабуларын лыбырлыбыр китереп, аяклары җылынганчы йөгерде, аннары яңадан «оясына» кереп утырды.

Күзен йомса, күз алдында гел җыелыш. Агарынган чырайлар... Шашынган күз карашлары... Берәү дә тыныч кына сөйләшә алмый. Якалашуга хәтле барып җитәләр. Тагын бер революция башланды. Авыл тамырыннан куба... Нинди хуҗалык булачак бу күмәк хуҗалык? Хәлим моны үзе дә принципта гына белә. Агайларның кулыннан агач суканы тартып алырга, үзләрен машинага атландырырга, бөтен авыл хуҗалыгын индустрия нигезенә корырга! Россияне икмәккә кинәндерергә! Калганы томанлы... Һәрхәлдә яхшы хуҗалык булырга тиеш.

Юкса партия бөтен авылны тамыры белән йолкып күчереп утыртмас иде. Яңа туфракта авыл яңача үсәр. Партия шулай ди. Хәлим партиягә ышана һәм, партия сүзләрен кабатлап, агайларны колхозга өнди. Әгәр бүген этисе исән булып, улыннан киңәш сораса, Хәлим этисенә дә: «Колхозга кермәсәң, син миңа бүгеннән эти түгел!» дип әйтер иде. Агайларга принциплар гына җитми, принципны икмәк урынына ашап булмый бит, ат урынына арбага да җигеп булмый, аларның колхозны дүрт яктан капшап карыйсылары килә. «Үзебез чәчкән иген үзебезгә булырмы?» «Булыр», ди Хәлим. «Нәрсә чәчәргә теләсәк, шуны чәчә алырбызмы? Өстән: «Фәләнне чәч!», «фәләнне чәчмә!» дип кычкырып тормаслармы?» «Тормаслар, ди Хәлим. — Җиргә сез хуҗа, нәрсә чәчәргә, кайчан чәчәргә — сез үзегез беләсез». «Чирләп киткәндә бүлнискә барырга ат бирерләрме?» — дип сорый сары сакаллы чандыр бер агай. — «Бирмичә...» (Җыелыштагы ике йөз житмеш өч авыз барысы бергә елмая: «Гали агайның үз кайгысы!») Аннары бер кара сакаллысы торып баса:

— Ат дигәннән, атларны үтереп бетермәбезме? Мин төнен өч торам, дүрт торам, атымның ашарына бирәм, калхузда канюхлар йоклап ятса?

— Ат үлсә, трактор булачак! — дип кычкыра арадан яшьләр тавышы. Ул да булмый, тагын бер озын мыек сикереп тора: «Әгәр дә мәгәр мин йортка килен төшерергә келәсәм, менә дигән тройка атлар сорасам — җиз клукуллары, көмеш шлияләре белән? Бирерләр микән, энекәш?» Ике йөз житмеш өч авыз бу юлы инде кычкырып ук көлә. «Бирмичә булмаслар», — ди Хәлим, җыелышка ияреп үзе дә көлә башлый.

Баштагы якалашулар онытыла. Күз карашларында мутлык һәм хәйләкәрлек елтырый. Хәлим сизә: җыелышны әкренләп уенга бора башлыйлар. Бүреген башының чүмеченә генә эләктереп куйган шактый калын тәнле бер агай үзенең кәбестә штие яратмавы хакында сөйләргә керешә, янәсе, колхозда, район ашханәсендәге кебек, гел әчегән кәбестә штие генә ашатып тормаслар микән? Әлеге ике йөз сиксән дүрт авыз (тәмәке тартырга чыгучылар керделәр) тагын елмая башлый. Арткы рәттән кемдер: «Гел итле токмач кына ашаганга капка баганасыдай юанаеп беттең инде, Биктимер! Калхузда борчак штие ашарсың, ябыгырга мач булыр», — дип, җыелышны тагын көлдерә.

Җыелыш холостой худка әйләнә башлый. Борып алырга теләп, уполномоченный сүз сорый. Аның әйткәннәре белән килешкән кебек, бөтенесе башларын селеккәләп тыңлап утыралар. Тәмәкечеләр әкренләп тагын чыгып бетә. Уполномоченный: «Булды, колхоз оеша», — дип куана. «Язылабызмы, агайлар?» — дип кулына кәгазь ала башлый. Чырайлар кинәт житдиләнә, әлеге ике йөз дә житмеш әллә ничә кеше барысы берьюлы авызына су каба. Шомлы тынлык урнаша. Бөтен җыелыш сагаеп тора башлый... Хәлим гүя җыелыш каршында басып тормый, ә сикерергә уңай момент сайлаучы ерткыч җанвар каршында басып тора... Күзгә-күз болай карашып тору озакка барырмы? Кинәт... бер агай башындагы бүреген идәнгә күтәреп бәрә дә:

— Яз мине! — дип кычкыра. — Гыйльмуллинов Мөхәммәдиша!

— Мине дә! Мөбаракҗан Шәйдуллин!

— Бүлнискә ат бирерлек булсалар, мине дә язып куй! (Бусы Гали агай тавышы).

Хәлим иркенрәк сулап җибәрә. Исемлек яза башлый. Кич бушка үзмады. Стенаның бер кыные ишелде.

Кышкы төн эчендә җем-җем итеп күренеп калган, еракта бик серле тоелган авыл утларына карый-карый, чана табаны шыгырдаганны тыңлый-тыңлый, Хәлим төн буе барды. Усал прокурор һич күңеленнән китмәде. Күз карашлары гына да кешене куркуга сала бит. Каян килә безгә шундый кешеләр?..

Иртә белән Хәлим үзе туган Идел-Тамак волостена барып житте. Ашханәгә кереп чыкканнан соң, райбашкармага барды. Волком секретаре, яшь чырайлы матур кеше, «Мин әле монда яңа себерке», диде. Иске секретарьны, бик каты «бөккән» өчен, Ногманов әйтмешли, «корбан тәкәсе» итеп чалганнар икән.

Яңа секретарь обком вәкилен, «бөгелешләр» вакытында ябылган кешеләрне күрсәтергә дип, төрмәгә алып китте. Төрмә дигәннәре чаңнары бәреп төшерелгән таш чиркәү булып чыкты.

Сакчыга документларын күрсәтеп, гыйбадәтчеләр аягы шомартып бетергән чиркәү бусагасын атладылар. Сакал-мыек баскан караңгы чырайлы кешеләр саламга түшәлеп ятканнар иде. Ят кешеләрне күргәч, байтагы аягүрә басты. Маңгай асларыннан сагаеп карап тора башладылар.

Житкән чәчләренә чал йөгергән йомры тәнле бер агай Хәлимгә кадалып карап тора иде. Хәлим дә аңа күзләрен терәп тора башлады.

— Гафият абзый! — дип, агайны танып алып, Хәлим тегенең каршысына таба китте. Гафият тә егеткә таба кузгалды.

— Исәнме, наным, — диде ул Хәлимгә ике кулын сузып. — Танымый торам! Әле кайчан гына малай идең, хәзер кап-кара мыекларың бар. Мена, наным, Миңнулла абзаң, сукыр тәре, күк терәве, мине кулак ясап өтермәгә яптырды.

— Колхозга каршы китмәгәнсең ич?

— Ходам сакласын, наным. Колхозга каршы бараммы соң, ю-ук!.. — диде Гафият күзләрен идәнгә терәп.

Хәлим волком секретарена нидер әйтте дә Гафияткә таба күрсәтте. Секретарь иңбашларын кысты: ягъни синең полномочиеларың зур, телисең икән, чыгар...

Болай ансат кына чыгып китәрмен дип уйламаган Гафият, «кайтып кит» дигәч, аптырап калды. Салам өстендәге капчыгын бер ала, бер кире куя башлады.

— Рәхмәт инде, наным, — дип, ниһаять, капчыгын жилкәсенә алып салды да, күзләреннән тәгәрәп килеп чыккан яшь тамчыларын бияләе белән сөртә-сөртә, тизрәк ишеккә таба ашыкты.

Бүтән тоткыннар да кузгалдылар. Янәсе, безне кайчан чыгарасыз? Секретарь белән вәкилне урап алдылар. Болар икәү маңгайга-маңгай басып киңәшергә тотынды.

— Хәзер барыгызны да исполкомга алып барырлар, — диде секретарь өмет белән өметсезлек арасында аптырашып көтеп торучы сакаллы агайларга, — гаепсезләр бүген үк кайтып китәр. — Аннары ишек төбендәге милиционерга кулы белән ишарә ясады: ягъни, бу кешеләрне исполкомга алып килерсез.

Хәлим, волисполкомнан жигүле ат сорап алып, Тауларга кайтырга чыкты. Гафият абзагыз да аның белән кайта иде. Ул кашларын салындырып, әвене янган кеше шикелле, кара көеп утыра. Вакыт-вакыт хәтта ыңгырашып куйгалый иде.

— Нәрсә син, — диде аңа Хәлим, — төрмәдән чыкканга куанмыйсың, ахры?

Гафият кыймылдап, хәрәкәтләнеп куйды.

— Куанырга, — диде ул, Хәлимгә карап алып, — менә син мине өтермәдән коткардың, ә сине чакырып кунак итәргә минем өем юк, хатын, бала-чагам кеше мунчасында тора, терлек-туарларымны бүлешеп бетерделәр... Сакал кырырга бритвам да калмады, кайсыдыр алып чыгып китте.

Тигез жиргә чыккач, Хәлим атны кызулап жибәрде.

— Бер Миңнулла абзый эше генә түгелдер инде? Авылның карары бардыр?

— Миңнулла, озын пәри, йөрде. Син нип кулагы, сәвит кулагы, ди. Шайтан таягы кебек котырып үсеп киткәнче тамырыннан ук йолкып атыйк, ди. Йолкып аттылар...

— Гафият абзый, — диде Хәлим. — Теге вакытта кайтканда мин сиздем: синең чамаң бик ямап баерга иде. Дөрес сизгәнмен ме?

— Дөресме дип... Сәвит үзе әйтеп торды ич... Абрассауный дисезме әле теге? Әнә шундый итәргә азапландым бит инде мин хуҗалыгымны. Вулыстан килеп-килеп карадылар. Гәҗитләрдә мактап яздылар. Укымадыңмыни? Казан гәҗитләрендә басылып чыкты. Байларны сыйныф ясый башлагач, Миңнулла, сукыр тәре, килде дә: «Син кулак», диде. Тотып өтермәгә яптырды. Син баерга тырышты дисең... Ә соң рәвәлүтсәне без ни өчен ясадык? Кәрәстиян гомер-гомергә ярлы-фәкыйрь яшәсен өченмени?

— Син кулак ягына бик каты каера башлаган идең, мин күрдем бит...

— Алайса илтеп яп мине кире, — дип, Гафият абзагыз кинәт кенә үпкәләргә тотынды. — Нигә алайса мине чыгарттың?

«Чынлап та, — дип шиккә төште Хәлим, — ябылудан чыгартуым белән авыл каршында уңайсыз хәлгә калмыйм тагы...»

Гафият бик озак вакыт сөйләшми кара көеп утырды. Инде авылга кайтып җиттек дигәндә генә (җил тегермәннәре әнә якын гына!) Гафиятнең теле ачылды:

— Наным, минем йорт-җирләремне кайтарырлар микән?

Хәлим, закон буенча кайтарырга тиешләр, диде.

— Менә авыл җыелышында куярбыз. Тагын кемнәрне сөрделәр? Малик киттеме?

— Беренче көнне үк...

— Теге вакытта судка эләккән иде бит ул, ялган кәгазьләр белән урман кистереп.

— Аннан бирле инде... — диде Гафият. — Утырып чыкты ул күпмедер...

Тегермән тавыннан төшә башладылар. Авылга кайтып кергән вакытта гел була торган моңсулык тойгысы Хәлимнең күңелен тагын буып алды. Малай чаклары, тегермәнгә этисе белән он тарттырырга менүләре, мәрхүмә әнисе... Истәлекләр күңелне ниндидер рәхәт тырнау белән тырный иде.

Казаннан «палнамучный» килгән дигәч, «палнамучныйның» түбән оч Галиулла малае Хәлим булуын да ишеткәч, Маликтан калган йортның бусагасында халык өзелеп тормады. Килеп керәләр дә, Хәлимне күргәнгә гаҗәп куангандай булып, ерактан ук кулларын сузып килеп күрешәләр. Аннары артка чигенеп, егетнең түшәмгә тия язган буена, матур кара мыекларына гаҗәпләнеп карап торган булалар. «Ни ара шулай үсеп җиттең әле син? Иелеп кермәсәң, башың ишеккә бәрелә торгандыр», дип җибәрәләр. Ничә тапкыр авылга кайтып, бер тапкыр Хәлим дип сүз катмаган кешеләргә хәтле бүген бик шатланган булып сөйләшә башлыйлар иде. Янәсе, кайтып бик яхшы иткәнсең, наным. Менә безне монда, калхуз итәбез дип, тамырларыбыз белән куптардылар да, хәзер инде кай якка аварга да белмичә, иләс-миләсләнеп йөрибез. Берәү килә дә, колхоз яхшы, ди, икенчесе килә дә, колхоз начар, кермәгез, ди. Башларыбыз аптырашта... Беркөннәрне авыл аркылы икс хәерче узды, калхузга кергән иек, менә шушы көнгә калдык дип ипи сорашып йөриләр... Кемгә дә ышанырга белмәгән инде... Менә син авылдаш кеше, бер куас чиләгендә әчегән камыр, бездән яшермә, дөресен әйт: бу колхоз дигәннәренә керсәк, алданмабызмы? Хәлим җавап бирергә, дип авызын ачып өлгерми, арага икенче агай килеп кысыла: таптың, янәсе, сорар кеше, авылдаш дигәч тә ул ич үз ихтыярындагы кеше түгел, палнамучный ич ул, калхузны мактар өчен килгән,

шуның өчен зур акча бирәләр ич аңа. Шулаймы, авылдаш? — ди ул Хәлимгә таба әйләнеп һәм елмаеп. — Өстенә ук китереп бастыммы, ә?

Хәлим дә елмая-елмая тыңлый. Барлык авыллардагы кебек, монда да бетмәс сорау, хафалану, шомлану... Берсе әйтә: иписез ук калмабыз микән? — ди, — хөкүмәт икмәкне бик ярата, басудан ук җыеп алып китеп бетермәсме? — ди. Бүтәннәр дә аның сүзен куәтлиләр.

Икенче бер чуар йөрәклесе Хәлимгә якынрак килеп идәнгә чүгәли дә күңелдәге шиген чыгарып сала: әйтик, менә мин эшлим, тырышам, ә бүтән берәүнең эшлисе килми, нишләтәбез ул кешене? Тыңлап утыручылардан бер җилбәзәге, бу сүзләрдән соң кинәт сикереп торып, кулындагы бияләйләрен бер почмакка ыргыта да: «Төрдер әле берне, йөрәк янганчы тәмәке янсын!» дип кемнеңдер тәмәке янчыгына сузыла. Янчык хуҗасы:

— Ә син калхузмы — юкмы? — дип сорый. Теге колхоз түгел икән, исемлектән үзен сыздырткан, симәнәсен кире сорап йөри.

— Юк инде, — диләр аңа,— калхуз булмагач безнең тәмәкене тартма! — Янчыкны бирмиләр, бөтереп бәйләп кире кесәгә салып куялар. Агай идәндәге бияләйләрен алып кия дә:

— Калхузныкын мин үзем дә тартмыйм, кирәге юк! — дигән була, стена буена барып чүгәли, үз ише колхоздан кыяклаганнар аңа төрдерәләр.

— Ә минем ат үземнән башка берәүне дә тыңламый, — дип тотына бер йомры башлысы. Янәсе, калхуз аның атыннан барыбер хәер күрә алмас, үз сараемда гына торсын... Аның сүзләреннән көлешәләр.

Колхозга бер кереп, бер чыгып йөрүчеләрне симәнә мәсьәләсе бик борчый икән. Аларның симәнәләре әле һаман колхоз амбарында ята бит.

— Өләшер вакыт җитте инде, март узып бара,— дип обком вәкиленә бәйләнәләр.

Хәлим авыл җыелышына сылтый: менә бүген кичен җыелабыз, шунда җәмәгатьтән сорарсыз.

— Җәмәгатьтән сорарга минем үз симәнәм ич ул! Менә син үз әйберенне алганда кешедән рөхсәт сорыйсыңмы?

— Соң бит син, җанкисәгем, колхозга керәм дип, симәнәңне амбарга үзең китереп салгансың, хәзер аны җәмәгатьтән сорамый кемнән сорарга, синеңчә?

— Якаңнан алгач, син дә китереп салырсың, салмый кара пупрубый...

Хәлим бик аңлый: агайның орлыгын кайтарып бирергә кирәк, бирдең, шундук бүтәннәр капчыкларын тотып килеп җитәчәк. Ярты амбарны ташып бетерәчәкләр...

Агай тәмам каныкты: бирегез дә бирегез. Юкса амбар ишеген каерып ачып, ул үзе алачак! Ахырда тәмам ярсып, әллә ниләр белән янап чыгып китте.

Шундый вакытта да үсен-көлкесез яши алмаучылар авыз ерырга җай китереп чыгаралар: янәсе, менә мин ишеттем, атларның койрыкларын кисеп сдавайт итеп бетергәч, хатыннарның толымнарын кисәчәкләр икән, калхузга кергән хатынны ел саен кыркып торачаклар икән дип сөйлиләр, дөрескә чыгар микән шул?

— Тапкансың ис китәрлек әйбер, — дип эләп ала мәзәкчеләрнең икенче берсе. — Чәче булса ни дә булмаса ни, чәчтә түгел хикмәт хатыннарның, ә менә миңа базарда сөйләделәр, кытайлар кузгалган имеш, сары тараканнар кебек бөтен Себерне басканнар ди, Уралга килеп җитеп, тоз чыга торган Суликамски дигән җирне алганнар ди дә әйтәләр ди: калхузны туктатмасагыз, тоз бирмибез дип әйтәләр ди. Тозсыз бәрәңгене ничек ашарбыз?

— Тозсыз ашаган кеше көндез йолдыз күрә дип әйтәләр, без дә көндез йолдызга карап утырырбыз, — дип көлешәләр бүтәннәре.

Мәзәкчеләр Бер ярым Миңнулланың кергәнен сизмирәк калдылар, Миңнулла абзагыз боларның авыз ыржайтып көлешеп, колхозны мыскыл итеп утыруларын ишетеп өлгерде.

— Иптәш палнамученный, — диде ул Хәлимгә, чынлапмы-уйнапмы әйткәнен картның кәҗә битедәй очлы битенә карап аңлап булмый иде. — Син нәрсә үз күз алдында калхузга каршы сүзләр сөйләтеп утырасың, шуларның авызларына әйбәтләп сукмыйсың, ә? — Һәм озын сыйраклары белән түргә таба узды.

Хәлим аны бу кайтуда элеккедән шактый картая төшкән итеп тапты: чәчләре агарган, бөкресе чыккан, тик шулай да үзе яшьләрчә шаярып сөйләшүен һаман ташламаган икән әле.

— Сиңа миннән вапрус, — дип тотынды ул Хәлим каршына килеп,— минем кулдагы инструкцида язылмаган, синекендә ничек, бу бабачыларны раскулачларгамы икән, юкмы икән? Ни трудовой алиминт бит?

— Безнең авылда бабачылар бармыни? — диде Хәлим көлеп.

— Әле син белмисеңмени? Гапсаттар абзаң иске чалгысыннан пәке ясатып алып бабачылык кәсебенә кереште бит. Бик дахутный кәсеп, ди. Гапсаттар, дахутный диден бит? — Миңнулла почмакта тәмәке пыскытып утыручы Гапсаттарга карады.

— Аны раскулачласак, безнең малайларыбызны кем сөннәткә утыртыр? — дип тотындылар мәзәкчеләр. — Юк, аны раскулачларга ярамый. Түлке менә әйтми бит әле ул: кисеп алганын кая итә икән? Ит загатуфкасына җибәрәме әллә, каһәр?

Барысы да көлешә башладылар. Гапсаттар үзе дә басып кигән мескен бүреге астыннан күзләрен елтыратып көлеп утыра иде.

Миңнулла килеп Хәлимнең җиңеннән тартты: синдә йомыш бар, чыгып керик әле!

Алар ишек алдына чыгып, бүрәнәгә утырдылар. Хәлим агач башындагы кара каргаларга, колгадагы сыерчыкларга карады. Каргалар иске ояларын сипли башлаганнар. Сыерчыклар тузынышып сайрыйлар.

Миңнулла абзагыз амбардагы чәчүлекне бүлешүдән халыкны көчхәл белән генә тыеп тора икән. Колхоздан чыккан кешеләр, бүлешәбез, давай амбар ачкычларын дип, Миңнулланың әллә ничә тапкыр якасына ябышканнар. Миңнулла амбарларга мылтыклы сакчылар куйдырткан, үзе дә, төнен әллә ничә чыгып, амбар төбендә утырып кергә икән. Җыелышта симәнә чутыннан талаш-тартыш бик яман булачак, палнамученный «паникка» бирелмәсен дип әйтергә чакырып чыгарган икән.

— Никакуй бүлешү юк, ишеттеңме? — дип Миңнулла бабагыз Хәлимне кисәтеп куйды.

— Кара әле, Миңнулла абзый, — диде Хәлим, — ничек соң сез бу хәтле каты боргычлап ташлыйсы иттегез? Гафият агайга хәтле кулак ясагансыз!

— Баеды ул, энем. Нип чүпрәсендә кабарды. Кулак!

— Юк ла! Бик тырышса да кулак була алмады. Бөгештергәнсез.

Миңнулла абзагыз бармагы белән колак артын кашып куйды.

— Килгән палнамученный безнең башны әйләндереп ташлады: бөтенесен наскруч кумәклә, наскруч сыйныф ит тә бетер, ди. Без тырыштык.

— Гафиятнең таланган малын кайтарып бирегез.

— Ансат кына — бирегез. Бөтен авылга таралган ич ул, ничек җыйыйм мин аны хәзер...

— Ничек тараттың, шулай җыярсың.

Миңнулла, үпкәләп, ишек алдыннан кереп китте. Хәлим бүрәнә өстендә утырып калды. Ул Маликның тузган оясын бер тапкыр күздән

кичерде. Кайчандыр бу ишек алдына авыл кешеләре башларын түбән иеп курка-курка гына керәләр иде. Хәлимнең исендә: урак урган өчен Биктаһир карттан акча сорарга килгәч, Маликның атасы Биктаһир, саңгыраулыкка салышып, акчаны бирми азапланган иде. Ә хәзер Маликның ишек алдына теләсә кем килеп керә, йортында тәмәке тартып утыра...

Сыерчыклар үткән елгы ояларын чүп-чардан тазарталар иде. Хәлим, малай чакларын искә төшереп, карап утырды. Хәтерендә, тактадан оя корыштырып кыекка меңгезеп элгәч, оялата алмыйча аптырап беткән иде. Килеп карап-карап йөриләр, яратмый китеп баралар... Һәр көнне иртүк йөгереп чыгып өй кыегына карый иде. Бер көнне шулай эреп бетмәгән кар өстенә ялан тәпи генә йөгереп чыкса, куанычыннан ут капкандай кычкырып җибәрде: «Әни, оялаганнар!»

Аяклары туңганга тыпыр-тыпыр килеп, оя башындагы сыерчыкка бик озак сокланып карап торган иде. Шул чакларны хәтерләп, бүрәнәдә кояшта утырган Хәлим сыерчыклар оядан чыгарып ташлаган ниндидер ялтыравыклы нәрсәне кулына алып карады да исе китте. Алтын тәңкә! Оя эленгән тал төбенә йөгереп барды. Караса, монда да алтын тәңкәләр... Хәлим шундук агач башына тырмашып менеп китте. Сыерчыклар куркышып күрше агачка кундылар да сәерсенеп карап тора башладылар. Хәлим ояны агачтан чишәргә тотынды. Аска ташламакчы иде дә, аннары ташламаска, кулына тотып төшәргә булды. Сыңар кулы белән ябыша-ябыша әкрен генә төште, итеге белән тибеп ояны ватты.

— Хәлим абый! — дип кычкырган тавышка күтәрелеп караса, бер малай кычкыра иде. — Хәлим абый, кер тизрәк, Гафият абзый белән Миңнулла бабай сугышалар!

Хәлим ватык ояны тоткан килеш өйгә йөгереп керде. Бөтен халык аяк өс калыккан. Сугышучыларны аерып өлгергәннәр. Миңнулла, эт каршындагы мәче кебек, сыртын кабартып бер читкә баскан, ертылган изүләрен төзәтеп маташа, ә Гафиятнең ике кулыннан ике кеше тотып тора, битләре тырналган, күзләре акайган.

— Минем гомер буе җыелган малымны кайтарыгыз! — дип, күзләре ояларыннан чыгарга житкән Гафият кешеләрнең кулыннан ычкынмак була, Миңнуллага ташланмак була.

Ә Миңнулла читтән генә Гафиятне үчекләп тора иде:

— Налог түлисең бар идеме? Бар иде. Капиратифка пай кертәсең? Бар иде. Тракторга аванс? Бар иде. Шунда керде дә бетте синең мал. Юкны сорап йөрмә!

— Ә минем сакал пәкем кемдә? Сакал пәкемне табып бирегез... — дип кычкырды Гафият.

Кешеләр бер-беренә карашып елмаештылар. Кемдер берәү шаярмыйчыдый алмады.

— Гапсаттар, үткен пәкегә син бик мохтаҗ, синдә түгелме Гафият абзыйның сакал пәкесе?

Хәлим, бөтен җыелган халыкны гаҗәпкә калдырып, бүрегендәге алтын, көмеш тәңкәләрне өстәлгә чыгарып салды. Бөтен кеше өстәл кырыена килеп өелде. Барысының исләре китте.

— Сыерчык оясында дисеңме? Ай, Малик!..

— Тотып карарга ярыйдыр бит? — дип, берьюлы берничә кул тәңкәләргә сузылды.

— Тотып карарга ярый, кесәгә салырга ярамый...

— Үзем тапкан булсам, их! — дигән булды берсе. — Байыйм икән...

Гафият абзагыз да, пәке кайгысын онытып, алтын тәнкәләрне карарга килде.

— Әй, әй, Гафият! — диде аңа Миңнулла. — Учыңа йомарладың түгелме бер алтын тәңкәне!

Тәңкәләрне жыеп алдылар да, санап, акт яздылар. Алтын табылу хәбәре сәгате-минуты белән бөтен авылга җәелде. «Кая куярлар ул хәтле алтынны?» дип, кайберәүләр хәсрәткә төште. «Пошаман булма, — диделәр икенчеләре, — табарлар кая куярга, сиңа китереп бирмәсләр...»

...Ә кич белән Хәлим җыелышка барырга чыкты. Ябалак-ябалак җепшек кар егетнең битләренә ябышып эри иде. «Сталин хатын аңлатырмын, льготалар турында сөйләрмен, кредит турында...» дип, ул күңеленнән хәзерләнеп бара иде.

Казан асларында янган утларның шәүләсе урамга төшкән, өй турыларында кар кып-кызыл... Күктән кызыл кар ява... Хәлимнең шунда исенә килде: әтисе ничектер аның соравына җавап итеп әйткән иде: «Кызыл кар яугач булса булыр инде, улым, безгә бәхет!» Шул сүзләрдән хәзер көлемсерәп куйды. Ил бәхете белән бергә йөри икән кешенең бәхете. Әтисе белмәгән.

Хәлим кызу-кызу атлый. Тәрәзәләр турысында һаман кызыл кар ява. «Бәхет кары...» дип елмая Хәлим.

## 23

Хәлим Казанга беренче пароход белән кайтып төште. Авылдан соң шәһәр йортлары бик зур, урамнары бик киң булып тоелды. Ул юкта институтта нинди үзгәрешләр булып бетте икән инде? Бераз китеп торсаң, син юкта әллә ниләр булгандыр кебек тоела бит. Егетнең күңеле, нидер сизенгән кебек, ашкына, очына иде. Хәлим моны бүген кич Галимә белән булачак очрашу шатлыгына юрап кайта. Трамвайдан төште дә җилкенә-җилкенә урам буйлап китте. Каршы очраган ят кешеләргә елмая, тегеләр сәерсенеп шулай ук елмаеп калалар иде. Гомуми торак баскычыннан менгәндә, каршы очраучыларга сәлам бирә-бирә, йөгерә-йөгерә менде. Гомер булмаган хәл, ишектән килеп керүгә, Броневикның муенына ук ташланды:

— Нихәл, әти! Мин юкта сугышып бетмәдегезме?

Ак күмәч белән чәй эчәргә утыргач, Броневик ялгыш кына ычкындыргандай әйтеп куйды:

— Кафия турында син бернәрсә дә ишетмәдеңме?

— Юк. Нәрсә булган? Әллә Черновка кияүгә чыктымы?

Броневик, кружкасын этәреп куеп, караватына китеп утырды. Нигәдер бик озак дәшмәде. Хәлим түземсезләнеп:

— Нәрсә булган Кафиягә? — дип кабатлап сорады.

— Начар хәбәр... авылда...

— Үтергәннәр!? Кем әйтә?

Броневик Ак-Чернов караватына ишарәләде. Чернов ишетеп кайткан. Хәлим янына килгән Кафияне озатып куя-куя, Чернов ул кыз белән якынаерга өлгергән иде. Хәлим аларны әллә ничә тапкыр урамда да бергә күрде. Кафияне үтергәннәр...Булмас. Ул бит бу юлы авылга бармаган иде.

Кайткач Чернов та кайгылы хәбәрне раслады. Хәлимнәрдән соң тагын бер төркем «турайтучылар»ны Актаныш, Минзәлә якларына җибәргән булганнар. Кафия шулар белән Актаныш ягына киткән.

— Нинди бәлагә юлыккан соң ул, сөйлә тизрәк! — дип, егет Черновка ябышты. Ләкин Чернов үзе дә рәтләп белми икән әле.

Хәлим юл отчетын язды да тизрәк обкомга, Хәйри янына чапты. Бусагадан ук Кафия турында сорау бирде. Телеграмма бар икән. Бер Кафия генә түгел, бүтәннәр дә хәрап булганнар. ГПУ комиссиясе тикшерергә киткән. Шуннан артык Хәйри дә берни әйтә алмады. Менә комиссия кайткач инде мәгълүм булыр...

...Хәлим миңгерәгән кеше кебек обком коридорында басып тора. Һич уйламаганда... Әле кайчан гына урамда күргән иде... Гыйшыклары сүнгән булса да, дуслык бетмәгән иде... Тавык күзле килеш спектакль уйнап йөргән чаклары исенә төште... Мәчет каршында беренче тапкыр үбешү... Хәлимнең күңелендә ике Кафия бар: берсе детдом малае белән бер партада утырырга теләмичә күчеп утырган, ә соңыннан Хәлимне үзе үк кочаклап үпкән Кафия... Икенчесе инде Казанга килгәч, озын чәчле футуристларга ияреп йөргән, мәче тычкан белән уйнаган кебек, Хәлим белән уйнаган Кафия... Икесе дә хәзерниләре беләндер күңелгә бик якын... Үлгәнгә күрә, бәлки, шулай якындыр...

Кафия анысы кыланып йөрүнең кимен куймады... Бер тапкыр футуристлар белән хәтта милициягә барып эләкте... Шәһәр газетасының «происшествие» бүлегендә яздылар. Муеннарына кашыклар тагып, трусиктан гына трамвайга барып кергәннәр... Бу күптән инде, моннан берничә еллар элек... Бөтен Казан шаулады. «Долой стыд» оешмасы төзегән булганнармы шунда... Шулай дип яздылар. Соңыннан Кафиядән сорап карагач, Кафия көлә-көлә Хәлимгә сөйләде: һичбер төрле «Долой стыд» оешмасы юк иде, газеталар уйлап чыгарган оешма ул, диде. Чыннан да, озын чәчле берничә җилкуар юләр сатып йөргән икән, аның кай төше оешма булсын... Бездә юк җирдә дә оешма табарга яраталар инде.

Обкомнан урамга чыккач, Хәлимнең башына: «Бәлки әле исәндер, менә кайтыр да төшәр...» дигән кызык уй килде. Һәм күңеле тынычланып киткән кебек булды...

ГПУ комиссиясенең авылдан кайтуын түземсезлек белән көттеләр. Хәлим көн саен диярлек Хәйригә шалтыратып торды.

Менә бер көн Хәлимгә:

— Обкомга кил, комиссия кайтты, — дип, Хәйри үзе шалтыратып хәбәр итте. Егет, дәресләрен ташлап, шундук обкомга йөгерде. Шул барудан ул кич белән генә кайтып керде. Беркемгә бер сүз дәшмичә караватына барып утырды. Кафия юк инде... Тикшерү әле бетмәгән, тик шулай да Кафия юк инде... Ничек үлүе турында шаһитлар төрлечә сөйли... Төн уртасында симәнә амбарына ут капкан, болар чабышып килгәннәр... Берәүләр әйтә, яна торган симәнәне бушатырга дип амбарга кергәч, өсләренә утлы бүрәнә ишелде, ди... Икенчеләре, аларны утка тотып аттылар, үзебез күрдек, диләр. Комиссия әле тәмам эзенә төшмәгән, ни генә булса да Кафия инде терелеп кайтмаячак... Аларның кара көйгән гәүдәләрен күргән кешеләр бар...

Хәлим шушы фаҗигале хәбәрне иптәшләренә кайтып сөйләде дә Мәскәүгә, Анатолийга хат язарга утырды.

Өч ел узды. Хәлим укуын бетереп Казанда эшкә калды. Хәйри обкомнан китте. Техникумда директор. Өйләнде. Балалары бар. Быел җәйли Мәскәүдән Натолька кайтып китте. Авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә художник оформитель булып эшли. Өсте-башы бөтенләй мәскәүчә... Кыяфәт тә үзгәргән, базда үскән чырайсыз бәрәңге сабагы түгел инде хәзер Натолька... Исеме дә Анатолий Богданович... Матур мыегы бар... Хәлимнең җыйнаксыз квартирасын күздән кичерде дә:

— Я, күрсәт үзеңнең красавицаңны, бик матур кызга өйләнәм дип язган идең бит. Әллә аерылышырга да өлгердеңме? — диде, чөнки Хәлимнең бүлмәсендә чынлап та хатын-кыз кулы сизелми иде. Караваг рәтләп җыелмаган, китаплар таралып ята...

Хәлим, елмаюын мыек астына яшергән килеш кәгазьләр арасыннан ниндидер бер фотокарточка чыгарып, аны Натолькага тоттырды. Карточканы күрүгә Анатолийның битендә елмаю балкый башлады.

— Ах, чибәр! — дип кычкырып ук җибәрде ул, фотодагы матур кыз-

дан күзләрен ала алмыйча. — Тукта әле, ник син миңа фотосын гына күрсәтәсең? Оригиналын давай!

Хәлимнең серле елмаюын сизеп, Анатолий көләргә тотынды.

— Син нәрсә, мине шаяртасыңмы? Күрсәт, давай!

— Әйдә, күрсәтәм, — дип, Хәлим өстәлдә аунаган кепкасын алып киде дә ишеккә юнәлде.

— Бергә тормыйсызмыни?

— Торабыз.

— Һични аңламыйм, — Анатолий, иңбашларын җыерып, Хәлим артыннан иярде.

Алар урамга чыктылар. Хәлимнең иреннәрендәге серле елмаю бер бетә, бер тагын кабына иде.

— Бүләк алырга кирәк,— дип, ул магазинга борылды.

— Син алгач, мин ник алмыйм, — дип, Анатолий да аның артыннан магазинга кереп китте. Бераздан, кулларына ак төргәкләр тотып, икесе дә килеп чыктылар да көлешә-көлешә урамдагы агач күләгәләреннән бара башладылар.

...Ике катлы кызыл кирпеч йортның өске катындагы ачык тәрәзәләрдә яшь кенә хатыннарның елмаюлы ак битләре күренә, аста бакчада торучы ирләр алар белән кычкырып сөйләшәләр иде. Хәлим белән Анатолий да бер ачык тәрәзә каршына килеп туктадылар. Хәлим тәрәзәдәге ак чырайлы хатынга, телсезләр сөйләшкәндәге кебек итеп, бармакларын тегеләй-болай китереп, нидер аңлатты да Анатолийның кабыргасына төртте. Менә бер вакыт тәрәзәдә Галимә күренде. Ул бик ак һәм бер дә матур түгел иде. Аннары кинәт елмайды да бик матураеп китте. Аның кыз вакытындагы матурлыгы хәзер әни булу матурлыгы, талгын һәм сабыр матурлык белән алмашынган иде. Хәлим аны тәрәзәдә күргә бөтенләй балкып китеп, «кочам үзеңне!»не аңлатырга тырышып, янындагы озын Анатолийны кысып кочаклап күрсәтте.

— Минем балалар йортындагы дустым, сөйләгән идеМ бит, — дип кычкырды ул тәрәзәдә елмаеп басып торган Галимәгә. Анатолий да бөтенләй таралып, балкып, югары карап тора иде. Хәлим тагын бармакларын тегеләй-болай китерде, кулын сузып, учын селекте.

— Күрсәт бәбине, күрсәт! — дип кычкырды.

Тәрәзәдән башын сузган Галимә көлеп җибәрде, нидер әйтте. Болар аңламый калдылар.

— Нәрсә? Нәрсә? — дип кабатлап сорадылар.

Галимә, көлеп, кулларын җәйде, эчкә таба төртеп күрсәтте. Хәлим, аның ишарәләрен төшенеп, Натолькага: «Янымда түгел» дип әйтә, диде. Аннары төргәкләрен баш очына күтәреп, Галимәгә нидер ымлады. Менә бер вакыт тәрәзәдән ак бау төшә башлады. Анатолий бу күренештән рәхәтләнеп көлергә тотынды. Җиргә төшеп җитә язган бауның очына ак төргәкләрне ничек кирәк алай бәйләделәр дә югарыга кул изәделәр. Галимә көлә-көлә ак бауны югарыга тартты.

...Кайтып барганда Анатолий тагын рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Өйләнәм! Мин дә өйләнәм! Синеке кебек матур хатын алам!

— Табарсың микән минеке кебекне... — дип көлде Хәлим. — Мин аны бер инженер кулыннан тартып алдым. Әнкәсе аны инде саткан иде.

Анатолий Хәлимдә берне генә кунды да икенче көнне, пароходка утырып, үзенең туган шәһәренә кайтып китте.

## 24

Хикәя шунда бетә. Миңа эш белән Актаныш якларына барырга туры килде. Пароходтан төшкәч, ат ялладым. (Ул заманда машиналар бик сирәк иде әле). Үрне менеп җитеп, тигез кырга чыккач, агай атын

кызуларга тотынды. Көн бик эссе, юл бик тузанлы, атның чабасы килми иде.

— Бара бирсен үз көенә генә, — дидем мин агайга.

Агай дилбегәсен тез астына кыстырды да тәмәке төрә башлады. Мин аңа папирос чыгарып бирдем. Үзем дә каптым. Без тарта-тарта сөйләшергә керештек.

Як-ягыбыздагы арыш басуында яшел дулкыннар чабышалар иде. Мин гадәттә авыл кешесенә бирә торган сораулар бирә башладым: янәсе, быел игеннәр ничегрәк күренә? Һәм башка шуныңише сораулар.

Шулай аны-моны сөйләшеп кайтканда, алда бер зур авыл күренде. Бу әле мин туктыйсы авыл түгел иде. Ындыр артыннан узган чакта, мин түгәрәк бер чирәмлектәге ак кабер ташына игътибар иттем. Агай әйтә, бу кабергә күмәкләшү вакытында кулаклар үтергән кешеләр күмелгән, ди. Мин кызыксынып төпченә башладым. Сораша торгач, шул ачыкланды: колхоз оештырырга килгән уполномоченныйларны кулаклар тотканнар да дөрләп янып торган утка ыргытканнар. Араларында бер хатын-кыз да булган. Хатын-кыз дип тормаганнар, аны да утка ташлаганнар. Ул заманны беләсез, уполномоченныйларны балта белән чабып та, мунча кергәндә мунчага бикләп яндырып та үтерделәр...

Агайдан шушыны ишеткәч, кылт итеп үзем белән бергә эшләүче Хәлим Галиуллин сөйләгән фаҗигале вакыйга исемә килеп төште. Аның яраткан кызын шушы Актаныш якларында кулаклар утка ташлап яндырган булганнар. Шул хәтеремә килгәч, мин каберне карап китәсе иттем.

Тарантастан төштек. Кабер ягына барабыз. Агай сөйли: моннан икеөч ел алда Казаннан бер кеше килеп, каберне карап-тикшереп китте, ди. Аның килүен авылда үзенә бер әкият итеп сөйлиләр икән. Имеш, башта юл өстендә кап-кара тузан болыты күренгән. Кешеләр бу нинди пәри туе дип торсалар, кара өермә эченнән тарантаска җигелгән пар ат килеп чыккан, шундый чабалар ди, атларның бот араларыннан аппак күбек чәчелеп бара, ди. Баштанаяк юл тузанына күмелгән бер кеше, тарантастан төшми генә, әлеге туганнар каберен сораган. Аннары атларын тагын җан фәрманга куалап, күрсәткән якка чапкан. Карап торучылар соңыннан сөйләгәннәр, тарантастан сикереп төште дә, дип әйтәләр ди, кабер ташы каршына килеп тезләнде, бик озак шулай тезләнеп торганнан соң, яңадан тарантаска утырып, Актаныш юлы белән кушаяклап чаптырып китеп барды, дип әйтәләр ди... Авыл арасына аннары сүз таралды: янәсе, килүче шушы кабергә җирләнгән кызның кайчандыр сөеп йөргән егете булган диме шунда, ачык белмим, хатын-кыз авызында шундыйрак әкият йөрде.

«Галиуллин килеп йөрдеме икәнни?» — дип уйлап алдым мин.

— Егете килгән алайса? — дип кайтарып сорадым, бик кызыксынып.

— Хатын-кыз сүзе генәдер,— диде агай.— Юл чатларындагы каберләр турында андый әкиятләр гел чыгып тора бит. Хатыннар сүзенә ышансаң, имештер, шушы кабер өстендә бер бик матур кызның елап утырганын уракчы хатыннар күреп кайтканнар. «Апаем, нишләп монда елап утырасың?» — дип сораганнар икән дә, теге башын гына күтәреп караган, бер сүз дә җавап кайтармаган. Ә үзенең күзләреннән мөлдерәп-мөлдерәп яшь ага ди, ә чәчләре болыт шикелле таралып төшкән ди. Узып киткәннән соң артларына борылып карасалар, ни күрсеннәр, матур кыздан инде җилләр искән. Аннары безнең авылның избач кыз сөйләгәне бар, Актаныштан кайтып киләм, ди, күз бәйләнер вакытлар, шушы кабер турыннан узганда: «Сеңелем, туктап кит минем янга!» дип, ялынып-ялынып үтенгән тавыш ишеттем, ди. Билгеле инде, куркып тизрәк йөгергән. Кабердән шулай дип эндәшсеннәр әле, син

дә куркырсың. Хәер, белмәссең, мин менә ничә еллар йөрим шушы кабер яныннан, бер тапкыр бер тавыш ишетмәдем, елап утыручы бер кыз күрмәдем, барысы да хатыннарга күренә дә хатыннарга ишетелә...— дип, агай үзе сөйләгән сүзләргә үзе үк ышанмавын сиздереп куйды.

Килеп җиттек тә туктадык. Искереп беткән агач рәшәткә. Такталары, берничә урыннан сынып, җиргә коелып төшкән. Җимерек урыннан атлап, мин эчкә кердем дә, таштагы язуны укымакчы булып, иелеп, кулларым белән теземә таяндым. Кышкы суыклар, көзге яңгырлар үз эшләрен эшләгәннәр, язу укып булмас хәлгә килгән. Шулай да тырыша торгач, мин гарәп хәрефләре белән ташны чокып язылган «Мең дә тугыз йөз дә утыз беренче сәнәдә... кулаклар тарафыннан вәхшиләрчә...» дигән сүзләрне аера алдым. «Галавет... Саб... дигәнен «Галәветдинов Сабирга» юрадым. Хатын-кыз исеменә охшардай бер исем дә тапмадым. Агай әйтә, хатын-кыз затыннан тәгаен берәү бар, ди, элгрәк, исемнәрен аерып булган чакларда укып караган кешеләр шулай дип әйтәләр икән. Безнең избач кыз аның исемен дә белә иде бугай. Фәкиһәме, Камиләме, онытылган инде...

Мин рәшәткә тирәли әйләнеп чыктым. Инде китәргә дә җыенган идем, күзләрем кабер өстендә үсеп утырган ут чәчәгенә төште. Җил искәндә аның ялкындай чайкалып-чайкалып куюларына бераз карап тордым. Әллә инде үзем дә халык телендә йөргән әкиятләр тәэсиренә бирелеп киттем. Беләсезме башыма нинди фикер килде? Сезгә, әлбәттә, сәер тоелыр. Мин шунда болай дип уйладым: яшьләй һәлак булган бичара кыз, үзенең дошманнарына үч иткәндәй, матур чәчәк булып кабере өстенә чыгып баскан да уттай күзләре белән якты дөньяга сокланып карап тора...

Без юл кырыенда калган тарантасыбызга барып утырдык та китеп бардык.

1965, август.
Аккош күле.

*РЕВОЛЮЦИЯГӘ КАДӘРГЕ МАТБУГАТ БИТЛӘРЕННӘН*

ШӘРИГАТЬЧЕ ПОП

**1909 елны Ташкенттагы татар яшьләре куйган театр уенына «Төркстан газетасы» редакторы миссионер Николай Остроумов та килгән иде. Спектакльнең ике пәрдәсен карагач: «Бу эшегез шәригатькә хилаф (каршы), бу турыда газета аша мөселман җәмәгатенең колагына төшерәчәкмен, дип чыгып китте»,— дип яза «Вакыт» газетасы хәбәрчесе.**

**Күрәсез, яңалыкка каршы көрәштә шәригатьне мулла гына түгел, җае чыкканда поп та яклаган.**

МАНАРА ЭЧЕНДӘ 15 МЕҢ ЧАКРЫМЛЫ СӘЯХӘТ...

**«Оренбургтагы Кәрван-сарай мәчетенең мәзине тоташтан 65 ел үз вазифасын үтәгән. Шуннан 50 ел кадәр хезмәтен калдырмый үтәгән булса, манарага көненә 5 тапкыр, елына 1800, илле елга 90 мең тапкыр менеп төшкән була. Кәрван-сарай манарасы 162 баскыч булып, һәр менгәндә анар 324 тапкыр атларга туры килә, һәр атлаганда азында өч чирек аршын атлыйдыр. Шул исәптән 29 миллион кат атлый, кимендә 22 миллион аршын яки 15 мең чакрым була» дип язганнар «Вакыт» газетасында. Икенче төрле әйтсәк, ул мәзин манара эчендә килеш Казан—Мәскәү арасы чаклы юлны 8 кат әйләнгән була.**

**И. РӘМИ.**

*Салих Баттал*

# ЧИРМЕШӘН ЯКЛАРЫНДА[1]

## Роман

### ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

КЕРЕШ СҮЗ УРЫНЫНДА БЕР ЧИГЕНЕШ

Язып бетермәкче булдым
роман исемә төшеп,
геройларымның югала
язган эзенә төшеп.

Ут тертүчеләргә килик.
Чирмешән күпереннән
бирге якта алар атка
чабата киендергән.

«Ат өстендә судан чыкмый
барганнардыр» дип уйлап,
кугын,
тояк эзен эзләп
Йөргән арама буйлап.

Кем белә, сизептер, бәлки,
ут тертүчеләр кечен,
табар өчен түгел, алар
эзләгән тапмас өчен.

Юкса, белгән килеш хәзер
канатлы атлар югын
«Күккә ашкандыр» дип, ничек
тапмыйча кайтсын кугын!

Бер яктан геройларымнан
аермам минем бик аз:
Чабаталы атта чабам,
кайда ул миңа пегас!

Данга күңел сузу кайда!
Бик канәгатьмен, әгәр
эземне тапмасалар да,—
«Күккә ашкан» дисәләр...

* * *

«Күккә ашу» дигәннән,
мин
Барига күчмәкчемен.
Үлде ул карт.
Бар мирасы —
авызына капкан чолем.

Урыны җәннәттә, мөгаен —
мәчеткә йөрде ул да.
«Тәмәке тартмагыз» дип бер
сөйләде шунда мулла.

— Мин тәмәке тартмыйм! — диде
кайткач та Габделбари, —
чолем, бәгырем, синә сүз юк, —
сине тартсам да ярый!..

Укучым, бәлкем, көтәдер,
мөгаен, автор, диеп, —
шушы карт солдатына да
үзен охшатыр, — диеп,

Әйе!
Балкылдавы сыман
мае беткән лампының,
күптән түгел күргән идек
шушы авыл картының

---

[1] Башы 1965 елның 10 һәм 1966 елның 3 саннарында басылды.

соңгы кабат урамнарны
кыдырып йөргәнен бер.—
Бу җырлар, бәлки, минем дә
соңгы вянәгемдер?!

Бәлки, ул пыскыткан чөлем
һәм мин язган каралар —
йөрәкнең соңгы ярсуын
бастырырга чаралар?!

Җитте, каләм! Оят кирәк,
чигенүләрне кыскарт!
Соңгы финишеңә омтыл —
алдыңда — соңгы старт.

I

Өч ел үтте әле язган
вакыйгалардан алып.
Өч яз үтте, мәхәббәттән
яшьләр йөрәге янып.

Терлекләр өч җәй буена
кырга куаландылар,
бер үк көтүчеләр шуңар
өч кабат ялландылар.

Өчне бозаулады сыер,
үрелде өч муенчак.
Өч килде корбан гаете, —
һәм өч чарланды пычак.

Корбан чалган ул пычаклар
авыл котын алмады.
Тик бер коточкыч пычактан
авыл котылалмады.

Сугыш башланды...
Иң әвәл
китте запастагылар.
Аннан, чираттагы яшьләр
моңая башладылар:

«Әнкәй, мине тапканчы
бер кыз бала тапсаңчы;
солдат итеп озатканчы
таш бәйләп, суга атсаңчы!»

«Безнең башлар югалдылар
ярман сугышларында;
Туган илемне уйлармын
соңгы сулышларымда».—

Никрутлар төркеме шулай
урамда җырлап бара,
тәрәзәләрдә әнкәйләр,
җанкайлар елап кала.

Җилгә җырланмыйлар алар —
туры адреслары бар.
Кем турысыннан узалар —
төртеп җырлыйлар шуңар:

«Турыгыздан җырлап үтсәк,
ачуланма, хәзрәт, — дип,—
күрмәгәнгә күрсәтмәсен,
бигрәк авыр хәсрәт»,— дип.

Хәзрәт өчен юк, әлбәттә,
ачуланырга урын,
ул үзе мөнбәргә менеп
җырлады патша җырын:

— Кем дә кем ошбу сугышта
җан тәслим итә,— диеп,—
урыны оҗмахтадыр. Чөнки
ул шәһит китә,— диеп.

Җырлый китәчәк шәһитләр:
«Кайгылар моңайта,— дип,—
җыр җырлавы тәсбих түгел,
тик күңел юата» — дип.

(Ярый әле, тәсбих түгел,
кыйбатка төшәр иде:
безнең җырлар тәсбих булса
дин мәңге яшәр иде.)

«Аккош очар, күл тынар;
без киткәчтән ил тынар.
Без киткәнгә куанмагыз —
бездән яманнар туар...»

Җырның бусын кем башлады? —
Мәгъзияләр нәселе бу,—
ут төртүченең энесе —
егетләрнең асылы бу.

Абыйсы яткан чагында
урманда качкын булып,
бусы аңарга ризыкны
аулады лачын булып.

Ялынып ул бай Хәмиттән
юкка көтте биргәнен;
алды орлыкны бораулап
астан келәт идәнен.

Ут та төртеп карады ул
йортының бер чатына.
Мунча янды — өй салынды
страхау акчасына.

Моның да энесе үсэ —
«Кода итэм байны,— дип,—
Мэгъзия малае булмыйм,
алмасам Алманы!» — дип.

II

Әйдә, алар үсэ торсын,
Килик Хэмиткэ тагы.
Аның да хуҗалыгының
котырып үскэн чагы.

Ат тегермэне өстенэ
пар тегермэне дэ бар,
машиналар арасында
йон теттергэне дэ бар.

Антон китте армиягэ,
тик эш җимерелмэде,
һаман да халык аңарга
җимерелеп килэ эле.

Антон эшен башкаручы —
асрау хатын — Сара.
Ул — Хэмитнең мөдирэсе —
бар эшен алып бара.

Чыга ул ишек алдына
таң белэн, битен юып
һэм карый караңгылыкны
күз нуры белэн куып.

Калкалар йөк өслэреннэн
кунучы-тэнэүчелэр.
— Минем чират!
— Юк, баштарак
минеке! — диючелэр.

Җыр юк хэзер. Тыныч чорда
беткэн алар җырланып.
Онлы сакаллар укмаша
тир белэн камырланып.

Сара шулар арасында
көнне үткэрэ менэ.
Лыкылдарга вакыты юк —
ым да ишарэ генэ.

Хэзерге заманда булса
аның башкарган эше,
әртил кирэк булыр иде,—
штатында — йөз кеше.

Хэмит үзе ач бүредэй
Идел буенда ауда:
бер феодал куй көтүе
куып китергэн анда.

Ялварып сата Хэмиткэ
шуны: «Зинһар өчен ал!»
һэм алды Хэмит: Кирэк бит
Алафузовка чимал!

III

Сэлим иңендэ — чыбыркы.
Бу инде — икенче көз.
Хэмит көтүе иңэнен
төшенэбез инде без.

Көтү алып уңгач былтыр
кыргыз феодалыннан,
җыйнады быел авылның
аерым хуҗаларыннан.

Чиркэндергеч көзге яңгыр
җанга бэрелеп бара.
Сарык көтүе өстеннэн
пар күтэрелеп бара.

— һау! — ди Сэлим, көтүенең
тайгак эзенэ басып,
үз тавышы белэн үзе
елыныр өчен ярсып,—

— һау! — ди, туктатмый көтүне.
Карамый да борылып.
Тик азыклы җирдэ көтү
туктала ябырылып.

Куптара көтүче аны
юрган ачкан шикелле.
Кузгала тагын да көтү
утка баскан шикелле.

Ә көтүче төшке ялга
ашыгып куа аны:
якында үз ышыгына
чакыра урман аны.

Аерым үскэн агачлар.
Кушылган ботаклары.
Гүя урман —
мең аяклы
дэү бер җанвар сап-сары.

Көтүне туплады Сэлим
Шушы җанвар астына —
Аның кытыршы тиреле
аягы арасына.

Бу урыннар таныш аңар.
Алпавыт җире — ары.
Ужым сөреп чәчә анда
Австрия пленнары...

Ә сарыклар ята кушәп,
елытып тоякларын,
ара-тирә селкеткәләп
тамгалы колакларын.

Алдан кыйган, арттан кыйган,
я очыннан чапкан «ук» —
монда ничә хуҗа салган
нинди генә тамга юк!

Хәмит, алгач, уйга калды:
тамга салырга ничек? —
һәр сарыкның уң колагын
төптән үк атты кисеп.

Берәү әйтсә: «Колагыннан
колак какты хайваным...»
Бөтен авыл аңлый аны
Хәмит сатып алганын.

* * *

Җәенке имән төбенә
зур учак ягып, бүген
ятты Сәлим ял итәргә
читкә тибәреп келен.

Мич башыдай эссе анда.
Йоклый Сәлим.
Төш күрә:
Җәй уртасы, имеш. Кояш
аркаларны пешерә.

Әнисе аны җитәклап
уракка бара икән,
тик урасы җиргә кадәр
бик ерак ара икән.

Әйтә әнисе: «Ял итик,
карыйк кошлар очканын.
Очкан кошлар аңлар кебек
күкрәгемнең кысканын».

Тал төбендә урын табып,
утырды хәлдән таеп.
Җырлый, имеш, салмак кына
бишек сыман чайкалып:

«Еракгын сары күренә
без урачак җир микән?
Җир йөзендә иң зур михнәт
безнекенә тиң микән?

Кайчан бетәр ураклар,
Җирләребез ераклар...
Бераз гомер итәр өчен
ни күрми газиз башлар!

Алда үрләр — биек кенә,
менәрбез ничек кенә...
Менәр идем үрләремә
җил булып исеп кенә».

Менә юк булды әнисе
җил булып искән кебек.
Сәлим талның аръягында
нидер ишеткән кебек.

Әнә анда — тегермән.
Тегермәннең өеннән
Антон абзый килеп чыкты —
ап-ак онга күмелгән.

Анда ич аның әнисе!
Антон да шунда барып,
яфраклар күләгәсендә
утыра шадраланып.

Юк, икәве генә түгел,
алар күбәүләр сыман.
Килешәләр, ул күргәнче
аны күргәннәр сыман.

Антон изүендә, әнә,
кадаган эналәре,
киндер күлмәк җиңнәрендә —
капчык келәймәләре...

Юк, Антон түгел, Сәлимнең
ул бит әтисе икән!
Ул Сәлимгә бармак изи:
«Монда кил! Юкса китәм!»

Күренә: куак артында —
башмакчы Бәшир дә бар,
тегермәнгә килүчеме? —
таныш түгел ир дә бар.

Юк, Австрия плены —
ул карый йөзен чытып:
җилкәсенә сарык салган
аякларыннан тотып.

Баш киеме кызык икән —
катламлы нәрсәсе бар.
Маңгай турында кадаган
бөрлегән тәлгәше бар.

«Әйтмә!» дигәнедер инде, —
Сәлимгә бармак яный.
Әйдә, алсын! Тик бер сарык —
ул соң Хәмит байга ни!

## IV

Мин тагын үз тарафымнан
дөресен генә әйтим —
Сәлимнең соңгы күргәне
төш түгел иде ләкин.

Сарыкны мәче урынына
җилкәсендә йөртүче —
Мәгъзиянең олы улы —
волостька ут төртүче.

Ул елны йорде дә качып,
әзе суыну белән
комисиягә керде никрут
алыптай сыны белән.

Чишенде ул. Комисиянең
башлыгы — өлкән врач:
— Годен! — дип кычкырып куйды
таң калып торгач бераз.

Авыру җирен эзләп түгел,
тикшерде ул аны тик
тере кеше микән бу, — дип,—
сын түгел микән антик?

Егетне интектермәде
солдат җәфасы гына:
— Раз! Два! — санап торалар,
шуңар басасы гына.

Бер кеп-кечкенә ефрейтор
өйрәтте аны. Таки
яңаклый алмады аны,
үрелеп тә хәттаки.

Бер әтәчләнгән чагында
— Я, кыйна инде! — диеп,
аны алдына иүтәреп,
барысын көлдерде егет.

* * *

Сугышта булмады кебек
батырлыгы да аның.
Һәм юк иде кебек өйгә
кайтырлыгы да аның.

Казак атларын кызганды:
ерак походтан килеп,
алгы сызыкка җиткәч тә,
яталар ачтан үлеп.

Чалгы таптыра бу егет
һәм теләгеп аңлата:
тик борын төбендә генә
«ничейный» болын ята.

Төннәр җитеп, чыклар төшкәч,
берни булмаган кебек,
гади арбага утырып
чалугa китә егет.

Гади бер эш.
Батырлыкка
охшыймы аз гына бу?!
Көннәр үтә, эскадронны
аякка бастыра бу!

Батырлык күрсәтүче, дип,
сугыштан соң атаман
казаклар белән беррәттән
моның исемен атаган.

«Моның өчен илләренә
ул кайтып килсен, — диган,—
тем более, иңбашына
шартлагыч пуля тигән».

* * *

Казан коменданты әйткән
моңар винтовка биреп:
— Юлның өсте. Тапшыр илтеп
шул әсирләрне, — диеп.

Кайтканда туктаган җитеп
урман мөгезенә бу.
Дәү бер әсирнең формасын
киенгән үзенә бу.

Үз киемен биргән аңар:
«Куда хошь— туда иди.
Только комендатурага
яңадан не попади!»

Шулай әсир булып калган
ул туган җирләрендә.
Кайгырта: ач, ким-хур итми
башка әсирләрне дә.

Алпавытта эшләүчеләр
алар бары — уникe.
Өсләрендә — әсир киеме,
башлары — егетнеке.

## V

Купты көтү. Калды Сәлим,
йокысыннан купмады;
өнен-төшен бергә бутап
йоклады да йоклады.

Таркалды көтү. Чөнки ул
ятмаган иде туеп.
Игеннәрне ашап, таптап
кайта җилгә арт куеп.

Тыны-тоны эшче көчләр,
көзнең соңына калып,
ура иде ул елларда
башактан карлар кагып.

Бүген поскан уракчылар
зурат ышыкларына,
сарыкларны куып алып
кайттылар йортларына.

Көтәләр Хәмит ялчысын,
— Килсен дә алсын,— диләр,—

тулэп, тапталган, ашалган
иген бәһасын,— дилэр.—

Куп сорамыйбыз. Кайтарсын
уз талаганын гына.
Шикэр бетте. Ә йөземнең
бер сум бит кадагы да!

VI

Хэмит эле сөйлэшмэскә,
түзэргә булды бүген:
«Сарыклар улмэс — кимендә
ашаган өч көнлеген».

Сарыклар түзэр. Тик башка
четерекле факты бар:
тотучылары сабырсыз,
бигрэк тә солдаткалар:

— Бушка киткэн иде, хайван,
табылды, дилэр, эмэл —
уз баясен ашаган бу,—
суйсам да ите хэлэл.

(Сатылган терлек онытмый,
кайта уз капкасына.
Берсе дә читтә калмады,
ия чыкты барысына.)

* * *

Тире тәкъдим итте берсе
иртэн аңарга килеп:
— Кича алып кайткан идем
курше базардан, — диеп.

Сарык тиресе. Колаксыз.
Киселгэннэр төптэн ук.
Берсе — яңа кисек. Берсе —
төзэлгэн бик куптэн ук.

Төшенэ Хэмит: бу узе —
сарыкны суйган карак.
Тиресен аңар китергэн
туп-туры кузгэ карап.

«Тугыз кыз»ның иң олысы,
Алпавытта асрау ул.
Кулына капсаң, үзеңне дә
тунар өчен асар ул.

Уйлый Хэмит: «Нинди мыскыл!»
Тыштан тынычланды ул.
Тешлэре шыкырдавын тик
сизмичэ дэ калды ул.

Алып кайтты да тирене,
нерде абзарга Хэмит.
Һэм эмер бирде Сэлимне
хэзер ук табарга дип.

Басты да бер почмаккарак,
көтэ сабырсызланып,
кошка ташланырга торган
мэчедэй калтыранып.

Керде Сэлим. Караңгыга
кузлэре өйрэнмэгэн.
Һэр хэлгэ эзер. Бу хэлгэ
лэкин эзерлэнмэгэн.

Ярсу Хэмит. Тик һаман да
тыныч иде тыштан ул.
Кул кутэру кайда, хэтта
кутэрми тавыш та ул.

Түземлектә, эрсезлектә
һәркемгә урнак биреп,
яши иде, хэйлэсе һэм
акылы белэн җиңеп.

Үзе ерткыч,
кэчлелэргэ
теше утэ торган ул,
көчлерэклэр арасыннан
сайлый иде корбан ул.

Тик чыгырыннан чыгарды
бу тире вакыйгасы.
Тора карап көтучегэ
һэм белми — ни кыласы?

Ничэ сарык! Ничэ тушкэ!
Купме йон, купме тире!
Китте шуның аркасында
бэлки кайтмаска кире!

— Өйрэтермен! — дип, бер генэ
сүз әйтте ул тегеңэр.
Сугып тэгэрэтте, шуннан
башланды өйрэтулэр.

Бу кыйлануга сөяге
кэлгэ дунэр иде дэ,
лэкин бала, — туп шикелле,
типкэч, тэгэри генэ.

Җиңелэеп китэр кебек
кычкырса бер: «Алла!» дип.
Тыела ул — ишетмэсен
һэм сизмэсен Алма, дип.

* * *

Мэхэббэт! Ярдэм итмисең
син нинди эштэ генэ!
Нинди йэрэккэ кермисең
нинди рэвештэ генэ!

Сэлимнең дингэ-сэннэткэ
корбан чагыннан алып

һәм аңар шәфкать тоташы
булган чагыннан алып

Алма яши Сәлим өчен
гүзәллек, сафлык булып;
тик чабуы кагылса да
сизелә шатлык булып.

Патша, я хан кызы кебек
әкият геройларын
Алма итеп күз алдына
китерә Сәлим барын.

Шул Алмага лаек икән,
Егет икән — чыдасын! —
Куллары белән урап, ул
зурларча саклый башын.

Бу хурлыклы кыйналуны,
авазын аның, үзен
Алмадан яшермәкче ул...
Тәкәнде ләкин түзем.

Туган чакта әрәмәдә
елагандагы сыман,
саркып чыкты зәгыйфь тавыш
сабырлык басымыннан.

Шул җитә калды Сарага,
ишетте, керде ана.
Күрде Хәмитне, бәркеттәй
һөҗүм итте ул аңа.

Уйлап торырга вакыт юк
ни кылып, ни диясен.
Шундый сукты ул Хәмиткә,
гүяки сукты яшен.

— Әйт, кычкырыйммы халыкка
бу шашуыңны синең —
сабый белән сугышасың,
ярманың шулмы синең?!

Күтәреп кара кулыңны
син миңа каршы менә!
Шул да йөри бит, ир исемен
тагып ыштан төбенә...

Киттек, улым! Бу авылны
каргагандыр шүрәле.
Муеныбыз бар чагында
камыт табылыр әле!

Бу чәпчүдән Хәмит артка
чигенәмени инде!
— Бар, алдыңнан артың матур! —
димәкче генә иде,

Тик Сараның артындарак
башка кеше бар икән.
Ул кеше — Антон.
Шул әйтте:
— Ул китсә, мин дә китәм!

* * *

Антон кайткан иде. Сугышып
бер ел да тутырмады.
Кузьма Крючков кебек ул
немецларны кырмады.

Унбишенче ел язында
атакага чыкты ул;
немецлар җибәргән газда
буылып, тончыкты ул.

Көчкә котылды үлемнән.
Ләкин, үпкә һәм йөрәк
төзәлсен өчен, — диделәр, —
авыл һавасы кирәк.

Кайда Антонга саф һава,
далаларның киңлеге?!
Хәмит байга кайтып эшләү —
бердәнбер мөмкинлеге.

һәм кабул итте аны бай —
Хәмитнең акылы бар:
Сара баш тарта башласа
алмашка Антоны бар!

Ләкин өлгерде Хәмитнең
ниятен ачарга ул:
димәк, Антоннан бау ишә
Сараны асарга ул!

Сара китсә, ул да китә!
«Икесе дә китсә, — дип,—
эшләрем ничек барыр?» дип
бик нык уйланды Хәмит.

Алардан башка бармый эш, —
хуҗадан башка бара!
Шуңар алар «китәм» диеп
аны куркыта ала.

Гаҗәпме соң, әнә шулар
бар эшне кулга алса;
хәтта дәүләт эшен алар
үзләре алып барса?

Шушы кетүче малайның
хәтта бер йоклавы да
зур бәһа бирүне сорый
аның аеклыгына.

Әйе! Ялчылар йокласа
байлык бетәчәк әреп,
Сәлим йоклагач, таркалып
эрегән көтү кебек.

* * *

Якты сузылды абзарга,
аның ишеген ачтылар,
һәм муен суздылар аннан
узган-барган ялчылар.

Алда, әнә, күпне күреп
тора сукыр Әптери,
кырып салган кристаллдан
ак төшкән күзен тери.

Әсәт кулы — кесәсендә.
Ул, чырапычак алып,
сугыштан котылыр өчен
бармагын өзгән чабып.

Артындарак — Габделваһап.
Ныклап күренми үзе.
Күренә, бозып шештергән,
кеше башыдай тезе.

Менә шулар һәммәсе дә —
Антоннар һәм Саралар,
патшага хезмәт итмичә,
хезмәт итәләр аңар.

Башка чыккан улын Хәмит
кайтартты ришвәт биреп.
Шул ник көнгә бер мәртәбә
хәлен сорасын килеп!

Юк ул! Барлык таянычы —
шушы ялчылар аның.
Ялчылардан башка нинди
таянычы бар аның?

Хәмиткә җыелган байлык
тик аларның эшләре.
Үзләрендә кала бары —
күз агы, тез шешләре.

* *
*

Талпынгандай итте Хәмит,
ул айнып китте микән,
аның хезмәтчел йөрәге
ныграк типте микән? —

Менә кул сузды Сарага.
Аптырап калды Сара:
сузыла, бай кулы түгел,
эшче кулы — кап-кара.

Шушы куллар алачыкта
запас частьлар ясыйлар,
ялан килеш кызган тимер
тотып, суга ташлыйлар.

Күз төшерде Сара аның
өздергән бармагына;
чырапычак эше түгел, —
кысылган йон валына.

Кысты Хәмит Сара кулын,
— Гафу боерыгыз, — дип, —
мин этәргән юлга, зинһар,
атламый торыгыз, — дип.—

Староста сайлаганда
кыйныйлар бит ил белән [1],
шушындый хәл булып алды
бүген дә Сәлим белән.

Кем белә соң, булыр, бәлки,
үскәч, староста ул...
Кыйналуларын кайтарыр,
әгәр дә карышсак ул.

Тыела алмады Сара,
әйтте ул, гәрчә тыйнак:
— Старостага сайла син,
әнә, кызыңны кыйнап!

— Юк, кызымны кыйнатмамын
мин киявеннән дә! — дип,
Сәлимгә мәгънәле ымлап,
бармак янады Хәмит. —

Иртәгә һәммәгезгә ял.
Тик йөрмәгез ач карын —
һәм Хәмит китте өләшеп
кесәсендә ни барын.

Таралдылар. Калды Антон.
Барысы киткәннән соң ул
ирония белән Хәмиткә
әйтеп калды: «Сен-Симон!»

Хәмит тыныч: җайланды эш,
чыгырыннан чыкмады.
Акчаны күп өләштем дип
ул чыраен сытмады.

Сәлимне кияү дип ымлап
кысты күзен дә Хәмит.
Шаярттымы, чынлапмы бу —
белми үзе дә Хәмит.

Героен үзе дип белеп
уйнаган артист кебек,
киткәндер ул, бәлкем, шулай
ярлы ролен кереп?

Бәлки, барадыр асылда
артистлык юлында ул;
вакытлы гына уйныйдыр
бай Хәмит ролен дә ул?

Шундый уеннарда бүген
зур камиллеккә җитеп,
Сараны таныгандыр ул
лаек партнеры итеп?

Онлы бияләе белән
гүя тик грим генә

[1] Биләр якларында патша вакытында авыл старосталары сайлаганда аны кыйнау йоласы бар иде. *С. Б.*

яңагына салган Сара —
бай сөртми йөри бирә.

Никадәр оста уйный бай
әверелеп башкага,
шулкадәр оста үзенең
сыйнфый ролен башкара.

Әйе, халтура түгел ул,
зур сәнгать — сыйнфый көрәш.
Дөньяның бар юксыллары,
шушы сәнгатьтә берләш!

Садакалар, яллар биреп,
гафу үтенеп,
кайнар,
оста уеннары белән
җиңмәсен безне байлар!

* * *

Җиңде Хәмит. Өч ялчысы
иң башлап, акча алып,
китте, Хәмит подвалында
тустыганлап бал салып.

Кайткач ук хатыннарына
бирделәр катгый әмер:
— Тотылган сарыкларны, — дип,—
илтеп бирегез хәзер!

«Кара халык — кара сарык»
димәсләр иде, әгәр
берсе купкач, һәммәсе дә
ду кубып йөрмәсәләр.

Карый шушы «кара сарык»,
сарык күрсә, шул җитә:
— Кара әле, сиңа әйтәм,
Әсәтнекеләр илтә!

Килеп ала белмәделәр,
ачыгып бетте, хайван.
Акчаны китереп бирмиләр,
барып алырбыз аннан...

Ялчылар үз акчаларын
күрсәтеп санаттылар.
Моны күргәч, «илтик!» ди-ди
куптылар солдаткалар.

Нигез бар иде тотарга
таптаганда кырда мал.
Аны илтеп япкач, менә
Хәмит абзарыннан ал!

Ялчыларына шулай ул
бераз садака биреп,
котылды башкаларыннан
«Исәплашербез» диеп.

Калды җыелып әрсезләре,
интектерде шулары:
буш кул белән һич кенә дә
килми кайтасылары.

Төрлечә подход ясыйлар
өйгә кайтмаска теләп:
— Сәлимне өйләндерергә
бар, имеш, синең теләк?

Әле ул малай гына бит,
үссен, ныгысын егет...
Җавабы кыска Хәмитнең:
— Һәммәбез малай идек.

Сезнең кебекләр каршында
югалып кала идек.

Өйләндек бит, менә хәзер —
уллар, кызлар атасы...
Тегеләрнең һаман килми
буш кул белән кайтасы:

— Кемне димлик икән аңар? —
Минем дә, синең дә бар
җиткән кызлар...
Әйтә Хәмит:
— Кызлар җүн хәзер, табар.

Шул вакыт урамда җырлап
никрут яшьләр үтә,
Хәмитнең соңгы сүзләрен
гүяки раслап үтә:

«Әфичәрләр якасына
кызлар ука укалый,
тагын да бер набор булса
кызлар сука сукалый...»

## VII

Сәлимне дәвалый Антон
бергә анасы белән,
күгәргән тәнен малайның
уа аракы белән.

Аракы тыелган ел. Тик
эзләде, тапты ана.
Көтмәгәндә ярдәм итте
иске танышлык аңа.

Шәкертне әйтәм, Казанда
укый кыш көнендә ул.
Җәен сатучылык итә
мулла кибетендә ул.

Һаман күңел күзе белән
Сараны күзли әле,
аны кулга төшерүдән
өметен өзми әле.

Сара, эзләгәнен тапмый,
өметен өзгән иде,

хәзрәт кибетенә бары
кайтышлый кергән иде.

Шәкерт куйды да шешәне
Сарадан ераграк,
кызыктырып, әйтте: «Бу бит
зәмзәмнән дә сафрак».

Һәм килде, кукәй урларга
ала карга килгән кук,
чышылдады ул теленә
кызган таба тигән кук.

Чышылдаулар арасында
тавышы чыкты аның,
шулай тәгәрмәч шыгырдый
бер кат әйләнгән саен...

Ни сөйләвен бәйнәләмим —
бәет озын булмасын;
укучының бер дә юкка
кәефе бозылмасын.

Язам, аның сүзләреннән
Сара аңлый алуын —
аның өчен Нәфисәнең
тик ялгыш кыйналуын.

Рисвайлыкка лаек булган
бары тик Сара гына.
Әйтә шәкерт: «Котылдың, — ди, —
минем аркада гына».

Алдый ул. Безгә билгеле
ничек аның Сараны
рисвай кылып йөретергә
омтылып караганы.

«Шулай аны хур кылып, бер
борынын төшерсәм, мине
инша алла кире какмас»
дип өметләнгән иде.

Һәм тарихи тәҗрибә бу:
бик куп пычрак җанлылар
олы җанлыларны шулай
пычрата алдылар.

Бүтән корбан әләккәч тә
корган тозакларына,
юрамакчы моны шәкерт
Сараны саклавына.

Шушы хәйләсен чышылдап,
шыгырдап бетерде дә,
куйды шешәне Сараның
алдына китерде дә.

Җавап итеп, бары этләр
турында әйткән төсле
әйтте Сара:
— Һәр эт, — диде, —
үз оясында көчле...

* * *

Эт оясында гынамы! —
Хәмит йортына җитеп,
Сара сездә бүген үзен
бүре өнендә итеп.

Ана булганым юк. Белмим,
әгәр баламны минем
шулкадәрле кыйнасалар,
анда мин нишләр идем?

Шагыйрь була торып, белмим:
шигырь дигән баласын
редактор кыйнап кугәртсә,
автор нишли ала соң?

Үземне язып, вакытны
әрәм итмичә, шуңар
кыйналган Сәлимгә кайтыйк,
бәлки, ни булса чыгар.

## VIII

Шулай итеп, хәзер Антон
аның анасы белән
кугәргән тәнен малайның
ышкый аракы белән.

Сәлим риза кыйналуга.
Хәтта аңар ошады:
болай гынамы көн саен
кыйнады тормыш аны!

Арыган, миңгегән иде,
тәмам интеккән иде;
йокысы туяр көнне ул
бәйрәмдәй көткән иде.

Тик аз гына йокласа да,
кубрәк саташа иде —
Һаман да шул ук көтүен
көтеп маташа иде.

«Төн җитте» дип, кайчагында
йокыга ятса арып,
ул төше икән! Уятып,
таң торгыза кубарып.

Бу тәмуг әйләнәсеннән
чыгалмас иде гомер,
бүгенге шикелле Хәмит
кыйнамаса иде бер.

Дучар булган иде Сәлим
аның бер пычагына;
шуннан соң да ташланды ул
иркәлек кочагына.

Әкияттә дә, бәхеткәчә
кеше гел газап күрә.

Күп булганга түгел,
бәхет
зур була азга күрә.

* * *

Татлы сызланулар аша
Сәлимнең, ара-тирә,
колагына әнисе һәм
Антон сүзләре керә:

«Судта кемнәр? — Чиновниклар,
кара урман шикелле.
Адашырсың. Башың кайтмас
судка бирсәң эшеңне».

Суд — Сәлим өчен күңелсез.
Бу сүзләрнең шуңа да,
үзен яклап сөйләнүен
китерми башына да.

Тагын ишетә: «Бик вакыт
аларга дөмегергә
бөтен строе белән —
патшасы белән бергә!»

Ә Сәлим йокы аралаш
моны аңлый бик кызык:
патшасы дөмексен. Ләкин
бар бит аның бер кызы!

Алма кебек бик матур ул,
иркә ул Алма кебек.
Пар ат җигеп, Сәлим аны
алырга бара кебек.

Бу аның әллә кайчангы
гамьсез бер чагы кебек.
Алма — балчыктан ясалган
аның курчагы кебек...

* * *

Юлдан читкә чыккан арба
кайтып эзгә төшкән кук;
һәм кояш болыт артыннан
чыгып күзгә төшкән кук,

әнисенең һәм Антонның
аңгәмәсенә һаман
кайтып кушылмакчы була
чыгырыннан чыккан аң.

Ләкин ничек эзен тапсын
шул хәлдә сабый күңел,
хәтта бу тормыш үзе дә
үз чыгырында түгел!

Бер уфтанган иде ана
Сәлимне «ятим» — диеп,
кинәт Сәлим аңга килде
кычкырып «Әти!» диеп.

Әтисен ул белми хәтта.
Сагышка да шул сәбәп:
кайберәүләр сагындыра
булмау аркасында нәкъ.

Сагына белгәнгә генә
кеше бит кеше дә ул.
Ә сагындыручыларны
күрә тик төшендә ул.

* * *

Нигә йоклый кеше? — чөнки
төштә — рәхәт дөньясы,—
ботыннан сөйрәсәләр дә,
килми аерыласы.

Баш очында утыручы
Антон белән икесен
күрде Сәлим, күрде гүя
әнисен һәм әтисен.

Ике кулы белән кочты
муеннарыннан Сәлим.
һәм алар ярдәме белән
торды урыныннан Сәлим.

* * *

Ир сөргенгә килеп тапкан
хатынын, улын сөя.
Кыйналып һәм күгәренеп,
калкый революция.

Әйтерсең лә яраланган
аягын кисеп атып,
революциягә таба
кыскарып, атлый вакыт.

*(Өченче кисәкнең соңы.)*



## Альберт Хәсәнов

*Мин — Казан артыннан, Дөбъяз егете. 1937 елда туганмын. 1961 елны Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, Лениногорск шәһәренең «Ильич васыятьләре» газетасында әдәби сотрудник булып эшли башладым. Беренче хикәяләрем дә шушы газета битләрендә дөнья күрде. Газетабыз кечкенә генә булса да, миңа язучылык эшенең никадәр зур, авыр, мәшәкатьле хезмәт икәнен тоярга мөмкинлек бирде. Яхшы әсәрләрне укырга гына җиңел икән!*

*Ә яхшы әсәрләр язасы килә. Миңа калса, кеше онытылып, «кулындагы кашыгын куеп» укырлык әйбер тудыру өчен тирән каршылыклар белән аның эчке дөньясын күбрәк ачарга, хисләрен, уй-фикерләрен тулырак бирергә кирәктер. Мин үзем тирән конфликтлы психологик әсәрләр ягында.*

# ГӨМЕР ИТКӘН НИГЕЗ

*Хикәя*

— Менә яңа фатирга гына күчик, обязательно үзем белән алып китәм. Бергә яшәрбез: бары — бергә, югы — уртак булыр, — дип, Рифкать күптәннән инде ата-аналарын үзләре янына Әлмәткә күчәргә димли иде. Картлар үзләре дә шәһәр җиренә күчәргә каршы түгел икәнлекләрен җае чыккан саен сиздерә тордылар. Хәдичә абыстай бигрәк тә:

— Монда тормыш итү бик авырайды. Карар кешең булмагач, малтуар асравы бик кыен. Ә утын-печән хәстәрләүне сөйләп тә торасы юк. Җитмәсә, атагыз да бик картайды, каравыл торудан башкага ярамый, бөтен хуҗалык минем өскә калып бара... Шәһәргә күчү ягын хуплап хатлар яздыра килде.

Көтә торгач, ниһаять, Рифкатьнең дә фатир чираты җитте. Авылдан картларны да алып килергә җыенам дигәч, аңа фатирның зурысын — өч бүлмәлесен бирделәр. Ләкин картларны үз янына күчерергә Рифкать ашыкмады әле. Хатларында шәһәргә бүгеннән күчәргә риза булып язсалар да, вакыты җиткәч, аларны гомер иткән нигезләреннән кузгату җиңел булмаячагын ул яхшы белә иде. Башта ул әти-әниләрен кунакка гына чакырды. Картлар көттермәделәр. Хәдичә абыстай үзе суккан йон палас, ә Ислам абзый каклаган каз һәм бер чирек әче бал күтәреп, килеп тә җиттеләр.

Фатир бик ошады аларга. Андагы уңайлыкларга бер кавым шаклар катып карап йөрделәр. Краннан сиптереп аккан суны, плитәдә зәңгәрләнеп янган газны карап, Хәдичә абыстайның соклануы эченә сыймый, аның саен: «Гомеребез газап эчендә узган икән ләбаса, я ходай, кара инде син бу рәхәтне, — дип кабатлый иде.

Ә Ислам абзый характеры белән дә аз сүзле кеше буларак, соклануын саранрак, җыйнаграк белдерә. Матур итеп буялган тәрәзә рамнарын, ишек яңакларын, ишектән зур, киң, якты тәрәзәләрне, ялтырап торган җиз краннарны — һәммәсен дә үз кулы белән тотып-тотып караганнан соң, бөтен канәгатьләнүен бер сүзгә салып: «Һәйбәт!» — дип куя иде. Картлар яңа фатирга тынычлык, иминлек, ә аның хуҗаларына тазалык, саулык, тигезлек теләделәр. Хәдичә абыстай исендә калган бер-ике догасын да укып алды. Ә Ислам абзый үзе дингә-мингә ышанулардан бөтенләй азат карт. 1945 елны ук сугыш кырында калдырып кайтты ул аларны. Балачакта ятлаган берничә догасын да Мәскәү астында контузия алгач, оныттЫ. Ләкин бу юлы ул да, олы кешегә башкача килешми дигәндәй, Хәдичә абыстайга кушылып, өч мәртәбә «Алла әкбәр, амин!» дип битен сыйпады.

Ә шәһәргә бөтенләй күчү турында Рифкать сүзне картлар авылга китәргә җыена башлагач, соңгы тапкыр чәй янына утыргач кына, анда да җае белән генә кузгатты.

— Кара атасы, ник дәшмисең, улыңа төпле җавабыңны бир! Күчәбез диген, ваннада сөякләрне йомшатып чыккач, балалар белән бер чүкердәшеп чәй эчүләре ни тора бит, — дип, Хәдичә абыстай Ислам абзыйны җилтерәтеп кыстарга кереште. — Менә көтүләр генә керсен, алла кушса, язган ризыгыбыз булса, бер сүзсез күченербез дә килербез.

Көтүләр кергәч, аяк аслары туңгач, Рифкать биш көнгә ял алды да, хатыны белән кече малаен ияртеп, авылга, карт белән карчыкны алырга кайтып китте.

Картлар, Рифкатьнең аларны алып китәргә кайтуына кул чабып сөенмәсәләр дә, бармыйбыз дип тә әйтмәделәр. Картларча, ашыкмый гына юлга хәстәрләнә башладылар. Рифкать аларның күңелен күтәреп җибәрү өчен, дөнья эшен белеп булмый, шәһәр җирен бик ошатып куймасагыз, тагын, кире авылга кайтып торырсыз, шуңа күрә йорт-җирне берәр елга сатмый торыйк дигән тәкъдим кертте. Картларга бу бик ошады, әлбәттә. Шәһәргә китәбез дип кенә, бер бүрәнәләп җыеп салган нигезләрен таркаттырасы, ят кешеләр кулына калдырасы килми иде аларның.

Ашыкмый гына җыенып та, биш көн дигәндә картлар юлга хәстәрләнеп җиттеләр. Баздагы бәрәңгене сатып, ике бәрән китергән сарыкны күршегә асрамага биргәннән соң, Рифкать ишек алдына йөк машинасы алып кайтты. Йорт-җир кирәк-яракларын Хәдичә абыстай үзе өйрәтеп торганча, җае-җае белән машинага төяргә керештеләр. Иң түр почмакка ястык-юрганга төрелгән җиз самовар менеп кунаклады. Калайлары һәм түбе купкан тоткасыз ике сандык та шулай ук түрдән урын алды.

— Улым, менә монысын бик сак урнаштыра күр инде, мин шушы нигезгә килен булып төшкән елны алган идек, — дип, Хәдичә абыстай алъяпкычы белән пыяласын һәм рамнарын сөртә-сөртә, көмешләре кубып, тузып беткән стена көзгесе күтәреп чыкты.

Әмма йорт эчендә истәлекле әйберләр бер күзгә белән генә бетмәде әле. Хәдичә абыстай кулына эләккән, күзенә чалынган бар әйбер үзенчә истәлекле, кай җирләре беләндер берәр вакыйганың тере шаһитлары иделәр.

— Балалар, сез теләсәгез ни әйтегез, моны да калдыра алмыйм. Атагыз сугышта йөргән елларда кышкы озын төннәрне икәү кыскарта торган идек, — дип, Хәдичә абыстай әллә каян, тышына әллә аю, әллә инде күке баласы төшерелгән, ә соңгы еллар эчендә тик үрмәкүч кабиләләре өчен штаб-квартира хезмәтен үтәүче бер герле сәгать табып чыкты. «Исламыңны көт-көт!» дигәндәй, әрмый-талмый чаба иде, җанашым. Соңгы елларда гына әллә ни булды үзенә, кәрәчин сөртсәң дә, каз

мае тидерсәң дә файдасы юк, йөрми, — дип сөйләнә-сөйләнә, сәгатьне дә йөк төяүче егеткә сузды.

Килен дә, Рифкать үзе дә, эти-әниләрен үпкәләтмәс, җәберләмәс өчен, Хәдичә абыстай ни күтәреп чыкса шуны: кирәген дә, кирәкмәсен дә машина өстенә сала бардылар. Шул исәптән, машинага кисәү агачы, бозау муенчагы, май атлагыч гөбе, тешсез урак, күмер соскычы, инде ничәмә еллар моннан элек төп вазифасын ташлап, хәзер йомырка саклауга күчкән бер колакчынсыз бүрек, җилпуч, китек чуен, чабата калыбы, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр — барысы да машина өстендә үзләренә тиешле урын таба бардылар.

— Ә мине кемгә калдырмак буласыз? — дигәндәй баскыч төбендә мыекларын тырпайтып утырган ата мәчене дә каз утырта торган кәрзингә салып һәм яхшылап өстен каплап, Хәдичә абыстай шулай ук өскә бирде.

Ислам абзыйның йөге зур булмады. Ул беренче эше итеп, инде күп еллар буена эшкә йөртә торган җиңел балтасын бүкәннән алып машина бортына китереп кыстырды. Аннары: «Мондый җилле чалгы күршеколанда юк, кемгә генә бирсәң дә җәл, кадерен белмәсләр, йортны сипләткән елны үтеп баручы чегәннәрдән өч чиләк бәрәңгегә алмаштырып алган идем»,— дип сөйләнә-сөйләнә лапастан чалгы күтәреп чыкты һәм аны да уңай җир табып йөк өстенә урнаштырды.

Бөтен кирәк-яракларны төйи торгач, өч тонналы машина кузовы да таман гына булып чыкты. Шофер егет бортларны көч-хәл белән генә япты. Сыгылганрак күренгәч, көпчәкләргә типкәләп карады да, кабинасына кереп, моторны кабызды.

— Ягез, кузгалабызмы инде? — диде Рифкать сәгатенә карап.— Шәһәргә якты белән барып керү уңай.

— Улым, тагын әз генә сабыр итегез, күзгә чалынмыйча тагын берәр нәрсә калмагае. Булмаса, тагын бер әйләнеп чыгыйм,— дип, Хәдичә абыстай ашыга-ашыга тагын өй эченә кереп китте. Ә Ислам абзый янчыгыннан зур гына чемегем тәмәке алып, салмак кына төрде һәм баскыч төбенә утырып, башын түбән игән хәлдә тирән-тирән итеп, төтен суырырга кереште.

...Машинага төялгән әйберләрнең яңа фатирны бизәмәгәнен һәм шәһәр тормышында аларның бөтенләй хаҗәте булмавын Хәдичә абыстай үзе дә яхшы белә иде. Шуңа да карамастан, ул, кулына туры килгән, күзенә чалынган бер әйберне төятә торды. Яткан урын-җире, ашаганэчкән савыт-сабасына һәм эш коралларына алданып, гомер кичергән нигезеннән кузгалып китүе җиңелрәк булыр шикелле тоелды аңа.

Менә инде машина да төялеп бетте. Ә күңеле һаман тынычланып житә алмады. Өй эчендә инде бернәрсә дә калмаганын белә торып, ул тагын эчкә атлады.

Хәдичә абыстай ак өй бусагасыннан яртылаш атлаган килеш, ишек яңагына сөялеп, туктап калды. Тәрәзәләргә тышкы яктан буй-буй итеп такта кадакланганлыктан, өй эче яртылаш караңгы. Түшәмнән һәм стеналардан купкан обойлар ишек ачкан уңайга әкрен генә тирбәләләр, моңсу кыштырдыйлар. Мич арасында өзеп-өзеп кенә чикерткә сайрап ала. Шул арада, кайдандыр бик ашыгып, инде ничәмә еллар урам як тәрәзә өстендә ялгыз гомер кичерүче карт чыпчык кайтып керде. Тәрәзәгә кагылган такталарны күреп, башта бик гаҗәпләнде. Чырык-чырык килеп, канәгатьсезләнүен белдерде, оясына кергәч тә, пыр тузынды, кыш якыная дип тормады, анда тулган вак салам кисәкләрен, йон бөртекләрен чыгарып ташлады. Аннары: «Тукта, мин бу хәлне хуҗаларга җиткерим әле» дигәндәй, тәрәзәгә кадакланган такталарның берсе өстенә кунып, ике-өч тапкыр тәрәзә пыяласын чукып алды. Эчтән җавап булмагач, өй түрендәге шомырт ботагына кунып, тәрәзәләргә такталар кадаклаганда оясына килгән зыян, кышка каршы

аны япа-ялгыз калдыра язулары турында, үзенең чыпчык телендә, зәһәрләнеп-зәһәрләнеп, бөтен ишек алдына кычкырып-кычкырып чыркылдарга керешге. Ә Хәдичә абыстай обойларның моңсу кыштырдавында да, чикерткә сайравында да, карт чыпчык зарында да, тик бер сорау: «Ә безне кемгә калдырасың?» дигән сорауны ишетә иде. Бу минутларда ул шушы йортта үткән кырык елдан артык гомерен күңеленнән уздырды. Ачлык кичерде, байлык күрде. Шушы нигездә дөньяга өч бала китерде. Алар дөбердәшеп кенә үсеп килгәндә, сугыш башланды. Башта аталары китте, ике елдан соң бер-бер артлы Ильясы белән Илһамы киттеләр. Өйдә алар төпчек улы Рифкать белән генә калдылар. Ислам абзый үзе исән-сау әйләнеп кайтты. Тик балалары — ике күз нурлары гына мәңгегә чит җир туфрагына ятып калды. Лачындай ике егетне сугышка озатуы бүгенгедәй хәтерендә әле. Ильясның йөргән кызы Нажия әле хәзер дә Хәдичә абыстайны үз итә, якын күреп йөри. Язын бәрәңге утыртыша, көзен алыша, вакыты булганда, аргы як чишмәдән йомшак чәй суы алып чыгып бирә...

Озын-озын итеп кычкырткан машина тавышына Хәдичә абыстай сискәнеп куйды. Аны чакырып кычкырттулары иде. Машина тагын бер сузып сигнал биргәч, ул әкрен генә тышка атлады. Барысы да әзер, аны көтәләр иде.

— Килен син дә, улым син дә гаеп итмәгез. Сезне борчып, эшегездән аерып йөрүебез өчен ачуланмагыз инде, балалар. Бу нигездә мин кырык елдан артык гомер кичердем. Бик авыр минутларым да булды, рәхәт чакларым да күп булдылар. Стенасына сулышым сеңгән, ташларына тирем тамган. Бүген генә ташлап китә алмыйм шул мин аларны, — диде ул калтыравыклы тавыш белән. — Аннары, үзегез дә әллә ни ерак тормыйсыз. Бер кайтмасагыз бер кайтырсыз, ташлап бетермәссез әле, — дип, яулык почмагына елап җибәрде һәм, әкрен генә кирегә, өй эченә кереп китте.

Шуны гына көткәндәй, Ислам абзый да, инде күптән сүнгән төпчеген, тагын бер кабат сүндереп, җиргә ташлады һәм җәһәт кенә урыныннан торды. Кыстырган җирдән балтасын алып, кире бүкәнгә чапты. Аның соңында, иплән кенә чалгысын чиште һәм бармаклары белән аның үткенлеген капшый-капшый шулай ук кирегә, лапас эченә табан атлады.

———●●●———

*Саҗидә Сөләйманова*

## Язылмаган җырлар

*Поэма*

Саргаеп көйгәнне,
Сөюдән үлгәнне
Сөйлиләр борынгы бәетләр.
Янсаң да, көймә син,
Саргаеп сөймә син,
Замана гаепләр.

Тик минә һаман да
Бу яңа заманда
Кешедә сагыш бар, кайгы бар.
Күңелләр көр була,
Максатлар бер була,
Ә юллар нигәдер аерыла.

Йолалар искерә,
Тик минә хис кенә
Һаман шул: буйсынмый, тузына.
Диңгезләр кушыла,
Айга юл сузыла.
Бу күңел дигәнең өзелә, сызыла.

Күкләрне күкрәтә,
Тауларны тетрәтә
Очканда очрашкан җисемнәр.
Нидә соң кодрәте? —
Күпләрне тетрәтә
Янәшә җырланган исемнәр.

Мин дә җыр тыңладым.
Йокысыз төннәрем
Таң белән тоташты, сизмәдем.
Ишеткәч, түзмәдем,
Иясен эзләдем
Күңелне кузгаткан сүзләрнең.

Тыңладым, оныталмыйм,
Үземдә йорталмыйм, —
Сөйлимен күргәнне, белгәнне.
Кем өчен өзелә дустымның үзәге? —
Сорама, ачалмыйм серләрен.

Эшенә карамый,
Төсенә карамый, —
Мәхәббәт бәхеткә тиңдәштер.
Мәхәббәт азатмы?
Әллә ул газапмы?
Укучым, тыңла да, киңәш бир.

■

Карлар, карлар,
алка карлар,
ап-ак карлар ява.
Җәйләр,
көзләр,
йөргән эзләр
кар астында кала.
Кара күзе,
сабыр сүзе,
әллә үзе якын.

Карлар ява,
карлар ява,
ә йөрәктә ялкын.
Йолдыз карлар
һавалардан
нигә төшә җиргә?
Күрми торсам,
онытыр идем, —
төшләремә керә.
Күктән йолдыз яудыралган
Сөю бар ди,
чындыр.
Салкын кышта
яндыралгач,
Гыйшык уты шулдыр.

■

Яр тулып бозлар акканда,
Нигәдер күңел тула.
Елыйсы килгән чакларда
Җырласаң җиңел була.

Тамчылар тама, таш яра,
Ирешә теләгенә.
Күз яше эзләр уялмас
Берәүнең йөрәгенә.

Ә күктә кояш елмая,
Урамнар дәрья төсле.
Яз быел матур килә бит,
Кешеләр көләч йөзле.

«Чык-чык» дип килә чыпчыклар
Тәрәзәм турысына.
Каршылыйм таңны, сөялеп
Тәрәзә борысына.

Сыерчык килгәнен көтәм,
Күңелемне аңлар иде.
Барыр да аның каршына,
Талпынып сайрар иде.

Сыерчык теленә салып
Җибәрсәм сагышымны,
Ул да бер моңланыр әле,
Ишетеп тавышымны.

Сәламен, бәлки, җибәрер
Җырчы кош канатында...
Сыерчык килгәнен көтәм,
Күңелемне аңлатырга.

■

Күзләреңнән нурлар агылганда,
Керфекләрең ничек талмый соң?
Син карыйсың миңа, гел карыйсың.
Әйтер сүзең әллә бармы соң?

Син карыйсың үзең,
керфекләрең
Серләреңне җыя, яшерә.
Син яшермә инде,
әйт, яшермә,
Сүз табалмыйм башлап дәшергә.

Көн дә йөргән юлларыңа чыгам,
Дәва эзлим йөрәк сызлауга.
Син кызганма инде,
һич кызганма,
Күз нурыңны сирпе узганда.

Күзләреңдә, ахры, тылсым бардыр, —
Сине күрми бер көн түзалмыйм.
Мин эзләмим сине,
юк, эзләмим,
Биргән вәгъдәм бар шул, бозалмыйм.

■

Иртәрәк килмәдең,
И ләйсән яңгыры.
Боредә йомылган
Яфраклар арыды.

Саргаеп көтteләр
Үләннәр, уҗымнар.
Сарылган тузанны
Тамчылар юсыннар.

И яңгыр, ю әле
Бераүнең тәрәзен.
Күтәреп карасын
Күңеле пәрдәсен.

Китәм дә әйләнәм,
Керсәм дә тар сыман.
Күңелендә мин түгел,
Бүтәннәр бар сыман.

Тамчылар, тамчылар,
Белегез бер серне:
Мин бердән береме,
Күпләрнең берсеме?

Нигә соң тәрәзә
Томанлы, тузанлы...
И ләйсән яңгыры,
Юдырып уз әле.

■

Кайдан синдә бу кадәр
Сөенеч, шатлык?
Шатлыгың миңа күчә,
Үзеңнән артып.

Очраштык. Әйтер сүз юк.
Үтәргә юл юк.
Сиңа ни сөйли икән
Тынычсыз тынлык?

Кара коңгырт күзләрнең
Төрлесен беләм.
Яз сыман яктыларын
Беренче күрәм.

Үзем нигә елмаям,
Сәбәпсез көләм?
Нигә сөенүеннең
Сәбәбен беләм.

■

Күзләр белән күзләр очрашканда,
Калам төсле упкын читендә.
Сагына да үзе,
чакыра да...
Соңгы адымны ясау читен дә.

Тиңсез сагыш
кара тирәнлектән
Якты өмет булып бәркелә.
Әллә котә,
әллә икеләнә,
Кулын сузмый, куя иркемә.

Ә мин һаман сихерләнгән сыман
Басып торам упкын читендә.
Күзне йомсам, бәлки, атлар идем,
Күрәләтә керү читен лә...

■

Яңгыр ява,
яңгыр ява,
гөрләп сулар ага.
Җыелмаган бөртекләрем
кала инде,
яна.

Урылганы,
егылганы,
сугылганы бергә...
Нигә килү кирәк инде
чакрылмаган җиргә.

Җыяр идем,
куяр идем
келәтләрне биккә.
Йозак-келә табалмадым
йөрәккә
һәм
күккә.
Яшьнәп, күкрәп калыйм диме, —
Җәйнең соңгы ае.
Үсәсенә файда да бит,
каласыга авыр.

Яңгыр ява,
ява, ява...
Гөрләп сулар ага.
Галәм суы сүндералмый,
Яна йөрәк,
яна.

■

Табышмакның җаваплары кызык, —
Я бик ерак, я бик якыннар.
Син эзлисең мичтән пәрәмәчләр,
Алар йолдыз булып балкыйлар.

Йөрәгенә ут салучы бала
Кайда йөри?
Табу, һай авыр.
Ә ул синең каршыңда ук икән:
Кайнап торган сары самовыр.

Җиз самовыр җырлый, гөрли генә,
Дус-ишләрне җыя табынга.
Тик йөрәге
кеше кулы белән
Утлы күмер салып кабына.

Янар йолдыз
төннәр карасына
Үз яктысын биреп яктыра.
... Синең күзләр йолдызларга тиңме, —
Хыял илләренә чакыра.

Эзләгәнне бик якыннан тапсаң,
Табу сөенече ник сүрән?
Ерактагы учак якты сыман,
Якын килсәң, инде ул сүнгән.

Табышмаклар дөньясына кереп,
Әллә инде үзем югалам.
Минем өчен әле табылмаган
Табышмак син.
Эзлим, уйланам.

■

Чәчләреңне тарар идем
Күзләреңә карап.
Алар көзге көндәй соры,
Болыт сыман кара.

Беләм бит мин ул күзләрнең
Иң бәхетле чагын.
Тибрәндереп, сискәндереп
Карарларны тагын?

Сизенәсем калган алдан,
Шикләнәсем калган
Чикләнмәгән, бикләнмәгән,
Без белмәгәннәрдән.

Кояш кебек кирәк мина
Яздай якты йөзең.
...Атналары бик тиз уза,
Бәйрәмнәре озын.

Отыламы, онтыламы
Язылмаган жырлар.
...Иңнәремә салынмаган,
Кагылмаган куллар.

Чәчләренне тарар идем,
Күзләреңдә томан.
Алар бүген ерактагы
Кара урман сыман.

■

Болытларны айкап нидер үтте,
Әллә яшен, әллә ажаган.
Табылмаган,
танылмаган уктай
Йөрәгемә нидер кадалган.

Кузгата да, сызлата да сыман,
Жәрәхәт тә кебек,
түгел лә.
Көе табылмаган,
язылмаган,
Жырланмаган жырдай күңелдә.

Сызлаган да булды,
эзләгән дә.
Ул чакларны инде оныттым.
Эзләгәндә түгел, сизмәгәндә
Юлларыма нигә юлыктың?

Сизелмәгән,
әле бизелмәгән,
Өзелмәгән гөлләр кирәкме?
Күз күрмәгән гөлнең энәседәй
Нидер чәнчеп тора йөрәкне.

■

Ялан аяк юлга чыгам,
Әле янам, әле туңам,
Һаман барам бер ялгыз.
Әллә җәй бу, әллә кыш.

Берәү аңлый, берәү каргый,
Аяк тала, йөрәк арный,
Һәр борылыш — сөенеч,
Әллә бәйрәм, әллә эш.

Бер югала, бер табыла,
Я еракта, я янымда, —
Кояш кына бата кич.
Әллә өн бу, әллә төш.

■

Бозлы диңгез ятса арабызда,
Эретер иде кайнар хисләрем.
Карлы таулар булса,
мәхәббәтнең
Канатлары белән кичәрмен.

Юллар, еллар безне аерсалар,
Йөрәкләргә алар киртәме?
...Бер сукмактан йөреп,
очрашканда,
Туктап кул да бирми китәмен.

Күзләреннең сихри нуры сүнәр,
Караларын түгеп карама.
Очып,
йөзеп,
атлап чыгалмаслык
Кеше язмышы бар
арада.

■

Синең куллар белән минем куллар,
Синең юллар белән минем юллар
Очрашса да, бергә үрелмәс.
Сауммы диеп кемнәр кул бирмәс.

Ә мин кулым бирәм син сузганда,
Ә мин өнсез булам син узганда,
Йөрешләрең әллә тылсымлы,
Очрашулар безнең бик соңмы?

Үзем кулым алам кулларыңнан,
Үзем күзем алмыйм юлларыңнан,
Булыр төсле бераэр могҗиза.
Көн артыннан шулай көн уза.

Ә мин сыныйм акыл белән хисне.
Баскан җирдә карлар эрер төсле...
Йөрәк каты тибә, тиз эремәс.
Күзләреңә туры карасам да,
Эчләремдә утлар кайнаса да,
Кулым салкын булыр,
сиздермәс.

■

Кашларың кыйгач дигәннәр
Чәчеңне үрмәсеннәр.
Башларың ялгыз дигәннәр
Яшеңне күрмәсеннәр.

Гөлләргә тиңләсеннәр,
Алларга тиңләсеннәр.
Ярага тисә, тисеннәр,
Арага кермәсеннәр.

Сагышлар йөздә чагылса,
Әйдә, бер сөйләсеннәр.
Сагына дисә дисеннәр,
Ялына димәсеннәр.

■

Буранлы кышларым,
яшенле җәйләрем,
Йокысыз таңнарым,
кичләрем...
Кайларда кышлады,
кайларда җәйләде
Хыялда сакланган төсләрең?
Ә хыял канатлы,
ябуны яратмый.
Кошларга киңлек бир,
югалмый.
Кундың да, очтың да,
тотарга кыялмыйм,
Бәхетме,
әллә син хыялмы?
Ә бәхет түгәрәк,
Килә ди тәгәрәп,
Туп итеп уйнарга, чөяргә...

Очасың,
төшәсең,
Туктама,
тәгәрә.
Кояшы артыннан
Жир калмый,
ияра.

■

Кайсыннан алыйм да,
Бирим соң кайсына, —
Бераүнең бәхете —
бераүнең кайгысы.
Кайгыны бүлешәм,
шатлыкны өләшәм.
Ә бәхет бүленми,
ник аның яртысы?

Торналар очалар,
Яшәргә кушалар,
Жыр белсән, кошка бир,
таратыр.
Кешедән качырган,
Эченә яшергән
Сукыр ут саргайтыр.

Чаткылар уйнасын,
Йоклаган уянсын, —
Мин күккә йолдызлар чәям.
Сүнсә дә, нур калсын,
Көл түгел,
жыр калсын, —
Янам мин,
сөям!

——◆——

*Гали Халит*

# БӘХӘССЕЗ ҺӘМ БӘХӘСЛЕ ХАКЫЙКАТЬЛӘР

## I

Егерменче йөз башындагы Россиядә һәм шул җөмләдән татар җәмгыятендә дә мәйданга чыккан демократик хәрәкәтләр милли әдәбиятның электә булмаганча күтәрелешенә һәм әчке яктан катлауланунына китерделәр. Әдәбиятта яңа чорның рухы тулысы белән өстенлек итә башлады. Татар әдәбияты бигрәк тә халыкка, хезмәт ияләренә якынаюда, аларның азатлык һәм бәхет идеалларына турыдан-туры хезмәт итүдә яңа тарихи дәверен ачты. Бу дәвернең бөек хәбәрче һәм җырчыларыннан берсе Габдулла Тукай булып, ул — халыкка илһамлы ышаныч һәм бетмәс мәхәббәт белән: «Халык — зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», — дип белдерде. Шул рәвешчә, Тукай һәм аның алдынгы замандашлары татар әдәбиятының төп кыйбласы — халык икәнлеген тулы тавыш белән, кыю итеп раслау югарылыгына күтәрелделәр, аның какшамас халыкчан җирлеген салдылар. Халыкка мөнәсәбәт һәм аның белән бәйләнеш мәсьәләсе милли әдәбиятның да нинди юлдан барышын һәм язмышын хәл иткән факторлардан берсенә әверелде. Бу юл — реализм булып, тик шуның аша гына халык белән әдәбиятның тормышчан тирән бәйләнешен тәэмин итәргә мөмкин иде. Төгәлрәк итеп әйткәндә, халыкка хезмәт итү, аның төп теләкләрен аңларга омтылыш безнең әдәбиятның реализм җирлегендә үсешенә рух һәм этәргеч бирде. Тукай һәм аның замандашлары шул юлга басып иҗат итүнең төп максат икәнлеген төшенделәр. Хәтта үз иҗатында романтизм принципларына шактый зур урын биргән Г. Ибраһимов та: «Мөхәррир үзенең тугры тасвире белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдында ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен! Әдәбияттагы реализмның бердән-бер әһәмияте фәкать шул ноктадандыр», — дип раслады. («Тормыш», 1915 ел, 27 февраль).

Әлбәттә, татар демократик әдәбияты халыкның тарихны үзгәртүче, аны яңадан коручы реаль һәм потенциаль көчен бөтен колачы һәм мәһабәтлеге белән аңлап күрсәтү югарылыгына күтәрелә алмады. Гомум гуманизм һәм мәгърифәтчелек иллюзияләре көчле иде. Әмма бу — халыкның тарихтагы ролен күрмәү һәм аңа актив мөнәсәбәт белдермәү дигән сүз түгел әле. Моңа Тукай иҗаты — җанлы бер шаһит. Татар халкының ирегең һәм алга үсешен буып торган һәртөрле реакцион көчләргә рәхимсез нәфрәт белдереп һәм көрәшкә чыгып, шагыйрь үзенең төп иҗат позициясен билгеләде. Шуның белән бергә ул, халыкны кызганып, аның башыннан сыйпап юандыручы гына түгел, ә аның гасырлар буенча килгән наданлыгын, артталыгын, йомыклыгын һәм башка шундый бик күп кимчелекләрен хөкем итүче дә, халыкның рухи яраларына төртеп күрсәтүче дә иде. Тукай иҗатының буеннан-буена үткән мондый тенденция, ягъни чынлыкның акмы-карамы икәнлеген ярып күрсәтү, аны бөтен рәхимсезлеге белән күз алдына бастыру татар критик реализмының төп рухын, идея пафосын билгеләде. Явызлыкка халык ноктасыннан ләгънәт һәм нәфрәт белдерү, халыкны шул явызлыкка

каршы рухландыру максатын байрак итеп. Тукай татар әдәбиятының прогрессив ролен бик югары күтәрде, аның гуманистик табигатенә актив идея көче өстәде һәм критик юнәлешен һич булмаганча баетты. Тукай дөньяга карашындагы тарихи оптимизмның да төп мәгънәсе менә шунда. Бу оптимизм һәрвакыт 1905 ел революциясе идеалларына турылыклы булып калды, һәм тарихның, тормышның иң авыр көннәрендә дә шагыйрь шулар белән рухланды, азыкланды. Ләкин моңардан Тукай тормышны үзгәртүдә туры мәгънәсендә һәм эзлекле революцион позициядә торды дигән нәтиҗә ясалмаска тиеш. Бер ул гына түгел, аның күпләгән алдынгы замандаш язучылары бу мәсьәләдә бик каршылыклы булдылар. Аларның тарихи оптимизмына, барыннан да элек, халыкны агарту, мәгърифәтле итү, аның аңын һәм культурасын үстерү нәтиҗәсендә булачак үзгәрешләргә, прогресска ышану кебек, милли азатлык һәм мәгърифәтчелек романтикасы хас. Тукай дөньяга карашы да бу романтикадан азат түгел иде. Аның иҗатындагы күп кенә каршылыкларның бер чыганагы, сәбәбе дә шунда булды. Менә шундый каршылыклар күренеп торуга да карамастан, татар демократик әдәбиятының һәм аеруча Тукай иҗатының реалистик һәм критик эчтәлеге алардан күп мәртәбә көчлерәк булып, халык аңын һәм рухын революционлаштыруга хезмәт итте.

Егерменче йөз башындагы татар әдәбиятының иҗтимагый-идея колачы киңәюгә һәм төрлеләнүгә нисбәтән, аның тормышка эстетик мөнәсәбәтендә дә, иҗат методларында һәм стильләрендә дә тирән үзгәреш һәм катлаулар барлыкка килде. Болар, үз чиратында, әдәби традицияләрнең чуар һәм калын катламнарын өскә чыгарып, яңалык, новаторлык өчен көрәшнең кискен каршылыклар эчендә баруын күрсәттеләр. Бу чордагы татар әдәбиятын Россиядә, Европада һәм Көнчыгышта булып үткән һәм булып торган әдәби хәрәкәтләргә бәйләнештән аерып карау һич тә мөмкин түгел иде инде. Чөнки татар әдәбиятының демократик җирлеге ныгу, реализм һәм халыкчанлык өчен көрәшнең аңлы юнәлеш алуы — болар һәммәсе аның милли чикләрен күп киңәйтте, ягъни элекке йомыклыкны катгый рәвештә җимерергә тиеш булды. Һичшиксез, бу процессның үзәгендә дә Тукай иҗаты торды. Төрки поэзия тарихында беренче мәртәбә дияргә мөмкин, аның иҗатында Көнчыгыш һәм Көнбатыш шигъри традицияләре бер-берсе белән очрашып, тыгыз мөнәсәбәткә, бәйләнышка керделәр, бер-берсеннән аерылмаслык эретмә, синтез хасыйль иттеләр. Шагыйрь татар поэзиясенә алып килгән яңалыкның күләме һәм мәгънәсе шул традицияләргә нисбәтән генә тулы ачылырга һәм бәяләнергә мөмкин.

Әйткәнебезчә, егерменче йөз башындагы татар демократик әдәбиятының бөек казанышы — реализм һәм халыкчанлык булды. Әмма болай дию белән без һич тә башка иҗат методларының һәм әдәби агымнарның урынын һәм әһәмиятен кимсетергә, читкә этәрергә теләмибез. Шулар арасыннан бигрәк тә романтизмның татар әдәбиятындагы роленә игътибар итми мөмкин түгел. Чөнки аеруча егерменче йөз башы шикелле революцион тетрәүләр белән тулы бер заманда романтикасыз әдәбиятның булуын күз алдына китерү бик кыен.

Төрле әдәбиятларда романтизмның барлыкка килүен гадәттә ике иҗтимагый факторга бәйләп карыйлар: берсе аның милли азатлык хәрәкәте белән бәйләнгән булса, икенчесе — шәхес иреге өчен көрәш ихтыяҗының үсүе. Болар икесе дә башлыча капиталистик мөнәсәбәтләр тамыр җәя башлагач мәйданга чыгалар.

Аеруча егерменче йөз башындагы хәрәкәтләр татар әдәбиятындагы романтик мотив һәм настроениеләрнең тагын да күтәрелеп китүенә азык бирделәр. Мондый күренеш башлыча беренче рус революциясе елларында көчәеп, изелгән шәхеснең азатлык көрәшенә кушылуын, ашкынуын чагылдырды. Гомумән алганда, ул көрәш гражданлык азатлыгы һәм милли ирек өчен барган зур демократик хәрәкәтнең бер гәүдәләнеше иде. Бу прогрессив романтик идеаллар бер бөтен булмыйча, алар, нигездә, ике юнәлештә тәрәккый итә башладылар. Берсе шәхес азатлыгын төп максат итеп алга этәрде. Ф. Әмирханның Газизе: «Хөррият шәхсиям[1] миңа бар нәрсәдән дә кадерле. Мине татар җизненнән (тормышыннан) туйдырган нәрсә дә именно шул хөрриятe шәхсиянең юклыгы» («Яшьләр»), — дип игълан итүдә татар әдәбияты аша үткән бер романтик идеал яңгырады. Аның көчле мотивлары С. Рәмиев поэзиясендә урын алып, шунда ук

[1] Шәхес ирегем.

андый омтылышларның халык азатлыгы идеалы белән бәйләнеше байтак зәгыйфь булуы да күренде. С. Рәмиев тудырган романтик лирик геройда индивидуализм һәм бунтарьлык сыйфатлары өскә калкып чыктылар. Шәхес көрәшенең иҗтимагый максатлары томанлы һәм чикле булганлыктан, бу герой тарихи оптимизм югарылыгына күтәрелә алмады. Әмма шулай да, аңардан кеше кыйммәте һәм ирек өчен көрәшкә сусау тавышы ишетелеп, ул тавыш татар әдәбиятына тирән булып үтеп керде.

Икенче романтик юнәлеш исә, шәхеснең халык белән, аның көрәше белән бәйләнешкә омтылышын чагылдырып, җәмгыятьне яңадан кору өчен барган киң демократик хәрәкәт җирлегендәге тарихи оптимизм белән рухланды. «Юк, юк! Кол булып гомеремне үткәрәсем килми. Үз ирегем белән кулыма богаулар киясем килми. Туры юлны табасым һәм шул юлдан барасым килә», — дип ашкына Г. Коләхметовның романтик герое Давыт («Ике фикер») һәм шул туры юлны, чын хакыйкатьне халык азатлыгы өчен барган сыйнфый көрәш мәйданында, пролетариатның революцион тәгълиматында — «Кызыл фикер» ягында таба.

Поэзиядә прогрессив романтизмның көчле яралгылары Тукай иҗатында да чагылып, татар демократик реалистик әдәбиятының аерылмас сыйфатларына әйләнделәр. Прогрессив романтизм кешенең азатлыгын идеал итүе белән әдәбияттагы герой ролен, аның иҗтимагый активлыгын тагын да югарырак күтәрде. Шул яктан ул реалистик әдәбиятка зур өлеш кертте. Тукайның: «Хөр кеше алдында җирләр һәм дә күкләр калтырар!» («Гөнаһ», 1911) — дип, азат кешенең көченә һәм матурлыгына дан җырлавында алдынгы романтизм девизын ишетмәү мөмкин түгел. Изүче җәмгыятькә каршы күелган һәм үзенә ирек даулаган шәхес, шагыйрь образы — җирдән һәм халыктан югары торган пәйгамбәр яки читлек эчендәге кол кош булып түгел, ә җир тормышы һәм халык рухы белән нык бәйләнгән көрәшче ролендә мәйданга чыкты. Тукайча әйтсәк: «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә!» — дип язылган иде ул романтик геройның байрагына. Тукайдан соң бу байракны аның шәкертләре күтәреп алып киттеләр, һәм Ш. Бабич шикелле талантлы яшь шагыйрьләрнең иҗатындагы романтизм шул халыкчанлык рухы белән үтәдән-үтә сугарылып, аның традицияләре турыдан-туры совет әдәбиятына килеп кушылдылар.

Татар әдәбиятындагы прогрессив романтизмның формалашуында рус һәм Европа романтизмының да роле зур булды. Тукайның Пушкин, Лермонтов, Байрон һәм Гейне кебек шагыйрьләргә мәхәббәтен алардагы романтизмнан һич тә аерып карап булмый. Аның, мәсәлән, Байрон турындагы фикерләре бу ноктадан бик тә гыйбрәтле. «...Бөтен дөньяга «байронизм» мәзһәбен[1] тудырган вә, бәгъзы көчсез кешеләр күңелендә туып та, аларның күңел вә каләм ягыннан гаҗизлекләре сәбәпле, дөньяга чыга алмый яткан бөек, югары вә гүзәл бер хисне руе-зәмингә[2] агызып җибәргән кеше...» дип атады Тукай Байронны. Моннан ачык аңлашыла ки, Тукай прогрессив романтизм әдәбиятының заман һәм кеше белән тирән бәйләнештә булуына игътибар итеп, аның «б е е к, ю г а р ы в ә г ү з ә л» тойгылар тәрбияләүче гуманистик табигатен күрә алган. Шуның өчен дә ул классик романтизм үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итүгә зур игътибар бирде. С. Сүнчәләй кебек шагыйрьләрнең эшчәнлеге турыдан-туры Тукай тәләкләрен тормышка ашыру юлындагы бер тырышлык булып, татар әдәбиятын дөнья күләмендәге прогрессив романтизм традицияләре белән бәйләүгә зур өлеш кертте. Бераздан һ. Такташның күтәрелеп чыгуында да моның әһәмияте аз булмады.

Әмма сөйләнеп үтелгәннәрдән Тукай, романтизм белән реализмны бер-берсеннән аерып карап, соңгысына өстенлек биргән, дигән нәтиҗә чыкмаска тиеш. Шунысы, бәзнеңчә, бәхәссез: бу ике иҗат методы татар шагыйре мирасында беренче мәртәбә тыгыз мөнәсәбәткә кереп, бер-берсеннән аерылмас башлангыч тәшкил иттеләр һәм милли поэзиянең үсешендә яңа дәвер ачтылар. Романтик элементлар Тукай реализмының эчке, психологик җирлеген һәм гуманистик табигатен баеттылар. Бу яктан да аңарда Пушкин һәм Лермонтов традицияләренең роле кечкенә булмады. Бу ике шагыйрь дә рус поэзиясендә романтизм белән реализмның органик керешү дәверен башлаганнар иде. Егерменче йөз башындагы татар әдәбиятында исә Тукай иҗаты шуңа охшаш бурычны үтәде.

[1] Мәктәбен, агымын мәгънәсендә.

[2] Җир йөзенә.

Татар әдәбиятының барышына һәм язмышына фәкать «көнчыгыш романтизмы» ноктасыннан гына карап, рус һәм Европа йогынтысына каршы торучылар, әлбәттә, Тукай иҗатындагы реализмның да, романтизмның да мәгънәсен аңламадылар. Алар Тукай иҗаты тора-бара «ирекле көнчыгыш рухы»ннан аерылып калды, дип күрсәтергә маташтылар. Шундый карашны яклаучылардан берсе, мәсәлән, Н. Думави булып, ул — кеше, сәнгать иясе хыялында иман һәм мәхәббәт өстенлек итә, ә алар фән һәм акыл белән сыеша алмыйлар, дип чыкты. («Аң» журналы, 1916 ел, 9 сан.) Мондый карашлар шул вакытларда күп таралган идеализм, декадентлык шаукымыннан башка нәрсә түгел иде.

Тукай иҗатының дидактик, үгет-нәсихәт әдәбияты белән бәйләнештә башлангане — билгеле нәрсә. Әмма шагыйрьнең кыюлыгы һәм новаторлыгы да шунда иде ки, ул бер үк вакытта дидактизм басымыннан котылу һәм реализм юлына чыгу өчен көрәшне дә башлап җибәрде. Ул бик тиз арада дидактик поэзиянең метафизик, катып калган нормаларыннан югары күтәрелеп, чынбарлыкка тарихи һәм психологик мөнәсәбәт җирлегендә тормышны, кеше уй-тойгыларын сәнгатьчә, шигъри чагылдыру серен ача алды. Әнә шундый мөнәсәбәт аның иҗатындагы тематик колач киңлеген тудырды, аның дөньяга эстетик карашы күп яклы һәм иҗтимагый-әдәби интереслары төрле булуын таләп итте. Шагыйрьнең замандашлары арасында аның иҗатындагы бу граждaнлык сыйфатларына, шигъри күптавышлылыгына, полифонлыгына эчке бөтенлек һәм эзлеклелек хас түгел диючеләр дә булды. Ә чынлыкта исә, Тукай лирик дөньясы бер бөтен булып, аның үзәгендә шагыйрьнең конкрет образы басып торды. Ул образның үз биографиясе һәм тарихи эволюциясе бар. Шуна күрә Тукай лирик герое шагыйрьнең үз реаль шәхесенә бик тә якын, ә һич тә аңардан аерым яки шартлы түгел. Ул, тормыш белән иң кискен каршылыкларга кергәндә дә, үз эченә бикләнмәде, әйләнә-тирәдәге тормыштан ваз кичеп, аңардан «югары» күтәрелеп, үз манарасыннан торып кына ләгънәт укларын яудырмады. Нәкъ менә шул сыйфат — тормышның, вакыйгаларның һәм уй-кичерешләрнең хәрәкәтчеллегенә туктаусыз игътибар, аларның күп якларын үз эчке дөньясына кабул итеп поэзиягә әверелдерү сәләте Тукай иҗатының реалистик тирәнлегендә ята да инде. Аңардагы сурәтләү чаралары, эпитет һәм троплар туктаусыз үзгәреш һәм хәрәкәттә булып, алар шагыйрь уй-тойгыларының, чынбарлыкны сәнгатьчә хис итүенең активлыгын күрсәтәләр.

Һичбер вакыт булмаганча, Тукай татар поэзиясен гражданлык пафосы һәм публицистик эчтәлек белән баетты. Милли поэзия хәзинәсенә заманы өчен бик тә әһәмиятле булган иҗтимагый-политик темаларны, мотивларны алып килде. Болар һәммәсе шагыйрьнең дөньяга карашы, хис дөньясы аша үткән һәм шигырь сәнгатенең төз, гармоник формасын алган поэзиягә әйләнде.

Тукай иҗатында аңа кадәр татар әдәбиятында күренмәгән темалар һәм идеяләр генә түгел, хәтта сәнгать игътибарыннан бөтенләй читтә торырга тиеш дип каралган тормыш, көнкүреш «вaклыклары» да эстетик мәгънә алдылар. Һәрвакыт һәркемнең күз алдында җәелеп, таркалып яткан тормыш «прозасы»на татар поэзиясендә тулы хокук бирелде. Болар һәммәсе шагыйрьнең стилендә дә үзенчәлекле һәм күп буяулы төсмер тудырдылар.

Лексикада гына түгел, ә экспрессив чараларда да шигъри тел белән гади сөйләм арасындагы чикләрне, барьерларны Тукай кыю рәвештә «җимерә» башлады. Моны, барыннан да элек, татар поэзиясенә «кыю гыйбарәләр» алып килү, шигырь белән публицистика арасындагы традицион һәм тематик чикләрне алып ташлау, шигырь һәм проза кебек лексик катламнарны аралаштыру, иң борынгыдан килә торган әдәби стиль чаралары белән җанлы, гади сөйләмне бер-берсенә якын кую дип аңларга кирәк. Мондый күренешләр, әлбәттә, Тукай иҗатының беренче нәүбәттә, реалистик табигате белән аерылмаслык булып бәйләнгән иде.

## II

Көнчыгышның озак гасырларга сузылган дидактик-рационалистик поэзиясе шәхеснең, кешенең эчке, субъектив дөньясына, аның тарихи үзгәручән диалектикасына аз игътибар бирде, чөнки моның өчен кирәкле иҗтимагый шартлар тумаган иде яки акрын үсте. Патриархаль-феодаль йомыклыкның озак дәверләр какшамас булып торуы

поэзия белән шәхеснең эчке дөньясы арасындагы тормышчан мөнәсәбәтләргә, якынаюга киртә булды. Дин яки фикерләү догмалары мөмкин кадәр үзгәртелмәскә, җимерелмәскә тиеш дип каралды. Мондый догмаларның сәнгатькә дә тәэсире, басымы көчле иде. Шул сәбәптән, шигъри канун һәм традицияләрдә дә һәр искенең какшамаска тиешлеге дәгъва кылынды һәм дәвердән-дәвергә күчә килде. Традицияләр аша яналыкка юл ачу максаты беренче булып тормады. Татар поэзиясе дә шундый авырлыклар эчендә үсте. Тукай исә, революцион чорның яңа идеяләре, тойгылары белән рухланган шагыйрь буларак, милли поэзияне шул авырлыклар басымыннан тиз арада коткару бурычының күп өлешен үз өстенә алды. Ул Көнчыгыш поэзиясенә хас шартлы формалардан, кануннардан һәм шигъри чаралардан күп югары күтәрелде, нинди дә булса бер поэтика нормаларына гына буйсынып калмады, тормышны һәм уй-кичерешләрне реалистик чагылдыру юлына алып чыккан ирекле поэтиканың олы капкасын ачты.

Ирекле поэтика дигәч тә, Тукай элекке әдәби мирас традицияләреннән тәмам арынып, саф новаторлык юлына чыкты һәм «өр-яңа шигъри мәктәп» тудырды мәгънәсендәге беркатлы һәм яссы фикер, әлбәттә, күз алдына килмәс дип уйлыйбыз. Киресенчә, сәнгать һәм әдәбияттагы яңалык, новаторлык, борылыш, үзгәреш фәкать элекке мирас һәм традицияләргә нык бәйләнгән, таянган хәлдә генә мәгънәле һәм яңа чорның сәнгатьчә таләпләренә җавап бирерлек булырга мөмкин. Тукай иҗаты — шушы хакыйкатьнең классик мисалларыннан берсе. Һичбер яңа әдәби форма кинәттән генә, үзлегеннән генә килеп чыкмый. Заманның яңа идея-эстетик ихтыяҗларын шагыйрь, художник күпме тулырак һәм тирәнрәк аңлау сәләтенә ия булса, аның әдәби, сәнгатьчә формаларны яңартуга, үзгәртүгә кертән өлеше дә зарури һәм нәтиҗәле. Монда яңа үсемлекләр үстерүче галим-бакчачы белән табигать арасындагы мөнәсәбәткә билгеле бер күләмдә охшашлык бар шикелле. Тукай поэзиясендәге форма яңалыклары турында сөйләгәндә дә, менә шундыйрак бер табигый хәл күз алдына килә. Безнең шагыйрь иҗатында Көнчыгыш поэзиясенең иң борынгы үрентеләре белән Көнбатышның XIX—XX гасырдагы поэзиясе һәм татар халык иҗаты үрентеләре тыгыз бәйләнешеп, аралашып, ялганышып һәм кушылып үсеп киттеләр. Бу — төрле җирлектән килгән үрентеләр, Тукай шигырь бакчасында яңа төр үсемлек дөньясына әверелеп, яңа һәм мул җимешләр бирделәр.

Көнчыгыш поэзиясендәге традицион формаларның, жанрларның күп кенә төрләрен Тукайның файдаланганлыгы шулай ук сер түгел. Әмма шагыйрь аларны ничек кабул итте һәм яңартты кебек сорауларга җавап һаман да бирелгәне юк әле. Чөнки ул җиңел генә табылмый һәм өстә генә ятмый.

Реалистик поэзиядә жанр чикләре, кануннары классицизмдагы шикелле катгыйлеге белән таләп ителми яки романтизмдагы кебек фәкать сайланма жанрлар гына күздә тотылмый. Анарда һәртөрле жанр урын ала. Кеше уй-тойгыларының байлыгын, чынбарлыкның катлаулылыгын, төрлелеген сурәтләү максаты реалистик поэзиядә жанрлар һәм формалар арасындагы бәйләнешне һәм керешүне тагын да үстерә, ныгыта. Анда инде жанр һәм формалар иерархиясе юк. Классицизмның рациональ (акыл белән үлчәү) яки романтизмның эмоциональ (хис белән үлчәү) чикләре читкә этәрелә, һәм бу ике күренешнең, башлангычның икесен бер бөтен, гармоник чагылдырган төрле жанрларга тигез урын бирелә. Тукай поэзиясендәге жанр һәм формаларны караганда да, әнә шул сөйләнеп үтелгән моментларны истә тотарга кирәк. Һичшиксез, Көнчыгыш поэзиясендәге традицион форма һәм жанрларга мөнәсәбәттә Тукай реалистик позициядән килде һәм татар поэзиясендә аларның тирәннән яңара, үзгәрә башлавына нигез салды.

Соңгы елларда чыккан кайбер хезмәтләрдә Тукай поэзиясендә, мәсәлән, традицион газәлнең тирән үзгәрешләр кичерүе, яңартылуы хакында билгеле күләмдә искә алынып үтелде инде [1]. Мәгълүм ки, газәл ул Көнчыгыш классик поэзиясендәге лирик форманың иң борынгыларыннан, зурларыннан һәм күп таралганнарыннан. Күпчелек очракта мәхәббәт темасы белән бәйле булган бу шигъри жанрның эчтәлеге заманнар аша акрынлап катлаулана һәм үзгәрә килгән. Анарда теге яки бу күләмдә иҗтимагый

[1] Карагыз: Х. Госман. Татар шигыре. 77—85 битләр; История татарской советской литературы. Рус телендә. Мәскәү. 1965 ел, 25 бит.

мотивлар да урын ала барган. Шулай итеп, газәлдә чагылган уй-кичерешләр мәхәббәт белән генә чикләнми башлаган. Моңа охшаш бер хәлне Европа поэзиясендә, мәсәлән, элегия жанры да кичергән.

Тукай иҗатында газәлнең иҗтимагый-гражданлык эчтәлеге аеруча киң һәм бай булып ачылып китте. Аңардагы газәл формасында традицион-шартлы элементлар күпме генә сакланмасын, ул жанрда шагыйрь конкрет чор кешесенең катлаулы кичерешләрен һәм иҗтимагый-фәлсәфи карашларын эзлеклелек һәм тулылык белән гәүдәләндерде. Нәкъ шушы җирлектә газәлнең структурасында да әһәмиятле үзгәреш барлыкка килде: традицион газәлгә хас булганча, строфалар — бәетләр ирекле-ге, ягъни аларның урыннарын алмаштыру яки хәтта төшереп калдыру мөмкинлеге шикелле ирек-лек, бик нык чикләнде. Әгәр дә традицион газәлдә строфалар арасындагы бәйләнеш — уй-кичерешләр градациясен, эчке үсешен гәүдәләндерү тик яралгы хәлендә генә булса, Тукай газәле исә шагыйрь уй-тойгыларының диалектикасын, хис һәм фикерләренең бердәм тибешен, аларның катлаулы бер ноктада киеренке булып агылышын чагылдырды. Рус поэзиясендә беренче булып Пушкин элегиягә үз тормыш тәҗрибәсен салган булса, шуңа охшаш күренешне татар поэзиясендә Тукай газәл жанры аша күрсәтте. Аңарда субъектив-лирик башлангыч бик ачык булып, шагыйрьнең үз заманы кешеләренә турыдан-туры төбәлгән кайнар монологы бәреп торды. Бу хәл, үз нәүбәтендә, газәлнең эчтәлеген бик нык үзгәртеп, аны Көнбатыш поэзиясендәге элегия һәм рустагы дума жанрларына якынайтты. Тукайдагы газәл үзенең формаль тышкы билгеләре белән байтак кына очракларда рифмалар аша беркетелгән бәетләр тезмәсен хәтерләтсә дә, асылда ул бер бөтен лирик монолог, уй-тойгылар градациясеннән гыйбарәт әсәр. Шушы ноктадан караганда, аның ныклы поэтик темасын һәм сюжетын табу да җиңел. Мисал өчен «Яшьләр» (1910) шигырен генә алып карагыз. Аның газәл формасында төзелгәнлеге күренеп тора. Әмма эчтәлеге Лермонтов поэзиясендә зур урын алган дума жанрын хәтерләтә: ул татар яшьләренең заманга, тарихи барышка һәм үз халкына мөнәсәбәте турындагы тирән борчылулы уйлар белән тулы. Шул ук елда язылган «Өзелгән өмит» шигырендә дә шундый ук тышкы билгеләр: бәетләр һәм аларның рифмалашу тәртибе кебек, газәл формасына хас элементлар сакланган. Ә эчтәлектә шагыйрьнең коллык һәм реакция белән көрәш шартларында туган газаплы уй-кичерешләренең көчле лирик ташкыны чагылган. Монда инде элегия жанры белән охшашлык зур. Шул рәвешчә, Тукай, традицион газәлнең билгеле бер шартлы элементларын саклаган хәлдә, аны бик нык яңарта: аңа үз заманының уй-кичерешләрен салып, лирик геройның, шагыйрьнең үз биографиясе аша үткәрә, азатлык өчен көрәш юлына чыккан яшь кешенең катлаулы һәм каршылыклы психологик тарихын ача. Монда инде тышкы яктан газәлгә охшаган бәетләрнең саны да, үзара бәйләнешләре һәм хәтта рифмалашулары да элекке, традицион дәрәҗәсендә катып калмадылар. Бер газәл генә түгел, Көнчыгыш поэзиясенең башка төр һәм жанрлары да Тукай иҗатында шундый рухта тирән үзгәреш кичерделәр, милли форманың аерылмас бер элементына әверелделәр.

Тукай поэзиясен tуkландырган традицияләрне һәм шагыйрь татар шигыренә биргән яңалыкларны өйрәнү мәсьәләсенең тармаклары һәм проблемалары күп. Боларның кайбер әһәмиятле өлешләре безнең әдәбият белеме тарафыннан көн тәртибенә куелган инде. Шундыйлардан берсе итеп, мәсәлән, татар шигырь төзелешенә Тукай ясаган реформа мәсьәләсен алырга мөмкин.

Күп вакытлардан бирле әдәбият белгечләребезнең игътибарын җәлеп иткән нәрсә — Тукай төрки силлабик шигырьне ни дәрәҗәдә гарәп-фарсы поэзиясендәге аруз (гаруз) метрикасына һәм рус поэзиясендәге силлабо-тоник системага бәйли яки якынайта алды рухында булып, бу көндә дә ул үзенә лаеклы җавапны көтеп кала әле. Моңа кадәр булган тикшеренүләрнең күпчелегендә Тукай арузга ияреп иҗат итә башлады һәм аңардан аерылмады, яки, киресенчә, ул арузны силлабика һәм силлабо-тоника белән алмаштырды кебек капма-каршы фикерләр әледән-әле кабатлана тордылар, һәм соңгы вакытларга кадәр алар һаман да үзләрен сиздерәләр әле.

Сугыштан соңгы елларда, башка бик күп фән өлкәләрендәге шикелле үк, шигырьне өйрәнү юлында да тирән ачышлар һәм үзгәрешләр мәйданга килде. Шушы процесста түбәндәге хакыйкый бер фикер какшамаслык булып расланды дисәк — һич хата булмас: «Шигырь төзелеше ничек кенә специфик һәм үзенчәлекле булмасын, ул телгә бәйле һәм сөйләмнең милли формаларыннан тышта кабатлана алмый. Поэзиянең сәнгать-

тә иң милли форма булып калу сәбәбе дә менә шунда» (Б. Томашевский. Стих и язык. М.— Л., рус телендә, 1959 ел, 68 бит).

Гомумән төрки шигырь тарихы һәм аеруча аның милли тармаклары үсеше бу фикернең хаклыгын тулысы белән раслый. Соңгы елларда казакъ, әзербәйҗан, татар, башкорт, уйгур һ. б. төрки халыклар шигыре тирәсендә барган бәхәс һәм тикшеренүләрнең үзәге шуңа кайтып кала. Әмма төрки шигырьдәге аруз традицияләренә килеп кагылу белән, карашларда төрлелек һәм каршылыклар бигрәк тә калку булып чыгалар. Берәүләр, төрки классик шигырь аруз йогынтысы белән генә чикләнмәде, ә аны үзенең метрик нигезе итте, дигән фикерне яклыйлар. Ә икенче берәүләр төрки поэзиягә борынгыдан ук халык шигыре генә (бармак кына) хас булмыйча, төрки телләрнең фонетик үзенчәлегенә бәйле бер күренешкә — ачык һәм ябык иҗекләрнең чиратлашуына нигезләнгән классик шигырь дә хас икәнлеген дәгъвалыйлар. Мәсәлән, Х. Госман «Татар шигыре» (1964) дигән хезмәтендә тулысы белән шушы карашны алга сөрә. Төрки һәм шул исәптән татар шигырь төзелешенә карата шушы ноктадан килеп тикшерү ясый башлау, һичшиксез, кыю бер адым. Моны, билгеле, электә татар әдәбият фәнендә әйтелгән фикерләрне атлап үтү, ташлап калдыру мәгънәсендә аңларга кирәкми. Төрки һәм татар классик поэзиясендә ачык һәм ябык иҗекләр чиратлашуы — иң әһәмиятле бер күренеш булу күптән ачылган һәм өлешчә тикшерелгән инде. Х. Госман, моны тагын да тирәнрәк һәм төгәлрәк тикшереп, төрки тел законнары белән бәйле мөстәкыйль бер шигъри күренеш итеп аңлатырга теләде.

Тукай шигырь төзелешендә аруз белән охшашлык, якынлык кайдан килгәнлегенә, нидән гыйбарәт булганлыгына игътибар итеп тә, татар милли шигыренең үзенчәлеген читтә калдыру — менә бу элекке тикшеренүләрнең зур кимчелеге булды. Бөтенләй башка бер тел законнарына һәм шигъри нормаларына буйсынган аруз нигә һәм ни дәрәҗәдә татар теле җирлегендә туган шигырь кагыйдәләренә, ритмикасына, мелодиясенә чыганак һәм таяныч булырга тиеш дигән сорау куелмады, ә киресенчә, аруз — төрки поэзияләрнең милли формасы мәгънәсендәрәк күз алдына китерелде.

Арузны башка әдәбиятларның милли формасы дәрәҗәсенә куеп карауның дөрес булмаганлыгын искәртеп, таҗик әдәбияты белгечләреннән З. Г. Османова болай ди: «Метрик системаның фәкать бер органик кисәге буларак, аруз фарсы һәм таҗик әдәбиятларының, шулай ук Урта Азия һәм Кавказдагы кайбер башка әдәбиятларның милли формасындагы күпләгән компонентлардан берсе булып тора» («Социалистический реализм в литературах народов СССР», җыентык. Мәскәү, 1962 ел, 162 бит). Күп гасырлар буенча гарәп арузы тәэсирендә үскән фарсы-таҗик поэтикасын өйрәнүчеләр шундый нәтиҗәгә киләләр: «Шигырь метрикасы өлкәсендә, — ди, мәсәлән, С. Айни, — таҗиклар гарәпләрдән фәкать терминнар, үлчәүләр һәм үлчәү төрләре — әфагыйль алганнар» (шунда ук, 160 бит).

Башлыча фарсы-таҗик поэзиясе аша кергән арузның төрки шигырьдә тагын да башкачарак дәрәҗәдә булуы, байтак үзгәрешләргә дучар ителүе шулай ук билгеле. Заман үткән һәм төрки поэзияләрнең милли тавышы көчәйгән, милли җирлеге ныгыган саен, алар белән аруз арасындагы мөнәсәбәтләр дә үзгәрә барганнар. Шул процесста гарәп-фарсы арузыннан байтак аермалы булган төрки аруз[1] формалашкан. Әгәр дә борынгырак чорда гарәп-фарсы арузының билгеле бер нормаларына төрки шигырьне хәтта буйсындыру, көчләү күренешләре күбрәк очраса, соңгы чорларда исә төрки милли поэзияләрнең үз нормалары һәм үзенчәлекләре өстенлек ала һәм аруз элементларын үзенә буйсындыра барган. Чөнки милли телләрнең үсеше табигый рәвештә шуны таләп иткән. Шуңа күрә төрки поэзияләрнең ритмик табигатен һәрвакыт борынгы нормаларга гына үлчәп карау мөмкин булмавын заман үткән саен әдәби практика үзе үк раслый һәм күрсәтә барган. Димәк, XV гасырдагы төрки аруз белән XX йөз башы татар поэзиясендәге аруз элементлары арасында нинди охшашлык һәм аерма булырга тиешлеген исәпләми сөйләү — догматизмнан башка нәрсә булмас иде. Тукайның һәм замандашларының арузга мөнәсәбәтен караганда да бу момент бик нык истә тотылырга тиеш.

---

[1] Бу термин тюркология фәнендә кабул ителгән. Карагыз: И. В. Стеблева. О проникновении арабо-персидских метров в тюркоязычную поэзию. «Проблемы теории литературы и эстетики в странах Востока» дигән җыентыкта. Мәскәү, 1964 ел.

Һичшиксез, Тукай поэзиясен гомумән Көнчыгыш әдәби традицияләреннән аерып карау мөмкин булмаган шикелле, аны аруздан да читтә калдыру мөмкин түгел. Аның башлангыч иҗаты, беренче шигъри тәҗрибәләре байтак ягы белән арузга барып бәйләнгәнлеге турында күптән әйтелгән инде. Тукай үзенең беренче шигырьләрендә аруз кануннарына ничек һәм ни күләмдә ияргә хакында сөйләүче бер факт итеп, аның мәсәлән, тел-стиль чараларындагы корамалылыкны гына искә алу да житә. Чөнки турыдан-туры арузга ияру шундый корамалылыкка, татар теленә һәм шигыренә чит ясалмалылыкка илтергә тиеш булды. Әмма шуның белән бергә үк шагыйрь татар поэзиясенең үзенә хас табигатеннән башка шигырь язып булмаганлыгын да бик иртә төшенә. Казанга күчеп килгән вакытларда инде ул үзенең бу ышанычларында, караш-ларында тәмам ныгып иҗат итә башлавын күрсәтте. Татар поэзиясе үзенең милли формасыннан башка дөньяга килә алмавын Тукай да һәм аның замандашлары да ачык аңладылар. Бу яктан яшь шагыйрь С. Сүнчәләйгә С. Рәмиевнең 1910 елгы бер җавабы бик характерлы: «Шуны белегез: иң әүвәл без — татарлар, аннан соң гына шагыйрь-ләрбез. Шуның өчен безнең шигырьләребез татар шигырьләре булырга һәм шуның өчен безнең шигырьләребез татар вәзеннәре белән генә үлчәнергә тиешле. Бер дә Сез үзегезне гарәпләр белән чуалта күрмәгез, шигырьләрегезне гарәпләр вәзене белән үлчәмәгез, аларның вәзене безгә бер дә ярамый» («Идел» газетасы, 1910 ел, 29 ноябрь).

Тукай шулай ук татар поэзиясе өчен аруз кануннарын саклаган шигырь бердәнбер үрнәк һәм ул һаман дәвам итәргә тиеш дигән консерватив караштә тормады. Шагыйрь-нең «Халык әдәбияты» (1910) дигән хезмәте генә дә аның иҗат декларациясе нидән гыйбарәт икәнлегенә гүзәл бер дәлил. Киң мәгънәсендә әйтелгән: «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачак-тыр», — кебек фикерләрендә Тукай татар поэзиясе нинди нигездә үсәргә һәм нинди юлдан барырга тиешлеген гаҗәп бер ачыклык һәм сизгерлек белән күз алдына бас-тырды. Шагыйрь, бик кыю рәвештә татар поэзиясенең милли һәм халыкчан кыйбласын билгеләп, аның киләчәгенә өметле караш ташлады һәм юнәлеш бирде.

Ләкин моннан егерменче йөз башындагы татар поэзиясе һәм аеруча Тукай иҗаты гасырлар буенча килгән традицияләрдән һәм шул исәптән аруздан да тәмам аерылды, йөз чөерде дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Сүз монда, беренче нәүбәттә, татар поэзиясе-нең милли үзенчәлеген һәм мөстәкыйльлеген тәэмин итү өчен көрәш кирәклеге, татар поэзиясенең ике аягы белән дә шул юлдан нык басып атларга тиешлеге турында бара иде.

Бу чорда инде традицияләргә мөнәсәбәт һәм аларның татар әдәбиятына бәйләнеше мәсьәләсе дә кискен үзгәреш кичерә. Конкрет алганда, төрки аруз элементлары Тукай иҗатында тагын да нечкәрәк һәм тирәнрәк булып татар шигыренең милли формасы белән яраштылар. Бу инде татар шигырен аруз нормаларына буйсындыру түгел, ә киресенчә булган бер күренеш иде.

Моңа кадәр төрки поэзияне өйрәнүчеләрнең күпчелеге арасында ачык һәм ябык иҗекләр чиратлашуы — арузда озын һәм кыска сузыкларга корылган ритмиканың бер күренеше, хәтта күчермәсе, кабатланышы мәгънәсендәге фикер яшәп килде, һәм ул бүген дә дәвам итә әле. Мондый фикернең күпме нигезле икәнлеген заман күрсәтер. Без бу урында тикшерелә торган мәсьәләнең һаман да каршылыклы булып калуын һәм һәрьяклап өйрәнелергә тиешлеген искәртү белән генә чикләнәбез.

Төрки классик поэзиядәге ачык һәм ябык иҗекләр чиратлашунын аруздагы озын һәм кыска сузыкларга бөтенләй бәйләнеше юк дигән фикерне яклау шулай ук тарихи дөреслеккә күз йому гына булыр иде. Һичшиксез, төрки поэзиядә ачык һәм ябык иҗекләрнең чиратлашу законы арузның искә алынган үзенчәлегенә тыгыз бәйләнештә формалашып, тора-бара үзенә мөстәкыйльлек алган. Димәк, аруз төрки телдә һәм поэзиядә булмаганны түгел, ә булган элементларның ачылып һәм үсеп китүенә тәэсир иткән. Шуңа охшаш хәлләр, мәсәлән, рус поэзиясендә дә булган. Әйтик, авазларның төрле озынлыгы чиратлашуына нигезләнгән метр — антик шигырь рус шигыре өчен дә үлчәм ролен үтәгән. Моның төп сәбәбе итеп шигъри сөйләм нигезендә сүзне музыкаль уку ятканлыгын күрсәтәләр (мисал өчен карагыз: В. Огнев. Поэтическая интонация. «Вопросы литературы», 1961, № 4). Төрки поэзиядәге ачык һәм ябык иҗекләр белән аруздагы озын һәм кыска сузыклар арасындагы мөнәсәбәтне дә иң элек әнә шулай

шигъри сөйләмне музыкаль уку ихтыяҗыннан туган бер күренеш, якынлык итеп карау дөресрәк булмасмы икән? Тукай поэзиясе дә моны расласа кирәк.

Әйткәнебезчә, безнең әдәбият белеме гомумән татар һәм аеруча Тукай поэзиясендә ачык һәм ябык иҗекләр чиратлашуның әһәмиятле бер ритмик күренешкә әверелүен күптән билгеләп үткән иде инде (мәсәлән, Х. Вәли, Г. Нигъмәти хезмәтләрендә). Шул уңай белән Г. Нигъмәтинең үз вакытында бәхәссез саналган бер фикерен искә алыйк: «Соңгы елларына чаклы Тукай шигырьләренең күп кенәсендә ачык һәм ябык иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә нәүбәтләшүләренә игътибар итү, шулай ук иҗекләр саны тигезлегенә генә түгел, иҗекләрнең «зурлыгына» да игътибар итү анда электәге гаруз ритмы элементларының саклану күренешләреннән итеп каралырга тиешле» (Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958 ел, 237 бит).

Шул рәвешчә, Г. Нигъмәти һичбер икеләнүсез Тукай поэзиясендә ачык һәм ябык иҗекләрнең чиратлашуын, хәтта аларның зурлыгына игътибар итүне дә аруздан алынган элемент дип карый. Ни өчен аруз, ә татар теленең һәм шигыренең үз табигате, үз хасияте түгел бу дигән сорау шулай ук гаҗәп булмас. Чөнки Тукайга кадәр үк инде төрки поэзиянең үзендә бу хасият ачылган һәм формалашкан иң. Тукайның шуны татар теле һәм шигыре җирлегендә тагын бер югары баскычка күтәрүе өчен нигә арузга әйләнеп кайтырга кирәк? Тукай аруз кагыйдәләрен күпме генә белгән һәм үзләштергән шагыйрь булмасын, татар поэзиясе милли тел җирлегендә «халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы» белән бәйләнештә туарга, үсәргә тиешлеген ул бик тиз арада аңлап алды һәм шул юнәлештә иҗат итте. Бу коры декларация яки изге теләк кенә түгел иде. Безнеңчә, Тукай поэзиясендә ачык һәм ябык иҗекләрнең чиратлашуы кебек ритмик күренеш, гомумән төрки поэзиядәге шикелле үк, аруздагы озын һәм кыска сузыклар тәртибенә өлешчә охшаган, туры килгән элемент булу белән бергә, татар классик шигыренең бер музыкаль нечкәлеген, гармониясен чагылдырган новаторлык, яңа ачыш итеп тә каралса, хакыйкатьнең реаль мәгънәсен аңлау җиңелрәк булыр иде.

## III

Тукай поэзиясендәге ритм стихиясенең югары дәрәҗәгә күтәрелгән бер сыйфаты — аның көйдән, мелодиядән аерылгысыз булуы. Бу да, гомумән алганда, традицион күренеш. Ләкин мондый көйлелек, музыкальлек кайдан килә, нинди чыганаклардан азыклана? Татар поэзиясендә Тукай — хәтта һәрбер авазның ритмик һәм музыкаль бәрәмлеген сизеп, үлчәп иҗат иткән шагыйрьләрнең иң күренеклесе. Аның шигъри телендә сүзләрнең рациональ, мәгънә эчтәлеге генә түгел, аларның эмоциональ һәм музыкаль төсмерләре дә ялтырап китте, шигъри сыгылмалылыгы (пластиклыгы) ачылды. Бу очракта шагыйрьнең Көнчыгыш поэзиясендәге сүз виртуозлыгыннан бик оста өйрәнүен дә истә тотарга кирәк. Аның шигырьләре үзләреннән-үзләре җырлап, көйгә салынып торуына шагыйрьнең замандашлары аеруча әһәмият бирделәр: «Тукай шигырьләренең укучыны мөсәххәр[1] итә торган хосусиятләреннән берсе тагы — аларның гадәттән тыш музыкальный булуларыдыр. Безнең күп шагыйрьләребезнең татарча язган «шигырь»ләре укып булмаслык дәрәҗәдә авыр булганда, Тукай шигырьләре үзләреннән-үзләре укылалар», — дигән иде Г. Рәхим 1913 елда (Тукай турында замандашлары. 235 бит).

Тукай поэзиясенә хас мондый күренеш шигырь юлларын һәм хәтта строфаларны музыкаль фразага әверелдерә. Бу урында да аруздан килә торган элементларга охшашлык яки якынлык бардыр, бәлки. Аруз шигырен гарәпләр көйсез укымыйлар, диләр. Гарәпләрдә генә түгел, төрки халыкларда да бик борыннан шигырь музыкадан, көйдән аерылгысыз булган иң. Төрки арузда да бу хәл бик нык сакланган. Әмма Тукай шигырьләрендәге көйлелек аруздан киләме икән? Безнең шагыйрьне һәм арузны яхшы белгән замандашлары андый шикләнү белдермәгәннәр кебек. Дөреслекнең нигезе — татар теленең музыкаль, шигъри табигатендә, халык көйләрендә булуын бәхәссез дияседе килә.

Тукай шигырь төзелешенең формалашуына, аның милли үзенчәлеге ачылуга хәлиткеч йогынты ясаган традиция һәм факторларның берсе, һичшиксез, бу — татар халык

[1] Сихерли торган.

поэзиясе һәм музыкасы. Гомумән алганда, Тукай иҗатының халык әдәбияты белән бәйләнеше турында байтак сөйләнелде һәм сөйләнелә кебек. Әмма бу мәсьәләнең дә күп кенә серләре ачылмаган көенчә, яшерен хәлдә тора бирә.

Әлбәттә, Тукай иҗатының халыкчанлыгын өйрәнү юлында хәзер инде элекке белән чагыштырмаслык уңышлы эзләнүләр мәйданга килде. Шулай да, аларның иң зур өлеше Тукай дөньяга карашының социологиясен, идея эчтәлеген күрсәтүгә багышланган, ә шагыйрь поэтикасына, әдәби осталыгына турыдан-туры бәйле булганнары бик аз әле. Мәсәлән, Тукай шигыренең халык җыры һәм музыкасы белән ничек бәйләнеше күтәрелмәгән чирәм хәлендә ята дисәк, шаять, ялгышмабыз. Ә бу бәйләнешнең гаҗәп тирән һәм бай бер сәнгать хәзинәсе икәнлеген шик астына алу яки читләтү — акны кара дию шикеллерәк бер мәгънәсезлек булыр иде.

Күтәрелгән мәсьәләнең күләме һәм эчтәлеге зур икәнлеген истә тотып, без аның тик кайбер якларын искәртеп үтү генә дә алдагы тикшеренүләргә билгеле бер төстә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

Көй белән җыр (шигырь) арасындагы мөнәсәбәт, бәйләнеш турында Тукай үз иҗатының беренче елларында ук уйлана башлый. «Шигырьләребез» (1907) мәкаләсенең беренче юлларында ук ул: «Безнең татарларның шигырь сөйли торган бәхерләре гаять гүзәлдер. Бер татар шигырен әллә ничә төрле көйләргә җырларга мөмкиндер. Безнең татарлар җырлый торган көйгә рус шагыйрьләренең бик күп шигырьләре килеп кенә торадыр... Тагы да гарәпләрчә вә гомум исламча мәмдүх булган[1] «Касыйдәи бөрдә»не дә теләсә нинди татар көе белән җырлап буладыр», — дигән кызыклы гына бер фикерне әйтеп китә. Димәк, шагыйрь татар шигыре белән генә түгел, хәтта башка халыкларның шигыре белән дә татар көе арасында ниндидер ритмик һәм музыкаль бәйләнеш мөмкин икәнлеген сизә. Моның сере нәрсәдә соң? Безнең фикеребезчә, көйнең мелодик колачы киң булуда. Тукай менә шуңа бик игътибар итә һәм шигырьнең көй дулкыннарында тирбәлә алуын кыйммәтле сыйфатлардан саный.

Мәгълүм ки, татар халык җырларының соңгы заманнарда киң таралган һәм ныгыган ритмик үлчәме унбишәр иҗекле юллардан тора. Тукай шигырьләре арасында да һәр юлы унбиш иҗеккә корылганнары зур урын ала. Шагыйрьнең төрле елларда, төрле темаларга язылган һәм төрле уй-кичерешләрен чагылдырган «Пар ат», «Туган җиремә», «Шүрәле», «Китмибез!», «Өмит», «Мәхәббәт», «Өмитсезлек», «Өзелгән өмит», «Сайфия», «Көзге җилләр», «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», «Татар яшьләре», «Ах», «Кечкенә теләк», «Көтмәгәндә» кебек шигырьләрен генә искә төшерик. Болар унбиш иҗекле юллардан гыйбарәт булып, хәзерге көндә таралган «Әтнә», «Арча», «Сарман» шикелле күп кенә көйләргә җырлана алалар. Әмма моның белән без, Тукайның унбиш иҗекле юллардан гыйбарәт шигырьләре һәр очракта да искә алынган типтагы көйләргә җырланалар һәм турыдан-туры халык үлчәменнән киләләр, аларның классик төрки шигырьгә һәм аның аша аруз бәхерләренә һичбер мөнәсәбәте юк, дияргә уйламыйбыз. Монда шунысы кызык: бу төр шигырьләрнең күпчелегендә ритмик мелодия һәм үлчәм тәгәллек белән татар көйләренә туры килеп, ниндидер күләмдә халык җырлары белән очраша. Бу — Тукай поэзиясендә бик характерлы булган эстетик стихиянең киңлеге һәм байлыгы турында сөйләмиме икән? Моны һич тә очраклы бер күренеш дип кенә булмый. Үз нәүбәтендә, бу факт Тукай поэзиясенең милли үзенчәлеге никадәр тирән, нечкә һәм гүзәл булуы, гасырлар аша килә торган шигъри традицияләрнең никадәр бүгенге халык сәнгате белән табигый һәм органик бәйләнеше хакында сөйләсә кирәк. Менә шул ягы белән дә Тукай шигырьләренең татар халкы күнеленә хуш килүенә ышанмыйча булмый. Тукай шигырьләрендәге һәм халык җырларындагы унбиш иҗекле үлчәмнең ритмик буыннарында, паузаларында, цезураларында һәм көй темпларында зур гына аерма бар, әлбәттә. Шулай да, ничек кенә булмасын, Тукай шигырьләренең ритмик дулкыннары белән музыкаль дулкыннар (көй, мелодия) арасында бик күп очракларда тапкыр килү сизелеп тора. Чөнки Тукай поэзиясенең асылында сөйләү ритмикасы түгел, ә көйләү ята. Шуңа күрә ул бик тиз арада үзенең музыкаль ачкычын да таба ала.

Тукай шигыренең көйлелеге, әлбәттә, абсолют сыйфат түгел. Аны сөйләп тә укырга мөмкин. Ләкин ритмикада, цезура һәм интонацияләрдә аның үз законнары һәрва-

[1] Кабул ителгән.

кыт какшамас булып кала. Аларны теге яки бу төстә иректе укырга омтылыш — күп кенә очракта шигырьне гарипләндерәчәк. Тукай татар шигыренең традицион — силлабик нормаларына аеруча ритмик-музыкаль төгәллек бирде. Шуңа күрә ул С. Рәмиевнең «ирекле шигырь» белән бәйле кайбер эзләнүләренә, теоретик карашларына кушылмады. Ләкин моңа карап, Тукай Рәмиевнең татар поэзиясендә сөйләү шигыренә — интонацион шигырьгә юл ачарга омтылуына каршы килде, дигән нәтиҗә ясарга кирәкми. С. Сүнчәләйгә булган хатларының берсендә ул мондый фикерләрне язган иде: «С. Р. нең (С. Рәмиевнең — Г. Х.) вәзеннәр тугрысында артык лаф сугуына исегез китмәсен. Әле без татарларда «теория словесности» вә шигырьләр өчен «хорей», «дактиль» — фәләннәр ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк. Фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифадә[1] кирәк... Тургеневнең көйсез язылган «Отцы и дети» әсәре прозамыни? Анда вәзен рамкалары бер дә юк. Ә между прочим — поэзия!» («Совет әдәбияты» журналы, 1960 ел, 4 сан, 138—139 битләр.)

Аңлашыла ки, Тукай сәнгатьтәге формаль новаторлыкны кире кагып, мәгънәгә, эчтәлеккә ия булган поэзия турында сүз алып бара. Аның фикеренчә, эш шигырьнең формасында түгел, ә төрле эчтәлеккә лаеклы төрле формаларны таба белүдә. Димәк, Тукай үзе татар шигыренең көйле-традицион нигезләрен күпме генә сакламасын һәм үстермәсен, киң мәгънәсендә поэзиянең форма ирекле чикләнмәгәнлеген яхшы аңлый иде.

Күргәнебезчә, Тукай шигыренең ритмик каналлары, чыганаклары күп төрле булып, шулар арасында шагыйрьнең рус поэзиясе белән бәйләнеше дә бик әһәмиятле факторлардан берсе иде.

Традицион төрки шигырь системасын Тукайның рус поэзиясе рухында яңартуы һәм үзгәртүе турында да татар әдәбият белемендә байтак сөйләнелде инде. Шуңа бәйләнештә Тукайның рус поэзиясенә хас силлабо-тоник системаны кабул итүен дәгъва кылулар да аз булмады һәм һаман да булып тора. Ләкин бу мәсьәләнең дә күп кенә нечкә яклары, төп асылы тиешенчә ачыкланмаган һәм тикшерелмәгән хәлдә кала әле.

Бу урында шуны әйтергә кирәк: Тукайның татар поэзиясенә аруз урынына силлабо-тониканы кертүе хакындагы фикер билгеле бер мавыгу һәм көчәнүләр нәтиҗәсеннән башка нәрсә түгел. Шагыйрьнең арузга мөнәсәбәте дә, силлабо-тониканы «кабул итүе» дә гасырлар буенча яшәп һәм үсеп килгән төрки силлабиканы җимерү яки алмаштыру исәбенә булмаганлыгын расларга маташуның хәзер шулай ук артык кирәге юктыр кебек. Моннан һәр үсемлекнең тамыры үзе үсә торган туфрак белән тоташканлыгын һәм шуннан тукланганлыгын шик астына кую, бәхәс кылу сыман бер сафсата гына килеп чыгар иде. Башка-башка системадагы телләр һәм поэзияләр арасындагы мөнәсәбәтләр тик аларның һәрберсенең үз законнарына һәм табигатьләренә туры килү, охшашу яки якынлык чамасының нинди булуы белән генә үлчәнергә, бәяләнергә мөмкин икәнлеге — шулай ук ачык бер хакыйкать. Мәгълүм ки, силлабо-тоник шигырьдә иҗекләр саны һәм ритмик буыннар системасы гына түгел, сүзләрдәге фонетик басымнарның чиратлашуы да зарури закончалык. Шул ике элемент катгый төстә саклanырга тиеш. Ә бу — рус теленең табигатенә турыдан-туры бәйле. Төрки шигырьдәге силлабика исә иҗекләр санының билгеле бер чиратлашуыннан гыйбарәт булып, ул сүз аралыгы һәм ритмик буыннар системасына корылган. Бу да төрки телләрнең табигатеннән килә. Шуңа күрә төрки шигырь арузны туры һәм тулы мәгънәсендә кабул итә алмаган шикелле, силлабо-тониканы да үз җирлегенә нигез итеп күчерә алмый. Димәк, сүз теге яки бу шигъри системаның аерым элементларын, мәсәлән, бу урында татар шигырен баету, камилләштерү өчен файдалану турында гына барырга мөмкин. Тукай да нәкъ шундый юлны тотты. Аның русчадан тәрҗемәләре яки рус шигырьләренә охшатып язган кайбер әсәрләре арасында билгеле бер төстә силлабо-тоник интонациягә тартымлылык белән аерылып торганнары да бар. («Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Кичке азан», «Бала белән күбәләк» һ. б.) Бу тартымлылык, бер яктан, татар сүзләрендәге фонетик басымнарның сүз азагына туры килүе белән, ә икенче яктан, ритмик басымнарның урыны белән тәэмин ителә. Ләкин рус сүзләрендәге басымнар закончалыгына корылган силлабо-тоникадагы принцип һич тә нигез булып ятмый. Русча шигырьләрне файдаланганда яки тәрҗемә иткәндә, Тукай

[1] Әйтә белү мәгънәсендә.

оригинал үлчәменә һәм ритмикасына якынлыкны беренче нәүбәттә юллардагы иҗек һәм хәтта аваз саннарының тәгәллеге белән тәэмин итәргә омтыла. Нәкъ менә шушы урында арузга булган мөнәсәбәт һәм бәйләнешнең дә бер сере ята шикелле. Димәк, татар шигыренең силлабик принципларын нык саклаган хәлдә, шагыйрь силлабо-тоника белән ритмик һәм интонацион уртаклыкның гаҗәп матур, көчле яңгырашына ирешә, алар арасында охшашлык иллюзиясен тудыру серен ача. Бу да төрки силлабиканың мөмкинлекләрен киңәйтү һәм баету юлындагы зур ачыш, новаторлык иде.

Рус классик поэзиясеннән үрнәк алып, Тукай татар шигыренә синтаксик берәмлекләрне бүлү, күчерү (перенос) һәм тезем (период) шикелле күренешләрне кертеп, шулай ук төрки поэзиядәге традицион норма чикләрен атлап чыкты, күпкә киңәйтте. Күренекле филолог Ш. Рамазанов үзенең «Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» исемле мәкаләсендә тезем кебек катлаулы шигъри һәм синтаксик форманың, үрнәкләрнең татар поэзиясенә килеп керүен элек булмаган әһәмиятле бер яңалыкның барлыкка килүе дип бәяләгән иде. «Бу үрнәкләр үзләренең сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан Пушкин һәм Лермонтов үрнәкләренә охшыйлар»,— дигән нәтиҗә ясады Ш. Рамазанов («Татар теле буенча очерклар», 1954 ел, 90 бит).

Тукай тудырган теземнәр бер һәм берничә строфадан башлап бөтен бер шигырьне тәшкил итәләр («Китап» һ. б.). Бу урында характерлы бер мисал китерми калу кыен:

Шома тормыш юлында гизгәнеңдә яңлышып тайсаң,
Иезеннең дәфтәренә син хайаән кер вә тап салсаң,
«Кабахәт», «бәдбәхет», «юньсез» кеби күп ямьсез ат алсаң,
Сине ташлап бөтен дөнья, үзең ялгыз фәкать калсаң,—
Белеп тор: мин чыгармын таш күңелләләр арасыннан,
Көлеп тормам, карап читтән, синең бәхтең карасыннан...

(«... га», 1911)

Шул рәвешчә, милли шигырьне бер юл күләме белән чикләнгән синтаксик конструкциядән азат итү шигырь юлларын һәм хәтта строфаларын җанлы сөйләм законнары буенча, шигъри фикерләү логикасы, агылышы буенча җәелдерү мөмкинлеген тудырды. Шигырьнең мәгънә колачы һәм ритмик сулышы киңәйде. Тукай керткән бу яңалыкны башка шагыйрьләр дәвам иттерделәр, үстерделәр.

Сөйләнгәннәрдән кыскача нәтиҗә шул: Тукай поэзиясе — һәм эчтәлеге, һәм формасы белән бик катлаулы һәм бай сүз сәнгате. Аның ачылмаган серләре һәм нечкәлекләре гаять күп. Бу мәкаләнең төп максаты — Тукай шигъри мирасын төрле яклап тирән итеп тикшерү, өйрәнү үзенең бөтен җаваплылыгы белән көн тәртибендә торуын искәртүдән гыйбарәт.

---

### САЛКЫН ИЧ...

*(Тукай исеме белән бәйләнгән мәзәкләрдән берсе)*

Чынмы, уйдырмамы, йөгенә керә алмыйм. Вакыйганың эчендә булган кешедән ишеткәнемне сөйлим:

— Төнге сәгатьләрнең берсе. Каяндыр кайтып килгән бер төркем яшьләр (Тукай, Г. Ибраһимов, тагын кемнәрдер, шушы мәзәкне сөйләгән Ибраһим Күли, арада Исхак Бикчурин да була) арасында Столыпин реакциясе, цензура басымы, иҗат эшендәге кысынкылыклар турында зарлану сүзләре булды. Эсер журналист Бикчурин: «Төкер дөньясына, әйдәгез Кабан күле бәкесенә ташланабыз», ди.

Кабаны да без килгән Балык базары (хәзерге Куйбышев) урамы өстендә, бәкесе дә күпер төбендә, борылып кына төшәсе. Сукыр күп күрер, аксак күп йөрер диләр, бәкегә табан беренчеләп китүче дә аксак Бикчурин булды. Батарга исәпләре булмаганнар да иярделәр.

Хатын-кыз кер чайкый торган бәкегә җиттек. Бездән башка берәү дә юк. Тукай «бисмиллаһ» дип бармагын бәкегә тыкты да:

— Я ходай! Монда ничек батмак кирәк, салкын ич... — диде. Шуннан: — Егетләр, чак кына сабыр итегез, кайтып тун киеп килим әле мин, — дип китте.

«Фаҗига» көлкегә әйләнде. Аның артыннан иярдек.

Язып алучы: И. РӘМИ.

*Резеда Ганиева*

# УРТАК КОЯШЫБЫЗ

Лак халкының танылган язучысы, җәмәгать эшлеклесе һәм күренекле революционеры Сәет Габиев сөекле шагыйребез Габдулла Тукайны, борынгы Русьның мәшһүр җырчысы белән чагыштырып, «Волга елгасының бөек Бояны» дип атады [1]. Бик гыйбрәтле, зур һәм тирән мәгънәле сүзләр бу!

Әйе, Тукай әдәби зәвыкларының горизонтлары гаять тә киң иде. Ул, зур ихтирам белән, бөек рус шагыйрьләре Пушкин белән Лермонтовны үзенең әдәби остазлары итеп кабул итә, аларның тәрҗемәләре һәм иктибаслары аша инглиз, немец әдәбиятларының даһи әдипләре Шекспир, Байрон, Шиллер, Гёте һәм Гейне иҗатлары белән таныша. Тукай Фирдәүси, Хаям, Низами, Хафиз һәм Физулиләрдән тырышып өйрәнә. Көнчыгыш халыкларының яңа заман әдәбиятын һәм вакытлы матбугатын зур кызыксыну белән күзәтеп бара. Төрек һәм әзербайҗан әдәбиятының күренекле вәкилләре Габделхак Хәмид, Намыйк Кәмал, Тәүфыйк Фикрәт, Җәлил Мамедкулизадә, Галиәкбәр Сабир иҗатларына аеруча зур игътибар бирә. Шул рәвешчә, татар шагыйре иҗатында бөтендөнья әдәбиятының — һәм көнбатыштагы, һәм көнчыгыштагы — традицияләре аерылгысыз бер бөтен булып кушылалар.

Тукайның көнчыгыш әдәбиятларына булган мөнәсәбәтен билгеләгәндә, без нигездә ике моментны: бу әдәбиятлардан иҗади өйрәнү, һәм, алган традицияләрне сыйфат ягыннан үзгәртеп, аларны яңартып, үзләренә үк кайтару процессын күрәбез.

Тукай шигырьләренең образ-сурәтләр системасы, форма үзенчәлекләре күпчелек очракта урта гасыр көнчыгыш әдәбиятлары традицияләрен хәтерләтә. Шагыйрь еш кына гарәп, фарсы, төрек һәм иске татар романтик поэзиясе өчен хас булган мәдхия, касыйдә, газәл, кыйтга жанрларына мөрәҗәгать итә. Ләкин ул көнчыгыш поэзиясенең эчтәлек һәм форма мөмкинлекләренә новатор буларак якын килде, үз заманының милли-азатлык хәрәкәте таләпләреннән чыгып, аларга яңа иҗтимагый яңгыраш, яңа идея-эстетик мәгънә бирде. Озак гасырлар дәвамында мәхәббәт лирикасының традицион формасы булып исәпләнгән газәл жанры Тукайда тирән социаль эчтәлек белән баетылды. Моңа ачык мисал — «Көзге җилләр» шигыре. Биредә лирик геройның мәгъшукасы белән очрашу яки аерылышуы турында да сөйләнми, кавыша алмаганга аһ орып, елау-сыкрау да юк, героиняның матурлыгын мактау өчен «бакча», «гөл», «сандугач» кебек традицион образлар да кулланылмаган. Тукайның «Көзге җилләр»е хезмәт белән капитал арасындагы каршылыкны күрсәткән социаль контрастлар белән тулы, һәм бу шигырьдә сәнгатьчә гомумиләштерүнең нигезләре дә бөтенләй башка. Идеаллаштыруга нигезләнгән һәм традицион романтизм методы белән язылырга тиеш булган газәл урынына, «Көзге җилләр»дә без тирән психологизм, трагик буяулар һәм ямьсез көлке (безобразно-комическое) башлангыч белән үреп бирелгән критик реализм әсәрен күрәбез.

Көнчыгыштан килә торган традицияләргә иҗади якын килүне мәдхия, касыйдә жанры мисалында да күреп була. Бөек мәдхияче Хакани (1120—1199) заманыннан килә торган ода поэзиясенең югары стилен, күперенке үгет-нәсихәтчелеген, абстракт-романтик фикерләвен Тукай агитацион-публицистик максатларга буйсындырды, реаль эчтәлек белән баетты. Гасырлар буенча җир һәм күк аллаларын мактаган, кеше табигатенең әхлакый асылын яңартуны максат итеп куйган фәлсәфи һәм панеги-

[1] «Мусульманская газета», 1913 ел, 8 апрель, 16 сан. (Даталар иске стиль белән бирелә.)

рик касыйдәләр Габдулла Тукай иҗатында татар феодаль-буржуаз җәмгыятенең черек нигезләре турында җитди уйланырга мәҗбүр иткән, иҗтимагый явызлыкка каршы көрәш кирәклеген раслаган публицистик шигырь булып үсеп киттеләр. Көрәшкә чакыру, өндәү формалары белән үреп бирелгән бу шигырьләрнең әһәмияте гаять зур булды.

Шагыйрьнең иҗат мирасында иске дини поэзиягә, аерым алганда үзбәк шагыйре Сөләйман Бакыргани, төрек әдибе Мөхәммәт Чәләби әсәрләренә пародия-назирә формасында язылган байтак кына шигырьләр бар. Бу очракта да без шагыйрьнең мәсьәләгә новаторларча якын килүен күрәбез. Тукайда «Бакырган», «Мөхәммәдия» китапларының романтик мистика, дини-әхлакый мотивлар белән сугарылган эчтәлеге алып ташланды, илаһи көчләрнең бөеклеге, дәһшәтлелеге, аларга буйсыну кирәклеге турында сөйләгән шигъри форма сатира максатларына юнәлдерелде. Борын-борыннан татар укучысына таныш булган көйле китап кысаларына капма-каршы эчтәлек салу Тукай шигырьләренең идея-эмоциональ тәэсир көчен бермә-бер арттырды («Хатирәи «Бакырган», «Хөррият», «Тотса мәскәүләр якаң» һ. б.).

Гарәп, фарсы һәм төрки әдәбиятларында озак гасырлар буена өстенлек итүче иҗат методы — традицион романтизм булды. Феодализмның көнчыгыш халыклары тормышында кирәгеннән артык озын гомерле булуы бу әдәбиятларда реалистик тенденцияләрнең үсеп китүен шактый соңлатты. Татарлар яшәгән территориядә капитализмның чагыштырмача тизрәк үсүе, милли азатлык хәрәкәтенең тамырлары тирәнрәк булу, татар әдәбиятының рус реализмы казанышларын барлык жанрларда да беркадәр алданрак үзләштерүенә сәбәп булды. Үз чиратында, бу — рус әдәбиятының ирек сөючәнлек, азатлык идеяләре белән рухланган Тукайга көнчыгыш романтик әдәбияты традицияләрен моңарчы күрелмәгән тизлек белән реалистик планда яңартып җибәрергә мөмкинлек бирде. М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Ибраһимов һәм башка язучылар белән берлектә, ул татар критик реализмының нигез ташларын салды һәм шул ук вакытта башка төрки халыкларның иҗтимагый һәм әдәби фикер үсешенә дә уңай йогынты ясый башлады. Тукайның әле үзе исән чакта ук чыккан күп санлы шигырь җыентыклары, Казан, Оренбург, Уральск шәһәрләре аша, казакъ, кыргыз далаларына, Төркстанга таралалар, таулар аша кичеп, Кырым һәм Кавказга барып чыгалар. Башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, таҗик, комык, кара-калпак, уйгур укучылары Тукай шигырьләрен яратып укый, көйли-җырлый башлыйлар.

Октябрьга кадәр күпчелек төрки халыкларның культура эшлеклеләре һәм әдипләре Тукай әсәрләрен оригиналда укыдылар. Моңа телләрнең тугандашлыгы, графиканың уртак булуы, культура традицияләренең якын булуы да зур ярдәм итте. Баштарак казакъ, кыргыз, үзбәк, комык укучылары һәм үзбәк телен яхшы белүче таҗиклар Тукайның «Шәкерт яхут бер тәсадеф», «И каләм!», «Ифтирак соңында», «Пушкинә», «Теләнче», «Кечкенә генә бер көйле хикәя», «Хөррият хакында» кебек, демократик мәгърифәтчелек белән сугарылган, прогресс һәм милли азатлык өчен көрәшкә чакырган әсәрләре белән аеруча мавыкканнар. Шагыйрьнең революцион демократик эчтәлекле шигырь, мәкалә һәм фельетоннары да төрки халыклар арасында көннән-көн күбрәк тарала бара. «Уклар», «Яшен», «Ялт-йолт» сатирик журналлары аша Бохара, Хорезм, Сәмаркандның мәдрәсә шәкертләре Тукайның урта гасырчылык, әмирчелек, ишанлык идеологиясенә каршы юнәлдерген сатирик публицистикасы белән танышалар һәм аларны татар шагыйренең Урта Азия халыкларына турыдан-туры мөрәҗәгате формасында кабул итәләр. Бу хәл чалмалы «бохара козгыннарын» зур борчуга төшерә, «изге Бохара»да феодализмның черeклеген сурәтләгән дәһри татар шагыйре әсәрләрен укыган шәкертләрнә каты эзәрлекләү башлана[1]. Ләкин инде Россиядән килгән милли-азатлык хәрәкәте дулкыннарын туктату, Идел буеннан Тукай шигырьләре белән таралган революцион демократик мәгърифәтчелек һәм көрәш идеяләре ялкынын сүндерү мөмкин булмый.

Октябрьга кадәр казакъ, кыргыз, үзбәк, төркмән, кара-калпак, таҗик язучылары рус әдәбиятының гражданлык пафосын, тирән гуманизмын, беренче чиратта, Тукай

[1] Ш. Харисов. Изумительный мир поэзии. «Коммунист Таджикстана» газетасы, 1961 ел, 26 апрель, 16 сан.

иҗаты һәм тәрҗемәләре аша кабул иттеләр. Кыргыз язучысы Камчы Жунусов билгеләп үткәнчә, «ул заманда Тукай шигырьләрен рус әдәбиятын өйрәнгән кебек өйрәнгәннәр» [1]. Бу уңайдан үзбәк һәм таҗик әдәбиятларының нигез ташларын салучы күренекле язучы Садретдин Гайни сүзләре аеруча игътибарга лаеклы. Шагыйрь һәм тәрҗемәче Семен Липкинның: «Сезнең иске Бохарада, революциягә тикле Пушкин турында ишеткәнегез булдымы? — дип соравына җавап биреп, ул: «Ишеттем дә, укыдым да. Тукайдан укыдым»[2], ди.

Егерменче йөз башында таҗик культурасы әһелләренә һәм әдипләренә татар демократик әдәбиятының уңай йогынтысы аеруча көчле була. Хәтта телләрнең шактый ерак торуы да әдәби бәйләнешләрнең үсүенә киртә була алмый. Үзбәк халкының телен яхшы белүче, фарсы телендә сөйләшүче таҗикларга рус һәм татар реалистик әдәбиятының казанышларын иҗади кабул итү өчен киң мөмкинлекләр ача. Бүгенге көндә таҗик иптәшләр татар-таҗик әдәби бәйләнешләре турында бик кызыклы тикшеренүләр алып баралар, бу мәсьәләгә караган махсус хезмәтләр язалар.

Тукайның вакытсыз үлеме, трагик язмышы аның иҗаты белән кызыксынуны тагы да арттырды. Үзәктәге һәм окраиналардагы рус матбугатында, әзәрбайҗан, казакъ һәм башка телләрдәге газета-журналларда шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында күп санлы мәкаләләр басылып чыкты.

Күренекле галим-ориенталист В. В. Бартольд тарафыннан редакцияләнгән «Мир ислама» журналында Тукай турында татар һәм төрек матбугаты битләрендә басылган материалларга зур күләмле күзәтү бирелде [3]. Шагыйрь иҗатының халыкчанлыгын раслаган демократик эчтәлекле мәкаләләргә басым ясау — бу күзәтүнең В. В. Бартольд каләме белән язылуы турында сөйли. Ул материалларның «Туркестанский курьер», «Туркестанские ведомости» кебек В. В. Бартольд актив язышкан газеталарда кабат басылып чыгуы да шул ук фикерне раслый [4].

«Мусульманская газета», «Заря Дагестана» газеталарында Сәет Габиев Тукайның үлемен тугандаш халыкларның демократик интеллигенциясен, алдынгы яшьләрен кара шәүләле бүгенге яшәеш турында тирәнрәк уйланырга ярдәм итүче, аларда иҗтимагый явызлыкка каршы көрәштә үз көчләренә ныклы ышаныч тәрбияләүче зур югалту итеп бәяләде. Тукайның башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, таҗик, дагестан халыклары аңына, әдәби үсешенә ясаган тәэсире турында язып чыгучыларның да беренчесе С. Габиев булды. Ул бу халыкларның художество интеллигенциясен Идел буеның бөек ашугы күтәргән азатлык идеалларына турылыклы булырга, халыкка фидакарь хезмәт итү эшен киләчәк буыннарга эстафета итеп тапшырырга өндәде.

Тукайны югалтуның төрки халыклар дөньясында зур резонанс тудыруы, аның иҗатының халыкчанлыгы турындагы тирән эчтәлекле мәкаләләрнең күпчелеге Ж. Дагестанлы тарафыннан язылып, ул мәкаләләр «Каспий», «Русская молва», «День» газеталарында басылды. Тукай иҗатының царизм тарафыннан изелгән халыкларның азатлык өчен көрәш тарихы белән тыгыз бәйләнештә булуын күрсәтеп, Ж. Дагестанлы болай ди: «Тукай һәм Сабир кебек шагыйрьләрнең үлеме, интеллигенциядән бигрәк, халыкны дулкынландыра... Переворот инде түбәннән башланды, аңа бернинди киртәләр дә каршылык күрсәтә алмас» («Каспий» газетасы, 1913 ел, 20 апрель.)

Тукай үлеме татар һәм башка халыкларның иҗтимагый фикерен тагы да көчлерәк кузгатып җибәрүе һәм шагыйрь иҗатына багышланган мәкаләләрдә шагыйрьнең үлемен изелгәннәрнең тарихи көрәш перспективасы белән бәйләп аңлату — патша цензурасын да зур борчуга төшерә. Милли азатлык хәрәкәтенең тагын да тирәнгә китүе турында сөйләүче бу фактны цензура, мөселманнарның самодержавиегә каршы милләтчелеге дип бәяләп, татар һәм тугандаш халыкларның укучы яшьләрен, демократик карашлы интеллигентларын махсус күзәтү астына алу кирәклеге турын-

---

1 «Совет әдәбияты» журналы, 1961 ел, 4 сан, 44 бит.
2 Шунда ук, 62 бит.
3 «Мир ислама» журналы, 1913 ел, II том, VIII чыгарыш, 572—593 битләр.
4 «Туркестанский курьер» газетасы, 1913 ел, 21 апрель, 87 сан. Газетаның 88, 89 саннарында да Тукай турында мәкаләләр бар.

да Россиянең төрле шәһәрләрендәге жандарм управлениеләренә үзенең «бик тә яшерен» донесениеләрен тарата (Украина ССРның Үзәк дәүләт архивы. 274 фонд, 1 опись, 3151 эш, 447 бит).

Татар һәм әзербәйҗан әдәбиятлары, Тукай һәм Сабир иҗатлары арасындагы үзара бәйләнеш һәм йогынты исә тагын да тирәнрәк, тәэсирлерәк һәм нәтиҗәлерәк булган. Уральскида чакта ук Тукай әзербәйҗан вакытлы матбугатын күзәтеп бара, бу әдәбиятның кайбер үрнәкләре турында фикерләрен дә әйтеп калдыра. 1906 елда ук әзербәйҗан телендәге «Хаят» газетасында Тукайның берничә шигыре дә басылып чыга. Революцион-демократик юнәлештәге «Мулла Насретдин» журналын Тукай яратып укый, шагыйрьнең бу журналны кулына тотып төшкән бер рәсеме дә бар. Ул әзербәйҗан критик реализмның күренекле вәкилләре Мамедкулизадә һәм Сабир иҗатлары белән кызыксына. Тукай Сабирның яраткан «һөд-һөд кошы» имзасы белән үзенең берничә шигырен дә бастыра һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Кавказдагы фикердәш дустының иҗатын күзәтеп бара. 1908 елда ул Сабирның «Шикаять» дигән сатирик әсәрен «Мулланың зары» исеме белән татарчага тәрҗемә итә. 1910 елда «Ялт-Йолт» журналының 7 санында Сабирның «Дилбәр» шигыренә «Шагыйрьләребез тоусифе[1] буенча матур кыз» дигән пародия-назирә басыла һәм карикатура белән иллюстрацияләнә. Абстракт романтик формада кеше матурлыгын бирергә маташучы эпигончы газәлчеләрне тәнкыйть иткән бу шигырьне татарчага тәрҗемә итүдә, әдәби эшкәртүдә, һичшиксез, Тукай зур роль уйнаган. Галиәсгар Камал сүзләренә караганда, «Ялт-йолт» сатирик журналын Тукай бер үзе диярлек эшләгән[2].

1911 елда Сабир үлә. 1912 елда аның беренче сатирик шигырьләр җыентыгы «һоп-һоп намә» («һөд-һөд китабы») басылып чыга. Бу җыентыкны Тукай иптәшләре һәм үзе өчен өч данә Бакудан соратып алдыра[3].

1911 елда Астраханьга баргач, Тукай бирегә сөргенгә җибәрелгән күренекле әзербәйҗан язучысы, җәмәгать эшлеклесе һәм революционер Нариман Нариманов белән таныша. Туберкулезга каршы үткәрелгән «ак чәчәк» бәйрәмендә Нариманов Тукайны «татарның атаклы шагыйре» дип тәкъдим итә. Тукай үлгәннән соң, Нариманов, аның иҗаты турында лекция укырга рөхсәт сорап, берничә мәртәбә властьларга мөрәҗәгать итә. Ләкин аның үтенече канәгатьләндерелми[4]. Нариманов, Астраханьнан Бакуга кайткач та, Сабир белән Тукайның әзербәйҗан һәм татар халкына күрсәткән фидакарь хезмәтләрен искә алып, аларның исемнәрен киләчәк буыннар өчен мәңгеләштерү кирәклеге турында «Бәсирәт» (1914 ел, 20 сентябрь) газетасында мәкалә белән чыга.

Тукай һәм Сабирның татар һәм әзербәйҗан халкының әдәби-иҗтимагый фикере үсешендә тоткан урыннары, татар-әзербәйҗан культура бәйләнешләры турында Кавказдагы «Каспий», «Баку», «Икбал» газеталарында полемика да булып ала. 1913 елның җәендә, татар артистларының Бакудагы гастрольләре вакытында, Тукай шигырьләре Тагиев театрында укыла һәм публикага зур тәэсир ясый. Бу мөнәсәбәт белән («Каспий» газетасында), Ж. Дагестанлының әзербәйҗан культура эшлеклеләрен, әдипләрен татар шагыйре иҗаты белән якыннанрак танышырга өндәгән мәкаләсе дә басыла. Тукай иҗатына бирелгән югары бәя кайбер әзербәйҗан буржуаз интеллигентларына ошамый. «Баку» газетасында алар «татар шагыйре безнең өчен чит», «аңлашылмый» дип чыгалар. Үз заманында Сабир белән аралашкан күренекле журналист Хаҗи Ибраһим Касыймов бу карашның ялгыш икәнлеген тәнкыйтьләп чыгыш ясый («Икбал» газетасы). Ж. Дагестанлы фикерләрен куәтләп, ул Тукайны Сабир кебек үз талантлары итеп кабул итәргә, аннан өйрәнергә чакыра[5].

Әзербәйҗанда соңгы елларда Сабир иҗатын һәрьяклап өйрәнүгә игътибарның үсүе аның замандашы булган Тукай белән кызыксынуны да арттырды. Сабирның

---

[1] Тоусиф — сурәтләү, характеристика.
[2] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960 ел, 77 бит.
[3] Г. Мирәхмәдов. Тукайның Сабирдан бер тәрҗемәсе хакында. Әзербәйҗан ССР Фәннәр академиясе хәбәрләре (әзербәйҗан телендә). 1954 ел, 5 сан.
[4] «Каспий» газетасы, 1913 ел, 24 апрель, 13 май һәм 1 июнь саннары.
[5] «Баку» газетасы, 1913 ел, 2 июль; «Каспий» газетасы, 1913 ел, 6 июль.

Шамаха шәһәрендәге музеенда Габдулла Тукай рәсеме дә куелган. Назим Ахундов [1], Газиз Мирахмедов [2], Панах Хәлилов [3], Ә. Әфәндиев [4] хезмәтләрендә һәм аеры мәкаләләрдә Тукайның әзербайҗан әдәбияты белән бәйләнешләре турында кызыклы гына күзәтүләр бар. Әзербайҗан дәүләт университетының СССР халыклары әдәбияты укытучысы доцент Панах Хәлиловның Тукай турындагы лекцияләре студентларның хәтерендә шулкадәр сеңеп калган, шулкадәр ошаган, алар П. Хәлиловны бөек татар шагыйренең исеме белән, «Тукай» дип атап йөртәләр. Панах Хәлиловның Галимҗан Ибраһимов һәм Муса Җәлилнең әзербайҗан прозаигы Йосыф Вәзиров иҗатына булган уңай тәэсире турындагы мәкаләләре дә бик кызыклы һәм игътибарга лаек.

Тугандаш халыкларның бик күп язучы һәм шагыйрьләренә — С. Дөнентаев, С. Торайгыров, С. Муканов, А. Токымбаев, К. Жунусов, Ш. Туктаргази, Н. Батырмурзаев һәм башка бик күпләргә — Тукай әдәбият мәйданына халык интересларын яклаучы буларак килергә ярдәм итте. Шагыйрьнең ничек итеп социаль каршылыкларны аңларга булышуы турында Сабит Муканов «Минем мәктәпләрем» исемле романында да язып үтә. Тукайның хезмәт ияләренә олы мәхәббәтен, изүчеләргә тирән нәфрәтен суратләүче истәлекләрнең, гыйбрәтле хикәя формасында, чуваш халык иҗатына үтеп керүе дә очраклы түгел [5]. Шагыйрьнең башкорт халкының революцион аңын үстерүдәге ролен күрсәтү — һадия Дәүләтшинаның «Ыргыз» романындагы мөһим мотивларның берсе. һ. Дәүләтшинаның иҗатын, рухи дөньясын Тукайдан башка аңлау читен. Булачак язучының шигърият белән беренче танышуы, әдәбият дөньясына килүе дә Тукай исеме белән бәйләнгән.

Тукай, әсәрләре нигезендә яткан халыкча фикерләү, хезмәт кешесенең бөекләгән раслау, иҗтимагый явызлыкка нәфрәт һәм протест белдерү, азат Россия өчен көрәшкә чакыру белән, тугандаш халыклар интеллигенциясенең аңын тәрбияләде, интернациональ шагыйрь буларак, аларны алда торган социаль сугышларга әзерләү эшенә билгеле бер өлеш кертте.

Тугандаш халыкларның тарихи-социаль үсеш дәрәҗәләренә, рухи һәм әдәби ихтыяҗларына бәйле рәвештә, Тукай иҗатының әдәби-эстетик пландагы йогынтысы төрле чорда төрле характерда һәм төрле күләмдә кабул ителде. Унынчы елларда Тукай казакъ, үзбәк, таҗик әдәбиятларында реалистик юнәлешне үстерүдә шактый зур эш башкарды. Баштарак бу әдәбиятларның язучылары Тукай иҗатының мәгърифәтчеләгән һәм критицизмын бертигез дәрәҗәдә диярлек кабул иттеләр. Көнчыгыш халыклары тормышында империализмның урта гасырчылык белән чарпакланып яшәве, аларның әдәбиятларында да мәгърифәтчелек реализмы белән критик реализмның аерылгысыз бергә үрелеп бирелүенә сәбәп булды.

Пролетар революцияләр чорында мәгърифәтчелек идеяләренең киң таралуы беренче карашка анахронизм булып күренергә мөмкин. Әгәр дә без егерменче йөз башы рус әдәбияты җирлегендәге мәгърифәтчелек эстетикасы турында сөйләсәк, бу билгеле, әдәби анахронизм булыр иде. Ләкин художество үсеш дәрәҗәләре шактый артта калган көнчыгыш әдәбиятлары өчен мәгърифәтчелек реализмы шул заман өчен зарури күренеш булды һәм ул халыкның аңын уятуда шактый зур роль уйнады. Әдәби процесс никадәр генә катлаулы булмасын, аның төп үсеш тенденциясе көнчыгыш халыкларында да критик реализмга таба борыла. Мәсәлән, 1912 елда ук Әкрам Галимов Тукайның критик реализм рухында язылган шигырьләрен казакъчага тәрҗемә итә һәм «Яшьлек җимешләре» исемле җыентыкта бастырып та чыгара. Тукай шигырьләре тәэсирендә әдәбият мәйданына килгән С. Дөнентаев, С. Торайгыров иҗатларында критик, реалистик тенденция көчәя. Абай башлаган, Тукай дәвам иткән критик реализм казакъ әдәбиятының киләчәктәге магистраль үсеш юлы булырга тиеш дигән фикер әдәби-

---

[1] Н. Ахундов. Сатирические журналы Азербайджана (1906—1922 гг.). Докторлык диссертациясенең автореферaты. Баку. 1965 ел; Тукайның сирәк очрый торган рәсеме хакында. Әдәбият мәсьәләләре. Баку. 1964 ел (әзербайҗан телендә).

[2] Г. Мирахмедов. Поэт, призванный революцией. Баку. 1964 ел.

[3] П. Хәлилов. Сабир һәм Тукай. «Әдәбият һәм сәнгать» газетасы. 1963 ел. 18 апрель (әзербайҗан телендә).

[4] Ә. Әфәндиев. «Тукайның Сабирдан бер тәрҗемәсе хакында. «Әдәбият һәм сәнгать» газетасы. 1962 ел. 12 март.

[5] Народное красное слово. Пенза китап нәшрияты. 1959 ел. 99—100 битләр.

тәнкыйть мәкаләләрендә дә үткәрелә башлый. Бу яктан караганда, Назифә Кулжанованың 1916 елда «Казакъ» газетасы битләрендә басылган мәкаләләре аеруча игътибарга лаеклы. Көнчыгыш романтизмыннан килә торган традицияләрне европа һәм рус реализмы казанышлары белән уңышлы үреп бирүнең классик үрнәге итеп, ул Абай һәм Тукай иҗат методларын күрсәтә һәм үзенең замандашларын бу ике зур шагыйрь башлаган критик реализм юлын дәвам итәргә чакыра [1].

Тугандаш халыкларның әдәбиятлары югарырак үсеш баскычына күтәрелгән саен, аларга Тукайның йогынты сферасы да киңәя бара. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларында бу халыкларда шагыйрьнең революцион публицистик характердагы әсәрләре аеруча популярлык казана. Мисал өчен комык әдәбиятыннан аталы-уллы Нухай һәм Зәйналабид Батырмурзаевлар иҗатын алып була. Алар Октябрьгә кадәр үк Тукай әсәрләре белән яхшы таныш булганнар. Яшь Зәйналабид беркадәр вакыт Астраханьда һәм Казанда яши, татар вакытлы матбугатында актив языша. Беренче империалистик сугышка каршы юнәлдерелгән җыр язып, Петербургка җибәрә, һәм, нәтиҗәдә, Казаннан куыла [2]. Әтисе Нухайның да Казан белән элемтәсе нык була, ул татарча китап, газета-журналлар алдыра. Дагстанда совет властен урнаштыру өчен каты көрәш барган чорларда Батырмурзаевлар «Таң-чулпан» исемле журнал чыгара башлыйлар. Бу журнал битләрендә Нухайның Дагстан язучыларын Тукайдан өйрәнергә чакырган «Әдәбиятчыларыбызга бернича сүз» [3] дигән мәкаләсе басылган. Кызыклы күренеш: традицияләргә бай әзербайҗан әдәбияты күршедә генә булуга карамастан, егерменче йөз комык әдәбияты үзеннән еракта торган татар әдәбиятының уңай тәэсирен күбрәк кабул итә. Дагстанда яшәүче башка халыкларның да интеллигенция вәкилләре Тукай иҗатын яхшы белгәннәр.

Егерменче-утызынчы еллар дәвамында Тукай башкорт, казакъ, төркмән, үзбәк, комык, кара-калпак, чуваш әдәбиятларында сатирик юнәлешнең киң планда үсеп китүенә ярдәм итте. С. Донентаев, С. Торайгыров, Б. Кербабаев, Х. Хакимзадә Ниязи, Аткай, Шәләби һәм башка бик күпләр Тукай юморы һәм сатирасы традицияләрендә иҗат иттеләр. Милли телләр формалашу уңае белән, бу елларда Тукай әсәрләрен төрки телләргә тәрҗемә итү эше дә җанланып китә.

Бөек Ватан сугышы елларында Тукай иҗатындагы зур иҗтимагый яңгырашка ия булган туган ил, азатлык һәм патриотик мотивларны иҗади үзләштерү тугандаш әдәбиятлар алдына зарури бурыч булып баса. Бу мотивлар башкорт әдәбиятында Сәйфи Кудаш иҗатында аеруча калку чагылыш тапты. Тукайның Сәйфи Кудаш иҗатына йогынтысы дәвамлы процесс һәм ул — махсус өйрәнүне таләп итә торган зур тема. Моннан ярты гасыр элек — 1913 елда — Тукай шәкерте буларак каләм сынаган шагыйрь бүген дә үз остазының халыкчанлык һәм реализмы рухына турылыклы булып калуын, ике әдәбиятның олы традицияләрен үз җилкәсендә күтәреп баруын дәвам итә. Шагыйрьнең интеллектуаль-фәлсәфи фикер, тирән психологизм белән сугарылган «Минем бакчамда» исемле җыентыгы һәм соңгы шигырьләре шул турыда сөйли. Билгеле, Тукайның башкорт әдәбиятына йогынтысы бер Сәйфи Кудаш исеме белән генә чикләнми. Бөек Тукай дистәләгән башкорт шагыйрьләрен үз поэтик мәктәбе аша үткәрде һәм аларның социалистик реализм әдәбиятына килү юлын өлешчә җиңеләйтте.

Октябрь революциясенә кадәр Тукайның башка әдәбиятларга тәэсире башлыча көнчыгыш халыклары сферасында барса, совет чорында ул, күп санлы тәрҗемәләре аша, Бөтенсоюз укучысының сөекле шагыйренә әйләнде. Тукай тугандаш халыкларның рухи дөньясына көннән-көн тирәнрәк үтеп дәвам итә һәм, үзенең лаеклы шәкерте Җәлил белән бергәләп, бөтендөнья әдәбиятының киң ареңасына аяк басты. Соңгы елларда немец, инглиз, француз, төрек һәм башка телләрдә Тукай һәм Җәлил иҗатын өйрәнүгә багышланган монографик хезмәтләренең һәм мәкаләләренең чыгуы нәкъ шул турыда сөйли.

---

[1] «Казакъ» газетасы, 1916 ел, 9 апрель.
[2] Аткай. В Кумыкской степи. Махачкала. 1960 ел.
[3] «Таң-чулпан» журналы, 1917 ел 8 сан (комык телендә).

*Г. Сәгъдеваккасов,*
филология фәннәре кандидаты.

# УЙГУР ӘДӘБИЯТЫНА Г. ТУКАЙНЫҢ ТӘЭСИРЕ[1]

Октябрь революциясе белән кешелек дөньясында яңа дәвер башланды. Яңа иҗтимагый төзелеш, кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр, үз нәүбәтендә, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дә яңа форма һәм эчтәлекнең барлыкка килүен таләп итәләр. Егерменче еллардан башлап, уйгур шагыйрьләре һәм язучылары алдында да әдәбиятыбызның үсеш юлын билгеләү һәм аны социализм төзүче хезмәт ияләренең прогрессив таләпләренә лаек яңа форма, эчтәлек белән баету кебек мөкатдәс бурычлар торган иде. Шул зур эшне уңышлы башкарып чыгу өчен, шагыйрь һәм язучыларыбыз, үзләренең барлык талантларын, акыл көчләрен эшкә җигү белән бергә, халык иҗатына, классик әдәбиятыбызның гүзәл үрнәкләренә, шулай ук тугандаш халыкларның әдәбиятына... мөрәҗәгать иттеләр.

XX гасыр башларында, тарихи шартларга баглы рәвештә, башка төрки халыклар белән чагыштырганда татар культурасы шактый зур прогресска ирешкән иде. Октябрь революциясенә хәтле һәм Совет властеның беренче елларында төрки телләрдә язылган китапларның зур өлеш Казан шәһәрендә нәшер ителүе дә моңа дәлил була ала. XIX йөзнең азакларыннан башлап, Казан шәһәре белем-культура, революцион хәрәкәт үзәкләреннән берсе була...

Боларның барысы да шул чактагы татар интеллигенциясенең үсеп җитлегүенә, аларның дөньяга карашлары формалашуга, шулай ук революцион-демократик рухтагы татар әдәбиятының барлыкка килүенә сәбәп булдылар. Күп тә узмый, татар әдәбияты царизм чорында үсә алмый калган яки бөтенләй югалу куркынычы алдында торган башка халыкларның әдәбиятларына үрнәк булырлык прогрессив сыйфатларны мәйданга китерде.

Революциядән элекке татар әдәбиятының иң мәшһүр вәкиле Габдулла Тукай иде. Ул бары хәзерге заман татар реалистик поэзиясенең генә түгел, бәлки илебездәге башка кардәш халыкларның реалистик поэзиясе нигезен салучыларның да берсе сыйфатында таныла. Үзбәк, төркмән, кыргыз, казакъ һәм уйгур шагыйрьләренең күбесе, бик хаклы рәвештә, Габдулла Тукайны үзләренең остазлары дип таныйлар.

Гомәр Мөхәммәдинең, бигрәк тә Ташкентта укып йөргән чакларында, Тукайдан һәм Һади Такташтан өйрәнгәнлеге безгә яхшы мәгълүм. Талантлы шагыйрь Исмәгыйль Саттаров, Габдулла Тукайны бик яратып укуын, аңардан өйрәнүен әйтеп, Тукай поэзиясенә карата булган чиксез хөрмәте турында язган иде. Шенҗаң уйгур шагыйре Лотфулла Моталлиб[2] Габдулла Тукай иҗаты белән Голҗадагы татар мәктәбендә укыган чакларында ук якыннан таныша, аның рухи һәм әдәби тәэсире астында шагыйрь булып үсә. Өлкән шагыйребез Һәзим Искәндәров Тукайның шигырьләрен, дастаннарын зур илһам белән уйгур теленә тәрҗемә итте. Димәк, Габдулла Тукайның уйгур әдәбиятына ясаган тәэсире шөбһәсез. Әмма ул тәэсир нәрсәләрдән гыйбарәт соң?

Габдулла Тукай иҗатының 20 һәм 30 елларда Г. Мөхәммәди, Һ. Искәндәров, Н. Исраилов, И. Саттаров, К. Хәсәнов шикелле уйгур совет шагыйрьләренә бигрәк тә Шенҗаңның ялкынлы җырчысы Л. Моталлибка иң элек идея һәм эчтәлек җәһәтеннән көчле йогынты ясавын аерым күрсәтеп узу урынлы булыр иде. Билгеле бул-

---

[1] Мәкалә «Коммунизм тугы» газетасының 1961 ел, 26 апрель санында басылган. Уйгур теленнән М. Госманов тәрҗемә итте.

[2] Шенҗаң — Кытайда Сии-цзян провинциясе. Л. Моталлиб иҗатыннан үрнәкләр «Совет әдәбияты»ның 1961 елгы 1 санында бирелгән иде.

ганча, бөек рус әдипләренең прогрессив уй-фикерләрен үзләштереп, Габдулла Тукай, үзенең барлык сәләтен үз халкының киләчәк бәхет-сәгадәтенә багышлады; үзе гомер кичергән иске җәмгыятьнең бөтен җинаятьләрен фаш кылып, хезмәт ияләрен көрәшкә чакырды, аларны әсирлектән, фәкыйрьлектән котылырга өндәде; хатын-кызларның иреген яклады; эшче-игенчеләрнең авыр тормышын реалистик ысул белән тасвирлады; хәятның гүзәллеген нечкә сиземләү белән көйләде. Габдулла Тукайның үлмәс иҗатында гәүдәләнгән идеяләр һәм тормыш таләбеннән туылган төрле темалар аз санлы халыкларның да узгандагы тормыш-чынбарлыкларын, милли үзенчәлекләрен чагылдыру хосусиятына ия булдылар. Менә шуңа күрә, уйгур шагыйрьләре дә Габдулла Тукай поэзиясенең идея һәм эчтәлегеннән иҗади файдаланып, аны үзләре гомер кичергән дәвернең шартлары белән, үз халкының тормыш таләпләре белән тагын да тирәнәйттеләр, баеттылар. Мәсәлән, Гомәр Мөхәммәдинең «Исемдә», «Яфраклар көелгәндә», «Моңайма, сеңелем» дигән шигырьләрен Габдулла Тукайның «Исемдә», «Чыршы», «Хатыннар хөррияте» кебек әсәрләреннән илһамланып язылганлыгын күрергә була. Әгәр Габдулла Тукай «Исемдә» дигән лирик әсәрендә:

Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар,
Гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар,
Исемдә һәм эчемнән көткәнем якты бәхетләрне,
Теләп яшьрен генә рәхәт, сәгадәтле вакытларны...

— дип язган булса, Гомәр дә «Исемдә»сендә:

Исемдә, дөньяга сыймый
Шатланып көлгәннәрем,
гел уйнаганнарым,
Исемдә урак тотып,
Җиңеп төреп, басуда
ашлык урганнарым...
Инде юк ул көннәр,
Күпме дәртләнеп кулыма сазым алып,
Хисләнеп чиртсәм дә көмеш кылларга...—

ди.

Шигырьләрнең гомуми настроениесе, эчтәлекләре бер-берсен хәтерләтәләр... Ләкин Гомәр Тукайның бу шигырьдәге төп поэтик орлыгын гына ала, үзләштерә һәм аңа милли төс бирә.

Тукайның «Шагыйрьгә» дигән әсәре белән Л. Моталлибның «Шагыйрь хакында мүәшшах» исемле шигыре турында да шундый ук фикерне әйтергә мөмкин булыр иде.

Билгеле ки, Тукай белән Лотфулла, мәгълүм сәбәпләр аркасында, аналогик иҗтимагый шартларда иҗат иттеләр. Тукай Россия азатлыгы, Лотфулла исә Кытай революциясе алды елларында яшәде. Әмма, тарихи шартлардан килеп чыккан бу уртаклыктан тыш та, Лотфулланың халык азатлыгын хыял итеп һәм хезмәт ияләре массасын көрәшкә чакырып язган шигырьләренең Тукайның шундый мотивтагы әсәрләренә аһәңдәш булуы бәхәссез.

20 һәм 30 еллардагы каләм әһелләре уйгур әдәбиятын хезмәтчел халыкка якынлаштыру, аның рухи азыгына әверелдерү бурычын куйдылар. Моның өчен, иң элек, гасырлар дәвамында хөкем сөреп килгән, күбесенчә гайре табигый хәлләрне тасвирлаудан гыйбарәт булган шәрык поэзиясенә хас феодаллык традицияләреннән ваз кичеп, күпчелеккә аңлаешсыз китаби тел урынына, гомумхалык уйгур телен кулланырга кирәк иде. Бу юлда уйгур шагыйрьләре, алдынгы рус поэзиясеннән өйрәнү белән бергә, шул чакларда ук бу катлаулы бурычны уңышлы хәл итеп өлгергән татар әдәбиятына да мөрәҗәгать иттеләр. Нәтиҗәдә, Габдулла Тукай иҗатына хас халыкчан характер һәм кайсыбер шигъри формалар уйгур поэзиясендә нык урнаштылар. Әдәбиятыбызда киң төрдә җәелеп өлгермәсә дә, поэзиябездәге чәчмә шигырь формасының безгә татар шагыйре Һади Такташның турыдан-туры тәэсире белән кергәнлеге шөбһәсез.

Шулай итеп, Габдулла Тукай уйгур халкының сөеп укый торган шагыйре генә түгел, бәлки әдәбиятыбызның үсеп, камилләшүенә лаеклы өлеш кушкан мәшһүр татар шагыйредер.

Гариф Гобәй

# Коръән серләре

*Повесть*[1]

## 6

### «Ә УЛ КЫЯМӘТ ДИГӘНЕҢ КАЙЧАН БУЛА?»[1] ЯӘҖҮҖ-МӘӘҖҮҖ ҺӘМ АНЫҢ ГАҖӘЕП БЕР ЫСУЛ БЕЛӘН ТУУЫ. ЗӨЛКАРНӘЙН КОЙМАСЫ. ГАЗРАИЛ ЗАРЫ ҺӘМ СИРАТ КҮПЕРЕ

Гарәп телен белмәгән мөселманнар бу турыда берни белмичә яши. Мулланың наданы үзе дә белми, белгәне «мужик балаларына» әйтми үтә. Киресенчә, ул җәннәтне Мөхәммәтнең үзеннән дә әйбәтрәк итеп тасвирлый. Мәсәлән, хур кызларының саннары турында Коръәндә әчмүхә сүз дә юк. Мулла абзыйлар исә аларның саннарын җитмеш җидегә җиткерә. Җитмеш җидегә дә канәгать түгелсен икән, корбан чаласың. Каны күккә ашып, хак тәгалә һәр тамчы каныннан синең өчен бер хур кызы ясап куячак!.. Мөселман әгүзе белән бисмилланың ни икәнен белмәсә дә, бу турыда яхшы белә.

Әйткәнемчә, кыргый гарәп өчен, бигрәк тә фәкыйрьләр өчен, гомеренә туйганчы ипи, су күрмәгән, аракыны татып та карамаган, хатын-кыз затыннан мәхрүм кол гарәп өчен Мөхәммәтнең җәннәте әйбәтнең аръягында. Ул шуна өмет баглый, шунда керү хыялы белән яши.

Тик менә, кайчан була соң синең ул җәннәтең, Мөхәммәт?

— Ахыр заман булгач, кыямәт җиткәч.

— Ә кыямәт кайчан?

— «Йолдызлар җиргә төшкәч, җир тетрәгәч, таулар җимерелеп, туфракка әйләнгәч».

*(Коръән, «Төшүчеләр» сурәсе, 1—5 аятьләр.)*

— Юк, син боргалап маташма, — диләр гарәпләр. — Ул кыямәт дигәнең кайчан?

Мөхәммәткә ничек әйтсә дә вай. Тиз түгел дисә, курыкмаслар, тиз дисә, ялганга чыгар. Ул алла исеменнән шундый җавап бирә:

---

[1] Дәвамы. Башы 1, 2, 3 саннарда.

«Кыямәтнең якынаеп килүе турында хәбәр ит. Ул көнне кяферләрнең җаннары бугазларына килеп тыгылыр», ди.

Аннан срокны тагын да якынайтып, ачыклый төшеп:

«Кешеләрнең хисап бирер көннәре якынайды...» ди.

*(Коръән, «Иманлы кеше» сүрәсе, 18 аять, «Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 1 аять.)*

Күрәсең, гарәпләр тагын да ачыграк җавап даулыйлар, алла Мөхәммәткә мондый вәхи җибәрә:

«...Әйт син аларга, көтегез диген... Миндә сезнең белән бергә көтәм диген».

*(Коръән, «Хайван» сүрәсе, 159 аять.)*

Уйлап карыйк. Гарәпләр белән бергә Мөхәммәт тә көтә. Моннан күренә ки, кыямәт Мөхәммәт заманында ук булырга тиеш булган. Ләкин, безгә мәгълүм булганча, алланың бу сүзләре акланмый, Мөхәммәт үлгәнгә инде 1310 ел, әле һаман кыямәтнең булыр исәбе күренми.

Кыямәтнең ислам диненә ышанучыларны юатыр өчен, имансызны өркетер өчен уйлап чыгарылган «буки» икәнен исбат итүгә шул кадәресе дә җитсә кирәк.

Көтеп-көтеп булмый калгач, Коръәннең әйткәннәре акланмагач, дин әһелләре һәр илдә, шул исәптән Казан шәһәрендә кыямәтнең яңа сроклары күрсәтелгән Бакырган, Тәкыйгаҗәп, Бәдәвам кебек әкият китаплары басып чыгаралар.

«Гайсә ингәй тәмам түгел тугыз йөздә».

Ягъни 1900 нче ел азакларында күктән Гайсә төшәргә тиеш була — ә ул әле дә төшми.

«Тугыз йөздә унбиштә Яэҗүҗ чыккай» — ләкин анысы да күренми әле.

«Гайсә белән Мәһди барып Турга ашкай».

Монысы да булмый калды.

Әле тагы «Мең дә бер хәдис»нең 198 нче хәдисе нигезендә һәрбер гасыр башында ислам динен яңарта торган (?) кеше килергә тиеш була. Бу исәптән Мөхәммәттән соң инде 14 «яңартучы» килергә тиеш иде. Аларның да һич берсен күргән кеше юк.

Инде нишләргә? Сезнең күзегезгә генә күренми ул диярсезме? — Ышандырып булмас. Алла үзенең кыямәт срогы турында хөкемен үзгәрткән диярсезме? Ярамый. «Румнар» сүрәсенең 5 нче аятендә ап-ачык итеп әйтелгән: «Алла беркайчан да үзенең вәгъдәсен үзгәртми». Ничек итәргә соң?.. Болай калдырып булмый, уен эш түгел, халыкта ахыр заманга ышану бетсә, дин үзе дә бетәчәк!...

Мөхәммәтнең кыямәт турындагы ялганнарын аклау өчен, дөресрәге — оныттыру өчен дин башлыклары кызык-кызык яңа уйдырмалар уйлап чыгарганнар. Аларның кыскача эчтәлеге шуңардан гыйбарәт.

Кыямәт алдыннан галимнәр Коръәнне, газиләр шәригатьне оныта. Мөселманнар Римны алырлар. Төньяк уллары Константинопольне, Шам белән Каһирәне алырлар. Мөхәммәт нәселеннән Мәһди исемле пәйгамбәр килер. Мәһди ислам динен торгызачак[1]. Ләкин Дәҗҗал диген бер явыз килеп чыгып, халыкны үзенә ияртеп алып китәчәк. Шуннан соң күктән Гайсә төшәр. Ак атка атланган, аты ике аягы белән бер фәрештә канатына баскан, ике аягы белән икенче бер фәрештә канатына. Өстендә ак җилән, башында яшел чалма, кулында сөңге, билендә кылыч. Гайсә Дәҗҗал гаскәрен күз ачып йомганчы тар-мар итәр. Аннары Синай тавына менеп яшел чатыр корып ятыр. Шуннан соң инде Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ диган коточкыч бер зат пәйда булыр. Галәмәт зур. Хәзер әле җиде кат җир астында. Җир өстенә чыгарга омтылып, көн саен

---

[1] Дин галимнәренең бу тырышлыкларыннан файдаланып, Көнчыгыш илләрдә берничә бәндә үзләрен Мәһди дип игълан итәләр. Аеруча мәшһүрләре Һиндстанның Мирза Әхмәт белән иран сәүдәгәре Гали Мөхәммәт. Соңгысы шәригать өчен Коръән искерле, әһәмияте калмады дигән шигар күтәреп чыга, Коръән урынына «Бәян» исемле яңа китап яза. Бу «Мәһдине» феодаллар изүеннән интеккән ярлы халык, чыннан да, Мәһди итеп таный. Аның җитәкчелегендә берничә урында баш күтәрүләр була. 1850 елда Иран шаһының әмере буенча атып үтерәләр. Көнчыгыш илләрдә нярченнәр хәзер дә бар. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң реакцион мөселманнар Гитлерны Мәһди шул икән, тиз көндә янәдән дөньяга килеп, безне коммунистлардан коткарачак икән дигән хәбәр тараталар.

җирне ашап менә. Инде чыгам, күкәй кабыгы хәтле калды, дигәндә, ходаның рәхмәте, мәзиннең иртә намазга азан әйткәнен ишетә дә гайрәте бетеп туктый. Ничә башлы, ничә авызлы, һәр авызы ни чаклы икәне дин китапларында юк. Аның каравы «Кассас-әл-әнбия»нең икенче җөзьәсендәге Зөлкарнәйн бабында кайчан һәм ничек дөньяга килгәне бик ачык итеп, бик тасвирлы итеп бәян кылынган. Моны һәр мөселман калебенә сеңдереп калырга тиештер.

«Адәм галәйһиссәләм төшләнде. Мәние җиргә агып, балчык белән катышты. Аллаһ тәгалә вә тәбарәкә Яәҗүҗ-Мәәҗүҗне шул мәнидән яратты...»

Кызыкмы? — Әйе, кызык. Ә хикмәте менә кайда: шундый гыйбрәтле, шундый изге ысул белән яратылган изге зат (Адәм галәйһиссәләм улы дисәк тә ялгышмабыз) җир өстендә пәйда булу белән Зөлкарнәйн коймасын тишеп чыгып, җир йөзендәге барлык нәрсәләрне рәттән сыпырып ашап йөриячәк!.. Шуннан җир йөзендә мөгезе күккә җиткән бер ерткыч пәйда булыр. Бер кулында Муса таягы, икенчесендә Сөләйман мөһере. Бу ерткыч, мөэмин-мөселманны, кяферләрдән аерып булсын өчен, аларга шул мөһерне сугып йөрер... ул көнне кояш көнбатыштан чыгар, Коръән күккә ашар, менә шунда инде гомер буена кендеген кояшка кыздырып яткан Исрафил фәрештә сикереп торып, быргы кычкыртып, фани дөньяның бетүе турында хәбәр итәр. Хуҗалары үлгәннән бирле ниндидер бер үгез мөгезендә яшәгән җаннар, зиратларга очып килеп, хуҗаларының тәннәренә керер. Һәм... мәетләр шундук каберләреннән кубып күккә ашар... Кешеләр генә түгел, дөньяда яшәгән һәрбер җан иясе терелеп, алла каршына менәчәк. Амбарыңны тишеп игенеңне ашап яткан күселәр дә, итәгеңне умырып алып калган усал этләр дә, умарталыгыңдагы балыңның башына җиткән аюлар да, каныңны эчкән кандала, борча, бет кебекләр дә, ризыгыңны пычратып, йогышлы чирләр йоктырып йөргән чебеннәр дә... (Тик шунысы, бу хәшәрәтләр җәннәттә дә дөньядагы эшләрен дәвам итәчәкләрме, әллә аларга карата алланың башка уе釆бармы? — мәгълүм түгел.) Шуннан Исрафил янә быргы кычкыртыр, кешеләр дәррәү тәгәрәп җан бирер. Исрафил янә бер кәррә быргы кычкыртыр, монысында бөтен фәрештәләр җан тәслим кылыр, инде Кояшны күтәреп торган фәрештәләр дә тәгәрәп җан бирер. Шуннан Кояш җиргә егылып төшәр. Барча йолдызлар җиргә сибелер. Аннан килеп, Газраил фәрештә үз җанын алырга керешер. Ул җанын йолкып чыгарганда шулкадәр каты кычкырыр ки, әгәр шул чак кешеләр тере булган булса, берсе калмый тәгәрәп үлгән булырлар иде. Газраил әйтер шул чак: әгәр җанга тәннән аерылу бу кадәр газап икәнен белгән булсам, бер кешенең дә җанын алмаган булыр идем, дияр...

Менә кыямәт кайчан була. Менә ул ничек башлана.

Заманында «кара халык»ның котын алып тору өчен яраган. Безнең әти-әниләр, әби-бабалар шуңа ышанып тетрәп торганнар.

Әйтергә кирәк, Мөхәммәтнең менә була, хәзер була, мин исән чакта ук була, дип төтен җибәрүенә караганда, монысы әйбәтрәк, — укыр өчен дә кызыклы. Тагын шунысы: бу әкиятне язучылар, үзләре дә сизмәстән, мәсьәләне безнең көйгә борып җибәргәннәр. Имештер, кыямәт алдыннан шундый-шундый хәлләр булачак... Ә андый хәлләрнең беркайчан да, беркайчан да буласы юк, димәк, кыямәтнең дә буласы юк. Нәкъ безнеңчә! Мин моны берничек тә инкарь итәргә мөмкин булмаган дәлилләргә нигезләп әйтәм. Менә ул дәлилләр.

1. Галимнәр дигәне — химиклар, математиклар, астрономнар, врачлар түгел; әлбәттә, дин әһелләре, муллалар, мөфтиләр, ахуннар. Синең белән миңа ни сан, хәтта әнә шул изгеләр динне онытачак. Ягъни, дин бетәчәк. Соң шулай булгач, ул диннән язган дин әһелләренең, ахуннарның, казый, мөфти вә муллаларның, бигрәк тә динне әллә кайчан оныткан «кара халык»ның, шул исәптән синең белән минем, дин юлында Рим белән сугышып йөрүебез мөмкинме? Аннан нигә Рим белән генә? Рим Италиянең нибары бер кечкенә кисәге булып калды бит хәзер. Тагын. Мөселманнарның Римны алганын бөтен Италия һәм аларның союзниклары, «ну егет тә икән бу мөселманнар, тәки булдырдылар бит» дип, карап торырлар микән соң?

2. Шам белән Каһирәне алачак Төньяк уллары кемнәр алар? Гарәбстанга нисбәтән борынгы рус иле булса кирәк. Ләкин аларның Каһирә белән Шамны беркайчан да алачаклары юк, чөнки хәзер рус иле дигән ил үзе юк, рус иле нигезендә төзелгән 100 милләтне, шул исәптән 30 лап мөселман милләтен берләштергән бөек Советлар иле генә бар. Һәм бу илнең Шам белән Каһирәгә каршы сугыш ачуы — чебенгә

туп ату булыр иде. Икенчедән, Советлар иленең ул Каһирәләр, Шамнар белән мөнәсәбәте бөтенләй-бөтенләй бүтән бит хәзер. Советлар иле аларны кан кардәшләре урынына үз күрә. Аларны берничә тапкыр һәлакәттән коткарып калды. Әледән-әле бөлгенлектән чыгарга ярдәм итеп тора. Инде килеп, берәр явызы бу илләргә тырнак белән генә чиертсә дә, Советлар иле аның башына күсәк белән сугып, ник туганына үкенерлек итәчәген дә әйтеп куйды.

3. Иртәгесен Дәҗҗал мөртәт чыгып, бөтен халыкны үз артыннан ияртеп алып китәр булгач, ул Мәһди дигәннәренең җиргә төшеп, ислам динен торгызып йөрүләрендә ни мәгънә? Бу да, әлбәттә, алланың мөселманнарны туфан вакытында коткарып калып, туфан бетү белән кырып бетерүе кебек үк сәер хөкеме түгелме?

Тагын. Бер Гайсә үзенең сөңгесе дә кылычы, яшел чалмасы белән генә ул Дәҗҗал гаскәрен ничек итеп җиңә алыр икән соң?

4. Зөлкарнәйн дигәннәре нинди кош тагын? Дин галимнәре аны ачык итеп әйтми, пәйгамбәр дә кебек, гади бер дәрвиш кебек тә. Коръәндә исә аның турында шундый сүзләр генә бар:

«...Ике тау арасына килеп җиткәч, Зөлкарнәйн кеше сүзен көч-хәл белән генә аңлый ала торган халыкка очрады. Алар әйтте: йә Зөлкарнәйн! Яәҗүҗ белән Мәәҗүҗ җирдә кяферлек таратып йөриләр. Без сина салым җыеп бирик тә, син безгә алардан сакланырлык итеп коймa корып бир»..

Зөлкарнәйн риза була. Ике тау арасына бик биек итеп мәгъдән эретеп коя.

*(Коръән, «Мәгарә» сүрәсе, 92—95 аятьләр.)*

Янәсе, кыямәт көнне Яәҗүҗ белән Мәәҗүҗ шул койманы ашап чыгачак. Ә кайда соң ул койма, җирнең кай төшендә? Кеше аяк басмаган, кеше белмәгән бер карыш җир дә юк бит хәзер. Кайда ул койман, Мөхәммәт агай? Юк андый койма.

Әйтергә кирәк, Мөхәммәт үзенең Коръәнендә берничә урында шундый дөньяда юк җирләр турында яза. Каф тавы ди. Андый тау юк. Ирем, Мәйдан, тагын әллә нинди шәһәрләр турында сөйләнә. Аларның шулай ук җир йөзендә булганнары юк. Ә Зөлкарнәйн? Менә анысы булган, ул тарихи шәхес. Зөлкарнәйн — аның кушаматы, ике мөгезле дигән сүз. Аның шлемы кайчандыр немец солдатлары киеп йөргән каска кебек ике мөгезле булган. Шунлыктан замандашлары шундый кушамат такканнар. Чын исеме Александр Македонский. Көнчыгыш аны Искәндәр дип тә йөри. Әлбәттә, ул пәйгамбәр дә, дәрвиш тә түгел. Коръән иңүдән 10 гасыр элек яшәгән Македония патшасы. Дөньяны тетрәтеп торган шанлы полководец, Иранны җиңгән, Сирияне буйсындырган, Һиндстанга хәтле барып җиткән. Үзе үлгәч, аның турында бик күп легендалар таралган. Мөхәммәт һәм дин язучылары илһамны шул легендалардан алганнар.

Алланың мөселманнар белән кяферләрне сортын сортка аертып, Сөләйман мөһерен суктырып йөртүе, барыннан да бигрәк, бу эшне фәрештәләргә кушмыйча, мөгезе күккә житкән, һәм фәкать шул эш өчен генә яратылган хәшәрәткә тапшыруы безне борчыганнан да бигрәк таң калдырды. Тагын бу хәшәрәт кемнең кем икәнен каян белер икән соң? Коръән әйтүенчә, кыямәт көнне алла үзе дә әле кемнең кем икәнен кешенең гамәл дәфтәрен укып карагач, тагын үлчәүгә салып үлчәгәч кенә беләчәк түгелме соң?! Шул ук вакытта бу алланың фәрештәләрдән гайри хәшәрәтләр ярдәменә дә мохтаҗ икәнен фаш итүе була түгелме? Безнеңчә, Мөхәммәт уйлап чыгарган алланың булдыксызлыгына, аның камиллектән бик ерак булуына, бу үзе генә дә җитәрлек дәлил.

Әйтергә кирәк, кыямәт көн алланың хөкеме гомумән хәзерге заман корольләренекеннән бер дә артык түгел. Ул көнне мәсьәләне әнә шул хәшәрәтләр дә фәрештәләр хәл итәчәк. Әйе, әйе, бу хак сүз. Алла кешенең штанын төшереп, Сөләйман мөһерен күрдеме? — Күрде. Мөнкир белән Нәкир, бу кеше кабердә иманын чатнатып әйтте дип раслап торамы? — Тора. Үзе шулар өстенә кешенең гамәл дәфтәрен үлчәп карадымы? — Карады. Шуларга таянып, бу бәндәне җәннәткә дип хөкем чыгардымы? — Чыгарды. Бәндә, сораша-белешә, җәннәткә йөгерде. Ә анда, исән торамсың: сират күпере! Кылдан нечкә, кылычтан үткен!.. Як-ягында фәрештәләр. Кулларында тимер ыргак! Менә кемнәр хәл итәчәк синең язмышны! Күпердән чыктым дигәндә генә фәрештәләр сыйрагыннан эләктереп алды исә, син җәһәннәм поход пошел!.. Я, әйт, укучым, мәсьәләне кем хәл итте?

Ә күпере, шагыйранә ялган буларак, күңелле генә. Тик менә кылдан нечкә, кылычтан үткен булгач, аннан табигый шартларда бишектән төшкәннән бирле мәңге намазлык өстендә утырган изге дә, хәтта Мөхәммәт үзе дә чыга алачак түгел. Корбанга чалган кәҗәңнең дә ярдәм итүе бик шикле. Моның өчен үзеңә дә гайри табигый булу кирәк, күпердән үтәрдәй кешегә алла шул гайри табигыйлекне бирәчәк тә инде, дисеңме? Менә ул чакта башка мәсьәлә. Ләкин ул чакта күпернең кылдан нечкә, кылычтан үткен булуының әһәмияте калмый түгелме соң?

Адәм галәйһиссәләмнең мәние белән балчык кушылудан яралган Яәҗүҗ-Мәәҗүҗнең башта бер зат булып соңра Яәҗүҗ белән Мәәҗүҗгә әйләнүе әллә ни гаҗәп түгел. Алла тоткандыр да, Адәм кабыргасыннан Хаваны ясаган кебек, Яәҗүҗдән Мәәҗүҗне әмәлләгәндер дә куйгандыр. Тик шунысы гаҗәп. Бу хәшәрәт җирнең җиденче катыннан бер төн эчендә ничек чыгып җитә икән, моның өчен дөньядагы иң йөгерек атка 40 тапкыр тизрәк йөгерергә кирәк булыр иде. Җитмәсә, бу хәшәрәт, үзенә юл салу өчен, алма эченә кергән корт кебек, җирне, аның эчендәге җир күмерләрен ашый-ашый, кайнап торган магъдәннәрне, нефтьне эчә-эчә йөгерергә тиеш бит. Бүген дә, иртәгә дә, 7 мең ел буена! Һәм һәр тапкырында җир кукәй кабыгыдай юкарып калганчы шул эшне дәвам итәргә тиеш.

Ә Кояшны җирдән бер миллион өч йөз мең тапкыр зуррак, кайнап торган тимердән 4 тапкыр кызурак Кояшны фәрештә ничек һәм нинди куллары белән тотып тора икән? Гомер буена бит! Ә Кояшның җиргә егылып төшүе, Кояштан миллион тапкыр зуррак та, миллион тапкыр кызурак та миллиардларча йолдызларның Җиргә сибелүе, бичара Җирнең шул чакта кымшанып кына да куймавы турында нәрсә әйтер идегез, мулла абзыйлар?

Иң кызыгы — Газраил зары. Имештер, ул мөселман җанын йомшак итеп ала белә, ә үзенекен кешенең коты очып үләрлек каты итеп куптара!.. 7565 ел буена ничәмә-ничә мең — миллиард кешенең җанын алып йөргән, ә җан бирүнең авыр икәнен белмәгән... «Белсә, янәсе, беркемнекен дә алмаган булыр иде...» Көләрсең дә, еларсың да...

## 7

## «ИМАН КИТЕРСЕННӘР ДИСӘ, АЛЛАҢ ҮЗЕ ТӨШЕП КҮРЕНСЕН». МОГҖИЗА КҮРСӘТ СИН БЕЗГӘ. МӨХӘММӘТНЕҢ КҮККӘ СӘЯХӘТЕ.

Кыргый-кыргый дибез дә, халык җүләр булмаган, тапкыр булган, мин әйтер идем, материалист булган. Мөхәммәтнең җәннәтләренә, кыямәтләренә ышанмый. Ике арада бәхәс китә. Һәм бу бәхәс алланы тагын бер тапкыр юкка чыгару, Мөхәммәтне ялганчы итеп күрсәтү белән бергә, халыкның уйлары никадәр төпле булганын, халыкка нисбәтән Мөхәммәтнең никадәр мескен булганын раслый.

«Төшендә күргәннәрен сөйли. Хәйлә белән үзе уйлап чыгарган... Дөрес булса, әнә элекке пәйгамбәрләр кебек могҗиза алып килсен ул безгә, ә бу шагыйрь генә бит», диләр.

*(Коръән, «Пәйгамбәрләр» сурәсе, 5 аять.)*

«Шагыйрь генә бит...» Бу сүз Мөхәммәтнең башына күсәк белән суккан кебек тәэсир итә. Ул шигырь дигән сүзләрдән шайтан бисмилладан курыккан кебек куркып яши. Чөнки гарәп шигырьне тыңларга яратса да, әхлак, мораль нормаларын башлыча шул шигырь аша өйрәнсә дә, хикмәтле сүзләрне шул ук шигырь аша үзләштерсә дә, шигырьне сихер эше, сихерчеләр эше дип белә. Шуңа күрә Мөхәммәт алла исеменнән тиз генә бер-бер артлы берничә аять әвәләп чыгара:

«Коръән — шагыйрь сүзе түгел, сихерче сүзе түгел, алла сүзе». «Без Мөхәммәтне шигырьгә өйрәтмәдек, шигырь аның өчен язык гамәл».

*(Коръән, «Котылгысыз» сурәсе, 41—42 аятьләр, «Ясин» сурәсе, 69 аять.)*

Бер үк вакытта алла могҗиза таләп итүчеләргә мондый җавап бирергә куша:

«Син аларга әйт, — ди алла. — Мин илче генә бит диген».

*(Коръән, «Исраил балалары» сурәсе, 95 аять.)*

— Нигә бүтәннәр дә илче генә булганнар түгелме соң? Һәм син үзең аларны әнә нинди могҗизалар күрсәтеп йөргәннәр диден түгелме соң?..

Мөхәммәт шундук алла исеменнән яңа вәхи әвәләп өлгерә: «Без индергән Коръән җитмимени аларга?» Янәсе, шул үзе могҗиза бит инде.

(*Коръән, «Үрмәкүч» сүрәсе, 50 аять.*)

Түгел шул. Гарәпләр аның бер дә могҗиза дияр җирен күрмиләр. Менә нәрсә диләр алар:

«Аллаң безне үзенә иман китертәсе килсә, үзе төшеп күренсен, яме! Яки безнең катка фәрештәләр җибәрсен...»

(*Коръән, «Форкан» сүрәсе, 23 аять.*)

Әйе, әйе. Фәрештәләр күк белән җир арасында гел йөреп торалар дисең түгелме соң син... Нигә бу якларга бер дә килеп чыкмыйлар?.. Иңбашларыбыздагыларның да, нигәдер, тавыш-тыннары ишетелми әле...

Мөхәммәттә монысына җавап юк. Ә алланың төшеп күренмәвен болай аклармакчы:

«Алла кеше белән вәхи аша яки чаршау артында торып кына сөйләшә».

(*Коръән, «Киңәш» сүрәсе, 50 аять.*)

— Яшь киленнәр кебек икән, хи-хи-хи...

— Ярый безгә чаршау артында торып сөйләшсә дә... Бар, алып төш үзен, Мөхәммәт.

Мөхәммәт алып төшми. Ә гарәпнең даулавы даулау:

«...Җирдән чишмә чыгармый торып, яки өстебезгә күкне ишеп төшерми торып, яки үзеңнең алтын белән бизәлгән өең булмый торып, яки үзең белән алланы һәм фәрештәләреңне алып килми торып, яки үзең күккә күтәрелми торып, без сиңа ышанмыйбыз».

(*Коръән, «Исраил балалары» сүрәсе, 92—95 аятьләр.*)

Чыннан да, кем гарәпне акыллы булган димәс!

Моңа каршы Мөхәммәт алла исеменнән фәкать бер «Җибәрелүчеләр» сүрәсендә генә дә: «Пәйгамбәрне ялганда гаепләүчеләр кыямәт көнне җәзасын алачаклар» дигән сүзләрне попугай кебек җиде тапкыр кабатлый.

Ләкин гарәп монысыннан да өркми. Хәзер Мөхәммәтнең алласы, «бул!» дию белән бөтен галәмне юктан бар иткән алласы, бер уч гарәпне үзенә иман китертү өчен ант итәргә мәҗбүр. Хәзер ул шундый түбәнлеккә төшүгә мохтаҗ. О-о, нәрсәләр белән генә, ничек кенә ант итми ул! Йолдыз белән дә, кояш, ай белән дә ант итә. Файдасы булмагач, түбә калае белән ант итә. Так-җеп белән ант итә. Зәйтүн агачы да калмый, каләм белән Синай тавы да калмый. Ниһаять, (бу кадәр илаһи, бу кадәр изге сүзләрне гади хәрефләр белән язарга мөмкинме!..), аллабыз ир җенесен, хатыннар җенесен ясый торган нәмәрсә белән ант итәргә мәҗбүр!

— Нәмәрсә — анысы әйбәт. Ләкин, син, Мөхәммәт туган, боргалап маташма, пәйгамбәр икәнсең, күрсәт могҗизаларыңны. Әнә бер дә булмаса, Сафа тавын алтын тавына әйләндер.

Алладан яңа вәхи:

«Әйт: могҗиза алла кулында диген».

(*Коръән, «Хайван» сүрәсе, 109 аять.*)

— Бик яхшы. Алайса аллаң үзе күрсәтсен.

— Әйе, әйе, безгә барыбер...

Бик аптырата башлагач, Мөхәммәт кызык кына бер хәйлә уйлап чыгара:

— Мин сезнең теләк белән аллага мөрәҗәгать итеп караган идем, ул миңа менә нәрсә диде:

Мин аларга могҗиза җибәрермен, җәл түгел, ләкин Фиргавен Мусага ышанмаган кебек, алар да сиңа ышанмаслар диде, нәтиҗәдә мин аларны, Фиргавенне һәлак иткән кебек һәлак итәргә тиеш булырмын, диде. Шуңа күрә мин алланың сезне һәлак итеп ташлавыннан куркып, сүземне кире алдым.

(*«Хайван» сүрәсе, 109 аять, «Шагыйрьләр» сүрәсе, 197 аять, Тәфсир ибне Җөзирнең 69—70 җөзьә, 15 битен кара.*)

— Үтми, пәйгамбәр, иман китертәсең килсә, могҗизаны чыгарып сал безгә!

Инҗилдә шундый әкият бар. Христианнарның Тихон исемле изгеләре, шайтанга атланып, бер төн эчендә Иерусалимга барып кайта. Мөхәммәт бу әкиятне белә һәм, гарәпләр үзен тәмам стенага китереп терәгәч, шул әкиятне могҗиза өчен тагын да зуррак масштабта, тагын да шаккатырмалырак итеп кабатлый. Әлбәттә, ул аны гамәлдә кабатлый алмый, тик таңнардан бер таңда бу хакта алладан шул могҗизаны раслау вәхие генә килеп төшә:

«Үзенең колын (Мөхәммәтне) бер төн эчендә Мәсҗеделхәрамнан иң ерак мәчеткә алып менеп, сәяхәт кылдырып кайткан аллага дан булсын! Без моны кешеләр гыйбрәт алсын өчен эшләдек», — ди алла.

*(Коръән, «Исраил балалары» сурәсе, 1 аять.)*

Алла (ягъни Мөхәммәт) бу сәяхәтне үзе әлләни тасвирлап сөйли алмый. Аның каравы, соңыннан шул аять нигезендә дин китапларының һәркайсында урын алган мәзәк кенә бер әкият дөньяга килә:

«Коточкыч караңгы, искиткеч тын бер төн иде. Бөтен табигать хәрәкәтсез калган, гүя бөтен нәрсә үлеп беткән. Бөтен нәрсә: әтәчләр, этләр, җил тынган, арыклардагы сулар, агудан туктап, катып калган. Мөхәммәт үзенең бикәче Хәдичә белән бер гамьсез йоклап ята... Төн уртасы җиткәндә Мөхәммәт таныш тавыш ишетеп уяна.

— Йокыңнан тор, әй Мөхәммәт! — ди тавыш.

Мөхәммәт, күзен ачып җибәрсә, Җабраил фәрештә. Канаты, һәрвакыттагыча җитмеш, өстендә энҗеләр, алтыннар белән чигелгән озынча күлмәк. Җабраил ялгыз түгел, янында Әльбрук исемле оча торган ат. Җәннәт аты. Фиргавен айгыры гашыйк булган бия түгел, бүтән. Канатлары — бөркет канаты. Койрыгы — мисле койрыклы йолдыз. Күзләре — таң йолдызы. Үзе ходаның хикмәте, безнеңчә сөйләшә...

— Атлан үзенә, әй Мөхәммәт, — ди Җабраил аның тезгенен пәйгамбәргә тоттырып.

Мөхәммәт шундук Әльбрукка атланып күккә аша...»

Ул анда китапның беренче өлешендә бәян кылынган төрле кыяфәттәге фәрештәләрне күрә. Әллә кайчан үлеп күккә ашкан пәйгамбәрләрне күреп сөйләшә. Алланың үзе янында була.

Алла бер кулын Мөхәммәтнең иңенә салып, икенчесен аның күкрәгенә куеп сөйләште диелә әкияттә. Алла кулы орынуга пәйгамбәрнең тәне эсселе-суыклы булып китте. Суык җелекләренә кадәр үтеп керде.

Тагын нәрсәләр турында сөйләшкәннәрдер, Мөхәммәт анысын үзе белән кабергә алып киткән. Җиргә төшкәч ул ишеткән-күргәннәреннән фәкать шуларны гына фаш итә:

«Алла намазны көнгә 50 тапкыр йөкләгән иде. Сатулаша торгач, 5 кә калдырды тагын,— ди.— Башка гыйбадәтләрне дә киметтермәкче булган идем дә, «минем сүзләрем үзгәртелми», диде».

Барыннан да күңеллерәге — «Мөхәммәт биредә мөселманнар өчен әзерләп куелган яшь кызларны (хур кызларын булса кирәк — Г. Г.) күрә. Гүзәллекләрен күз алдына китерү өчен безнең хыял көче җитә торган түгел. Берәрсе күк йөзендә пәйда булган чакта, нуры бөтен галәмгә җәелеп, Кояш оятыннан тутыгып кала. Әгәр дә мәгәр, диңгезгә берәрсенең бер генә бөртек төкереге тамса, диңгезнең авызга алгысыз тозлы суы эчеп туймаслык ширбәткә әверелә. (Әй, гарәп, гафил булма, иман китерсәң, әнә нәрсәләр көтә сине җәннәт багъларында!..)

«Мөхәммәт, янәдән җиргә төшеп, Иерусалим мәчетенә кереп, намаз укыды. Соңра, Әльбрукка атланып, өенә кайтырга чыкты. Менә инде ул үзенең өендә, янәдән хәләл җефетенең кочагында...»

Биредә гыйбрәт алырдай хикмәт шул: Мөхәммәт күккә менә, пәйгамбәрләр белән сөйләшә, алла белән әңгәмә кыла, намаз саны турында сатулаша, хур кызларының төкерекләре диңгезгә тамып суын ширбәт иткәнен көтеп тора, — өенә кайтып керсә, ходаның хикмәте, — бу сәяхәтнең бөтенесенә күз ачып йомган кадәр генә дә вакыт үтмәгән була!.. Җабраил кереп уятканда, ялгыш канат очы тиеп китеп, кувшинны аударган икән, Мөхәммәт әйләнеп кайтканда әнә шул кувшинның суы да түгелеп

бетмәгән, хәтта кувшин үзе дә идәнгә төшеп җитмәгән, Мөхәммәт аны тотып алып, урынына утыртып куярга өлгерә!..

Бер булса да, бергәйле могҗиза, шулай түгелме? Ә Мөхәммәтнең өенә кайтышлый бер кавемнең уттан ясалган кайчы (??) белән иреннәрен кисеп утырганнарын карап торганын да, аннары эчләренә елан-чаяннар кереп оялаган кавем (???) янынннан үтеп киткәндә дә, тагын хур кызлары түкереп ширбәткә әверелдергән судан соң юлда очраган кәрванчылардан гади су сорап алып эчүгә киткән вакытны да өстәсәк, могҗизаның бергәйлелеге тагын да көчәйсә кирәк.

Дин әһелләре тузга язмаган бу әкиятне авыз суларын корытып сөйлиләр, аңар Мигъраҗ кичәсе дип исем биргәннәр. Һәр елның рәҗәп аенда бәйрәм итәләр.

Әкиятнең кызыгы, аның чеп-чи ялган икәнен фаш итә торган урыны менә кайда.

Әкият раславынча, Мөхәммәт үзенең бу сәяхәте турында икенче көнне иртән торып чыккач, гарәпләрне җыеп сөйли.

— Ә, юк, батмый пәйгамбәр. Безнең алда эшләрләр син ул могҗизаңны, — диләр гарәпләр. — Алай син нәрсә сөйләмәссең...

Берсе, ышанган булып:

— Иерусалим мәчетендә дә булгансың икән, син безгә шул хакта сөйләп бир әле, ни рәвешле ул? — ди.

Мөхәммәт көтелмәгән сораудан каушап кала:

— Мин анда озак тормадым бит, караңгы да иде; рәтләп күреп булмады...

Җиде кат күкне йөреп чыккан, фәрештәләрне санап чыгарга, канатларын санарга, буйларын, миллион-миллион чакрымлы ике каш араларын үлчәргә өлгергән, хур кызларының төкерекләре җирдәге диңгезгә кадәр төшеп суны ширбәткә әйләндергәнен карап торган, татып караган. Ә менә мәчет турында, хикмәти хода, бер сүз әйтә алмый! Хәер, ничек әйтә алсын: бу мәчет Мөхәммәт туудан 600 ел элек җимерелгән була!

Хәзерге муллаларның, барысы да түгел, бөек Тукай язган кебекләре, «Кибәк башта кибән чалма, ишан булган имеш хайван» кебекләре бу әкиятнең фальшен томалау теләге белән, Мөхәммәт ул Мәсҗеделхәрамда түгел, Акса мәчетендә булган диләр, һәм монысы белән тагын бер кәррә көлкегә калалар. Әйе, Иерусалимда Акса дигән мәчет бар. Һәм ул Мәсҗеделхәрам нигезенә салынган. Ләкин — кайчан? Мөхәммәт вафат булгач, Гомәр исемле хәлифә Иерусалимны басып алгач!

Муллаларның намус дигән нәрсәне бөтенләй җуеп бетермәгәннәре, халыкны шыр тилегә санамаганнары, Мигъраҗ турында элек-электән эчтән тына килделәр, хәтта инкарь иттеләр. Мөхәммәтнең замандашларыннан Мәгавия белән Хәсән Басрый дигән ике галим, Мөхәммәт Мигъраҗ маҗараларын төшендә генә күргән, дип язып калдырганнар. Пәйгамбәребезнең хатыннарыннан бер хатыны Гайшә абыстай да шуны раслый.

*(«Тәфсир ибне Җөзир» 13 җөзьә, 15 бит.)*

Казанның атаклы дин галимнәреннән Сөнгатулла Бикбулат та үзенең 1914 елда бастырып чыгарган «Хәзрәте Мөхәммәт» дигән китабында борынгы хәдисләргә, авторитетлы ислам галимнәренең сүзләренә таянып, бернинди мигъраҗ булмаганны, пәйгамбәрнең аны төшендә генә күргәнен сөйләп килә-килә дә, үз сүзләреннән үзе өркеп:

«Мигъраҗның төштәме яки уягъ хәлдәме булганын җәнәби алланың үзенә калдыру тагын да артыктыр», — ди.

*(«Хәзрәте Мөхәммәт», 114—115 битләр.)*

Бу мәсьәләдә даһи Толстойны ислам диненә өндәп йөргән Казан дин әһелләренең карашы үтә кызыклы. Алар Толстойга язган хатларында мигъраҗны инкарь итеп кенә калмыйлар, аны булган хәл дип йөрүчеләрне динне бозучылар дию гә кадәр барып җитәләр. Ләкин, менә бәла! Мигъраҗ — ислам диненең әләмена язылган бит ул! Ислам диненең изге ташларыннан берсе бит ул! Мөхәммәтнең пәйгамбәрлек мөһере бит ул! Мигъраҗны инкарь итү — пәйгамбәрне инкарь итү, кимендә аны ялганчыга чыгару була бит!.. Уйлап карагыз, мулла абзыйлар, безнеңчә, шулай.

Дини китаплар Мөхәммәтнең пәйгамбәрлек чорын мигъраҗдан гайри дә бик күп могҗизалар белән бизиләр. Мәсәлән, ул, имештер, айны урталай ярып, берсен уң җи-

ненннән, икенчесен сул җиңеннән чыгарган... (Диаметры ун мең километрлы айны!) «Бу могҗиза» дин ислам шагыйрьләренә дә илһам биргән:

«Ярылды ай икегә
шунда чын халык гаян булды...»

Ләкин монысы да Мөхәммәттән 3—4 йөз еллардан соң әвәләнгән әкият. Имештер, ай ярылганны күреп торучылар да булган. Мәсәлән, ибне Мәсгуть, ибне Габбас, ибне Гомәр. Хәлбуки Гомәр белән Мәсгуть бу вакыт бик бәләкәй булалар. Ә Габбас тумаган да була әле!

Нигә Габбаслар!.. Мөхәммәтнең үз тормышындагы җыен чүп-чарларны язып та, бу могҗиза һ. б. могҗизалар турында язмавы, бернинди могҗиза булмауга өстәмә дәлил түгелме соң? Мөхәммәт соңга таба, инде сугышлар заманында, үзенең гади кеше икәнен раслап, үзе үк бернинди могҗиза эшләмәгәнен, эшли дә белмәгәнен раслап, менә нәрсә ди:

«Алла җир йөзенә төрле пәйгамбәрләр җибәргән. Алар төрлесе төрле юллар белән дингә өндәгәннәр... Ләкин болар гына җитәрлек булмаган... Хәтта әнә Муса белән Гайсә могҗизаларына да ышанмаганнар. Шуңа күрә алла минем кулыма кылыч тоттырып җибәрде».

Мигъраҗны селкенергә дә ирек бирми инкарь итә торган тагын бер дәлил бар. Имештер, Мөхәммәт алла белән сатулаша торгач, намазны 50 дән 5 вакытка калдырта. Ә намаз, беләсегез килсә, Мөхәммәт Мәдинәгә һиҗрәт кылгач та әле иртә кич кенә укыла торган була. 5 вакыт намаз Мөхәммәт вафат булгач кына кертелә.

## 8

## СУКЫР ТАВЫККА БАР ДА БОДАЙ. КӘҖӘНЕҢ СӨТЕ КАЙ ҖИРЕНДӘ?

Мөхәммәт, табигать баласы буларак, галәм һәм табигать турындагы аятьләрне аеруча зур дәрт белән язган, күп язган. Бөек Пушкин раславынча, әкият буларак, матур язган. Ләкин, әлепне таяк дип белмәгәне хәлдә фәнни яктан, замандашларыннан, ярым кыргый гарәпләрдән, дөресрәге, әби-бабалары сөйләгән әкиятләрдән, ерак китә алмаган, фәкать алар хыял иткәнчә генә фикер йөртә алган. Әгәр ул үзенчә фараз итүдән, әкиятләргә ышанудан, Тәурат, Инҗилләргә таянудан бигрәк үз заманында яшәгән гарәп астрономнарына, гарәп укымышлыларына таянып, яңа туып килгән табиплар белән аралашып эш иткән булса, бәхәссез, хакыйкатькә якынрак килә алган булыр иде, нәтиҗәдә бу кадәр үк көлкегә калмас иде. Хәер, ул чакта Мөхәммәт Мөхәммәт тә булмас иде, пәйгамбәрлек дәгъва итмәс иде. Гомеренә күпец булып калыр иде яки зирәк, тырыш, сәләтле бу гарәп бүтән берәр кәсепкә керешер иде.

Мөхәммәтнең табигать турындагы иҗатының күпчелеге пәйгамбәрлегенең башлангыч чорына туры килә. Бу чорда ул үзенең Коръәненә медицина, анатомия, физиология, биология мәгълүматларын да тутыра. Тик Мөхәммәт аларны төрләренә аерып тормастан, бөтенесен, уптым илаһи, табиплык (врачлык) гыйлеме дип йөртә.

«Коръән — мөселманнар өчен табиплык гыйлеме», — ди ул «Ачыклау» сүрәсенең 44 аятендә. Ләкин аның бу табиплык гыйлеме дә без китапның башында күреп үткән астрономиясе кебек үк соң дәрәҗәдә наив. Аның өйрәтүенчә: а л л а к е ш е н е б а ш т а т у ф р а к т а н я с а д ы, а н н а р ы җ и р ә н е ч т а м ч ы д а н, и р л ә р о р л ы г ы н н а н я с ы й б а ш л а д ы.

*(Коръән, «Фәрештәләр» сүрәсе, 12 аять, «Сәҗдә» сүрәсе, 6—7 аятьләр.)*

Күрәсез, пәйгамбәр коры судан, он кушмыйча, ипи изеп булмаган кебек, бер ирләр орлыгыннан гына кеше хасил булмаганын да белми. Ирләр орлыгына хатын-кыз орлыгы кушылу шарт, һәм шуннан соң инде бу эш өчен бернинди алланың да, мулланың да кирәге калмый.

Баланың бер аталык орлыгыннан хасил булуын дини китапларда күп кенә дәлилләр белән «исбат» итәләр. Әлбәттә, һичберсе җитди түгел. Шулай да без җөмләдән берсен укучы игътибарына тәкъдим итәбез.

Көннәрдән бер көн атабыз Адәм белән анабыз Хава арасында бәхәс куба. Бала миннән була! Юк, миннән!

— Исбат ит!

«Хава үзенен шәһвәтен бер шешәгә салды. Көтә-көтә көт булдылар, баланың «б»сы да юк. Инде атабыз Адәм үз шәһвәтен салды, шешәдә менә дигән углан пәйда булды!»

Шунлыктан аңа Шис дип исем бирәләр. Ә алла аны этисе урынына пәйгамбәр итеп куя.

*(Рабгузи, «Кассас-эл-әнбия», «Кыйсса Шис галәйһиссәләм», 30 бит.)*

Мөхәммәт пәйгамбәр шул рәвешчә, «табиплык гыйлеме» бабендә буталыпмы бутала. Аны ике тапкыр икенең дүрт икәнен белмәгән сабыйны кызганган кебек кызганасың, хәтта теләктәшлек күрсәтәсең килеп китә. Ләкин елмаймый үтә алмыйсың. Ә ул үзе бик җитди һәм кеше ясау турында ул аеруча мавыгып яза, күп яза.

«Без сезне җирәнеч сыекчадан ясыйбыз түгелме соң?» — ди ул алласы исеменнән бик белдекләнеп. — Ул җирәнеч сыекчаны билгеле бер вакытка ышанычлы урынга (!) урнаштырып куябыз да, шуннан сез килеп чыгасыз түгелме соң?»

*(Коръән «Җибәрелүчеләр» сүрәсе, 20—22 аятьләр.)*

«Кеше үзенең нәрсәдән яралганын күрсен иде. Ул күкрәк сөягеннән һәм арка җелегеннән агып килә торган сыекчадан ясала».

*(Коръән, «Төнлә килүче» сүрәсе, 5—7 аятьләр.)*

Никадәр тасвирлау, сурәтләү, кинаяІ.. — дияр иде бу урында тәнкыйтьче.—Ачыктан-ачык сөйли, әһ, бөтенесе-бөтенесе күз алдына килеп баса!.. Ә син, укучы иптәш, күрәм, җирәнеп йөз чөерәсең. Җитәр инде дисең. Ә син түз. Кат-кат укы. Укы да, моннан соң да алла, Коръән һәм Мөхәммәтнең никадәр надан һәм әдәпсез икәненә хәйран кал. Әти-әниләреңнең, әби-бабаларыңның мең ел буена алданып үткән гомерләрен кызган. Бүген синең улыңа, оныгыңа, мәктәптә шуларны ятлап миләрен чертергә кирәк булмаганга сөен.

Юк, бетмәде әле. Мин дәвам итәргә телим.

«...Без ул тамчыны ышанычлы җиргә урнаштыргач, — ди Мөхәммәт, — аннары кан оешы ясадык, ул канны бер кисәк ит иттек. Ул иттән сөякләр ясадык. (!!!) Сөякләрне ит белән капладык. (!!!) Аллага дан! Алла иң оста ясаучы».

*(Коръән, «Иманлы кешеләр» сүрәсе, 14 аять.)*

Күз алдыгызга китерегез әле: бала башта ит була. Аннан сөяккә әйләнә. Аннары сөяк ит белән каплана... Моның сабыйларча наив икәнен фаш итү өчен зур белем кирәкме?

Һәр ана өчен көн кебек ачык мәсьәләләрдә дә Мөхәммәт компетентлы түгел. Тагын. Мөхәммәт сүзенә караганда, ана баланы карынында 6 ай йөртә, күкрәк сөтеннән ике яшь тулгач аера.

*(Коръән, «Локман» сүрәсе, 13 аять, «Комнар» сүрәсе, 14 аять.)*

Кешедән хайваннарга күчеп, алла, ягъни Мөхәммәт менә нәрсә ди (монысының да сүзләре бик үк нәзакәтледән булмас, шулай да без аны йөгертеп кенә булса да, сыңар күзебез белән генә булса да, укып китик әле, укучым).

«Сезнең өчен мал-туарда да гыйбрәт алыр нәрсә бар, — ди Мөхәммәт «Балкортлары»ның 68 аятендә. Һәм безгә менә нинди гыйбрәтле белем бирә: — Без сезгә аларның корсакларындагы кан белән тизәкләре арасыннан саф һәм татлы сөт савып эчерәбез».

Комментарийлап тору кирәкмәс. Ә менә рәсемен нинди күңелле итеп ясап булыр иде. Сыер корсагының бер ягында кан, икенче ягында тизәк, уртада сөт. Алла, шуны савып алып, безгә эчерә!.. Мактый-мактый эчерә. Эчегез эч, бик тәмле ул, ди, бик саф ул, ди...

Әгәр бүген институт кафедрасыннан берәр ветеринария фәннәре докторы студентларга шундый лекция укыса, аны, әлбәттә, тилергән булуына әз генә шикләнмичә, шыпырт кына Арча кырындагы кызыл йортка озату чарасын күрерләр иде. Ә Мөхәммәт алласы турында нәрсә диярга соң?.. Фикер йөртеп кара, иптәш, әгәр алла чыннан да булып, ул кешене үз куллары белән ясаган булса, хайваннарны үзе яратка булса, алар турында шушы кадәр ахмак, шушы кадәр надан сүзләр сөйләп үзеннән көлдерер идеме?

Пәйгамбәребез өйрәткән «табиплык гыйлемнәре» арасында бар да шулай көлке генә түгел, зарарлылары бар.

Мәсәлән, ул:

«Ислам дөньясында авыруның көчүе юк», ди. Ягъни, мөселман булсаң, сиңа әнә нинди льгота: авыру йокмый. Кяфергә йога, сиңа юк.

*(«Мең дә бер хәдис», 979.)*

Әгәр син хак мөселман икәнсең, моның дөрес түгел икәнен белсәң дә, ышанырга тиешсең, ваба, тиф, чахотка, сифилис, чәчәк, кызамык кебек йогышлы авыруларга капканны ачып куярга тиешсең. Чөнки, чирне көчә дип белү, аңардан саклану — язык эш:

«Вабадан качучы кеше сугыш сафыннан качучы кебидер. Вабалы җирдә сабыр итеп торучы — дошманга каршы торучы кебидер».

*(582 нче хәдис.)*

Әгәр дә инде, йогу юлы белән түгел, алла рәхмәте белән шул чирләрнең берәрсе үзеңне бәреп екса, алладан узып докторга чапмаска, садака гына бирергә тиешсең син. Мөхәммәт үзенең 436 нчы хәдисендә бу хакта бер дә икеләнергә урын калдырмаслык итеп, бик ачык итеп безгә шуны васыять иткән: «Авыруны сәдака белән дәвалагыз»,— дигән ул.

Ләкин, белмим, хәзер пәйгамбәрнең бу боерыкларын кем генә тота икән. Ә бит 1300 ел буена нәкъ шулай «дәвалап» килгәннәр. Мулла өшкергән җимеш, тагын да шифалырагы — ишан өшкергән таракан җимеше, алтын белән тәлинкәгә язылган колһуалла... Нәтиҗәдә, чир миллионнарча яшь гомерне вакытсыз теге дөньяга алып киткән. Революциягә кадәрге елларны, мәсәлән, 1913 елны 1964 ел белән чагыштырып карагыз. Тегендә һәр 100 мөселман баласының 75 е үлгән, бирeдә 100 нең нибары 1—2 се генә үлә. Дога файдалымы, кяфер даруы файдалыракмы икәне шул саннардан аңлашылса кирәк.

Мөхәммәт пәйгамбәрнең «табиплык гыйлемендә» үтә сәер урыннар бар:

«Алла төчкергәнне сөядер», ди ул үзенең 203 нче хәдисендә.

Төчкерү өчен, һәркемгә билгеле булганча, сулыш юлларына бераз салкын тидерү зарур. Хәер, алла сөйсен дисәң, анысына гына тырышырсың. Бирeдә шунысы сәер: безнең төчкерүдән аллага ни файда икән соң? Ни ләззәт таба икән безнең төчкерүдән? Нигә сөя икән ул безнең төчкерүне?

Коръәннең, хәдисләрнең шундый урыннарын төртеп күрсәтеп, стенага китереп терәгәндә хәзерге мулла абзыйлар, анысын сезнең кебекләр бозган аның, диярга өйрәнеп киттеләр.

Безнең кебекләрнең яманатын йолудан элек Коръәннең башыннан үткәннәргә бераз күз төшереп алу кирәк. Коръән 23 ел дәвамында «иңә». Иңгәнен берен алда әйткәнемчә, пәйгамбәрнең сәркәтипләре язып баралар. Кәгазь дигән нәрсә юк әле. Тире, яфрак, комач кебек әйберләргә кара белән язалар. Агач, яссы таш, дөя сөяге кебекләрне чукып яки уеп язалар. Ул чакта әле ислам дине хәзерге кебек бөтен дөньяга сибелер, киләчәк буыннар өчен кирәк булыр, бу кадәр озак еллар шәригать һәм ислам законнарының төп китабы булып, изге китап булып йөрер дип уйлау юк, языла да онытыла, кайсы кайда тузанга күмелеп, чәч тә баш тузып ята бирә. Аның кадере Мөхәммәт үлгәч, Гарәбстан, дәүләт буларак, камилләшкәч, ислам дине күрше илләрдә җирлек тапкач кына беленә башлый. Бер кулга туплау эшенә керешәләр. — Ә фәлән вакыт фәлән мәсьәлә турында әйткәне кайда? Эзлиләр. Сәркәтипләр ярминкәләр, базарларга ат менеп чыгып, көтүдән кайтмаган терлек-туарларын эзләп йөргән кебек:

— Әй, кем Коръән сүзләрен белә, әйтегез, — дип кычкырынып йөриләр.

Әлбәттә, туплау процессында кайбер хаталар киткән, бәгъзе бер урыннары төшеп калган, югалган булулары бәхәссез. Югалтылган булулары да гаҗәп түгел. Ләкин,

беренчедән, «безнең кебекләргә» аларны төшереп калдыруның, бозуларның хаҗәте юк; икенчедән, табигый ки, бу мөмкин дә түгел. Коръәнне туплау эшенә Мөхәммәт үлү белән үк керешелә. Һәм моны, безгә түгел, «безнең кебекләргә» түгел, исламның иң могътәбәр кешеләренә, шул җөмләдән Мөхәммәтнең асрамага алып үстергән улы Зәет ибне Хөррәткә, беренчеләрдән булып иман китергән иң ышанычлы мөселманга тапшыралар.

Тупланып, төзелеп беткәннән соң, Мөхәммәтнең каенатасы Әбүбәкер — Мөхәммәттән соңгы беренче хәлифә — тарафыннан редакцияләнеп кул куела. Әбүбәкер үлгәч Мөхәммәтнең Гомәр исемле икенче бер каенатасы, Гарәбстанның икенче бер хәлифәсе, Мөхәммәтнең Хәфаса исемле хатынында сакланган нөсхәсе белән чагыштырып кабат тикшереп чыга. Аннары Госман хәлифә редакцияли. Дүрт нөсхәдә күчереп алып, берсен Мәдинәгә калдыра, өчесен Куф, Басра, Мәккә шәһәренә җибәртә. Бу нөсхәләр хәзергә кадәр шул шәһәрләрдә сакланалар. Дин әһелләре тыныч булсын, анда аларны безнең кебекләр түгел, иң могътәбәр дин башлыклары саклый, сүрә белән аятьләрен әйткән дә юк, сүзләренә, хәрефләренә кадәр саналып, хәлифәләр мөһере басылган. Җәмгысе 77.439 сүз, 323.621 хәреф. Әйтәсем килгәне: Коръән Мөхәммәт ничек язган, шулай сакланган. Кәҗәнең сөте кайда булу, кешенең ана карынындагы процессы, Айның ай азагында пальма ботагы булып калулары һ. б. тузга язмаган әкәмәтләр бөтенесе-бөтенесе — Мөхәммәтнең үз иҗаты.

Кыскасы, Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең табиплык гыйлеме белән дә эш чыгара алмый. Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чума дигәндәй, Мөхәммәт тагын бер кәррә җеннәрне үзенең карамагына җим итеп карый. Әнә җеннәр булып җеннәр иман китерә инде, ди ул хәзер...

— Ничек?

— Шулай. Үзләре сорап килде. Ә хәзер алар анда, үз илләрендә, иптәшләрен иманга өндәп йөриләр...

— Мәзәк кеше син, пәйгамбәр.

— Ышанмасагыз, алла шаһит... Миңа әле генә Җәбраил фәрештә китереп китте: «Без синең катка Коръән тыңларга бер төркем җен җибәрдек. Тыңлап бетергәч, алар, өйләренә кайтып, үз халыкларын иманга өндәп йөрделәр. Алар әйттеләр: «Иә, безнең халкыбыз! Без Мусага җибәрелгән китаптан (Тәураттан — Г. Г.) соң иңгән Коръәнне тыңладык. Ул туры юлга алып баручы китап икән. Иә, безнең халкыбыз! Алланың өндәвенә колак салыгыз, аллага ышаныгыз. Ул сезнең гөнаһларыгызны ярлыкар, җәзадан һәм газаптан коткарыр. Ә инде ышанмасагыз, эшегез харап...»

*(Коръән, «Комнар» сүрәсе, 28—31 аятьләр.)*

Юк, пәйгамбәрнең бу җименә дә балык чиертми.

— Мәзәк тә кеше син, пәйгамбәр дус, — диләр гарәпләр.

## 9

## «БИК ИМАН КИТЕРЕР ИДЕМ ДӘ, АЛЛА КУШМЫЙ». ЧҮП ӨСТЕНӘ ЧҮМӘЛӘ. ТАГЫН БЕР УҢЫШСЫЗ АДЫМ.

Инде нишләсен икән пәйгамбәр?.. Тукта, миңа ничек итсен әле...

Мөхәммәт үзе хыял иткән алласы исеменнән кинәт миңа шундый сәер аятьләр яудыра башлый:

«Әгәр дә синең аллаң теләсә, бөтен кеше иман китерер иде. Юк, син кешеләрне иман китертә алмыйсың. Кешенең җаны фәкать алла кушса гына иман китерә».

*(Коръән, «Юныс» сүрәсе, 99—100 аятьләр.)*

Безнең Җир шартларына күчереп әйткәндә: бала бик әдәпле, бик инсафлы булып үсәр иде дә, әтисе кушмый, әтисе азып-тузып йөрергә куша! — Шулай булып чыга, әйе, бит? Алай гына да түгел, кяферләр мөселман булырга кызыгып куймасыннар өчен, алла:

«Чынлыкта кяферләрнең кылган гамәлләрен үзләренә ал да гөл итеп күрсәтә»!!!

*(Коръән, «Кырмыскалар» сүрәсе, 4 аять.)*

Әлбәттә, хәзер иманлы кеше тагын: «Бозганнар!..» дияр. Хәтта имансызлар да шикләнеп куяр. Янәсе, буяуларын куертмыйсыңмы, язучы? Юк, куертмыйм. Хәрефенә кадәр дөрес. Бу мәсьәләдә тагын да сәеррәк аятьләр бар әле. Мин әйтер идем, берсеннән берсе сәерләр. Фаш итүем өчен мулла абзыйларның кәефләре китсә китәр, мин аларны яшереп кала алмыйм.

Имештер, менә нәрсә ди алла безнең пәйгамбәргә:

«Аларны тугры юлга өндәсәң ни дә, өндәмәсәң ни. Алар барыбер сиңа иярәчәк түгел. Чөнки без **аларның алларына да, артларына да киртә кордык, күзләрен томаладык**...»

«**Кяферләр Коръәнне аңламасын өчен, без аларның йөрәкләренә пәрдә кордык, колакларын чукракландырдык**».

*(Коръән, «Ясин» сүрәсе, 8—9 аятьләр, «Исраил балалары» сүрәсе, 48 аять.)*

Алла (чыны: Мөхәммәт) бу тезисны очына-очына кабатлый:

«Кяферләр арасында сиңа ияргә теләүчеләр бар, — ди ул Мөхәммәткә. — Ләкин без аларның йөрәкләренә, Коръәнне аңламаслык итеп, пәрдә кордык, колакларын чукракландырдык. Шуңа күрә алар, гыйбрәтләрнең бөтенесен җыеп күрсәтсәң дә, иман китерәчәк түгелләр». Чөнки мин шундый зат, теләсәм нишләп йөрим, миңа берегез бер сүз әйтә алмый дип кенә әйтеп бетермәгән. Хәер, беравыктан ул анысын да әйтә:

«Кеше алла теләгәнне генә тели ала. Алла теләмәсә берни эшли алмый». «Без теләсәк кешене юлдан яздырабыз, теләсәк туры юлга юнәлтәбез».

*(Коръән, «Боргычлау» сүрәсе, 29 аять, «Хикәя» сүрәсе, 68 аять, «Ибраһим» сүрәсе, 4 аять.)*

Бәс шулай икән, кяферләрнең ислам динен кабул итмәвенә кем гаепле булып чыга инде, мулла абзыйлар? Сез алланың бу хөкемен ничек аңлата торгансыздыр, без исә, әгәр алла чыннан да булса, аның җирләр-күкләр патшасы булуына карамастан, күзенә карап: мондый курчак уены, кешене болай мәсхәрә итү нигә кирәк булды сиңа, дияр идек. Кеше белән болай кузна уйнарга синнән гайри беркем сәләтле түгел, дияр идек. Бәхетенә каршы һәм безнең бәхеткә каршы, ул юк. Шуңа күрә дә хәзер без әңгәмәне бу аятьләрнең авторын Мөхәммәтнең үзен күз алдында тотып дәвам итәбез.

Бу аятьләр Мөхәммәткә нигә кирәк булган соң? — Нигә ул үзенең алласын шул тикле дәһшәтле итеп, теләсә нишләп ятучы итеп тасвирлаган? Алласының «һәрнә кылса ирке бар...» икәнен исбат итү өченме? Иман китермәүче гарәпләрне куркытыр өченме? Әйе, анысы да бардыр. Ләкин төп сәбәп ул түгел. Ул бу сәер аятьләре белән, беренче чиратта, **үзенең булдыксызлыгын акларга теләгән**. Янәсе, **миннән түгел, әнә алла теләми бит**... Шул ук вакытта бу — маневр. Һәм яхшы ук оста маневр. Имеш, алла бүген сезне туры юлга кертергә, мөселман итәргә теләми. Ә сез аңардан сорагыз, үтенеп сорагыз, ялварып сорагыз. Ул сезнең йөрәкләрегездән пәрдәне алыр, колакларыгызны ачар, күзләрегезне ачар... Менә шулай эшләп карагыз әле...

— Маташтырма, пәйгамбәр, бу бит синең алланы тану булыр иде, ә без, бигайбә, аның үзен алып төшеп күрсәтми торып, бар дип әйтә алмыйбыз.

Кыскасы, бу җимгә дә балык чиертми. Мөхәммәт ярык тагарак янында утырып кала.

Җор гарәпләр беткәнмени. Берсе:

— Әй, пәйгамбәр, мин син әйткәнчә эшләп карадым: пәрдәңне ал, колагымны ач, күземне чиш, мөселман булыйм инде дидем, зинһарлап, ялынып-ялварып сорадым... Булмый ди. Әйдә пәйгамбәр дус, бергә сорап карыйк әле... бәлкем, син әйткәч тыңлар...

Мөхәммәт аның көлеп әйткәнен аңлый... ләкин коралын ташламый. Аллаң үз кеше булгач, ничек ансат. Җабраил яңа вәхи китереп китә:

«Кяферләр, бәлкем, мөселман булырга теләрләр. Ләкин кирәк түгел, калдыр син аларны».

*(Коръән, «Хиҗер» сүрәсе, 2—3 аятьләр.)*

Менә шунда инде гарәпләр бик акыллы, бик зирәк сорау биреп, пәйгамбәрне тәмам хур итәләр.

— Син безне туры юлга өндисең, алла бозык юлга өстери. Әнә анда минем кордаш, хәтта үзе үк, мине мөселман ит, дип тора, ә аллаң, итмим, ди. Бу ничек була соң инде? Янә бер сорау: бәс шулай булгач, синең безне өндәвең, үзеңнең дә, безнең дә башны катырып йөрүең нигә кирәк, пәйгамбәр?

Мөхәммәтнең моңа каршы җавабы булгандырмы, юктырмы, — мәгълүм түгел. Без бүген бу сорауны, дин ислам әһелләре сезгә бирәбез. Ләкин, белеп торам, мулла абзыйлар, бөтенегез бергә җыелып уйласагыз да, бу гади сорауга җавап таба алмыйсыз... Ах, Иблис ләгыйн бутый дисез... Ләкин алла үз авызы белән әйтә бит: кеше шайтан котырткангa иман китерми дими, мин үзем теләмәгәнгә ди! Юк, монда шайтанга урын юк. Аның вазифасын алла бик төгәл рәвештә үзе үтәп бара!

Көләрсең дә, еларсың да.

Шулай итеп, ун ел хезмәт Мөхәммәт өчен шатлыклы булмый. Нибары 70 сәхабә [1]. Ул да булса, хатыны Хәдичә, асрамага алган улы Зәед, Әбүталип улы Гали, берничә вак сәүдәгәр, калганнары — тамак туклыгын, кешечә тормышны җирдән таба алмагач, күктән өмет итүче ярлы-ябагай, коллар.

Ә яше бара, пәйгамбәр дип туктап тормый. Илленең өстенә чыкты бит инде...

Бер килсә килә икән ул, көтмәгәндә генә Хәдичә абыстай үлеп китә. Ул да түгел, агасы Әбүталип вафат була. Чүп өстенә чүмәлә!.. Мөхәммәтнең Әбүләһәпкә укыган каргышы кабул булмый. Явыз Әбүләһәп җәһәннәмгә китми, кулы да кормый, киресенчә, бу дин дошманын Әбүталип урынына шәһәр башлыгы итеп сайлыйлар. Хәдичә белән Әбүталип барында бик үк кыймаган дошманнар хәзер теш-тырнакларын күрсәтә башлыйлар. Мөхәммәтнең малларын базарга кертмәүгә кадәр барып җитәләр. Аның нәселеннән кыз алу, кыз бирүләр туктатыла.

Мөхәммәтнең өмет шәмнәре бер-бер артлы сүнә, пәйгамбәр тәмам төшенкелеккә бирелә. Риваятьләрнең, дин китапларының әйтүләренә караганда, ул бер мәлне хәтта үзенә кул салырга исәп итә.

Риваять нигезсез түгел. Аны «Шагыйрьләр» сүрәсенең 2 нче аяте бер дә икеләнергә урын калдырмый торган итеп ачып бирә:

«Алар (Мәккә кяферләре — Г. Г.) иман китермәгәнгә карап, син б ә л к е м үзеңне-үзең үтерергә уйлыйсыңдыр?..»

Бер үк вакытта бу аять Мөхәммәтнең бернинди дә пәйгамбәр түгел, гап-гади кеше икәнен кабат раслый.

Әйтергә кирәк, бу китапта без пәйгамбәр сүзен иске гадәт буенча гына кулланабыз. Пәйгамбәр — алда булачак хәлләрдән хәбәр, бирүче дигән сүз. Мөхәммәт исә андый эшләр кулыннан килмәгәнен үзе үк әйтеп бирә:

«Ә г ә р а л л а н и л ә р б у л а с ы н б е л с ә м, мин үземә күп итеп хәзинә җыяр идем», — ди.

Тагын:

«Мин алдагы көндә үземә һәм сезгә нәрсә буласын белмим», — ди.

*(Коръән, «Киртәләр» сүрәсе, 188 аять, «Комнар» сүрәсе, 8 аять.)*

Дин әһелләре, Мөхәммәтнең үзен-үзе үтерергә йөрүе турындагы аятьнең «бәлкемен» төртеп күрсәтеп, Мөхәммәтне акларга итенәләр. — «Бәлкем» дигән бит... Ләкин бу «бәлкем» һәм Коръән битләренә сибелгән бик күп «бәлкем»нәр Мөхәммәт белән алла файдасына сөйләмиләр. Киресенчә, Мөхәммәт ясаган алланың тоттен икәнен, хәтта әкият образы булырга да яраксыз икәнен фаш итәләр. Аның белү сәләте безнеккеннән артык түгел икәнен фаш итеп, аны гакылы белән дә нәкъ безнең кебек бер кеше кыяфәтендә алдыбызга китереп бастыралар. Моны исбат итү өчен Коръәннең алла исеменнән язылган берничә дистә аятен китерергә мөмкин:

«Алладан куркыгыз, б ә л к е м, бәхетле булырсыз».

«Алла, акыл белән эш итәләр дип ы ш а н ы п, сезгә шундый могҗиза җибәрә».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 243 аять.)*

---

[1] С ә х ә б ә л ә р — Мөхәммәтнең үзе исән чакта иман китергән кешеләре.

«Кайсы гына шәһәргә пәйгамбәр җибәрсәк тә, без аның халкын бәхетсезлек белән һәлак иттек. Менә инде, бәлкем, юашланырлар».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 185, 243 аятьләр, «Киртәләр» сүрәсе, 92 аять.)*

Бәни Исраилне Фиргавен золымыннан коткарып алып кайтырга дип, Муса белән Һарунны җибәргәндә алла болай ди:

«Икегез дә Фиргавенгә барыгыз, ул ахыр чиктә котырына, холыксызлана... Үзе белән юаш кына сөйләшегез, б ә л к е м, бездән куркып акылга утырыр».

*(Коръән, «Таһа» сүрәсе, 45—46 аятьләр.)*

Б ә л к е м — бәлкем килеш кала. Алда күренгәнчә, алланың өмете акланмый. Шул ук бәни Исраилне, бозауга табынып ятканнары өчен орышып, алла болай ди:

«Без сезне гафу иттек. Моның өчен безгә шөкрана кылырсыз дип б е л д е к».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 49 аять.)*

Мәгълүм булганча, алланың «дип белүе»дә акланмый. Бәни Исраил кяфер булып кала. Алланың Адәм белән булган конфликтын хәтерләгез.

«Адәмгә әйттек: Шайтан үзегезне җәннәттән ч ы г а р ы п к у й м а с ы н д и д е к».

*(Коръән, «Таһа» сүрәсе, 115 аять.)*

Димәк, чыгарасын-чыгармасын белмәгән?

«— Уң кулыңда нәрсә ул, Муса?

— Таяк, — ди Муса, һәм сабый бала аңлаткан кебек аллага аңлатып бирә: мин аңа таянып йөрим һәм сарыкларыма агачтан яфрак коям. Ул минем тагын кайбер нәрсәләр өчен хезмәт итә торган коралым».

*(Коръән, «Таһа» сүрәсе, 18—19 аятьләр.)*

Мөхәммәткә үзен-үзе үтерү уеннан кайтуга нәрсә сәбәп булганы мәгълүм түгел. Шунысы бәхәссез: көн дә берничә аять язмый калмаган Мөхәммәт хәзер айлар буена бер сүз язмый йөри. Ниһаять, башын күтәрә. Ул хәбәш халкының кылын тартып карау, җае чыкса, дингә өндәү максаты белән үзенең якыннарын Хәбәшстанга, Әдис-Әбәбә шәһәренә җибәрә, үзе шул ук теләк белән Мәккәгә якын гына булган Таиф шәһәрчегенә күчеп килә. Андагы халык Әллат исемле хатын аллага табыналар икән. Бер ай эчендә Мөхәммәткә бер кеше иман китерми. Чиләк төпләре кага-кага, этләр өстертә-өстертә мәсхәрәләп шәһәрдән куып чыгарып җибәрәләр.

Мәккәгә кайтса, хәбәр: Хәбәш патшасы сәхәбәләрне химая кылган, ләкин диннәре турында ишетергә дә теләмәгән...

# Дүртенче бүлек

«Кяферне күргән бер җирдә бәр дә үтер, бәр дә үтер».

*Коръән*

## I

## ПӘЙГАМБӘР КОЙРЫКНЫ СЫРТКА САЛА. МӨХӘММӘТ ӨЧ ДИН ПӘЙГАМБӘРЕ. ДҮРТ ЯГЫҢ КЫЙБЛА.

Инде нишләргә?

Мәккәдән 400—500 километр җирдә саф сулы елга буенда яшеллеккә төренеп, иркен сулап, Ясриб (Мәдинә) дигән кечерәк кенә бер борынгы шәһәр җәелеп ята. Еврей шәһәре. Гарәпләр дә байтак... Еврейләр 6 гасырдан бирле үзләре ясаган яһүд динен тоталар. Изге китаплары — Тәүрат. Берazы христиан динендә. Боларының изге китаплары — Инҗил. Гарәпләр исә мәҗүси диндә. Аларның да, Мәккә гарәпләренеке кебек үк, кабилә саен алла, гыйбадәтханәләрендә шул аллаларның сыннары тезелеп басып тора. Гарәп кабиләләре үзара этле-мәчеле. Шулай да аларны еврейләр белән булган

һәм милли, һәм дини дошманлык берләштерә. Тагын сәяси нигездәге дошманлык: шәһәрдә власть еврейләр кулында.

Таифтән соң Мөхәммәтнең күзе шул шәһәргә төшә. Моның тагын бер бик мөһим сәбәбе бар: Мәдинә гарәпләре Кәгъбә мәсьәләсендә Мәккә гарәпләре белән тату түгелләр. Ә яһүдләргә килсәк, алар Мәккә белән күптәнге һәм милли, һәм дини дошманнар. Кыскасы, бу шәһәр болганчык су. Ә андыйда балыкны коры кул белән дә тотып була бит... Мөхәммәт моны бик яхшы аңлый, Мәдинәне сайлаганда бигрәк әнә шуңа исәп итә дә.

Һәм ялгышмый. Мәдинә гарәпләре Мөхәммәтне, аның сәхәбәләрен колачны киң җәеп каршы алалар.

Бу вакыйга тарихка «һиҗрәт» исеме белән кергән. Һиҗрәт — күчү дигән сүз. Әлбәттә, бу күчү берникадәр әзерлектән соң гына гамәлгә ашырыла. Башта Мөхәммәт, яшерен килеп, мәҗүси гарәпләрнең генә түгел, яһүдләрнең дә диннәрен, дини йолаларын өйрәнә, сүз үтәрдәйләрен үз диненә өндәп йөри, яшерен җыеп сөйләшә. Тиз арада 70 ләп кешене үз ягына аударганнан соң гына, берәм-берәм сәхәбәләрен күчерә, соңыннан үзе күчеп килә.

Күчеп. Качып. Ике төрле сөйлиләр. Расланмаган риваятьләргә караганда, Мөхәммәтне Мәккә мөшрикләре тотып үтермәк булып, төннәрдән бер төндә ишегеи ватып керәләр, ә бу ятагына башка берәүне, агасының улын, соңыннан ислам диненең иң могътәбәрләреннән берсе булып китәчәк Галине яткырып, качып китәргә өлгергән була.

Бу вакыйгага бәйләп дини язучылар бик күп могҗиза-әкиятләр уйлап чыгарганнар. Мәсәлән, имештер, Мөхәммәт Мәдинәгә качып китеп барышлый Мәккәдән берничә сәгатьлек юлдагы бер мәгарәдә яшеренеп ята. Куа чыгучылар килеп җитсәләр, мәгарә авызында акация агачы үсеп утыра, очына Мисыр күгәрчене оя корып, күкәй салган, тагын мәгарә авызында еш итеп үрелгән үрмәкүч авы... Куа килүчеләр, бу җиргә кеше аяк басмаганга биш былтыр икән, анда булмас, дип мәгарәгә кермичә үтеп китәләр...

Мөхәммәткә бәйләнешле башка могҗизаларныкы кебек үк, әлбәттә, монысының да шаһитләре юк. Хәер, Мөхәммәтнең бөтен сәхәбәләре, каберләреннән кубып, без шаһит, дип кычкырсалар да, без моңа ышанмас идек. Имеш, кичә бер чыбык та үсмәгән җирдә, бүген күгәрчен оя корып күкәй салырлык акация! Ә куа килүчеләр шуны шәйләмәгән!..

Мәдинәгә килү белән Мөхәммәт моһаҗирләрне (Мәккәдән күчеп килгән мөселманнарны), шулай ук ансарларны (Мәдинә мөселманнарын) бер союзга берләштерә. Шуның белән ул Мәдинә гарәпләренең үзара әтле-мәчеле яшәүләренә, икенче яктан, Мәдинә белән Мәккә мөселманнары арасында гасырлар буена килгән дошманлыкка чик куя. Моһаҗирләр белән ансарлар арасында кыз алышу — кыз бирешү аша туганлык җепләре белән бәйләү татулыкны ныгытуга шулай ук зур этәргеч була. Мөхәммәт дуслашу тамырларын шулкадәр тирән җибәрә ки, күп кенә дини китаплардагы риваятьләргә караганда, берничә хатынлы ансарлар, берәрсен аерып, хатынсыз килгән моһаҗирләргә бүләк итәләр.

Ә яһүдләр ничек?

Моңа җавап бирүдән элек, үткәннәргә кайтып, Мөхәммәтнең Мәккәдә чакта эшләгән ифрат зур бер дуамаллыгы турында әйтеп китү кирәктер. Ул анда чакта Адәмнән алып Гайсәгә кадәр «булган» барча пәйгамбәрләрне ун ел буена хак пәйгамбәрләр дип өйрәтеп килгәннән соң, үзенең бәясен күтәрә төшәргә теләпме, ялгышып китепме:

«Алла миңа җир йөзендә иң беренче мөселман булырга боерды... Мин аллага иң беренче кеше булып иман китерүче...» дип игълан иткән иде.

*(Коръән, «Төркемнәр» сүрәсе, 14 аять, «Хайван» сүрәсе, 163 аять.)*

Мөшрикләр генә түгел, мөселманнарга кадәр аның бу дуамаллыгын үзенә әйтеп, алайса, бүтән пәйгамбәрләр кяфер булганмыни соң? дип көлгәннәр иде. Инде Мәккәгә килгәч, Мөхәммәт үзенең иң беренче мөселман булуы турында авыз да ачмый. Киресенчә, ул Тәурат белән Коръән өчен, тагын Коръән белән Инҗил өчен уртак булган пәйгамбәрләрне, барыннан да бигрәк, Ибраһим белән Мусаны, Гайсәне күкләргә

күтәрә. һәм... ачыктан-ачык (сезгә ялган, мина чын) яһүд белән христиан диннәрен үтереп мактарга, пропагандаларга керешә!..

— Мөхәммәт?.. Яһүд белән христиан динен?.. Тузга язмаганны...

Сез хаклы: тузга язмаган, ә Коръәнгә язган. Һәм берничә урында язган. Әлбәттә, мулла-монтагай бу турыда һичбер кайчан халыкка әйтмәде, дөресрәге — 13 гасыр буена яшереп килде. Шунлыктан, ягъни бу мәсьәлә күпләр өчен күтелмәгән нәрсә булганлыктан, шул ук вакытта Коръәннең иң дә сәер, иң дә каршылыклы, иң дә тайгак җире булганлыктан, мин аңа кинрәк тукталырга кирәк табам.

Коръәннең үзеннән башлыйк.

«Тәурат кешеләре, — ди Мөхәммәт, Мәдинә еврейләренә алла исеменнән, — үзегез өчен алладан иңгән Тәуратны тотмаган тәкъдирдә (ягъни шуның буенча гамәл кылмаган тәкъдирдә, шунын буенча яшәмәгән тәкъдирдә — Г. Г.) сезнең бүтән таяныр нәрсәгез юк».

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 72 аять.)*

Икенче төрле итеп әйткәндә, Коръән сез яһүдләр өчен түгел, гарәп өчен, ә сезгә Тәураттан гайри таяныр нәрсә юк. Кыйбланамагыз шул сезнең.

Күрәсең, еврейләр арасында Тәуратка икеләнебрәк караучылар булган, Мөхәммәт чынлап торып аларның Тәуратка иманнарын ныгытуга өнди, икеләнүчеләргә карата хәтта сатира уклары яудыра:

«Кулларында Тәурат була торып, аңа ышанмаучы кешеләр — өсләренә китап төялгән ишәкләр бит алар».

*(Коръән, «Җомга» сүрәсе, 5 аять.)*

Хәзер ул үз диненә өндәү турында уйламый да, алласы исеменнән:

«Без Тәурат иңдердек, анда хаклык, анда нур», — дип кычкыра.

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 48 аять.)*

Алай гынамы әле!..

«Тәурат укучыларга әйт, — ди алла Мөхәммәткә, — без үзебезгә күктән иңгән Коръәнгә һәм сезгә иңгән Тәуратка ышанабыз, диген. Сезнең алла да, безнен алла да бер диген, без шул бер аллага иманабыз инде диген».

*(«Коръән, «Үрмәкүчләр» сүрәсе, 45 аять.)*

Мөхәммәтнең хәдисләрендә исә бу мәсьәлә тагын да ачыграк: «Һәммә пәйгамбәрләр бер бабаның балалары булып, аналары гына башкадыр, ә халыкларга алып килгән диннәре бердер».

*(277 хәдис.)*

Бу хәдис һәм аятьләрдән соң Коръән белән Тәурат арасында, ислам дине белән яһүд дине арасында, бу ике дин хыял иткән аллалар арасында Мөхәммәтнең бернинди аерма күрмәгәнен сөйләп торуның кирәге кала микән? Кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмә дигәннәр. Моңа ышану, әлбәттә, кыен. Ләкин акка кара белән язылган.

Мөхәммәт бу мәсьәләдә тирәннән тирәнгә кереп, яһүдләр белән мөселманнарны, хәтта христианнарны дөньялыкта гына тигезләп калмый, «Ризык» сүрәсенең 72—73 аятьләрендә аларга мөселманнар белән рәттән җәннәт вәгъдә итә:

«...Чынлыкта мөселманнарга да, яһүд динендәгеләргә дә, христианнарга да куркырга кирәк түгел, — ди ул, — аларга (теге дөньяда) кайгырырга туры килмәячәк».

Күрәсең, биредә инде кәмит уенына христианнар да килеп керә һәм Мөхәммәт, бер очтан, бу динне дә хак дин ди, шулай ук аларның Инҗиленә ышанырга өнди, бу турыда әледән-әле кабатлап тора:

«Без аллага, безгә җибәрелгән китапларга ышанабыз. Муса белән Гайсәгә җибәрелгән китапларга да (Тәурат белән Инҗилгә дә — Г. Г.) ышанабыз. Без алар арасында аерма күрмибез».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 130 аять.)*

Яһүд дине белән христиан диненә булган мөнәсәбәтен Мөхәммәт «Ризык» сүрәсенең 50—51 аятьләрендә тагын да ачыклый төшә:

«Мәрьям угылы Гайсәгә без шул эздән (Тәурат эзеннән — Г. Г.) барырга куштык. Ул туганчы иңгән Тәуратның хак китап икәнен расладык. Гайсәнең үзенә без

Инжил бүләк иттек. Анда хаклык, анда нур. Инжилгә ышанучылар шуның буенча хөкем йөртергә тиешләр. Алладан иңгән бу китап буенча хөкем йөртмәүчеләр — кяферләр алар!»

Күрдегез, кемне кяфер ди хәзер алла? Тәурат белән Инҗилгә ышанмаган кешене, ягъни христиан яки яһүд булмаган кешене? Я, әйтегез, безнен Мөхәммәт пәйгамбәр, дин ислам пәйгамбәре булу белән бер үк вакытта, кай җире белән яһүд раввины түгел дә, кай җире белән христиан попы түгел?.. Биредә Мөхәммәт безнең алга бер үзе өч дин пәйгамбәре булып килеп баса түгелме? Ничек кенә боргаламагыз, мулла абзыйлар, бу хакыйкатьне, никадәр ачы булса да, танырга туры килә сезгә.

Мәдинәгә килү белән Мөхәммәтнең максаты, чынлап та, өч динне берләштерү булганмы, йорт хуҗалары алдында ялагайлану гынамы — кисеп әйтү кыен. Ләкин аның алда телгә алынган аятьләре безне тагын бер үтә кызыклы, үтә мөһим нәтиҗәгә китерәләр: Мөхәммәт Мәккәдә ун ел буена өндәп килгән ислам диненә үзе чынлап торып ышанган тәкъдирдә, ул боларның тегесен дә, бусын да эшләмәс иде. Бу аятьләрне игътибар белән укыган кеше, диндарлыкның чигенә чыккан кеше булса да, без килгән нәтиҗәгә килми кала алмас дип беләм.

Инде алланың яһүдләр белән христианнарга гына түгел, мөселманнарга да мөрәҗәгать итеп: «Тәурат белән Инҗилгә ышанмаучыларга җәза каты булачак» дигәнен дә өстәсәк, мәсьәлә безнең алга көн кебек ачык булып килеп басар.

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 2—3 аятьләр.)*

2

## МӨХӘММӘТ ТЕШЛӘРЕН КҮРСӘТӘ БАШЛЫЙ. ЯҺҮДЛӘР ЭЧЛӘРЕ КАТЫП КӨЛӘ. ТУПАС ФАЛЬШЬ.

Яһүд шат. Христиан шат:

— Ә без аны безгә ябышыр дип курыккан идек тагын... Үз кеше булып чыкты әле... Ләкин тозагың түгелме бу синең, Мөхәммәт, хәйләң түгелме?.. Илдә тамыр җибәргәнче генә юхаланып маташуың түгелме бу синең?..

Еврей башында мондый шик тугандырмы, юкмы? — әйтүе кыен. Безгә шул кадәресе ачык мәгълүм: яһүдләр Мөхәммәтне гарәпләр кебек үк кочакны киң җәеп каршы алмасалар да, какмыйлар. Киресенчә, үз диннәрендә калган хәлдә, Мөхәммәт чакыруын кабул итеп, ул төзегән мөселман җәмгыятенә әгъза булып керәләр. Хәтта аның уставын төзүдә Мөхәммәткә ярдәм итәләр. Үзара тату яшәргә, берәр яктан һөҗүмфәләң була-нитә калса, яклашырга договор төзешәләр.

Мөхәммәт исә хәзер мәҗүсиләрдән дә тайчанмый, аларга да җәмгыять ишеген төбенә кадәр ачып куя. Уңышлардан башы әйләнеп киткән Мөхәммәт, өч дин арасындагы аерманы бөтенләй юкка чыгара торган аятьләрне сибә дә сибә. Хәтта, Кәгъбәдән баш тартып, Иерусалимне (Бәйтелмөкаддәсне — яһүдләрнең изге шәһәрен) кыйбла итеп игълан итә! Хәзер мөселманнар намазны һәм башка гыйбадәтләрне яһүдләр кыйбласына (!) карап укырга тиеш булалар. Һәм бу (Мөхәммәт, күрәсең, үзе дә сизми кала) сәхабәләрнең, бигрәк тә моһаҗирләрнең мөлдерәмә тулы касәләренә өстәмә тамчы булып тама. Ислам дине белән яһүд һәм христиан диннәрен тиңләштергәненә дә ризасызлык күрсәткән моһаҗирләр, бер дә тартынып тормастан, Мөхәммәт белән ачыктан-ачык низагка керешәләр. Бәгъзеләре хәтта Мәккәгә кайтып китү белән өркетәләр.

Мөхәммәт уйга кала. Моһаҗирләр хаклы. Кәгъбә бер ислам дине буенча гына түгел, ата-бабадан, мәҗүси чакларыбыздан бирле килгән изге йорт бит ул.... Булмагае... Бара-тора күз күрер, хәзергә шулай кирәк... Һәм пәйгамбәр моһаҗирләрнең «нигә кыйбладан баш тарттык, нигә намазны үзебезнең Кәгъбәбезгә карап укымыйбыз» дигәннәренә каршы, әле генә Җабраил китереп киткән аятьне игълан итә:

«Акылсыз кешеләр әйтер, — ди алла бу аятьтә, — нигә элек-электән килгән кыйблабыздан йөз чөерәбез, дияр. Син аларга әйт: көнчыгыш та, көнбатыш та барыбер диген, икесе дә алла хөкемендә диген».

«Көнбатышның да, көнчыгышның да хуҗасы бер алла диген, йөзеңне кайсына юнәлтсәң — алла шунда булыр диген».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 136, 109 аятьләр.)*

Чү, болай ярамый икән. Ә соң көньяк белән төньяк алла хөкемендә түгелмени, көньяк белән төньякның хуҗасы алла түгелмени, диюләре мөмкин ич... Алла шундук Җабраилне яңа вәхи белән чаптыра:

«Динлелек — йөзеңне көнчыгышка яки көнбатышка юнәлтүдә түгел».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 172 аять.)*

Чү! Болай да булмады. Хәзер йөзләрен теләсә кай якка юнәлтәчәкләр бит!.. Җабраил янәдән килеп җитә.

«...Хәзер без сиңа кыйбла итеп Мәсҗеделхәрамне билгеләдек. Син канәгать булырсың. Кайда гына булсаң да, йөзеңне шул тарафка юнәлт».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 139 аять.)*

Мөселманнар, иңбашларын җыерып, бер-берсенә карашып куя. Яһүдләр, Мөхәммәтнең күкәен кая салырга белми аптырап йөргән тавык шикелле кыткылдап йөргәнен күреп көләләр.

Яһүдләргә ияреп, без дә елмаябыз. Бер Мөхәммәт елмаймый. Ул җитди. Аңа ничек тә яһүдләрнең дустанә, җылы карашларын яуларга кирәк. Һәм пәйгамбәребез ислам динен яһүд йолалары белән бизәргә керешә. Кыска мөддәтле уразаларын шәригатькә кертә. Хәтта яһүдләр белән кыз алу — кыз бирүне Коръән белән законлаштыра:

«Әй, мөселманнар! Сезгә әхлаклы вә гыйффәтле мөселман кызларына, шулай ук Тәурат буенча гамәл кылучыларның (яһүдләрнең — Г. Г.) кызларына өйләнү дөрес», — ди.

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 7 аять.)*

Әнә шул дәвердә инде Мөхәммәт шәригатькә яһүдләрдән сөннәткә утырту йоласын кертә. Ләкин онытырмы, ничекме — ислам диненең төп йолаларыннан берсе булып киткән бу йоланы Коръәндә канунлаштырмый, — 99 яше белән барган Ибраһим пәйгамбәрнең сөннәткә утыруы турындагы әкиятне Тәураттан күчереп алу белән чикләнә.

Яһүдләр тагын шат, чиктән тыш шат.

Мөхәммәт, очынып китеп, яһүдләрнең бөтен йолаларын, гореф-гадәтләрен хуп күреп сөйләргә керешә. Шимбәне изге көн күреп бәйрәм итәргә өнди. Муса заманында шимбә көн ял итәсе урында балык тотып йөргән өчен алланың борынгы яһүдләрне маймылга әверелдергәнен исләренә төшерә.

Үзен яһүдләргә бирелгән итеп күрсәтү өчен, Мөхәммәт бөтен мөмкинлекләрдән файдалана. Яһүдләрнең атаклы бер юлбашчылары үлгәч, аның җеназасында була, хәтта, алладан мәрхүмнең гөнаһларын ярлыкауны үтенеп, кабере өстендә дога кыла. Баратора шуңа барып җитә Мөхәммәт: яһүдләр өчен меню төзеп бирә, шуны Коръәненә кертә:

«...Яһүдләргә без тояклы хайваннарны, туң май, сыер, сарык майларын тыйдык. Эч мае ярый...»

*(Коръән, «Хайван» сүрәсе, 147 аять.)*

Дин ислам пәйгамбәре яһүд ашын мөселманга, мөселманныкын яһүдкә дөресли.

«Бүген сезгә Тәурат кешеләре ашый торган һәртөрле ризыкны ашарга рөхсәт ителә. Алар ризыгы сезгә, сезнең ризык аларга рөхсәт ителә».

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 7 аять.)*

Нәтиҗә әйбәт. Искиткеч әйбәт! Һиҗрәткә ел дигәндә үк инде Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәдинә туфрагына җибәргән тамыры сизелерлек ныгый. Мөселманнар сафы

Мәдинә гарәпләре һәм тирә-як авыллардан килгән мәҗүсиләр исәбенә үсә. Дин ислам сафы гөлән тыгызлана бара. Ул да түгел, Хәбәш иленә качып киткән сәхабәләр кайтып төшә. Болай барса, Мәдинәдә тиздән үлчәүнен Мөхәммәт ягы басачак!.. Аппетит табын янында килә, диләр. Хәзер пәйгамбәр бөтен Мәдинәгә баш булу турында хыяллана. Һәм... яһүдләрнен шикләнүләре урынлы булган. Хәзер ул әкрен генә, иләп кенә яһүдләргә мөнәсәбәтен үзгәртә башлый. Сез әйбәт әйбәтен, Тәуратыгыз да тәти. Ләкин шулай да Коръән әйбәтрәк, ди ул хәзер. «...Алла Коръәнне анардан алда килгән китапларны төшендереп бирү өчен җибәрде», ди.

Ә бу инде сезгә бар да бер дигән сүз түгел. Ә менә монысы, түгел дә түгел: «Тәуратны аңлатып бирү өчен сезгә **б е з н е ң п ә й г а м б ә р** килде»,— ди.

*(Коръән, «Юныс» сүрәсе, 38 аять, «Ризык» сүрәсе, 18 аять.)*

Еврейләр көлә. Хәзергә көлә генә әле.

— Син безгә, еврейләргә, Тәуратны төшендереп бирәсең? Соң бит син үзең дә аны бездән ишетеп кенә беләсең ич...

— Әйе, әйе... без аңар үзебез дә төшенәбез. Безнең ерак бабаларыбызга аны Муса үзе төшендереп киткән инде...

Муса дисез сез... Гайсә үзе дә, беләсезме, кем генә?..

Һәм гайсәнең «кем генә» булуы турында Җабраил фәрештә көне-сәгате белән алладан вәхи китереп җиткерә:

«Мәрьям улы Гайсә әйтте: Әй, Исраил балалары! Мин... үземнән соң киләчәк Мөхәммәт исемле пәйгамбәр турында изге хәбәр тарату өчен килгән илчемен, диде».

*(Коръән, «Сафлар» сүрәсе, 6 аять.)*

Шулай итеп, хәзер менә кем генә булып кала Гайсә! Алла аны бары кешеләргә Мөхәммәт исемле пәйгамбәр киләчәген хәбәр итү өчен генә пәйгамбәр итеп куйган була!

Әлбәттә, бу Мөхәммәтнең чеп-чи ялганы. Нә Тәуратта, нә Инҗилдә Гайсәнең андый сүзе юк. Мөхәммәт биредә Инҗилнең менә кайсы аятеннән фальсификация ясаган:

Гайсә әйтте: әтидән үтенермен (Инҗил өйрәтүенчә, алла Гайсәгә әти тия — Г. Г.), ул сезгә бүтән юатучы җибәрер. **Һ ә м у л м ә ң г е с е з н е ң б е л ә н б е р г ә б у л ы р».**

*(Инҗил, Иоаннан, 14 бүлек, 16 җөмлә.)*

Бу тупас фальшьтан еврейләр эчләре катып көлә. Чыннан да, Гайсә хәбәр иткән «юатучының» һич кенә дә Мөхәммәт түгел икәнен, Мөхәммәтнең еврей булмавы үзе генә дә исбат итеп тора ич. Мөхәммәт исә тагын да тирәнрәк кереп, үзен тагын да күбрәк хурлыкка калдырып, Ибраһим белән Исмәгыйльне үзенең ерак бабалары итеп күрсәтергә маташа. Күп кенә дини китаплар, шул җөмләдән «Әнба-эл-әнбия» (47 бит), бу уйдырманы хәзергә кадәр күтәреп йөри:

«Исмәгыйль — Адәм галәйһиссәләмнең егерменче улыдыр. Мөхәммәт — Исмәгыйльнең егерме җиденче улыдыр» ди. Ләкин, менә бәла! — Бу исәптән Мөхәммәт үзе дә еврей булып чыга түгелме соң! Чөнки, гөнаһ шомлыгына каршы, ул заманда гарәптә Исмәгыйль дә, Ибраһим исеме дә булмый әле, ә Измаил белән Авраам яһүд исемнәре!...

Әйтергә кирәк, Коръәндәге күп кенә пәйгамбәр исемнәре яһүдләрдән алынган. Шист, Якуб (Иаков), Исхак (Исаак), Һуд, Давыд, Сөләйман (Соломон), Нух һәм аның уллары: Хам, Сам, Яфас еврей исемнәре. Якуб (Иаков) улы Вениамин «уң билемнең улы» дигән сүзгә туры килә. Пәйгамбәр хатыннарыннан Рәхиль белән Сара да еврей исемнәре. Хәтта Адәм белән Хава да. Адәм — «кызыл балчык» дигәнгә туры килә. Хава — кабырга дигән сүз. Җәһәннәм дә борынгы еврей сүзе — дөресе: геһеннәм. Җәннәт — Җаннә — бакча дигән сүз. Амин гына да гарәп сүзе түгел, грек сүзе. «Шулай булсын» дигән мәгънәгә туры килә. Фәрештә исемнәренең дә барчасы еврейләрдән. Газраил — Азраел, Исрафил — Израил, Микаил — Михаил, Җабраил — Гавриел —«алланың көче» дигән сүз.

3

## ЯҺҮД НАЧАР, ХРИСТИАН ӘЙБӘТ. ӘЛЕ БУ ЧӘЧӘГЕ ГЕНӘ.

Мөхәммәткә кайтыйк. Аның, Инжилдә хәбәр ителгәнчә, мәңге яшәмичә, моннан 1293 ел элек үлеп китүе аның христианнар көткән пәйгамбәр түгел икәнен өстәмә рәвештә исбат итсә кирәк.

Ләкин безнең Мөхәммәт бирешергә теләми. Яһүдләрне үзенә инандыру максаты белән ул аять арты аять яудыра. Берсеннән-берсе көлкеләр. Мәсәлән, Гыймран сүрәсенең 75 нче аятеннән аңлашылганча, Мөхәммәт заманында әле кимендә Гайсә белән Ибраһим пәйгамбәр исән була. Көннәрдән бер көн бу ике пәйгамбәр Мөхәммәт хозурына килеп, иман китерергә, аңа булышып йөрергә тиеш булалар.

Менә ул аять:

«Алла пәйгамбәрләрдән могаһәдә (договор) алды. Менә мин сезгә Тәураттагы гыйбрәтле сүзләрне бүләк итәм. Соңыннан сезгә кулыгыздагы китапның (Тәуратның) хак китап икәнен раслаучы пәйгамбәр килер. Сез аңа берсүзсез иман китерергә, аңа ярдәм итәргә тиеш булырсыз...»

— Әй, Мөхәммәт, Мөхәммәт!.. авызың ни әйткәнне колагың ишетәме синең?—диләр еврейләр, — соң алар әллә кайчан дөнья куйган бит инде...

Мөхәммәт ык-мык. Ул кабат хур булганын төшенә. Ләкин бу юлы да бирешми. Ибраһим белән Исмәгыйльне әле һәмишә үзенең бабалары итеп күрсәтергә маташканы хәлдә, аларны Кәгъбәнең нигезен салучылар дип игълан итә. Һәм (менә сиңа кирәк булса: иске авыздан яңа сүз):

«Ибраһим яһүд түгел иде, христиан да түгел, күп аллалы да булмады. Ул ханиф иде» ди.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 121 аять, «Гыймран» сүрәсе, 60, 89 аятьләр.)*

— Ханиф?!

Яһүдләр инде көлми, сагаялар. Кесәләрендә килеш кенә булса да кулларын йодрыклыйлар. Чөнки монысы яһүдләр алдында Ибраһимның якты истәлеген мыскыл итү булып чыга. Чөнки, алар уенча, Ибраһим бер аллага табынган, ә ханифләр мәҗүси диннән ваз кичәр-кичмәс, күктә нинди дер алла булырга тиеш дип, хыялланып йөрүчеләр генә!..[1]

Әлегрәк булса, яһүдләр моның өчен пәйгамбәрне өзгәләп ташларга да күп алмас иделәр. Хәзер алай итә алмыйлар шул инде...

Мөхәммәт кесәләрдәге йодрыкларны сизә. Ләкин ул инде курыкмый, ачудан кыйбланы янәдән Кәгъбәгә борып куя! Ул эшне бик кызу тота. «Бу хакта алладан вәхи ингәндә Мөхәммәт өйлә намазының ике рикагатен укыган иде инде, калган икесен Кәгъбәгә карап укыды».

*(Тәфсир Ногмани, 36 бит.)*

Күрәсең, Мөхәммәт Тәурат, Инжилләр һәм үз дине чытырманлыгында буталса да, ниһаять, сәясәттә ныклы эзгә баскан. Кыйбла үзгәртү яһүдләрнең көлүләренә җавап булу белән бергә, Мәккәгә баш иеп, сәлам бирү дә булып чыга. Бер үк вакытта семсерләре коелып йөргән моһаҗирләрнең генә түгел, ансарларның да күңелләре күтәрелеп китә, аларда Мәккәне басып алу дәрте кузгала. Бу вакыйга һиҗрәтнең (безнеңчә әйтсәк, Мәдинәгә качуның) икенче елында була.

Бер сугышта җиңеп кайтып, бераз аякка басканнан соң (сугышлар турында сүз алдарак), бигрәк тә шәһәрдә административ властьны үз кулына алганнан соң, Мөхәммәт яһүдләргә карата мөнәсәбәтне тамырыннан үзгәртә, хәзерге тел белән әйтсәк, ул хәзер аларга каршы салкын сугыш игълан итә. Нәкъ әнә шул көннәрдә инде Мөхәммәт Мусаны Исраил кавемен фиргавен җәберенннән коткарып, сихерле таяк ярдәмендә диңгез аша алып чыгып китүе, ә тегеләрнең Муса Гарәфәт тавында алла белән

[1] Коръәннең буеннан буена пәйгамбәр булып килгән Ибраһимны Мөхәммәтнең хәзер ханиф итеп калдыруы бер яһүдләр өчен генә түгел, һәркем өчен дә иске авыздан яңа сүз. Мулла абзыйлар бу хакта, шулай ук, эчтән тыналар.

сөйләшеп яткан арада алтын-көмештән бозау сыны ясап, шуңа табына башлаулары турында ачыйгланып яза:

— Ике йөзлеләр сез! — ди ул. — Сезнең ата-бабаларыгыз да әнә нинди әшәке җан булганнар! Аллага шөкрана итәсе, безнең Мусага рәхмәт әйтәсе урында әнә нишләп ятканнар бит, мөртәтләр!..

— Карале, тагын арттырып җибәрдең түгел микән син, Мөхәммәт? Муса нишләп сезнеке булсын?..

Яһүдләр тагын хаклы. Муса дигән исем гомумән юк, Моисей генә бар. Һәм ул еврей исеме. Еврейләрнең хаклы булуларына тагын бер дәлил: Муса (Моисей) гарәп булган тәкъдирдә, пәйгамбәр булып, мотлака гарәп халкына килер иде. Чөнки әнә анда алла:

«Без һәр халыкка пәйгамбәрне үзләре арасыннан сайлап куйдык», — дип тора ич!..

*(Коръән, «Ибраһим» сүрәсе, 4 аять.)*

Бәлкем, Мөхәммәт бу хакыйкатькә каршы нәрсә дә булса әйткәндер, ләкин Коръәнгә кермәгән, риваятьләрдә дә юк...

Мөхәммәтнең яһүдләргә булган мөнәсәбәтен шул урында калдырып торып, христианнарга күчик. Алар, әйткәнемчә, Мәдинәдә күп түгел, тирә-якта шактый. Ливан гарәпләренең яртысы христиан. Мөхәммәт аларга да исәп тота. Тик менә бер мәлне аларны, сезнең аллагыз өч, сез мәҗүсиләрдән дә әшәке, дип мәсхәрә иткән иде. Кирәк булмаган икән [1]... Хаер, анысын гына төзәтергә була.... Мөхәммәт нишли? Христианнарның да кайбер йолаларын, гореф-гадәтләрен үз диненә кабул итә. Һәм... инде яһүдләрне яманлап, христианнарны мактарга керешә. Аларны күкләргә ашырып алла исеменнән мактаган аятьләр «иңдерә».

Әлбәттә, сез үзегез дә, сезнең ата-бабаларыгыз да мондый аятьләрне мәчеттә мулла авызыннан ишетмәгән, шуңа күрә мин аларны тулысы белән күчереп чыгам.

«Син, әлбәттә, үзең дә күрерсең, — ди алла Мөхәммәткә «Ризык» сүрәсенең 85 нче аятендә, — мөселманнарның иң явыз дошманнары яһүдләр һәм күп аллалылар. Син, әлбәттә, үзең дә күрерсең, мөселманнарны иң көчле ярату белән яратучылар — христианнар... Чөнки, — ди алла, христианнарны мактавын дәвам итеп һәм безне күзләребез атылып чыгар хәлдә шаклар катырып, — чөнки... аларның поплары һәм монахлары бар. Вә һәм дә алар борын күтәреп йөрмиләр».

Мактаганны кем яратмый... Анысы өчен рәхмәт, диләр христианнар, ләкин, бигайбә, пәйгамбәр...

Кыскасы, христианнар да яһүдләр кебек үк, Мөхәммәт динен кире кагалар. Менә шунда инде җен ачулары чыккан Мөхәммәт, бер үк вакытта һәм яһүдләргә, һәм христианнарга каршы һөҗүм башлый. Ул хәзер Тәуратның да, Инҗилнең дә алладан иңгән рәвешләрендә булмаулары турында аять арты аять сибә.

— Бозган сез аларны!..

— Кайчан? Кай төшен?

Мөхәммәт әйтә алмый.

— Хәтерең кыска икән, пәйгамбәр... Соң бит әле кайчан гына син үзең Тәурат белән Инҗилгә ышанырга әйткән идең түгелме соң? Ышанмаучыларны хәтта җәһәннәм газабы белән куркыткан идең түгелме?

Хәзер Мөхәммәткә, аннан соң бозган сез аларны, диярргә генә кала. Ләкин бу инде кеше-кара күрмәгәндә, син үзеңнең ике кулыңны кисеп ташлагансың, дию кебек ахмак җавап булачак. Мөселман өчен Коръән никадәр мөкатдәс булса, яһүд өчен Тәурат шул кадәр үк мөкатдәс. Әле тагын күп әрепләшеп торсаң, әнә үзеңнең Вәрәка коданда

[1] Әйтергә кирәк, Мөхәммәт христиан диненең бу чатак җирен оста тотып алган. Эш шунда ки, христианнар, яһүдләр һәм мөселманнар кебек үк, алла бер диләр. Шул ук вакытта бу бер алланы өч элементтан тора дип өйрәтәләр: Бог-отец, бог-сын и святой дух. (Бог сын дигәннәре Гайсә.) Ә соң шул өч элемент бер алла булгач, бог-сын туганчы бог-отец белән святой дух мөстәкыйль булмаган булып чыга ич, ничек ул Галәмне бар кылган, ниһаять, ничек яшәгән дигәч, иңбашларын җыерып куюдан башка җавап таба алмыйлар.

Тәуратның син туганчы ук тәрҗемә ителгәне саклана, сәркәтибеңне алып кил, чагыштырып күрсәтсен, дииоләре мөмкин... Кыскасы, Мөхәммәтнең җавап бирер әмәле юк...

Шул рәвешчә, яһүдләр белән христианнар алдында, шулай ук үзенең сәхәбәләре алдында хурлыкка калгач, әле ике генә ел элек, Коръән ни дә, Тәурат белән Инҗил ни... дигән пәйгамбәребез хәзер Коръән Тәурат белән Инҗилдән өстен дип күтәрелеп чыга. Алай тына да түгел, ул инде хәзер Тәурат-Инҗилләрне бөтенләй юкка чыгармакчы, бер үк вакытта ислам динен көчләп такмакчы:

«...Ә инде ислам динен кире кагучыларны без утта яндырырга кушачакбыз», ди ул «Хатын-кызлар» сүрәсенең 59 аятендә. Бара-тора Мөхәммәт ислам динен күкләргә күтәреп мактаганы хәлдә, яһүд белән христиан динен аяк астына салып таптый. Үзләрен мөселман оешмасыннан куып чыгара. Сәхәбәләрне катгый рәвештә кисәтеп куя:

«Әй, мөселманнар! Христианнар белән дә, яһүдләр белән дә дус булмагыз. Алар үзара дуслар. Кем дә кем алар белән дуслаша, — үзе дә шулар өммәтендә дип исәпләнәчәк».

*(Коръән, «Ризык» сүрәсе, 56 аять.)*

Мөшрикләр бар бит әле. Аларның язмышы нишләп кала? Алар турында хөкем карары кыска: шулай ук союздан куып чыгара һәм бер генә сүз әйтә:

«Алла һәм рәсүл ничек итеп мөшрикләр белән союз төзесеннәр ди инде...»

Ә берәр ел үтүгә ул әле аларга менә нәрсә әйтәчәк:

«Әй, иманлы кешеләр! Мөшрикләр — тизәк бит алар. Быелдан соң аларны Изге мәчеткә якын да китермәгез».

Бер үк вакытта Мөхәммәт мөшрикләр белән кыз алышу — кыз бирешүгә дә катгый рәвештә чик куя:

«Иманлы бәндәләр! Күнелләрегезгә хуш килсәләр дә, күп аллалыларга өйләнмәгез. Иманлы кәнизәк һәм кол хатын-кыз күп аллалылардан яхшырак».

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 7, 28 аятьләр, «Сыер» сүрәсе, 220 аять.)*

Ләкин шунысы кызык, яһүдләргә өйләнегез дигән элекке аятен, — ни сәбәптән икәнен алдарак үзегез дә күреп шаккатарсыз, — беркайчан да үзгәртми.

Мәдинә капкасыннан, химая кылсагызчы дип, песиләнеп кенә килеп кергән, һәркайсына — яһүденә, христианына, мөшригенә түбәнчелек белән баш иеп узган Мөхәммәт пәйгамбәр, ике ел дигәндә, шул рәвешчә теш-тырнакларын күрсәтә башлый.

Ләкин бу әле чәчәге генә, җимешләре көзгә өлгерәчәк...

## 4

## КЫЛЫЧ — КҮКЛӘРНЕҢ АЧКЫЧЫ. ПӘЙГАМБӘРМЕ СИН, ЮЛБАСАРМЫ? ТАЛАП АШАУ — ХӘРАМ ТҮГЕЛ.

Яһүдләр белән барып чыкмады. Христианнар да шундыйрак итеп әйттеләр. Мөшрикләрнең күбесе әле һаман үзләренең сыннарына ябышып ята. Әйе, коры сүз белән генә әллә ни эш чыгарып булмый икән шул...

Әле кайчан гына «Син әйт аларга, теләгән кеше иман китерсен, теләмәгән — китермәсен» дип, хәтта: «Башка диндәгеләрне киендергән мөселманнарга фәрештәләр җәннәт чапаннары киертер» дип өйрәткән Мөхәммәт, кинәт бөтен көченә нәгърә орып, кәкре кылычын кыныннан тартып ала.

Мөхәммәтнең тактикасында бик отышлы, мин әйтер идем, хәлиткеч бер як бар: ул, имеш, бер генә адымын да үзлегеннән атламый. Кылычын кулына алудан элек әһеле исламга шундый вәхи килә:

«Аллага һәм кыямәт көнгә ышанмаучылар белән сугышыгыз».

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 29 аять.)*

Ләкин болай бик анык булмады. Алла беләг кыямәт көнгә яһүд тә, христиан да ышана бит. Алла тиз генә икенче бер вәхи җибәрә. Монысында ул алдагы әмерен аныклап:

«Сезгә кяферләр белән сугышырга кушабыз...» ди.

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 186 аять.)*

Һәм, мөселманнар бу боерыкны ансат кына күтәреп алмаслар дип белеп, шундый сүзләр өсти:

«Беләм, сугыш — сезнең өчен күңел кайтаргыч нәрсә. Ләкин агаһ бул, әй, мөселман! Сез бер эшне яратмыйсыз, ә ул сезнең өчен файдалы булып чыга, икенче бер эшне яратасыз, ул сезнең өчен зыянлы булып чыга. Сез белмисез, алла белә».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 212—213 аятьләр.)*

Мөхәммәтнең бәхетенә каршы, аның шикләнүе бик урынлы булмый; мөселманнар арасында аның чакыруын күтәреп алучылар житәрлек табыла. Болар, беренче чиратта, әлерәк кенә сахралардан килеп, Мөхәммәткә кул биргән гарәпләр — гомер-гомергә сахраларда кәрван талап йөргән, талау каннарына сеңгән ата юлбасарлар. Болар — Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали кебек шөһрәткә һәм малга хирес байлар. Болар — Хәбәштән тәмам өтелеп кайтып, Мәдинә урамнарында каңгырып йөрүчеләр. Болар, ниһаять, авызын ачса, үпкәсе күренер дәрәҗәгә килгән моһаҗирләр.

Ул заман гарәпләрдә регуляр гаскәр юк әле. Быргы уйналуга кулына корал тотардай һәрбер ир, кәсебен ташлап, кылычын биленә тагып, ук-җәясен алып, аты бармы, ишәгеме, дөясеме, — атланып, бер дә булмаса, җәяүләп быргычы янына чаба. Хәзерлек шуның белән тәмам...

Гарәбстанның зур базарларына, Шам шәһәрләренә, Сириягә бара торган кәрван юлы Мәдинәгә якын гына җирдән уза. Мөхәммәт беренче һөҗүмнәрен шунда юнәлтә. Ләкин әллә ни зур уңышка ирешә алмый. Ул арада рәҗәп ае килеп җитә. Ул заман гарәпләрендә башка вакыт урлау, талау, юл басу кебекләр әллә ни гаеп саналмаса да, рәҗәп аенда бу эшләр катгый рәвештә тыела. Бу — закон. Ул хакта шәһәрләр, кабиләләр арасында борын-борыннан килешү яшәп килә. Бу килешүне, бу законны Гарәбстан туфрагында беренче булып иң изге дин пәйгамбәре Мөхәммәт һәм аның юлбасарлары боза. Рәҗәп ае бит дип, бер дә шикләнмичә узып барган Мәккә кәрваны көтмәгәндә камап алына. Мөселманнар, берничәсен кылычтан үткәреп, бер-икесен әсир алып, малларын төяп, Мәдинәгә кайтып керәләр.

Бу оятсызлыкка бөтен Мәдинә, тирә-як авыллар күтәрелеп бәрелә...

— Әй, Мөхәммәт, Мөхәммәт, динеңнең өстенлеге шушымыни инде синең?!.

Мөхәммәт үзе дә тиргәнгәрәк кереп киткәнен төшенеп, уңайсызлана. Ләкин алласы исән булсын!.. Көне-сәгате белән Җәбраил фәрештә шундый дипломатик вәхи китереп җиткерә:

«Синнән тыелган ай турында, сугыш турында сорашалар. Әйт: тыелган айда сугышу зур гөнаһ диген. Ләкин алла юлыннан бармау, аллага, Мәсҗеделхәрамга ышанмау, аннан кешеләрне куып чыгару (Мөхәммәт һәм аның сәхәбәләрен Мәккәдән куу — Г. Г.) алла каршында бигрәк тә зур гөнаһ диген. Колларыннан килсә, алар динегездән яздырганчы сезнең белән сугышудан туктамаслар иде диген».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 214 аять.)*

Мөхәммәтнең малга хирес кеше идеке, дин әләме астына яшеренгән мәкерле бер гарәп юлбасары идеке алда яңа аятьләр, бәхәссез фактлар белән исбат ителер. Хәзергә шунысы игътибарга лаеклы: юлбасарлыкны бөтенләйгә тыю дин ислам пәйгамбәренең уенда да юк. Аныңча, юлбасарлык — гөнаһсыз кәсеп, юлбасарлык — фәкать тыелган айда гына язык эш. Башка вакыт кяферне ас, кис, кычкыртып тала, әй, Мөхәммәт өммәте!..

«Тыелган айлар үтеп киткәч, мөшрикләрне кайда күрсәгез, шунда тотып кыйнагыз», ди ул.

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 5 аять.)*

Сүз уңаенда әйтеп китү кирәктер: сугышлар мәсьәләсендә генә түгел, теләсә нинди җинаять эшләүдә Мөхәммәт өммәтенә чикләнмәгән хөррият! Моны алла «Сыер» сүрәсенең 193 нче аятендә әйтә. Менә нәрсә ди ул:

«Билгеле айларда хаҗ кылырга ниятләгән кеше (анда да хаҗ кылырга ниятләгән кеше генә — Г. Г.) ызгыш-талаштан, һәртөрле бозык эшләрдән тыелып торырга тиеш».

Талау сугышларының бөтенесен язу укучыны ялыктыру булыр иде. Без биредә аларның иң мәшһүрләрен генә, мулла абзыйлар иң изге күреп, авыз суларын корытып сөйләгәннәрен генә баян кылу белән чикләнәбез.

Рәҗәп арты шогбан. Рамазанның унбишләре... Монысы да юлбасарлык тыелган ай. Мөхәммәтнең разведкасы Кораеш сәүдәгәрләренең Сириядән кайтып килгәннәрен хәбәр итә: мең дөя, сагы нибары 30—35 кеше, башлыклары Әбү-Суфьян. (Бу бәндәне хәтерләп калыгыз. Теге Әбүләһәпнең кияве, Мәккәнең оста һәм гайрәтле сугышчысы, гаскәр башлыгы. Алда аның язмышы һич көтелмәгәнчә кызык булачак.) Мөхәммәт пәйгамбәр, өч йөз ундүрт башкисәрен ияртеп, кәрванга каршы чыга. Нияте — тегеләрне Бәдер чишмәсе буенда тар-мар итеп, малларын талау... Ләкин мәсьәлә ул уйлаганча ансат хәл кылынмый. Әбү-Суфьян Мөхәммәтнең ниятен сизеп алып, Мәккәгә чаптар җибәрә. Мәккәдән Мөхәммәт каргышы буенча күптән җәһәннәм төбенә дөмегергә тиеш булган кеше, Мөхәммәтнең иң зур дошманы, Мәккәнең шәһәр башлыгы, бик тә хаклы рәвештә Әбүләһәп, ягъни «Зирәк акыл» атасы дип йөртелгән, дин китапларына Әбүҗаһил, ягъни «Тиләләр атасы» булып кергән 70 яшьлек карт гарәп, гаскәр туплап килеп җитә... Әбүләһәп гаскәре җиңелә. Бу аяусыз сугыштан пәйгамбәр гаскәре хисапсыз күп мал, 70 ләп әсир алып кайта. Дошманның шул хәтле үк кешесе, шул исәптән Әбүләһәп үзе дә сугыш кырында үлеп кала [1]. Никадәр яралы, гарип, тол, ятим...

Мәккә, Мәдинә, бөтен тирә-як Мөхәммәтне каһәрли. Ә күзе тонган, уңыш шәрабе белән исергән пәйгамбәр бу вакытта җиңү бәйрәмен итә... Ганимәт малын бүләләр.

Ганимәт малы. Бу сүзне дин ислам әһелләре аеруча бер канәгатьләнү хисе белән яд итәләр. Хезмәт ияләренең үз кул көчләре белән тапкан малларыннан өстен күреп сөйлиләр. Ә ул, ничек кенә борталанма, нинди генә укалы кәгазьләргә төрмә — хәрам мал, таланган мал.

Талап кайткан малны бүлү, әлбәттә, алла тарафыннан билгеләнгәнчә, гаделлек белән алып барыла. Бу хакта алладан шундый вәхи килгән:

«Таланган малның биштән бере аллага (?!), пәйгамбәргә, аның туганнарына, ярлыларга, юлаучыларга тиештер...»

*(Коръән, «Табыш» сүрәсе, 42 аять.)*

Күрәсең, пәйгамбәр алла кушкан биштән бер белән генә чикләнмәгән, мөселманнар, ризасызлык белдереп, гауга чыгаралар... Ләкин, әлеге дә баягы, алла исән булсын да, Җәбраилнең канатлары түзсен... Күз ачып йомганчы күктән «Җыелыш» сүрәсенең 6 нчы аятен алып төшеп җитә:

«Мөхәммәткә алла үзе бирде. Ул аңа берничә ат, берничә дөя генә бирде бит. Алла үзенең пәйгамбәрләренә теләсә күпме бирә».

Мулла үзе урлый, үзе юллый, ди халык мәкале. Бу аятьтән соң мулланың алай эшләве укучыга аңлашылса кирәк. Пәйгамбәребез, авыр туфрагы җиңел булсын, моның үрнәген әнә үзе күрсәтеп үлгән бит.

Риваятьләрдә әйтелүенчә, бара-тора мөселманнарда талауга һәвәслек шуңа житә ки, комсызраклары, таланган малны тәяп кайту өчен сугышка ишәкләре белән хатыннарын ияртеп йөриләр. Бу үтерә, талый тора, хатын ишәккә төйи тора.

Әлбәттә, арада бу талауларга нәразыйлык күрсәтүчеләр дә табыла. Кайберләре, алла үзе дөресләп торуга карамастан, талаудан баш тарталар.

— Бәдердә үтерелгән ибне Хәсәннең чирләшкә хатыны белән итәк тулы баласы калган. Әнисе үлем түшәгендә. Ә без аның актык дөясен суеп ашадык... Артык бөгеп җибәрмибезме икән, пәйгамбәр?..

Монысына да җавабы әзер пәйгамбәрнең:

— «Ганимәт мал башка пәйгамбәрләргә хәрам иде, — ди ул. — Ә миңа алла үзе әйтеп хәләл итте...»

*(135 хәдис.)*

— Ай-һай... Ничек инде?..

— Ышанмыйсыз?..

[1] Ибне Хәлду шунысына кадәр тарихка кертеп калдырган. Габдулла исемле сәхәбә җәрәхәтеннән үлеп яткан Әбүҗаһилнең башын чабып өзеп Мөхәммәткә бирә. Аннан башны кулдан кулга йөртәләр.

Мөхәммәт үзенә ярдәмгә шундук Җабраил фәрештәне төшереп җиткерә:

«Сугышта талап алган нәрсәләрне иң хәләл ризык күреп ашагыз. Алла гафу итүче, алла шәфкатьле. Алладан куркыгыз».

*(Коръән, «Табыш» сурәсе, 70 аять.)*

Әйтерең бармы, икеләнергә урын калдырмаган: рәхәтләнеп тала кяферне, әй, мөселман!.. Ә менә ни өчен биредә «Алладан куркыгыз?» — Монысы алланың, карагыз аны, бу хакта Мөхәммәт белән бәхәсләшеп торасы булмагыз, кирәгегезне бирермен диюеме? Әллә, таламый калсагыз, җәһәннәмгә бөтереп тыгармын диюеме?— Һәрхәлдә, икесенең берсе, талауны дөресләү, таларга кушу!

Заманыбызның дин ислам әһелләре, пәйгамбәрнең бу юлбасарлыкларын акларга маташып, ул бит баю өчен генә түгел, кяферне иман китертүгә мәҗбүр итү өчен дә талаган диләр.

Нәкъ Гитлерча аклау! Ул да бит үзенә буйсындыру өчен генә Европаны бомбага тотты, меңләгән шәһәр-авылларны яндырды. 30—40 миллион кешене төрмәләрдә черетте. Яндырып үтереп, көлләре белән үзенең җирен ашлады!.. Батмый, мулла абзыйлар, аңа китсә, ходай тәгалә кулында иман китертүнең бүтән төрле юллары да булган бит. Җөмләдән берсе, иң ансаты: үзенең мөбарәк куллары белән кяферләрнең битләренә корган пәрдәне алып ташлау. Ник соң Мөхәммәт һәм аның алласы кешеләрне дингә кертү өчен шундый пычрак юл, сугыш юлын сайлаган? Нигә колакларын Коръән сүзләрен ишетмәслек итеп чукракландырган, нигә дөрес юлны күрмәслек итеп күзләрен сукырайткан? Әлбәттә, моңа бер мулла түгел, бөтен муллалар, ишан, ахун, мөфтиләр бергә җыйналып керешсәләр дә, җавап бирә алмыйлар.

*(Дәвамы бар.)*

### ШАГЫЙРЬНЕҢ ГОНОРАРЫ

Тукайның китап наширләреннән алган беренче гонорары турында артист Габдулла Кариев болай дип яза: «Уральскида Габдулла әфәнде Тукаев белән «Казан» мосафирханәсендә бер бүлмәдә тора идек. Язга таба (1907 елны — И. Р.) безнең икебезнең дә кесә такырайды. Кай числода икәне хәтеремдә юк (1907 елның маенда — И. Р.) Казаннан Шәрәфләрдән хат килде. Алар Тукаевның шуңа кадәр «Фикер» һәм «Әлгасрылҗәдит» тә басылган шигырьләрен китап итеп бастырырга сорап, условие язып җибәргәннәр. Басып тарату хокукын гомер буе үзләрендә калдырырга ясап, 30 сумга сатып алдылар».

Аңарчы китап бастыру, авторлык хокукы белән танышлыгы булмаган Тукай: «Басылган шигырьләрне нигә алалар, аннан ни файда чыга», дип аптырый. «Бер тарафтан Шәрәфләрне кызганган кебек, икенче яктан, «утырттым бит» дип көлеп сөйләгән иде. Мин дә бик ихлас күңел берлә Тукаевның тегеләрне тәмам алдаганына ышандым», ди Кариев.

Кариевның әйткәннәре Гыйльми Шәрәфнең Тукай турында язган истәлекләре белән дә раслана. Тик ул үзенең мәкаләсендә 30 сумга алганын әйтми.

Шул килешү кәгазе буенча тапшырылган материал «Габдулла Тукаев шигырьләре» дип исемләнеп, ике китап (беренче кисәге — 48 бит, икенче кисәге — 56 бит) күләмендә басылып чыга.

Шагыйрь «аннан ни файда чыга» дип уйлаган булса, коммерсант нашир моннан шактый файда чыгара. Бу ике китапны ул дүрт кат (1907, 1909, 1913 һәм 1918 елларда) бастыра. Һәр басмасын 4 мең тираж белән (барысы 32 мең) чыгарып, данәсен 12 тиеннән сата.

Казанга күчкәннән соң шагыйрь наширләр белән нинди шартларда эш иткәндер, анысы безгә караңгы. Хосусый наширләрнең эш кәгазьләре архивка кермәгән. Бу турыда нинди дә булса язма материал табылыр дип көтәргә туры килми.

1912 елны газеталарда басылган бер хәбәрдән түбәндәгеләр аңлашыла: «Ишетелүенә күрә, — дип яза «Вакыт» газетасы, — шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев үзенең әсәрләрен бастыру хакын бөтенләй «Мәгариф» көтепханәсенә (Шәрәфләргә — И. Р.) тапшырмыштыр. Габдулла әфәнденең хәзергәчә чыккан шигырьләрен кабаттан бастыру өчен «Мәгариф» көтепханәсе 960 сум түләячәктер. Нәсер илә язылган әсәрләре дә «Мәгариф» кә күчә икән. Шагыйрь моннан соң язган әсәрләрен беренче тапкыр журналда я газетада бастырырга үзе ихтыярлы булып, аннан соң «Мәгариф» шигырьнең бер табагына (басма 16 бит) 60 сум, нәсергә 30 сум түләячәктер».

Революция алды елларында «Мәгариф», «Сабах», «Гасыр», «Юл» нәшриятлары матур әдәбият әсәрләренә авторлык гонорарын китапның тиражына карап түләү тәртибен кулланалар. Китапның һәр табагына — данәсенә 12 тиен түлиләр. Мәсәлән, күләме 1 басма табак китап бер мең данә басылса, табагына 20 сум, өч мең басылса — 60 сум, биш меңгә — 100 сум. Шул сума китапның табак санына карап арта. Мондый гонорар Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал кебек танылган язучыларга гына түләнгән.

ИСМӘГЫЙЛ РӘМИ.

## Совет властенең 50 еллыгына

*Я. Румянцев*

# ИЛЬИЧ БЕЛӘН БЕРГӘ

XIX гасырның соңгы чирегендә революцион демократлар, соңрак народниклар хәрәкәте пролетариатның капитализмга, патша самодержавиесенә каршы кискен көрәше белән алышынды. Шушы чорларда оешкан Көньяк Россия эшчеләр союзы (1875—1877), «Төньяк рус эшчеләре союзы» (1878—1880) эшчеләр сыйныфының революцион хәрәкәтенә зур этәреш бирде. Бу хәрәкәттә 1885 елны Орехово-Зуевода Морозов фабрикасында Петр Мойсеенко житәкчелегендә уткәрелгән стачка аеруча зур әһәмияткә ия иде.

Эшчеләр хәрәкәтенең үсеше укучы яшьләр арасында да революцион идеяләрнең тагы да киңрәк таралуына сәбәпче булды.

Казан шәһәре бу вакытта революцион хәрәкәтнең зур үзәкләреннән берсе була. Күп кенә урта уку йортларыннан тыш университеты, ветеринария институты булган Казан шәһәрендә укучы яшьләрнең революцион хәрәкәте торган саен киңрәк колач ала бара.

1880 елларда Казанда укучы яшьләр арасында марксистик идеяләр шактый киң тарала. Марксистик әдәбиятны өйрәнү буенча күп кенә түгәрәкләр, землячестволар оеша. Шундый түгәрәкләрдән 1886 елда Н. Е. Федосеев һәм Н. А. Мотовилов житәкчелегендә оешкан түгәрәкләр аеруча зур әһәмияткә ия.

Мәскәүдәге Үзәк Дәүләт тарих архивында, шулай ук Ростов архивларында Казанда марксистик хәрәкәтнең башланып китүен һәм үсешен, бу хәрәкәттә Николай Евграфович Федосеевның ролен, Владимир Ильич белән бергә марксистик түгәрәкләрдә, 1887 елның 4 декабрендагы студентлар демонстрациясендә катнашкан Дон егетләренең эшчәнлеген, боларның Казанда һәм Донда марксистик хәрәкәтнең үсешенә ясаган йогынтысын ачыклый торган шактый документлар һәм материаллар саклана.

Владимир Ильич Ленин Федосеев турында болай яза:

«Н. Е. Федосеев марксистик юнәлештә торуларын беренче булып игълан итә башлаган кешеләрнең берсе иде...

Аеруча шунысы хәтеремдә калган: Федосеев, бөтенләй үз эшенә бирелгән иске заман революционеры тибы буларак, үзен белгән бөтен кеше арасында бик зур симпатия яулады... Идел буе һәм Үзәк Россиянең кайбер урыннары өчен Федосеевның роле ул чакта искиткеч зур иде, һәм ул заман публикасы, марксизмга таба борылыш ясаганда, гадәттән тыш талантлы һәм үз эшенә гадәттән тыш бирелгән бу революционерның йогынтысын үзендә, һичшиксез, бик һәм бик күп сынады»[1].

1887 елның көзендә Федосеев һәм Мотовилов түгәрәкләре берләшә, һәм аның эше Мотовилов тарафыннан эшкәртелгән программа буенча бара.

Үзәк Дәүләт тарих архивында Федосеевның Мотовиловка 1888 елның январенда һәм февралендә язган ике хаты һәм Казан губерна жандарм управлениесенең бу хатларга карата 1890 елның 2 октябрендагы язмасы саклана.

*«Китерелгән ике хатның һәрберсе, — диелгән жандарм управлениесе язмасын-*

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басма, 33 т., 437—438 битләр. Татарстан китап нәшрияты, 1963 ел.

*да, — Николай Александрович Мотовиловның Казан ветеринария институты студенты булган вакытында гына тугел, 1887 елның декабрендагы тәртипсезлекләрдән соң Казаннан сөрелгәч тә, Николай Федосеев эшчәнлегенә ясаган гаять зур йогынтысы турында сөйли».* (УДТА, 102 фонд, 1890 опись, 115 эш, 115 бит.)

Федосеев хатында бу турыда түбәндәгеләр әйтелә:

*«Безнең түгәрәк бөтенләй үзбаш булмарак оешты, уку өчен китаплар гына сайларга кирәк иде... Без В-в*[1] *белән сезнең янга, тәҗрибәле кеше буларак, бары тик программа өчен генә килдек. Ә В-в сезнең безгә кушылуыгызны күз алдында тоткан икән, мин бу турыда бернәрсә дә белми идем, шуңа күрә сезнең безнең түгәрәккә катнашырга теләвегез миңа бер дә ошамады... Нигә икәнен хәзер аңлатырга тырышам. Мин 6 класста укыганда ук бер шәхси түгәрәккә кердем, бу түгәрәккә минем иптәшем (Волков) һәм Голубев*[2] *та (ул вакыттагы яхшы танышым) катнаша иде.*

*Членнар арасында мөнәсәбәт коры. Эшкә формаль мөнәсәбәт, фактларны механик рәвештә генә үзләштерү безгә ошамады. Без тиздән аннан чыктык. Шул вакытта миңа Голубев мондый төрдәге кружковщинаның ирекле фикер уртаклашуга нигезләнмәгәнлеген, анда һәр җирдәгегә караганда да артык деспотизм үскәнлеген әйтте. Ул миңа үзебезгә яшерен түгәрәк оештыру кирәклеге фикерен белдерде, ә аны үстерүгә килгәндә, һәркем аңлый торган каталоглар, программа бар; бер тигез иптәшләр яки икенче берәүгә чын-чынлап ярдәм итәргә әзер торган кешеләр, ирекле фикер үсешенә бернинди көч куллануга каршы кешеләр белән ирекле фикер алмашу анда мөмкин. Без В-в (Волков) белән түгәрәк оештырдык (җиденче классның ахырында), максатны гаять киң куйдык — үз-үзеңне үстерү һәм мөмкин булган практик эшчәнлек максаты. Ә аннары сезнең белән очрашу... Әлбәттә, мин сезнең белән кушылу өчен барлык шартларны кулландым... Чираттагы җыелышта безнең түгәрәкнең барлык членнары кушылуга каршы булдылар. Бернична көннән соң сез минем янга кердегез. Бу әһәмиятле көн иде. Табигать белеме турында сезнең белән аз гына әңгәмә, аннары практик эшчәнлеккә әзерлек турында сөйләшү, ә иң әһәмиятлесе, сезнең эчкерсезлек мине сезгә тартты. Мин түгәрәк членнарына сезнең белән тагын бер очрашу турында тәкъдим ясадым, ә аннан соң бергәләп укулар китте һәм, әлбәттә, бары тик сезнең аркада мин чит кешеләр белән кружковщинага карата фикеремне үзгәрттем. Бәхетсезлеккә каршы, эш иң кызган вакытта «4 декабрь» килеп чыкты, һәм сез югалдыгыз».* (Шунда ук, 119 бит.)

Бу берләштерелгән түгәрәк белән бергә Казанда бүтән түгәрәкләр дә эшләп килә. Шундый түгәрәкләрнең берсенә, университетта оешкан түгәрәккә, яшь В. И. Ульянов та катнаша.

Таганрог шәһәреннән Казанга килеп укыган А. Скворцов үзенең истәлекләрендә Владимир Ильичның таганрогլыларның Богораз Лазарь (Сергей) түгәрәгенә йөрүе турында әйтә.

*«1886 елда, — дип яза ул, — мин Казан ветеринария институтына укырга кердем һәм тиздән шундагы революцион оешмага катнашып киттем. Андагы эшләр бик яшерен алып барыла иде. Мин үземә тиеш булганнарны гына белә идем. Мотовилов белән бергә институт студентларының исәбен алдык... Житәкчебез казанлы Березин иде. Ул безгә, Маркс хезмәтләрен, өлешчә «Капитал»ны файдаланып, политэкономия буенча лекцияләр укыды. Соңрак миңа бу оешманың эшчеләр һәм авыл укытучылары аркылы крестьяннар арасында эш алып баруы, башка шәһәрләр белән дә элемтәдә булуы беленде».* (Ростов өлкә партия архивы, 12 фонд, 3 опись, 1034 эш, 5—6 бит.)

Скворцов истәлеген болай дип дәвам итә: *«...Бу түгәрәк (Богораз түгәрәге турында сүз бара. Ред.) Собачий тыкрыгында Лазарь (Богораз) белән мин яшәгән квартирага җыела торган иде. Бөтен чардак безнең карамакта булып, аңа аерым баскыч аша менәргә кирәк һәм шуңа күрә ул бик уңай иде... Түгәрәк составын безнең эшнең конспиратив шартлары буенча белергә тиеш түгел идем. Бу түгәрәкнең эше һәр атна саен безнең түгәрәк җыелган вакытта ук үткәрелә иде».* (Шунда ук, 9 бит.)

Әгәр Скворцов үзе катнашкан түгәрәктән иртәрәк кайта икән, Лазарь түгәрәге эшен тәмамлаганчы, урамда көтәргә тиеш булган. Һәм шундый көтеп торуларның берсендә

[1] Гаврила Михайлович Волков — Федосеевның дусты һәм гимназия буенча сабакташы. Түгәрәкне оештыручыларның берсе.

[2] Голубев — гимназия укытучысы. Беренче түгәрәккә Федосеевны ул димли.

ул квартирадан чыгып килүче Ульяновны күрә.

Ул Владимир Ильич белән беренче семестр уртасында ниндидер уңай белән (бу турыда Скворцов анык кына хәтерләми) җыелган сходкада таныша.

*«Ул вакытта,*— дип яза Скворцов үзенең истәлегендә,— *иптәш Ленин бик яшь студент иде, һәрвакыт бик чиста киенеп йөри иде. Сакал-мыек әле чыкмаган иде бугай. Владимир Ильич кызылсу каштан төсендә куе, матур чәчле иде.*

*Инде моңа күп еллар узды һәм, Ильичны бер ун мәртәбәләр генә күргән булсам да, хәзер дә аның образы тере кебек күз алдымда тора... Аның Октябрьдән соң чыккан портретларыннан Казанда күргән яшь студентны бик тиз таныдым». (Шунда ук, 10 бит.)*

Федосеев үзенең Мотовиловка 1888 елның январенда язган хатында 1887 елның декабрендагы студентлар хәрәкәте турында сөйли.

*«Студентлар землячестволары арасында әһәмиятле борылыш, уңай якка борылыш булды,*— ди ул. — *Землячестволар тулылана. Безнең максатлар шактый киңәйде, хәзер без студентлар эше белән генә чикләнмибез*[1].

*Студентлар оешмасындагы әһәмиятле үзгәрешләрнең берсе — үз-үзеңне үстерү максаты белән түгәрәктәге укулар*[2].

*Университеттан чыгарылучылар — 72 кеше, ә институттан — 17 яки 20. М. М.*[3] *инде полициядә икенче ай утыра (14 декабрьдән бирле), аңарда тентү булган. Сембердән китереп Губковны, тагын кемнәрнедер полициягә утырткannар.*

*Нижний Новгородта Евг. Ч., Ф—в*[4] *кулга алынган, шулай ук С. Коронин*[5] *да кулга алыначак дигән хәбәр йөри»...*

Кулга алынганнан соң, 1890 елның 18 октябрендә Казан төрмәсендә Федосеев бу хатны язганлыгын таный.

1888 елның көзендә сөргеннән Казанга кайткач, В. И. Ульянов катнашкан түгәрәкнең эшчәнлеге турында Федосеев хатыннан без әнә шуларны беләалабыз.

Бу хатлардан тагын шул күренә: Казанда да, Ростовта да түгәрәкләр бер үк программа буенча эш алып баралар. Димәк, Идел буенда һәм Россиянең үзәк өлешендә һәм көньяк-көнчыгышында марксистик идеяләр бер үк чыганактан тарала-лар. Бу идеяләрне таратуда Федосеев һәм Мотовилов түгәрәкләре зур роль уйнаганнар.

---

[1] Мондый землячестволарны уку йорты кагыйдәләре катгый тыя. Шуңа күрә алар яшерен эш алып баралар. 1887 елда алар инде революцион әдәбиятны өйрәнәләр. В. И. Ульянов та 1887 елда шундый землячествога керә.

[2] Үз-үзеңне үстерү сүзе астында Маркс, Энгельс, Каутский, Плеханов әсәрләрен өйрәнү күз алдында тотыла.

[3] М. М. — присяжный поверенный ярдәмчесе Михаил Львович Мандельштам.

[4] Евгений Николаевич Чириков, Константин Иванович Фадеев — Казан университеты студентлары.

[5] С. Коронин — полиция күзәтүе астында булган Н. Е. Петропавловскийның әдәби псевдонимы.

# ТУКАЙНЫҢ МОҢАРЧЫ ЧЫККАН ҖЫЕНТЫКЛАРЫНА КЕРМӘГӘН КАЙБЕР ШИГЫРЬЛӘРЕ

1

Төркия янгын эчендә: монда ут һәм анда ут,
Анда дерзиләр кабынган, монда сүнсә арнавыд.

Арнавыдлар (албаннар) һәм дерзиләр — 1911 елларда Төркия кул астында яшәгән халыклар. Ул елда Төркия кул астындагы Траблиска (Триполигә) Италия басып керә, һәм, шул ыгы-зыгыдан файдаланып, күп милләтле төркиянең үзендә дә солтан монархиясенә каршы, югарыдагы кебек, кайбер милләт һәм кабиләләр милли азатлык даулап баш күтәрәләр.

«Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 20 санында, 9 биттә бер рәсем-карикатура бирелгән. Анда фәсле, мыеклы бер төрек басып тора, аның тирә-ягы ут-төтен, ялкыннар белән чорнап алынган. Астына әнә шул югарыда китерелгән ике юллык шигырь язылган. Имза куелмаган бу шигырь әлегәчә Тукай җыентыкларының берсенә дә кертелмәгән. Алым, тел, стиль, үткенлек, җыйнаклыгы һәм бер-ике сүздә тулы характеристика бирүе белән бу, әлбәттә, Тукайныкы.

2

И төрек, иң әүвәл үк әйтим сиңа: борының кылыч;
Гыйлм илә хикмәт базарында синең урының кылыч.

«Ялт-йолт» журналының шул ук елгы 21 санында, тышлыкта, борыны бик озын булып сузылып төшеп, җиргә җиткән, башы фәсле бер төрек сурәте бирелгән һәм бер ягына: «Тасвир Әфкарь» мөхәррире», дип язылган. Шул заманда, Истамбулда чыккан матбугат арасында, бу газета Төркия хөкүмәтенең булдыксызлыгын һәм чын хәлен, халыктан яшермичә, дөресен язарга тырышуы белән алда торган. Югарыгы ике юллык та шуңа багышланган. Шигырьнең астында имзасы юк, һәм бу шигырь моңарчы чыккан Тукай җыентыкларында юк; ләкин ул эчтәлеге һәм формасы, алымнары белән — анык.

3

Уңга да мин әйләнәм,
Сулга да мин әйләнәм;
Бай алдында җәдит күрсәм,
«Син кафир» дип бәйләнәм.

«Ялт-йолт»ның 1911 елгы 23 санында, урта биттә чалмалы бер җил тегермәне сурәте ясалып, астына шул җыр язылган. Шигырьдә, провокатор Ишмиләрнең җәдит мәктәпләрен яптырып, мөгаллимнәрне сөргенгә җибәрткәндә, муллаларның гомумән ике яклы роль уйнаулары күрсәтелә.

Җырның имзасы юк. Сурәтнең идеясе Тукай тарафыннан бирелеп, астына җыры да аның тарафыннан язылган булырга тиешле. Хәтта журналдагы кульязмасы да анык.

4

Һәзад-дөнья әкалле мин калили,
Кара сыра эчеп исерә Хәлили.

**Мәгънәсе:** бу дөнья дигәнең (адәм баласы өчен) аздан да аз нәрсә инде; Хәлили кара сыра эчеп исерә.

Хәлили Якуб — дәреслекләр язучы һәм (Тукай үлгәннән соң) «Сөембикә», «Балалар дөньясы» журналы чыгаручы редактор.

Бу эпиграмма Тукай томнарының берсендә дә юк. Ләкин ул әлегә хәтле, Тукайныкы булып, телләрдән төшми йөри, тәмам халыклашкан. Аның Тукайныкы булуында шик юк. Шундый мәкаль дәрәҗә-

сендә үткен итеп һәм аять-хәдис укыган кебек көйләп, колак торгызып, шуннан аңа мәгънә биргән кебек пародия белән тапкыр шигырь әйтеп ташлауга Тукай гына сәләтле.

5

Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш,
Усал эт төсле тик чәйнәш,
Безем корган нигезләр бер
дә селкенми дә чайкалмай.

**Бабай Сәйдәш — Казанда кадимчеләр органы булып чыккан «Бәянелхак» газетасының редакторы һәм нашире. Бу газета рус шовинистларының «Союз русского народа» дигән кара груһлар оешмасы тарафыннан чыгарыла. Әхмәтҗан Сәйдәшев, үзе татар булса да, шул союзның әгъзасы. Бу газета хатын-кызның йөзен ачтырмау, мәктәпләрдә яңача укытмау, татар театрын һәм сәнгать-әдәбиятын булдырмау өчен җәдитчеләргә каршы көрәш ача. Бу вакытларда Уральскида «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» журналы тирәсендә оешкан Тукай, Камил Мотыйгый, Габдулла Кариев һәм башкалар, бәянелхакчыларның реакцион йөзләрен фашлап, бик ачы, усал мәкаләләр язалар.**

**Әхмәтҗан Сәйдәшевнең «Бәянелхак» газетасы битләрендә Казанның кара груһчы муллалары Мөхәммәтгариф Салихи, Садыйк Иманкулилар Тукайны, Камилне һәм иптәшләрен «дәһри», «денсез», «кафир», «имансыз», «мөртәт» дип атап, кызу-кызу мәкаләләр язалар һәм Тукайны:**

Никадәр шәргыйгә иттең хыянәт,
Юк икән синдә инсаф һәм дианәт! —

**дип, шигырьләр белән тиргиләр, тәүбә итеп, газетага ачык хат яз, дип кушалар. Аның белән генә калмыйлар, Уральскига агентлар җибәреп, андагы «Фикер» газетасы редакциясен һәм типографиясен туздырырга погромнар оештыралар. Бу хакта Тукайның «Алай-болай», «Погром» һәм башка мәкаләләре бик кызыклы. (Кара: Габдулла Тукай. Әсәрләр, 3 том, 1956 ел.)**

**Югарыда китерелгән дүрт юллык, Тукайның «Алай-болай» мәкаләсендә чәчмә сүзләр арасына кертеп басылганга, тезмә формасы югалып, проза гына булып калган. Ләкин ул, күрәсез, тезмә һәм рифмалы шигырь. Дүртенче юлның рифмасы үзенә аерым булып, ул шундый калыптагы башка строфаларның ахыргы сүзләре белән рифмалашырга тиешле. Шуннан бу шигырьнең Сәйдәшкә каршы башка бер зуррак сатирик шигыреннән өзек булуы аңлашыла. Аның озынчасы миңа мәгълүм түгел. Ләкин бу тезмәчектә соңгы рифмадагы «чайкалмай» сүзе Тукайның «Соры кортларга» шигыре белән рифмадаш килүенә дә укучы игътибар итмичә калмас дип уйлыйм.**

6

## АВЫЛ ҖЫРЛАРЫ

Алтынланган чабатаңның ефәк мәллә
кәркеше,
Анда сукбай, монда ишан, кәсеп итә бер
кеше.

Җанкай сачың бер көлтә, җиккән атны
өркетә,
Туган җире «Чуртыш» бугай, торган җире
«Бөркетә».

Байлар курай уйнаганда, бай тирәли
әйләнә,
Асравына корсак ясап бер шәкерткә
бәйләнә.

Тау буена тал чыга, талга куна карчыга,
Һимәтлерәк муллалардан шундый-шундый
хәл чыга.

Бичура.

*(«Ялт-йолт» журналы, 1910 ел, 16 сан, 1 ноябрь, 11—12 битләр.)*

**Шагыйрьнең соңгы академик басмаларында «Бичура» псевдонимы Тукайныкы итеп алынган; шушы псевдоним белән басылган шигырь-мәкаләләр Тукайныкы итеп басылганнар. Шулай булгач, бу «Авыл җырлары» да аның әсәрләре рәтендә басылырга тиеш. Моңарчы Тукай томнарында 5 көлтә «Авыл җырлары» билгеле. Монысы 6 көлтә була.**

**«Бичура» — Тукай псевдонимы булу хәтлесен Казан Гел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре ачыклагандыр дип беләм.**

7

## БӘНДӘЛӘР

Нинди күп бездә ятимнәрне талаучы
бәндәләр!
Җантимерләрнең [1] итек астын ялаучы
бәндәләр.

[1] Җантимер — жандарм, полиция.

Ярлыга ярты тиен артса елаучы
бәндәләр,
Күзгә, ачларны аяп,— төкерек сылаучы
бәндәләр.

Күп, шөкер! — Бездә исәпсез күп иманлы
бәндәләр,
Тик... Ходай, ник каргадың? Юк бер дә
башлы бәндәләр.

Бездә бар комган, читек, казылык сатучы
бәндәләр,
Бармы ачларга сынык икмәк атучы
бәндәләр?

Без хәер-истинҗаны ятлап та белгән
бәндәләр,
Без «фаный» тормышны ташлап бик тиз
үлгән бәндәләр.

Бездә бик күп бит «Мөхәммәдия» көйләүче
бәндәләр,
Тик менә... бик-бик сирәк идеал биләүче
бәндәләр.

Бездә байтак зур авызлы, оста телле
бәндәләр,
Тик күренми күпне белгән, тук күңелле
бәндәләр.

Ис тә киткеч бездә күп зур-зур сакаллы
бәндәләр,
Әмма һич артык күренми хәлле-маллы
бәндәләр.

Бездә аз-маз чыккалый динне танучы
бәндәләр,
Бармы мазлум кыз-хатынны кызганучы
бәндәләр?

Күп — «мөселманлык калыпта» дип
белүче бәндәләр,
Күп — газаплы, көчле яшьләрдән көлүче
бәндәләр.

Юкмы дингезнең суын зәмзәм дип эчкән
бәндәләр?
Бармы бер чын да адәмлеккә ирешкән
бәндәләр?

Бездә беткәнме оятсыз, исерек, азгын
бәндәләр?
Бармы үз халкын сөеп эшләүче алтын
бәндәләр?

Бездә шиксез күп намазны ташламаучы
бәндәләр,
Азмы «таш башлык»ны пакь дингә ямаучы
бәндәләр.

Бездә бар «илһам, каләм-сатлык» диюче
бәндәләр,
Ак яка, тарту-эчү «аклык» диюче
бәндәләр.

*(«Ялт-йолт» журналы, 41 сан, 1912 ел.)*

**Имзасыз басылган бу шигырьне Фатих Сәйфи, Тукай шигыре итеп, үзе төзегән Тукай басмасына артка, белешмәләр рәтенә кerткән (II том, 156 бит) һәм аңлатмасында:**

**«Бу шигырьнең Тукай шигыре булуында һичбертөрле шик юк, чөнки ул Тукайның шул вакыттагы җәмагать хәленә ясаган тәнкыйте. Ул вакытларда цензура Тукай шигырьләрен нык тикшергәнгә күрә, имзасын куймаган булырга кирәк...**

**Аннан соң, «Ялт-йолт»та бары төп язучы Тукайның шигырьләренә генә тарих куеладыр иде...**

**Эслүбе [1], кафиясе, сүз теземе барысы да Тукай шигыре икәнен ачык күрсәтә», — дип яза да, шигырьне күчергәч, астына тагын: «Һичшиксез, бу Тукай шигыре!» дип тә өсти.**

Руслар эш күрәләр,
Мөселманнар төш күрәләр.

**«Яшен» журналының 1 санында (1908 ел) тышында шәһәр советына депутат булып сайланган гласныйлар рәсеме ясалган. Рус гласныйлары сөйли, татар өстәлгә баш салып йоклый. Астына югарыгы ике юл шигырь язылган.**

**Бу журнал Тукай инициативасы белән чыгарылып, кайбер номерлары баштанаяк дип әйтерлек аның каләме белән язылган. Шулай булгач, журналның беренче номерының тышлыгындагы карикатура астына язылган беренче сүз — мәкаль-шигырь формасындагы бу ике юл да — анык булырга туры килә.**

*Нәкый ИСӘНБӘТ.*

[1] Эслүб — стиль.

# Г. ТУКАЙ ХАТЫ

*Г. Тукайның бу хаты 1907 ел азагында Уральскидагы Газизә апасына (Усманова-га) язылган булырга тиеш. Шул ук числода ул Г. Кариевка да шушы рухтарак бер хат җибәрә (кара: Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том, 209 бит). Аннары 1908 елның 27 мартында Газизәгә язган икенче бер хатында да бу хатына ишарәләр бар шикелле (шунда ук, 210 бит).*

*Бу хат беренче мәртәбә «Ил» газетасының 1914 ел 2(15) апрель санында басылган. Аннан соң шагыйрьнең бер җыентыгына да кертелмәгән. «Ил» газетасы Тукайның башка хатларын басачагы турында искәртсә дә, бу вәгъдә гамәлгә ашырылмаган.*

Г. ХАЛИТ.

**Мөхтәрәмә Газизә апай!**

**Вакыты бераз үтә төшкән булса да, Сезне гает сәгыйт корбан берлә тәбрик итәм: гает корбан котлы вә мөбарәк булсын! Мәстүрә абыстай аркылы җибәргән хатыгыз, әманәтегез һәм әманәт сүзегез сәламәт тапшырылды. Илтифатыгызга бик мәмнүн вә мөтәшәккермен. Әманәт сүзегезне тәмам Сез теләгәнчә җиренә җиткереп китерәчәкмен. Әле бу арада бик яхшы гына авырып алдым. Хат яза алмадым. Кәефем вә тормышым яхшы. Дус-ишләр күп. Казанда тору күңелле, Уральск бик сирәк искә төшә. Шүрәле китабы җибәрдем. Монда кечкенә вакытымда тәрбия иткән әнкәмне дә таптым. Иртәгә күрешмәкче булдым.**

**Хәзергә хуш!**

Г. ТУКАЕВ.

30 декабрь.

# Г. ТУКАЙ АРХИВЫН АКТАРГАНДА


*(Шагыйрьнең дүрт шигыренә карата)*

**Г. Тукай әсәрләренең 1955—56 елларда чыгарылган дүрт томлыгының II томында бирелгән искәрмәгә караганда, «Җавап» исемле шигырь, шагыйрьнең кулъязмалары арасыннан табылып, Октябрь революциясеннән соң гына басыла башлаган. Чыннан да, бу шигырь беренче мәртәбә 1926 елда Ф. Бурнаш тарафыннан чыгарылган бер томлыкка кертелгән. Бу бер томлыкта «Җавап» шигыренең беренче ике юлы:**


«Шигъре Лермонтов[1] вә Пушкин н ы ң —
олуг саф дингез ул,
Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай —
өч йолдыз ул». —

**дип, беренче юлдагы «Пушкин» дигән сүзнең ахырына «н ы ң» иҗеге кушып басылган.**

[1] Бу урында янәшә ике «в» язылса да, укыганда берсе йотылып, «Лермонто-вә» дип кенә әйтелә. — С. И.



«Яшен яшьнәгәндә» шигыре кулъязмасының фотокүчермәсе.



«Мокатдимә» шигыре кульъязмасының фотокучермәсе.

Г. Кутуй, Тукайның үлүенә 15 ел тулуга карата язган, «Рус әдәбиятының Г. Тукайга тәэсире» исемле мәкаләсендә («Безнең юл» журналы, 1928 ел, 3—4 саннар) шигырьне, шулай ук «Пушкинның» дип, тулы, 15 иҗекле үлчәүдә китерә. Ә Тукай әсәрләренең 1929 елдан башлап хәзергә кадәр чыгарылган барлык томнарында да «Җавап» шигыренең беренче юлы 14 иҗек белән генә басылып килә. Бу, һичшиксез, хата, һәм төзәтелергә тиеш.

Шул ук II томда бирелгән искәрмәгә караганда, Тукайның «Кечкенә музыкант» шигыре дә шагыйрьнең кульъязмалары арасыннан табылып, Октябрь революциясеннән соң гына басыла башлаган. Бу шигырьнең өченче строфасындагы өченче юлы шагыйрьнең кульъязмасында:

«Бер тыңласаң чинау к и л ә, бер
тыңласаң», —

дип, алты сүз белән язылган, ә Тукай томнарында:

«Бер тыңласаң — чинау, бер тыңласаң», — дип, 5 сүз белән генә, ягъни «килә» дигән сүз төшереп калдырылып басылган.

Шул ук шигырьнең җиденче строфасындагы беренче юлы Тукайның кульъязмасында:

«Уйный боргы, һичбер м и н у т туктап
тормый», —

дип язылган, ә басмаларда «минут» сүзе «вакыт» дип үзгәртелеп, —

«Уйный боргы, һичбер вакыт туктап
тормый», —

дип бирелгән.

Тукайның «Я ш е н я ш ь н ә г ә н д ә» исемле шигыре белән дә шундый ук хәл. Искәрмәгә караганда, бу шигырь дә Тукайның кульъязмалары арасыннан табылып, Октябрь революциясеннән соң гына басыла башлаган. Бу шигырьнең кульъязмасында:

«Куркытма син, алла! Яшен белән,
Барыбер мин к у р ы к м ы й м, яши беләм!
Куркытсаң да — курыкмыйм, аязымны
Сатып алдым а һ ы м, яшем белән!

*Г. Т. 26 июнь. 1911 сәнә* [1], —

дип язылган.

Томнарда исә шигырьнең икенче юлындагы «курыкмыйм» сүзе «курыкмый» дип, дүртенче юлдагы «аһым» сүзе бөтенләй төшереп басылып килә. Бу хаталар шулай ук төзәтелергә тиеш.

Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының Тукай фондында тышлыгына:

«Мәктәп шигырьләре. Г. Тукаев. 1909 сәнә. 12 октябрь», — дип, шагыйрьнең үз кулы белән язылган бер дәфтәр саклана. Шул дәфтәрнең 1 битендә түбәндәге 4 юллык шигырь язылган.

## МОКАТДИМӘ

И көләч йөзле малай, җөргән малай
җаланаяк!
Бер дә тыштан кермичә уйнап йөрүче
шартаяк!
Чәкмәшәнне куй да бер якка, җөгер, кил
каршыма!
Шартаяктан да күңеллерәк бер әйбер бар
сиңа.

Балалар өчен язылган бу кечкенә шигыре, ни өчендер, хәзергә кадәр матбугатка чыгарылганы юк.

*С. ИСӘНБАЕВ.*

---

[1] Кульъязмалар СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты архивында Г. Тукай фондында саклана.

# *1965 әдәби ел йомгаклары материаллары*

*Мирсәй Әмир*

## ҖЫЕЛЫШНЫ АЧУ АЛДЫННАН

**Без, язучылар, бүген бирегә, гадәттәгечә, узган 1965 елгы әдәби иҗатыбызга йомгак ясарга җыелдык. Гадәттәгечә дию ем очраклы түгел. Соңгы елларда бездә мондый йомгаклаулар практикасы матур бер традициягә әйләнеп бара...**

**Чынлап та, ел бетәр бетмәстән без, дәртләнеп, аны йомгаклау мәсьәләсен күтәрәбез икән, димәк «санарлык чебешләребез» бар. Һәм ул чебешләрне без җыелышыбызга килгән кунаклар белән бергәләп барларга телибез икән, димәк, безнең эшебезне кызыксынып күзәтүче җәмәгатьчелек бар!**

**Шуңа күрә бу җыелышны, бәлки, язучылар өчен үзенә күрә уңыш бәйрәме дип карарга да булыр иде. Ләкин безнең алай дип атыйсыбыз килми. Чөнки, билгеле булганча, һәр бәйрәмнең мәҗлес түрендә утыручы үз геройлары була, гадәттә, күпчелек ташкил итә торган урталары була, шулай ук ишек төбеннән уза алмаганнары да, ишекнең тышкы ягында ук калганнары да, хәтта, искечәрәк итеп әйтсәк, гает көнне «мәчет астына» ябылырга тиешле намаз-ныязсыз, уразасыз гөнаһияләре дә була.**

**Язучыларны без алай бүлә алмыйбыз. Әйе, без бәйрәмгә, Фатих Хөсни әйтмешли, язучыларга к ә н ф и т өләшергә килмәдек, ә бәлки иҗат эшебезнең бүгенгесе һәм аның иртәгесе турында җитди сөйләшү өчен җыелдык. Шуңа күрә, бүгенге сөйләшүләрдә язучылардан теге яки бу иптәшнең исеме ишетелмәсә, ул кеше ишекнең теге ягында калган икән яки «мәчет астына ябылган» икән дип уйлаштан булмасын! Һәр язучының иҗади активлыгын аның берьеллык практикасына карап кына бәяләп булмый. Үткән ел бер язучы үзенең тәгаллләнгән уңышлы әсәре белән игътибар үзәгендә булса, быел иненче берәүләрнең шул хәлдә булуы бик табигый. «Бер елны тартай симерә, бер елны бүдәнә», ди халык.**

**Шулай ук бу җыелышны Язучылар союзы идарәсенең яки Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелегенең бер еллык эше турында хисап бирүгә багышланган дип аңларга да ярамый. Чөнки идарәнең эше, гәрчә ул нигездә язучыларның иҗатларын активлаштыруга буйсындырылган булса да, бик күп оештыру мәсьәләләрен, административ чараларны да эченә ала. Ә безгә бүген үткән елдагы иҗат эшебезнең нәтиҗәләре турында сөйләргә, шулар турында фикер алышырга кирәк.**

**Ул нәтиҗәләр нинди соң? Әдәбиятыбызның бүгенге гомуми торышы ничек? Иҗат активлыгыбыз ни дәрәҗәдә? Бастырган әсәрләребез бүгенге заман таләпләренә җавап бирәме? Әдәбиятыбызны алга әйди яки аны читкә тарта, аның үсеен тоткарлый торган нинди тенденцияләр бар? Кайсы жанр буенча нинди уңышларга ирешкәнбез, кайсы жанрда нинди кимчелекләр безне борчый?**

**Бу сорауларга тулырак җавапны без һәр жанр буенча сөйләнәчәк докладлардан һәм алар буенча булган чыгышлардан көтәбез.**

**Иң башта, барыбыз өчен дә куанычлы хәл итеп, шуны әйтәсе килә: идеология фронтының барлык тармакларында ленинчыл демократия урнаштырылу шартларында күтәрелеп киткән иҗат активлыгы һаман үсүдә, киңәюдә дәвам итә. Киң катлам укучының да, әдәби тәнкыйтьчеләнең дә игътибарын җәлеп итәрлек яңа әсәрләр күп язылды. Авторлары тарафыннан тәмамланып та, әлегә дөньяга чыгып өлгермәгән әсәрләр турында сөйләүне киләсе ел йомгакларына калдырабыз. Үткән елда басылып чыккан кадәресе дә җитәрлек.**



Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш залыннан.

Аерым китапларны, җыентыкларны һәм вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан роман, повесть, хикәя һәм очеркларны, поэма һәм шигырьләрне, сәхнә әсәрләрен, әдәбият белеме һәм тәнкыйть буенча булган хезмәтләрнең барын да санап чыксаң, әлбәттә, бер генә язучыбызның да исеме телгә алынмый калмас иде. Ләкин бу эшнең кереш сүздә генә түгел, хәтта һәр жанрга багышланган аерым докладларда да мөмкин булмаячагын сез беләсез. Шуңа күрә, үземчә хәзерге әдәбиятыбыз өчен үзәк мәсьәлә дип тапкан берничә моментка гына игътибарыгызны юнәлтәсем килә.

Социалистик реализм әдәбияты алдында һәрвакыт беренче бурыч булып торган эш — заманыбызның алдынгы кешеләре образын иҗат итү. Бу совет язучысы өчен мактаулы, шуның белән бергә, иң катлаулы, хәл кылу өчен авыр һәм җаваплы бурыч. Чөнки ул язучыдан бик күпне сорый. Аның өчен өстәл янында утырып эшләү генә җитми. Аның өчен коммунистик төзелешнең алдынгы сафында булырга, тормышның, көрәшнең эчендә кайнарга, заманыбызның актуаль мәсьәләләрен хәл кылучы кешеләрне үз күзең белән күреп белергә генә түгел, алар белән бергә үзең дә шул көрәштә катнашырга кирәк.

Шуңа күрә кайбер язучылар бу җаваплы һәм кыен эшкә тотынмаска, заманыбызның алдынгы кешесе образын иҗат итү проблемасын читләтеп үтәргә тырышалар. Дөрес, бездә тормыштагы кире яклар турында язу, мораль темалар, лирик кичерешләр дә кире кагылмый. Ләкин мондый жанрлар каләм ияләренә чагыштырмача җиңелрәк, мәшәкатьсезрәк бирелэләр, яки шулай дип уйланыла. Чөнки андый әсәрләрдә, еш кына очракта, авторлар идея ярлылыгын, әдәби кимчелекләрне, художество зәгыйфьлеген, теләсә кемгә таныш булган тормыш-көнкүреш детальләре, физиологик кичерешләр белән каплап, укучы яки тамашачы күзеннән ансат яшерә алалар. Художество дәреслеге урынына факт дәреслеген күрсәтеп котылырга тырышалар һәм күп вакытта котылалар да.

Заманыбызның алдынгы кешесе образларын, коммунистик төзелешнең алдынгы сызыгындагы геройларны гәүдәләндерүгә багышланган әсәрләр дә бездә шактый күп

язылды. Шулар арасыннан аеруча игътибарга лаеклыларыннан Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Ш. Маннурның «Муса» романнарын, С. Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасын күрсәтәсе килә. Беләм, кайбер иптәшләр: «Әдәби әсәрнең кыйммәтен тема хәл кылмый бит», диярләр. Әйе, беләбез, бездә әсәрләренең әдәби ярлылыгын тема актуальлеге белән капларга тырышучы авторлар да бар. Бәхеткә каршы, андыйлар хәзер күзгә күренеп кими. Чөнки һәркайда чын эстетик таләпләрнең үсүе нигезендә аларны фаш итүе җиңел. Сүз тема актуальлеге белән сәүдә итүче халтурщиклар турында бармый. Ә үз иҗатына чын язучы намусы белән караучы, халык каршында, партия каршында зур җаваплылык тоеп эш итүче язучылар турында сүз барганда, алар өчен тема сайлауның да әһәмияте зур икәнлеген һич инкарь итәргә ярамый. Әйе, әсәрнең художество кыйммәтен язучының әдәби осталыгы ни дәрәҗәдә булуы хәл кыла. Моның сы, һичшиксез, шулай. Ләкин язучы үзенең осталыгын нинди теманы хәл кылганда күрсәтә бит? Берәү, әйтик, чабата ясый яки кәрзин үрә. Ә икенче берәү яңа төр автомашина ясый. Икесе дә кирәк әйбер. Ләкин бәяләре бер дип булмый.

Иптәшләр, мине дөрес аңлагыз. Күләм зурлык турында сүз бармый, әдәби әсәрдә күтәрелгән мәсьәләнең, теманың әһәмияте ни дәрәҗәдә булуы турында әйтәм. Г. Әпсәләмов та, Шәйхи Маннур да, С. Хәким дә, батырларча, зур, авыр, почетлы темаларга тотындылар, көчләрен дә, осталыкларын да әдәби хәрәкәтебезнең олы юлын тәшкил итә торган әсәрләр тудыруга бирделәр. Аларның кимчелекле яклары булуы мөмкин. Әлбәттә, алар бар да. Шулай булган хәлдә дә, андый әсәрләрнең әдәби хәрәкәтебездә хәлкылгыч роль уйнавын онытмыйк диясе килә. Югыйсә, бездә соңгы вакытларда кайбер иптәшләр арасында әдәби осталыкны әсәрнең темасыннан, аның идея эчтәлегеннән аерып йөртергә теләү тенденциясе сизелә. Бүгенге фикер алышуларда бу мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк булыр дип уйлыйм.

Быелгы ел йомгакларында безне куандыра торган тагын бер як: әдәбиятыбызга, бигрәк тә поэзия өлкәсенә, талантлы яшьләр килә. Без аларны проза жанрында да күрәбез. Икенче бер куанычлы момент — әсәрләребез укучыларның игътибарларын елдан елга күбрәк тарта баралар. Китапларыбыз күбрәк басыла. Безнең китапларыбыз өчен хәзер икешәр яки массовый тиражлар белән чыгу табигый хәлгә әйләнеп бара. Журналыбыз «Казан утлары» 1965 елда 20 меңгә күтәрелгән булса, быел ул 37 мең таратыла. Безнең үк әсәрләребез басыла торган башка журнал-газеталар буенча да шул ук күренеш. Бу — безнең хезмәтебезнең әһәмияте артуын күрсәтә, иҗатыбыз турында тагын да җитдирәк сөйләшергә кирәклеген искә төшерә.

Нәрсә безне борчый?

Драматургиябез һаман да арттта калуда дәвам итә. 1965 елда чыккан яңа спектакльләрдән Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы»н искә алмаганда, безне куандырырлык әсәр булмады диярга туры килә.

Кайбер язучыларның үз иҗатларында гражданлык җаваплылыгын хис итеп җиткермәү, форма белән мавыгу күренешләре очрый. Матбугатта, аеруча, үзебезнең «Казан утлары» журналында кайбер уйланып җитмәгән, җавапсыз чыгышлар булу фактлары бар.

Бүген барысы турында да сөйләшербез, алдыбызда торган тарихи көннәргә тиешенчә әзерләнү буенча эшлекле тәкъдимнәр ишетербез дип уйлыйм.

*Рафаэль Мостафин*

# КИҢ КОЛАЧЛЫ, ТИРӘН ФИКЕРЛЕ

Соңгы еллар, аеруча 1965 ел, илебез тормышында гаять дәрәҗәдә кызыклы, әһәмиятле булды. Партия Үзәк Комитетының 1964 елгы Октябрь һәм аннан соңгы пленумнары тормышыбызның барлык тармакларына яңа рух һәм дәрт, зур омтылышлар алып килде. Волюнтаризмга, ягъни, объектив закончалыклар белән исәпләшмичә, шәхси ихтыярга гына таянып эш итүгә, кискен отпор бирелде. Җәмгыятебезнең экономик закончалыкларын өйрәнүгә игътибар тагы да арта төште. Фәндә, әдәбиятта һәм, гомумән, идеология өлкәсендә субъектив, чынбарлыкка туры килмәгән карашлар фаш ителде. Тормышның объектив законнарын өйрәнеп, шуларга таянып эш итү кирәклеге бүген барыбыз өчен дә көн кебек ачык.

Соңгы еллардагы үзгәрешләр — партия һәм, гомумән, халык тормышында Ленин принципларының ныгый, совет демократиясенең тагын да киңрәк җәелә баруы — әдәбият өлкәсенә дә шактый зур һәм житди яңалыклар алып килде. Әдәбиятыбызның, аерым алганда, прозаның колачы киңәйде, фикере тирәнәйде, карашы үткенәйде. Татарстан язучыларының моннан бер ел элек булып үткән VI съездында Мирсәй Әмир 1964 елны романнар, повестьлар елы дип атаган иде. Шул ук сүзләрне 1965 елга карата да кабатларга мөмкин. Чыннан да, 15—20 еллар элек матбугатта 3—4 елга бер роман яки повесть басылып чыкса, үткән елны зур күләмле өч яңа роман (Г. Әпсәләмов. Ак чәчәкләр; Ш. Маннур. Муса; И. Салахов. Күкчәтау далаларында), өч повесть (Р. Төхфәтуллин. Тамчылар ни сөйли; Г. Ахунов. Хыялый Хәйрүш егетләре; Н. Дәүли. Җимерелгән бастион), берничә хикәя һәм очерклар җыентыгы һәм газета-журнал битләрендә дистәләрчә кыска хикәяләр басылды. Боларның барына да тулы анализ бирүне өстемә алмыйча, аерым иң характерлы әсәрләр мисалында, бүгенге прозаның унай һәм кире тенденцияләре турындагы кайбер фикерләрем белән уртаклашырга телим.

## «АК ЧӘЧӘКЛӘР» РОМАНЫ НИ ӨЧЕН УҢЫШ КАЗАНДЫ?

1965 елда басылып чыккан әсәрләр арасыннан киң катлау укучылар тарафыннан җылы, яратып кабул ителгәннәрнең берсе — Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы булды. «Казан утлары» редакциясенә килгән йөзләрчә хатлар да, укучылар конференцияләрендә әйтелгән фикерләр дә, китапханә эшчеләренең мәгълүматлары да шуны раслый. Хәтта мин «Ак чәчәкләр» романын 1965 елның иң популяр әсәре дип атар идем.

Гаҗәеп хәл: берьяктан, әсәр шундый зур дан казана, икенче яктан, проза секциясе утырышында, Г. Әпсәләмовның каләмдәшләре романның шактый күп һәм житди кимчелекләрен дә күрсәтеп үтәләр. Мин секциядә әйтелгән фикерләрне кабатлап тормыйм: утырышның кыскача протоколы «Казан утлары» журналының 12 санында басылып чыкты, һәм бу тәнкыйтьтә, әлбәттә, хаклык бар. Ләкин факт факт булып кала: роман, кимчелекләре шактый күп булуга да карамастан, укучылар күңелен кузгатты, аларның мәхәббәтен казанды.

Моның сере нәрсәдә соң? Кайбер укучыларның зәвыклары талымсыз булудамы... Әйе, беркем өчен дә сер түгел: кайвакыт сәнгатьчә эшләнеше шактый йомшак әсәрләр дә бик популяр булып китәләр. Ләкин «Ак чәчәкләр» романының зур уңыш казануын бары тик укучыларның зәвык дәрәҗәсе белән генә аңлату дөрес булмас иде. Әгәр әсәр киң катлау укучылар арасында дан казана, халык күңелен дулкынландыра икән, бу беркайчан да сәбәпсез булмый. Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»е шундый киң яңгыраш алган икән, моны, беренче чиратта, әсәрнең эчтәлеге, күтәргән проблематикасы белән аңлатырга кирәк.

Әсәрдә сүз медицина эшчеләре — иң кешелекле профессия әһелләре турында

бара. Һәм роман, башыннан ахырына хәтле, чын гуманизм, югары кешелеклелек пафосы белән сугарылган. Әсәрнең төп геройларыннан берсе, профессор Әбүзәр Таһиров бөтен тормышын соңгы сулышына кадәр халыкка багышлый. Гөлшаһидә, Диләфрүз, Мансурлар, төн йокыларын калдырып, кеше сәламәтлеге өчен көрәшәләр, башкалар турында кайгыртып йөриләр. Әсәрнең конфликтын тормышның мәгънәсе турында ике төрле фәлсәфә, капма-каршы карашлар бәрелеше тәшкил итә. Берьякта Әбүзәр Таһиров, Гөлшаһидәләрнең гуманлыгы булса, икенче якта — шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы Саматов, Янгура кебек кешеләрнең принципсызлыгы.

Бу тема, бу көрәш бүген бик тә заманча, бик тә актуаль яңгырый. Әпсәләмов романында исә бу тема үзенең конкрет сәнгатьчә гәүдәләнешен тапкан. Романның популярлыгын, минемчә, шуның белән аңлатып була да инде.

Г. Әпсәләмов әсәре җылы каршы алынуның тагы бер сере авторның сюжет төзүдәге осталыгына бәйле. Чыннан да, автор романны бик мавыктыргыч, киеренке итеп төзи белгән. Укучылар аны тәмам бирелеп, дөньяларын онытып укыдылар. Роман журналда басыла башлауга, кайберәүләр ахырын көтәргә түземлекләре җитмичә: «Киләсе санда вакыйга ничек дәвам итә? Мансур Диләфрүзгә өйләнәме? Өйләнә генә күрмәсен, югыйсә бик зур хата ясый, әйтегез язучыга», дип, редакциягә хатлар язып тордылар.

Башка әсәрләрендә дә Г. Әпсәләмов үзен мавыктыргыч сюжет остасы итеп күрсәткән иде. «Ак чәчәкләр» романында аның бу сыйфаты тагы да чарлана төшкән.

Ләкин кайвакыт автор сюжетны ясалма рәвештә катлауландырып җибәрә (шул ук Мансурның бер дә нигезсез Диләфрүзгә өйләнергә теләп йөрүе, аның көтелмәгәндә хатсыз-нисез кайтып төшүе һ. б.). Г. Әпсәләмов әсәрләрендә сюжет, еш кына, характер ачыклау чарасы булудан бигрәк, үзмаксатка әйләнеп китә.

Г. Әпсәләмов уңай геройларын берникадәр идеаллаштырып, калку итеп, романтик буяулар белән сурәтләргә ярата. Кире геройларын тасвирлаганда исә ул, гадәттә, аларны үтә начар, хәтта җирәнгеч итеп күрсәтә. Шуңа күрә аның персонажларын, бер дә икеләнмичә, өч төркемгә бүләргә мөмкин: үтә яхшы, идеаллаштырылган, үрнәк булырлык геройлар (Әбүзәр Таһиров, Гөлшаһидә һ. б.); үтә начар, һәрьяктан тискәре геройлар (Сәләх Саматов, Тютеев, Илһамия, Янгура) һәм урталыкта торучы, кайбер кимчелекләре булган персонажлар (Мәдинә ханым, Фатихәттәй, Диләфрүз, Асия, Николай Максимович һ. б.). Характерлар тудыруда буяуларны артык куертып, романтик алымнар кулланып эш итү — Г. Әпсәләмов иҗатының төп үзенчәлекләренең берсе. Язучы үзе дә бу хакта ачыктан-ачык язып чыкты:

«Әдәбиятның үзәгендә җанлы кеше булырга тиеш. Зур хәреф белән языла торган кеше... Без «гомумән кеше» тарафдарлары түгел, без аңлы рәвештә уңай геройны яклыйбыз, аны романтик планда калку күрсәтәбез, кирәк икән п ь е д е с т а л г а да б а с т ы р а б ы з». (Г. Әпсәләмов. Ленинградтан кайткач. «Социалистик Татарстан» газетасы, 19 ноябрь, 1965 ел.)

Буяуларны куертып, уңай геройларны пьедесталга бастырып, кире геройларны әшәке, нәфрәт уятырлык итеп күрсәтү авторга үз карашларын, үз мөнәсәбәтен укучыларга җиткерергә ярдәм итә. Г. Әпсәләмов әсәрләрен укып чыккач, язучының үз геройларына булган симпатиясендә яки антипатиясендә бернинди шик калмый. Укучыларның күпчелеге Г. Әпсәләмов әсәрләрен шушындый гади, аңлаешлы, бераз романтик алым белән куертып, ак белән караны аерып күрсәткән өчен дә яраталар. Ләкин шул ук вакытта пьедесталга менгезүнең куркыныч ягы да бар: геройның тормыштан, реаль чынбарлыктан аерылып китүе мөмкин. Проза секциясендә «Ак чәчәкләр»не тикшерү вакытында чыгыш ясаучыларның күбесе әсәрнең нәкъ шушы якларын тәнкыйтьләп үттеләр дә.

Башка әсәрләрендәге кебек үк, Г. Әпсәләмовның бу романында да иң тормышчан, реалистик һәм матур образлар икенче пландагы, гади кешеләр; Фатихәттәй, Гөлшаһидәнең йорт хуҗасы Сәхипҗамал җиңги, Маһирә ханым һ. б. Аларны автор пьедесталга да күтәрми, кире якларын да куертмый — нәкъ тормыштагыча, үзләренең тапкыр сүзләре, каннарына сеңгән гадәтләре белән, матур итеп тасвирлап бирә.

«Ак чәчәкләр» романын тикшерүгә багышланган проза секция утырышының протоколы журналда басылып чыккач, мина шундый фикерләр дә ишетергә туры килде: роман халык тарафыннан җылы каршыланган, укучылар аны яратып укый, ни өчен аның кимчелекләрен казып чыгарырга кирәк булган? Әлбәттә, берәү дә Г. Әпсәлә-

мовка син алай язма, болай яз, дип әйтми. Аның методы, романтик алымнары да яшәргә хаклы, һәм күпчелек укучыларның романны шулай хуплап алуы үзе үк моны раслап тора. Ләкин әсәр басылып чыгу белән халкыбызның гомуми рухи байлыгына әверелә. Һәм әдәбиятның тагы да югарырак баскычка күтәрелүен истә тотып, без объектив рәвештә аның көчле һәм йомшак якларын күрсәтергә тиешбез. Шул караштан торганда төрле фикер, кискен бәхәсләр булуы бик табигый хәл.

## ҮРНӘК БУЛЫРЛЫК ГЕРОЙЛАР ГЫНА ИҖАТ ИТҮ МӘҖБҮРИМЕ?

Образларны бераз идеаллаштырып, калкурак итеп күрсәтү бер Г. Әпсәләмов иҗаты өчен генә хас түгел. Г. Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә, М. Әмирнең «Саф күңел»ендәге Сания шулай ук калку бирелгән, бераз пьедесталга күтәрелгән образлар. Әлбәттә, һәр язучы мондый геройларны, үзенә генә хас алымнар белән гәүдәләндерә.

Соңгы елларда безнең әдәбиятта икенче характердагы әсәрләр дә күренә башлады. Андый әсәрләрдә үрнәк булырлык геройлар юк диярлек, киресенчә, игътибар үзәгендә социалистик җәмгыятьнең төп юлыннан хәтта ерак торган, тормышның ниндидер читтәге сукмакларыннан баручы кешеләр тора. Беренче чиратта, мин Ә. Еникинең «Саз чәчәге» һәм «Рәшә», А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» кебек әсәрләрен күздә тотам. Үткән елны болар янына Н. Фәттахның «Артта калган юллар» исемле хикәясе өстәлде.

Кайбер тәнкыйтьчеләр, үрнәк булырлык геройлары булмаганы өчен, мондый әсәрләрне тәнкыйть уты астына алдылар. Мәсәлән, К. Фасеев үзенең мәкаләсендә «Рәшә» повестен Зөфәр Сабитов образына каршы торырлык уңай герое булмауда, тормыш дөреслеген бозуда, хәтта идея ягыннан ялгыш, зарарлы булуда гаепләп чыкты. Шул ук фикерне «Өч аршын җир»гә карата Ф. Мусин кабатлады. Ирексездән шундый сорау туа: язучы өчен үрнәк булырлык геройлар тудыру мәҗбүри бер шарт микәнни?..

А. Румянцевның «Правда» газетасында басылган «Совет интеллигенциясе иҗат эшенең партиялелеге турында» исемле мәкаләсендә бу сорауга ачык җавап табарга мөмкин.

«Әдәбиятның тәрбияви бурычлары һич тә үрнәк булырлык образлар тудыру белән генә чикләнми, — ди ул бу мәкаләсендә. — Ул бурычлар күп тапкыр киңрәк һәм тирәнрәк. Кеше шәхесенең чәчәк атуына, дөньяга карашын киңәйтүгә булышырлык, аны югары идеаллар белән дулкынландыра, мораль һәм интеллектуаль яктан югары күтәрә, дөньяны эстетик танып-белүен камилләштерә, үз тирәсендәге иске һәм яңа күренешләрне үткенрәк күрергә һәм аларга үткенрәк мөнәсәбәт белдерергә ярдәм итәрлек һәр әсәр, кыскасы, нинди әсәр шәхесне үстерергә, аның тормышка үзбаш һәм актив мөнәсәбәтен көчәйтергә ярдәм итә, коммунизм өчен көрәштә гомум халык эшенә ярдәм итә — шундый әсәр партияле сәнгатьнең төп юлында була һәм аның чын кыйммәтен билгели».

«Правда» газетасында басылган бу мәкалә белән танышкач, безгә дә кайбер искергән шаблон карашлардан арынырга вакыт җитмәдеме икән, дигән фикергә киләсең. Эш уңай һәм кире геройлар пропорциясендә түгел, беренче чиратта, язучының позициясендә. Язучы безнең тормышны нинди позициядә торып тасвирлый, кая чакыра, нәрсәгә нәфрәтләнә, кай ягын сокланып күрсәтә?

Әсәрдә уңай геройның бөтенләй булмавы ихтимал, әмма әсәр безгә кимчелекләрдән арынырга булышса, безнең өчен чит философиянең асылын фаш итсә, тормышны тирәнрәк аңларга ярдәм итсә — әсәр файдалы эш башкара, коммунизм төзелешенә хезмәт итә дигән сүз.

«Артта калган юллар» хикәясендә сүз сугыш еллары тудырган авырлыклар хакында бара. Бу кыенлыклар турында моңарчы безнең әдәбиятта беркемнең дә болай кискен һәм рәхимсез рәвештә язып чыкканы юк иде әле. Әсәрне укып чыккач, бездә сугышка карата нәфрәт туа, аны янадан булдырмас өчен көрәшнең кирәклеген тагы да тирәнрәк аңлыйсың...

Бер уйласаң, кем ул Хәмдия? Хезмәт фронтыннан качкан дезертир, җинаятьче. Ләкин автор Хәмдияне кара буяуларга манчып күрсәтми, киресенчә, ул аңа телэктәшлек белдерә. Моннан 10—15 ел элек мондый әсәрнең матбугатта чыгуы, бәлки, мөмкин дә булмас иде. Әсәрнең гуманистик, кешелекле характерында аның нәкъ бүген язылган булуы, заман рухы чагыла да. Әсәрне «Казан утлары» редакциясендә

тикшергән вакытта язучы Гомәр Бәширов хәтта шундый фикер әйтте: «Әгәр мин «Намус» романына бүген янадан алынсам, мин аны, бәлки, нәкъ шушы хикәядәгечә язган булыр идем». Әлбәттә, бу сүзләрне дөрес аңларга кирәк. Бәширов Фәттахча язмас иде, үзенчә, Бәшировча язар иде. Ләкин ул бүген ачылган хакыйкатьләрне искә алып, бүгенге карашлар югарылыгыннан торып язар иде.

Шул ук вакытта, Н. Фәттах хикәясенең шактый берьяклы булуын да истән чыгарырга ярамый. Фәттах үз хикәясен полемик рәвештә, тормышны гел матурлап кына күрсәтә торган әсәрләр белән бәхәсләшеп язган. Ә бу инде, күрәсең, язучының карашын берникадәр чикләгән. Хикәяне укып чыккач, халкыбызның Ватан сугышында күрсәткән батырлыгының чыганакларын, аның рухи көчен, Ленин партиясенә ышанычын тулысы белән күз алдына китерүе кыен. Әсәр натуралистик рухтарак язылган, автор, тормыш ваклыкларыннан югары күтәрелеп, зур гомумиләштерүләр ясый алмый. Әлбәттә, аерым язучыдан, бигрәк тә аерым әсәрдән без теге яки бу чор турында тулы хакыйкатьне таләп итә алмыйбыз. Андый хакыйкать гомум әдәбият агымы белән генә, күп әдипләр көче белән генә барлыкка килә ала. Әмма Н. Фәттах тормышның бу ягына да игътибар итсә, аның әсәре, һичшиксез, тагы да тулырак, тирәнрәк һәм художество ягыннан да көчлерәк булыр иде.

## ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДАГЫ РОМАН

1965 елны «Казан утлары» журналы битләрендә тагын бер зур күләмле әсәр — Шәйхи Маннурның «Муса» романы басылды. Романның М. Җәлил юбилее алдыннан басылып чыгуы — меңләгән укучылар өчен көтеп алган, кадерле бүләк булды. Автор сайлаган темасы өстендә эшләүгә сигез ел гомерен багышлады, бик күп эзләнде, Җәлилнең замандашлары һәм аның көрәштәшләре белән очрашты, бай материал туплады. Муса эзләреннән йөргән чакта, автор Муса биографиясенә һәм аның дошман тылында батырларча көрәшенә караган бик күп материалларны ачыклады, Мусаның фәнни биографиясен тулыландырырга ярдәм итте. Бу ачышлары өчен генә дә, Ш. Маннур романы зур ихтирамга лаеклы. Ләкин романның әһәмияте фактик материал туплау белән генә чикләнми. Автор көрәшче-шагыйрь образын, нигездә, уңышлы, калку, истә калырлык итеп тасвирлый. Редакциягә һәм авторның үзенә килгән хатларга караганда, укучыларның күпчелеге бу романны яратып укыганнар. Әсәр укучыларны дулкынландыра, уйландыра, үз иленә һәм халкына турылыклы булырга чакыра.

Шуның белән бергә, әсәрне укыган чакта, икенче төрле фикерләр дә туа. Татар халкының легендар улына багышланган роман үзенең сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да бик югары торырга тиеш кебек иде. Чөнки аны татар укучылары гына түгел, башка милләт вәкилләре дә кызыксыну белән укыячак. Инде әсәргә күп милләтле совет һәм дөнья әдәбияты таләпләре югарылыгыннан караганда, аның кимчелекләре тагын да ачыграк күренә. Беренчедән, әсәр артык озын язылган. Романның журнал өчен махсус кыскартылган варианты да 30 табактан артык урын били. Әлбәттә, сүз гади озынлык турында гына бармый. 50—60 табаклы эпопеяларның да җыйнак һәм кыска итеп язылуы мөмкин. Сүз әсәрнең файдалы мәйданы турында, ягъни автор үз алдына куйган максатка ирешү өчен кулланган чараларның барысының да ни дәрәҗәдә кирәк булуы турында бара. Гадәттә, шагыйрь прозага тотынса, проза әсәрен ул бик җыйнак, кыска язучан, аз юлларга да зур мәгънә салып язучан була торган иде. Монда исә киресе килеп чыккан. Авторның проза өлкәсендәге тәҗрибәсезлеге адым саен сизелеп тора. Әсәрнең төп кимчелеге — т а с в и р ч ы л ы к. Язучы Муса гомеренең бер дәверен тулы итеп һәм мөһим вакыйгаларның берсен бер калдырмыйча тасвирларга тырышкан. Әгәр без романны Муса биографиясенә образлы бер иллюстрация итеп карасак, аның һәрбер эпизоды да урынлы. Мусаның пленга төшүе дә, аның фашист лагерьларында күргән михнәтләре дә, яшерен оешма төзүе дә, кулга алынуы һәм башкалары да. Ләкин укучы өчен боларның барысы да кирәк микән? Бүгенге җитлеккән прозаның (һәм гомумән матур әдәбиятның) беренче таләбе — төп фикернең төгәл булуы, фикер ачыклыгы. Мәсәлән, Муса турындагы бу романда безне, беренче чиратта, Җәлил характерының чыныгуы, аның эчке рухи байлыгының югары ноктага күтәрелүе кызыксындыра. «Муса» романында исә бер пландагы эпизодлар, Муса характерына берни өстәми торган ваклыклар, сөйләп кенә бирелгән фактлар тулып ята.

Автор бай һәм кызыклы материал җыйган, ләкин ул бу материалны җиңә алмаган, киресенчә, материал аны җиңгән кебек тәэсир кала.

Романда башка житди кимчелекләр дә байтак. Тарихи шәхес тормышына багышланган әсәрдә дә язучы билгеле күләмдә фантазиягә урын бирергә хаклы. Ләкин ул фантазия реаль характер һәм тормыш логикасына каршы килергә тиеш түгел. Ш. Маннур исә кайвакытта бу логика белән исәпләшми. Мәсәлән, автор романның буеннан-буена Муса — Әлбидә линиясен үткәрә. Бу — уйлап чыгарылган линия һәм авторга ул, күрәсең, сюжетны тыгызрак бәйләр өчен кирәк булган. Ләкин халык күңелендә Муса, көрәшче һәм ялкынлы шагыйрь булып кына түгел, шундый ук турылыклы ир һәм ата булып та калган. М. Җәлилнең Моабит төрмәсендә язылган шигырьләре дә шуны раслый. Автор Мусаның Әлбидәгә карата булган хисләрен дуслык кына итеп күрсәтергә бик тырышса да, бу линия укучы күңелендә ниндидер ямьсез шик тудыра. Күрәсең, автор мәхәббәт линиясе булмаса, роман булмый дигән иске традицияләргә таянып эш иткән. Романда Муса характерына һәм тарихи обстановкага караган башка төгәлсезлекләр дә бар. Ләкин мин аларга тукталып тормыйм. Бу кадәресе — рецензентлар эше.

Романның иң житди кимчелекләреннән тагын берсе — икенче пландагы образларның йомшак эшләнгән булуы. Романда йөзгә якын персонаж катнаша. Ләкин аларның бик азы гына хәтердә кала. Укучы кайбер персонажлар турында, фамилияләреннән тыш, берни дә диярлек белми кала. Дошман образларын тасвирлаганда исә язучы, беренче чиратта, кара буяулар гына куллана. Дошман характерының да бит үз логикасы, эшләгән эшләренең үз мотивировкасы булырга тиеш. Ш. Маннур романында исә дошман образлары бер планлы, артык примитивлаштырылган карикатураларга кайтып кала (мәсәлән, Шәфи Алмаз, Шпигель, Карип Ишбулдин һ. б.). Реаль тормыштагы дошманнар мондый ахмак булсалар, Муса кебек бәркетне бик җиңел генә тозакларына эләктерә алмаслар иде. Дошманны акыллы, мәкерле, хәтта, кайсыдыр яктан сәләтле итеп күрсәтүдән куркырга, минемчә, бер дә кирәкми. Мондый очракта Җәлил һәм аның иптәшләре күрсәткән батырлык тагын да тулырак булып күз алдына басар иде.

Ш. Маннур кайвакыт, укучының сәләтенә ышанып бетмәгән кебек, барысын да үзе әйтеп бетерергә тырыша, геройларына карата үз мөнәсәбәтен ачык белдерә. Ә бу инде күп сүзлелеккә, тасвирчылыкка китерә.

Әлбәттә, кирәкле урында нокта куя белү, укучының хыялына да ирек калдыру — язучы хезмәтендә иң кыен моментларның берсе. Һәм ул язучының осталыгына гына түгел, аның эчке сиземләвенә, зәвыгына да бәйле. Кайбер язучылар, әсәрләрендәге шундый артык озынлыклар, кирәкмәгән ваклыклар турында сүз чыкса, бу минем кимчелегем түгел, ә үзенчәлегем дип акланырга тырышалар. Ләкин, һәрхәлдә, әсәрнең житлекмәгәнлеге, бүгенге таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә булмавы яхшы үзенчәлек түгел.

Сүз уңаенда шуны да әйтеп китим: безнең бик тыгыз, җыйнак яза белүчеләребез дә юк түгел. Үткән елны «Азат хатын» журналы битләрендә язучы Ә. Еникинең «Тауларга карап» исемле хикәясе басылып чыкты. Бу кыска гына хикәяне дулкынланмыйча уку мөмкин түгел. Кечкенә генә хикәягә язучы зур мәгънә сала алган, тирән фәлсәфи фикер әйткән, хәтта кешенең бөтен тормышын сыйдыра алган. Тормыш мәңге дәвам итәчәк, халык бар нәрсәне дә җиңеп чыга — менә нинди зур фәлсәфи нәтиҗәгә киләсең бу хикәяне укып чыккач. Кайвакытта калын-калын романнарда да мондый бер хикәядә әйтелгән кадәр фикер булмый.

А. Гыйләҗевнең «Үги ана яфраклары» исемле хикәясе дә, минемчә, шундыйлардан.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ОСТАЛЫГЫ ҺӘМ ДӨНЬЯГА КАРАШЫ

Югарыда әйткәнемчә, бездә зур күләмле әсәрләр күп языла башлады, прозаның колачы чагыштыргысыз киңәйде. Бу, әлбәттә, куандыра торган күренеш. Ләкин әдәби әсәрләрнең кыйммәтен, беренче чиратта, аларның сыйфаты билгели. Шуңа күрә, бүген бездә әдәби осталык мәсьәләләренә аеруча нык игътибар итәргә кирәк.

Шул ук вакытта икенче әйберне дә истән чыгарырга ярамый: әдәби осталык язучының белем дәрәҗәсенә, тормыш белән бәйләнешенә, мөстәкыйль һәм тирән фәлсәфи фикер йөртә алуына, кыскасы, аның дөньяга карашына бәйле. Фикеребезне ачыграк аңлату өчен И. Салаховның «Кукчәтау далаларында» исемле романына мөрәҗәгать итик.

И. Салахов романы, беренче битләреннән үк, күңелне җәлеп итә, аны мавыгып, чын эстетик ләззәт белән укыйсың. Язучы безне Казагыстанның иксез-чиксез далаларына алып керә, ул якларның үзенчәлекле табигатен күрсәтә, аның эчке бер моңын, матурлыгын ача, кырыс, ләкин бай рухлы кешеләре белән таныштыра.

Әсәрнең аеруча сокландыргыч ягы — аның бай һәм үзенчәлекле теле. Галимҗан Ибраһимов традицияләрен дәвам итеп, язучы романына күп кенә казакъ сүзләре, казакъ әйтемнәре кертә. Алар әсәргә үзенчә бер төс, ямь биреп тора, һәм шул ук вакытта, аларның барысы да диярлек укучыга җиңел аңлашыла. Минемчә, мондый тәҗрибәне хуплап каршыларга кирәк. Тугандаш төрки халыкларның тормышы, рухи байлыгы, аларның үзенчәлекле, ләкин безнең өчен бик якын булган тел стихиясе безнең әдәбиятны, һичшиксез, баета алачак. И. Салахов бу әсәре белән, бер яктан, халыклар дуслыгын ныгытуга хезмәт итсә, икенче яктан, татар әдәби тел байлыгына да берникадәр өлеш кертә.

И. Салахов чирәм җирләрендә яши. Әсәрне укыган вакытта авторның материалны яхшы белүе, романда барган вакыйгаларга язучының үзенең дә турыдан-туры катнашкан булуы сизелеп тора. Автор тормышчан, ышандырырлык детальләр сайлый белә. Көнкүреш ваклыкларын тасвирлаганда автор аеруча күзәтүчән. Ләкин кешеләрнең эчке кичерешләрен, герой язмышларын психологик мотивлаштыруда язучы, кайвакытта, өстән-өстән генә үтеп китә. Романның башлангыч өлешендә автор искиткеч катлаулы, тормышчан конфликт билгели. Ләкин аны ахырга хәтле чишә алмый, җиңеләйтә, герой кичерешләрен бөтен тирәнлеге белән күрсәтми. Шуңа күрә аның кайбер геройлары берьяклырак булып чыккан.

Романда сүз гаилә-мәхәббәт мәсьәләләре турында түгел, ә чирәм җирләрен үзләштерү турында бара, дип әйтүләре мөмкин. Әйе, язучы шактый дөрес һәм ышандырырлык итеп совхоз кешеләренең фидакарь хезмәтләрен күрсәтә, бу зур эшнең романтикасын ача, шул ук вакытта, беренче чорда булган кыенлыкларны да яшерми. Моннан 7—8 яки 5—6 ел элек басылып чыкса, әсәр, бәлки, әдәбиятыбызда зур бер вакыйга дәрәҗәсенә күтәрелә алыр иде. Әмма бүген безнең барыбызга да чирәм җирләрен үзләштерү вакытында эшләнгән башбаштаклыклар ачылды, һәм бу башбаштаклыклар шактый ямьсез нәтиҗәләргә дә китерде.

И. Салахов романы буенча фикер йөрткәндә исә, чирәм җирләрне күтәрүдә барысы да ал да гөл булган икән кебегрәк тәэсир кала. Башта берникадәр кыенлыклар булса да, роман ахырына алар барысы да җиңелә. Ә бит бүген дөньяга чыккан әсәрдән без бүгенге югарылыкта язылган булуны таләп итәргә дә хаклы.

Шулай итеп, авторның дөньяга карашы чикле булу аның әсәренең художество кыйммәтен дә шактый киметкән.

Язучы тормышны битараф күзәтүче түгел. Аның тормыш күренешләренә үз мөнәсәбәте, уйланып, әрнеп йөргән проблемалары, кыскасы, халыкка әйтә торган үз сүзе булырга тиеш. Әгәр дә инде ул андый күпләрне борчый торган мәсьәләләрне читләтеп узып, ниндидер икенче дәрәҗәдәге әйберләр турында яза икән, укучы да андый әсәргә башкача карый башлый.

Нефть якларында яшәүче ике язучы — Гариф Ахунов һәм Рафаэль Төхфәтуллин — исемнәре безнең матбугатта еш телгә алына. Чыннан да, Г. Ахуновның «Хәзинә»се һәм Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» повесте әдәбиятыбызда күренекле урын яулап алдылар, киң катлам укучылар да бу әсәрләрне яратып укыды. Шуңа күрә, бу язучыларның һәр яңа әсәрен түземсезлек белән, зур кызыксыну белән көтеп аласың. Ләкин, кызганычка каршы, бу өметләр һәрвакытта да тулысынча акланмый. Баштан ук шуны әйтәсе килә: бу язучыларның яңа повестьлары аларның үз иҗатларында да, гомумән татар әдәбиятында да зур вакыйга, яңа уңыш дәрәҗәсенә күтәрелә алмады. Әлбәттә, без бу әсәрләрне бөтенләй инкарь итәргә җыенмыйбыз, аларның һәрберсенең үз уңай яклары да бар.

Р. Төхфәтуллинның «Тамчылар ни сөйли» исемле повесте аңа гына хас лирик җылылык, тел чараларын сайлаудагы самимилек белән аерылып тора. Автор яшь замандашларыбызның характеры чыныгуын күрсәтә. Аның герое ниндидер тапталган сюжет сукмаклары белән йөрми, моңа кадәр әдәбиятта күп мәртәбә чалынган ситуацияләрне кабатламый — үз юлы белән бара. Әсәр үзәгендә — гади авыл малае Ильяс образы. Автор аны бер дә гадиләштерми. Ул аның эчке дөньясын, рухи байлыгын, бүгенгечә фикер йөртүен бөтен нечкәлекләре белән ачып бирә. Повестьның төп уңышы — бүгенге заман яшьләренең эмо-

циональ һәм интеллектуаль байлыгын күрсәтүдә.

Г. Ахуновның «Хыялый Хәйрүш егетләре» исемле повесте да, беренче карашка, шактый оста, җыйнак язылган. Бүгенге нефтьчеләр, яшь замандашларыбыз тормышын автор, матур детальләр табып, поэтик пафос белән тасвирлый. Әсәрдә без, аерым шәхес язмышыннан бигрәк, тулы бер коллектив тормышын күрәбез. Повестьның композициясе җыйнак, хикәяләү җанлы һәм киеренке. Әмма, авторның теле һәм башка сурәтләү чараларының камилләшә төшүенә дә карамастан, бу повесть, югарыда әйткәнемчә, Г. Ахунов иҗатында «Хәзинә» кебек үк әһәмиятле урын ала алмый. Моның сәбәбе, минемчә, әсәрдә зур фикер, җитди проблема булмауда. Повесть тормышны гадиләштереп күрсәтә, хезмәт кешеләрен борчыган бик күп мәсьәләләр автор игътибарыннан читтә кала. Повестьның яртысын диярлек институт бетереп кайткан Җәүдәтне каршылау, туйга әзерлек һәм туй ясау эпизодлары тәшкил итә. Әйтерсең, нефтьчеләрнең туй ясап, чәчәк үстерүдән башка эшләре дә юк. Җитмәсә, боларның барысы да эш вакытында эшләнә. Берәү килеп имән кәүсәсенә тимер чөй кагу белән, бөтен бригада диярлек эшен ташлап шунда җыела. Мондый ясалма моментлар әсәрнең кыйммәтен шактый төшерә.

Р. Төхфәтуллин повестеның да төп кимчелеге, минемчә, зур яңа фикер, җитди проблема булмауда. Шуның өчен, күрәсең, автор бу повестенда үз-үзен кабатлый башлаган. Шул ук сугыштан соңгы авыл тормышындагы кыенлыклар, шул ук Ильяс апасының начар кешегә кияүгә чыгып кире әйләнеп кайтуы, шул ук яхшы һәм начар председатель мәсьәләсе. Хәтта повестьның кайбер образларының да (мәсәлән, шофер Гарәфинең, Тәслимәнең, Шәйминең) Р. Төхфәтуллин иҗатында теге яки бу исем астында чагылып киткәннәре бар иде инде. Әсәрдә зур яңа проблема, җитди фикер булмау аның художество кыйммәтен дә төшерә. Һәрхәлдә, «Авылдашым Нәби» һәм «Йолдызым» повестьлары авторыннан без күбрәкне өмет иткән идек...

Һәм киресенчә, язучының янып йөргән үз темасы, халыкка әйтергә теләгән сүзләре булса, андый әсәрнең әдәби кыйммәте дә арта төшә. Нәби Дәүлинең «Җимерелгән бастион» повестенда фашизмга каршы көрәш күрсәтелә, фашизмның кабахәт фәлсәфәсе фаш ителә, совет кешеләренең дошман тылындагы батырлыгы ачыла. Әсәр «Яшәү белән үлем арасында» исемле повесте кебек автобиографик характерда булмаса да, анарда язучының үз башыннан үткәннәре, үз тәҗрибәсе һәм, иң мөһиме, фашизм әшәкелекләренә үз мөнәсәбәте күзгә бәрелеп тора.

Повесть шактый үзенчәлекле язылган. Вакыйга барышында автор сюжетның иң киеренке урыннарында, драма әсәрләрендәгечә, диалогка күчә. Бу чара әсәрдәге киеренкелекне көчәйтүгә, төрле карашларның капма-каршылыгын күрсәтергә, характерларның чын асылын ачарга ярдәм итә. Урыны-урыны белән, автор публицистик алымнардан да баш тартмый. Шулай итеп, драма һәм публицистика алымнары проза әсәрен баеткан, аңа заманча яңгыраш, зур пафос һәм гомумиләштерү көче өстәгән. Дөрес, кайвакыт автор геройлары башкарган эшләрне дәлилләп, аклап бетерми, аерым урыннарда персонажларның сөйләм теле үзенчәлекләрен күрсәтеп бирә алмый. Әсәрдә сай, өстән-өстән генә сөйләп бирелгән вакыйгалар, характерлар логикасына туры килмәгән моментлар да очрый. Ләкин, шуна да карамастан, бу әсәрне, нигездә, уңышлы дип бәяләргә, һәм ул «Яшәү белән үлем арасында» повесте шикелле үк, укучылар арасында популярлык казаныр дип ышанырга мөмкин.

## ХИКӘЯЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Үткән елны хикәяләр дә шактый күп басылды. Уңышлы хикәяләр арасында, Ә. Еники һәм А. Гыйләҗевларның югарыда күрсәтелгән хикәяләреннән тыш, И. Газиның «Гаепсез гаеплеләр», М. Шәрифуллинның «Көн алъяпкыч», Г. Мөхәммәтшинның «Дулкыннар», И. Нуруллинның Тукай турындагы хикәяләрен күрсәтергә мөмкин.

Шунысы куанычлы — үткән елны бу жанрда яшь прозаиклар активлаша төште. «Казан утлары» журналы битләрендә Р. Фәизов, М. Маликова һәм Г. Рәхимнең беренче хикәяләре басылды. Һәм алар, үзләре белән яңа материал һәм образлар гына түгел, сурәтләү чараларында да билгеле дәрәҗәдә яңалык алып килделәр. Үткән елда «Азат хатын» журналында да яшь авторларның матур-матур хикәяләре күренгәләде (мәсәлән, Т. Миңнулинның «Фирдәвес, Нәҗибә һәм мин» хикәясе). Татарстан китап нәшриятында яшь прозаиклар В. Монасыйпов һәм Т. Миңнуллинның беренче хикәяләр җыентыгы басылып чыкты һәм

укучылар тарафыннан җылы каршы алынды.

Шул ук вакытта бездә урта кул, вак темалы, әллә ни зур яңалык алып килми торган хикәяләр дә басылып тора (К. Хәмзиннең «Соңгы сый», Ш. Бикчуринның «Кайту» h. б.).

Соңгы вакытта хикәя жанрында яңача язарга омтылыш сизелә. Ләкин, хикәя үзәгендә зур яңа тема һәм мөһим фикер ятмаса, бернинди алым да хикәяне коткара алмый. «Литературная Россия»дә басылган мәкаләсенә карагында, Ф. Хөсни үзенең «Ике агроном, бер овчарка» хикәясен яңача, барысын да әйтеп бетермичә, «подтекст» ярдәме белән язарга тырышкан. Ләкин хикәянең үзенә килсәк, ул гади бер фактны, өстәвенә, очраклы фактны тасвирлаудан күтәрелә алмаган. Әлбәттә, бу — андый характердагы тәҗрибәләр кирәксез дигән сүз түгел. Киресенчә, хикәя жанры турында безгә авыз тутырып сөйләшергә вакыт.

Газета һәм журналларыбызның әйбәт хикәяләргә мохтаҗлыгын искә алып, безгә, минемчә, хикәя осталыгы турында аерым бер киңәшмә яки дискуссия үткәрергә кирәк. Проза секциясе утырышы булырмы ул, фәнни конференцияме, өлкән язучыларның тәҗрибә уртаклашуымы — һәрхәлдә андый сөйләшү бик кирәк.

■

Йомгак ясап, шуны гына әйтәсем килә: 1965 ел проза өлкәсендә аеруча бай булды. Кызыклы, үзенчәлекле әсәрләр күп. Сөйләшергә, фикер алышырга, бәхәсләшергә нигез бар.

## ФАКТЛАР СӨЙЛИ

I

«Тукай мәрхүмнең «Мәгариф» нәшриятында 500 сумнан артык акчасы калган. Шул акчага бер зирәк баланы мәктәптә тәрбия итегез, дигән васыять әйтеп калдыра», дип яза «Вакыт» газетасы (1913 ел).

1914 елны Казан яшьләре, «Тукай җәмгыяте» исемле мәдәни оешма төземәкче булып, уставын хөкүмәт карамагына кертәләр. Устав ике кат кире кайта, өченче тапкырында «югала».

Казанның бер урамын Тукай исеме белән атау турындагы үтенеч, 1914 елны шәһәр Думасына кертелсә дә, нәтиҗәсез кала.
Ул чагында бу теләкләрнең берсе дә үтәлми.

II

Бөек Октябрь революциясе шагыйрьнең кадерле исемен тиешле пьедесталына мендереп бастырды.
Казанда, Ташкентта, Алма-Атада, Уфада, Уральскида, башка шәһәрләрдә аның исеме белән аталган урамнар бар.

Тукай исеме бирелгән мәктәп, китапханә, клубларны кайда да очратасың.

Татарстанда Тукай исеме белән аталган колхоз булмаган район юк.

Тукай исемендәге филармония, аның җыр-бию ансамбльләрен Казанда һ. б. урыннарда кем белми?!

Казанда Куйбышев урамы бакчасында шагыйрьнең монументаль һәйкәле тора. Муса Җәлил исемендәге опера-балет театры янында икенче һәйкәле. Өченчесе — Тукай-Кырлай авылында. Туган авылы Кушлавычтагы һәйкәлендә: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», дигән сүзләре язылган.

Куйбышев урамындагы монументаль һәйкәл янында шагыйрьнең туган көне — Тукай көне укучы балалар, студентлар, әдип-шагыйрьләр, фән-белем ияләре катнашында һәр елны үтә торган матур җола булып әверелде.

Советлар Союзы халыклары әдәбияты, шулай ук тугандаш социалистик илләрнең әдәбияты арасында Тукай исеме, Тукай әсәрләре кермәгән берәрсе калды микән?!

Кыска гына итеп әйтелгән бу фактлар — ике чор, ике төрле нәтиҗә арасында атмосферик ераклыгында аерма булганын сөйлиләр түгелме?

ИСМӘГЫЙЛЬ РӘМИ.

# «ПЕЧӘН БАЗАРЫ ЯХУТ ЯҢА КИСЕКБАШ» ҺӘМ ХӘМСӘ, НАЗИРӘ ТРАДИЦИЯСЕ

Әдәбият галимнәребезнең күбесе Габдулла Тукайның «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» поэмасын иске «Кисекбаш»ка пародия рәвешендә язылган әсәр дип саныйлар. Ә менә Ф. Әмирхан исә, 1908 елда ук, бу әсәрне: «Иске «Кисекбаш»ка назирә буларак язылмыш көлкедер», дип бәяләгән иде. Р. Ганиеваның Тукай сатирасы турындагы хезмәтендә бу мәсьәлә Ф. Әмирханча яктыртыла. Безнеңчә дә шагыйрьнең бу поэмасын назирә формасында язылган пародия дип атау төгәлрәк булыр шикелле: пародия назирәдән шактый таррак һәм назирә, эчтәлек ягыннан, пародияне дә үзенә сыйдыра ала.

Көнчыгыш әдәбиятын өйрәнүче галимнәр назирәгә түбәндәгечә билгеләмә бирәләр:

«Назирә — үзенә кадәр яисә шул ук заманда язылган берәр шигъри әсәр сюжеты буенча шул ук темага, шул ук ритм, рифма, образлар белән язылган, өлешчә яки тулысынча үзгәртелгән яңа эчтәлекле поэтик әсәр» (А. Стариков. Взаимосвязи литератур Востока и Запада. Сборник.). Димәк, назирә охшатып язылган әдәби әсәр икән. Ләкин мондый әсәрдә һәрвакыт ярышу (көнләшү) элементы булырга тиеш.

Урта гасыр Көнчыгыш халыклары әдәбиятында (Иран, Һиндстан, Төркия, Урта Азия һ. б.) бер үк сюжет, тема, әдәби формалар бик күп атаклы шагыйрьләр иҗатында кабатланып килгәннәр, һәм бу хәл ул чор әдәбияты өчен гадәти, закончалыклы күренеш саналган.

Берничә гасыр буена көнчыгыш шагыйрьләре сюжет һәм формалары ягыннан төрле характерда булган биш поэманы, үзләре яшәгән чорның иҗтимагый таләпләреннән чыгып, яңача кабатлый торган булганнар. Ә кайберләре, өстәп, алтынчы һәм җиденче поэмаларны да язганнар. Хәмсә (пять сокровищ) язу традициясе әзербайҗан шагыйре Низамидан башлана дип йөртәләр. Әмма аңа кадәр дә тулысынча яки өлешчә яңартып кабатлау традициясе яшәп килгән. Соңга таба исә биш поэманы яңача кабатлау әдәби традиция булып киткән, һәм хәмсә язу, үзенчәлекле кагыйдәләре белән, XII—XIX гасырлар аша үткән. Низамидан соң биш поэмадан торган циклны Һиндстан шагыйре Әмир Хөсрәү (1253—1325) үзенчә кабатлый.

Кайбер мәгълүматларга карагаңда, безнең әдәбиятта да тулы хәмсә язучы булган дип уйларга кирәк. Ул — Болгар чоры шагыйре Мәхмүд бине Гали. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, Мәхмүд бине Галинең, «Нәһҗ әл-фәрадис» әсәре белән бергә, «Йосыф китабы», «Башлагали («Кисекбаш»)», «Нәсихәт әс-Салихин», «Бәдәвам», «Нәүрүз бәете» кебек әсәрләр дә язуын әйтә. Монда саналган әсәрләрнең өчесе — «Йосыф китабы», «Башлагали», «Нәсихәт әс-Салихин» — сюжетлары буенча да, тема, проблемалары ягыннан да традицион хәмсә поэмаларына бик якын.

Вакытлар узу белән, хәмсә составындагы берәр аерым поэмага гына ияреп язылган шигъри әсәрләр туа, һәм кемнең кемгә иярүен анык кына билгеләү дә кыенлаша башлый. Шул рәвешчә, «Ләйлә һәм Мәҗнүн», «Хөсрәү һәм Ширин», «Йосыф һәм Зөләйха» кебек поэма-дастаннарның йөзләгән вариантлары барлыкка килә. Бу традиция татар әдәбиятында да бик күптәннән килә. Мәсәлән, Котби, Низамига ияреп, «Хөс-

рәү һәм Ширин» әсәрен, Хисам Кятиб, Аттарга ияреп, «Җөмҗөмә» дастанын иҗат итә.

Еш кына хәмсә составындагы биш поэманың берсе Искәндәргә (Александр Македонскийга) багышлана торган була (Низами, Әмир Хөсрәү, Нәваи һ. б.). Заманына, урынына, иленә карап, бу образга салынган мәгънә гел үзгәрә, алмашына торган. Бер чорда ул «яхшы патша», икенче чорда «яхшы феодал» буларак сурәтләнгән, ә өченче бер чорда — «яхшы полководец». Искәндәр төрки әдәбиятларында Гали батыр («Кисекбаш») булып үзгәрә һәм дин берлеге өчен көрәшүче геройга әйләнә.

Гасырлар буе идеаль герой итеп тасвирланган, гел мактап килгән Искәндәр образына тәнкыйть карашы Абайдан башлана. «Искәндәр» исемле әсәрендә Абай аның комсызлыгын фаш итә, аңа акыллы һәм мәгърифәткә ия Аристотель образын каршы куя. Абай башлаган тәнкыйтьне, атаклы Карахмәте белән, безнең Тукай дәвам итә. Күренекле шагыйребезнең классик поэмасында бу типологик образ чын мәгънәсендә сатирик эчтәлек ала. Габдулла Тукайның «Печән базары яхут яңа Кисекбаш»ы — урта гасыр шагыйрьләренең назирә традициясен безнең чорга алып килгән әсәрләрнең иң уңышлысы. «...Яңа Кисекбаш» Г. Тукайның назирә һәм тәкълид традициясендә язылган бердәнбер әсәре түгел. Тәкълид һәм назирә язу шагыйрь иҗаты өчен гомумән характерлы күренеш. Аның «Сөекләмнең кабер ташына», «Шәкерт яхут бер тәсадеф», «Мөритләр каберстаныннан бер аваз», «Әдәбият ахшамы ясаучыларга» шикелле шигырьләре дә шул ук традицияләрдә иҗат ителгән.

Соңыннан безнең әдәбиятта, Тукайның «Яңа Кисекбаш»ына ияреп, унлап поэма язылды (Г. Камал. Өр-яңа Кисекбаш китабы, 1918 ел; Н. Исәнбәт. Өр-яңа Кисекбаш, 1928 ел; Н. Баян. Карахмәт, 1939 ел; Ш. Мөдәррис. Янки базары яхут яңадан-яңа Кисекбаш, 1953 ел; Ә. Камал. Кисекбаш, 1959 ел; Ә. Исхак. Мещан базары яки киселгән тел, 1965 ел һ. б.).

Тукайның башка әсәрләренә ияреп һәм ошатып язылган әсәрләр дә йөзләрчә. Тик безнең бүгенге әдәбият белемендә һәм әдәби тәнкыйтьтә «ияруләргә» ачык билгеләмә бирелеп, ияручеләргә тиешле таләпләр генә куелганы юк.

Шәмси-Кайса әр-Разиның (XIII гасыр уртасы) иран поэзиясе турындагы хезмәтләрендә назирә әсәрләре турында кызыклы күзәтүләр бар. Аның фикеренчә, әгәр нинди дә булса шагыйрь үзенә кадәр язылган берәр әсәргә ияреп яңа әсәр иҗат итәргә алына икән, аның ул әсәре гади кабатлау дәрәҗәсендә генә калмаска тиеш. Әгәр ияреп язылган әсәр үзенең элгәресеннән көчлерәк, яхшырак түгел икән, андый әсәрнең авторы әдәби карак — плагиатор саналган. Рюккерт-Перчның «Грамматика, поэтика һәм риторика персов» исемле китабында да бу мәсьәләгә карата шундый ук фикер әйтелә. Бу ноктадан караганда, Г. Тукайның «Яңа Кисекбаш»ы белән эш ничегрәк тора соң? Беренчедән, тел-сурәтләү чаралары, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан Г. Тукай поэмасы иске «Кисекбаш»тан күп өстен тора. Икенчедән, иске «Кисекбаш»ка капма-каршы язылган бу поэмада үзенең элгәресендә күренмәгән актуаль мәсьәләләр, яңа фикерләр күтәрелә. Бу соңгысы — аеруча әһәмиятле.

Назирә язуның ачык билгеләнгән кануннары булган. Назирә дип ике әдипнең ярышу процессында иҗат ителгән шигъри әсәрләрен атаганнар, һәм ул шул ук үлчәүдә, рифмада, шул ук тәртиптә язылырга тиеш булган. Билгеле, бүгенге көнгә кадәр ул кануннар шактый үзгәргәннәр, яңарганнар. Безнең фикеребезчә, татар әдәбиятында назирә рамкасына өлешчә т ә к ъ л и д, т а т а б б о (преследование), и с т и к ъ- б а л ь (встреча) һәм җ а- в а п үзенчәлекләре дә үтеп кергән, алар назирә традициясен шактый киңәйткәннәр. Татар шагыйрьләренең Г. Тукай әсәрләренә язган назирәләрендә и с т и к ъ- б а л ь — очрашу, ихтирам белән очрашу элементлары өстенлек итә. Моның ачык мисалы—С. Хәкимнең «Пар ат» поэмасы.

**Иптәшләрем, бәлки,**
**кичерерләр,**
**Читләшсәм дә бераз «Пар**
**ат»тан,**
**«Яшь Апуш»та иртә вафат**
**булган**
**Әниен өзелеп сөйгән,**
**яраткан, —**

бу юлларда шагыйрьнең Тукайга булган зур ихтирамы сизелеп, күренеп тора.

Безнең бүгенге әдәбиятта назирә дип аталырлык әдәби әсәрләр байтак. Ләкин, соңгы кырык ел эчендә назирә терминынын кулланылыштан төшеп калуы аркасында, авторлар тарафыннан төрле «яңа атамалар»

уйлап чыгарыла (мәсәлән: буенча; ...чә үк түгел; дәвамы рәвешендә; ...поэмасы һәм шигырьләре мотивында; ...ганиярепһ. б., һ. б.).[1] Бернинди кагыйдәләргә нигезләнмәгән бу атамалар күп буталчыклар тудыра. «Яңа атамалар» уйлап чыгарырга яратучы шагыйрьләребезнең кайберләре, укучыларның артык төпченеп тормавыннан файдаланып булса кирәк, еш кына күршеләр бакчасына да кереп чыккалыйлар. Һәм бу нәрсә бездә, ни өчендер, зур гаепкә дә саналмый.

**Н. ХАНЗАФАРОВ.**

[1] Г. Тукай буенча (М. Саттаров. Китмибез; Бичара куян, «Чаян» журналы, 1958 ел, 9 сан); А. С. Пушкин буенча рак (М. Саттаров. Алтын балык әкияте. «Чаян» журналы, 1965 ел, 4 сан); С. Хәкимчә үк түгел (Г. Әхмәтгалиева. Диңгез күреп суга сусаган. «Чаян» журналы, 1959 ел).

# ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ПАТША ЦЕНЗУРАСЫ

Ленинград архивларында халык шагыйре Габдулла Тукайның патша цензурасы тарафыннан эзәрлекләнүе турында яңа документлар җыелмасы табылды. Ул — СССР Үзәк дәүләт тарих архивында саклана торган 260 номерлы эш.

«МАТБУГАТ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА БАШ ИДАРӘ КАНЦЕЛЯРИЯСЕНЕҢ III БҮЛЕГЕ ЭШЕ «ГАБДУЛЛА ТУКАЕВ ШИГЫРЬЛӘРЕ. КАЗАН. 1907 ЕЛ. ШӘРӘФ ЭЛЕКТРТИПОГРАФИЯСЕ» ИСЕМЛЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ БРОШЮРА ТУРЫНДА»


№ 260 №

ДѢЛО

Отдѣленія

Канцеляріи Главнаго Управленія

по дѣламъ печати

19 года.

260 номерлы эшнең титул бите.

дип исемләнгән бу «эшкә» барлыгы 8 документ теркәлгән. Алар түбәндәгеләр:

1. 1911 елның 28 ноябрендә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты председателе М. Пинегинның Матбугат эшләре буенча баш идарәгә җибәргән кәгазе;

2. Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының Казан суд палатасы прокурорына җибәргән язуы;


3. «Габдулла Тукай шигырьләре» дигән җыентыкка кергән 6 әсәрнең русчага тәрҗемәсе;

4. Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының 1911 елның 18 декабрендә Матбугат эшләре буенча баш идарәгә җибәргән кәгазе;

5. Матбугат эшләре буенча баш идарәнең 1912 елның 5 апрелендә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетына җибәргән язуы;

6. Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының 1912 елның 10 апрелендә Матбугат эшләре буенча баш идарәгә җибәргән хәбәре;

7. Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының 1912 елның 28 ноябрендә Матбугат эшләре



М. В. Д.
Главное Управленіе по дѣламъ печати.
5 Апрѣля 1912 г.
№ 4417.

Въ Казанскій Временный Комитетъ по дѣламъ печати.

По встрѣтившейся надобности, Главное Управленіе по дѣламъ печати проситъ Казанскій Комитетъ по дѣламъ печати доставить копію съ представленія означеннаго Комитета въ Главное Управленіе отъ 28 Ноября 1911 года за № 1869, по поводу наложенія ареста на брошюру на татарскомъ языкѣ подъ заглавіемъ „Стихотворенія Абдуллы Тукаева".

За Начальника Главнаго Управленія по дѣламъ печати, Членъ Совѣта ...

Исп. об. Правителя Дѣлъ ...

Баш идарәнең Казан вакытлы комитетына җибәргән язуы.

буенча баш идарәгә җибәргән язуы;

8. Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Матбугат эшләре буенча баш идарәнең 1912 елның 20 апрелендә чыгарган циркуляры.

Бу документларның кайберләре белән укучылар таныш инде. Мәсәлән, Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының Казан суд палатасы прокурорына җибәргән язуы һәм «Габдулла Тукай шигырьләре» дигән җыентыкка кергән 6 әсәрнең русчага тәрҗемәләре хакында «Совет әдәбияты» журналының 1940 елгы 7 санында һәм «Красная Татария» газетасының шул ук елгы 11 июльдә чыккан санында да язылган иде.

Хәзер әлеге «эшкә» теркәлгән кайбер документларның кыскача эчтәлегенә тукталып үтик. 1911 елның 28 ноябрендә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты председателе М. Пинегин Баш идарәгә комитет тарафыннан арест салынган өч брошюра турында хәбәр итә. «Ул брошюралар, — дип яза Пинегин, — түбәндәгеләр:

1. «Эшчеләр партиясе нинди партия». Михайлович әсәре (татар теленә тәрҗемә итүчеләр Б. Иөзкаев һәм А. Газыкаев).

2. «Габдулла Тукай шигырьләре» һәм

3. «Төрле, төрле шәп җырлар». «Үрнәк» типографиясе нәшрияты».

Аннары беренче брошюраның русчага тулы тәрҗемәсе һәм соңгы ике җыентыктан зарарлы дип табылган шигырь һәм җырларның тәрҗемәләре җибәрелгәнлеге әйтелә.

Шуннан Казан вакытлы комитетының Казан суд палатасы прокурорына җибәргән язуы теркәлгән. Моныһы тарихи яктан аеруча әһәмиятле. Бу язуда «Габдулла Тукай шигырьләре» дигән җыентыкка кергән әсәрләрдән хөкүмәт өчен зарарлы дип табылган дүрт шигырьгә кыскача характеристика бирелгән.

Патша цензурасы шагыйрьнең «Китмибез» исемле әсәрендә күп кенә җинаятьле фикерләр таба һәм түбәндәге нәтиҗәне ясый: «Иҗтимагый төзелешнең нәкъ менә шул якларын гына күреп, аның бүтән якларына игътибар итмәү ул төзелешкә карата нәфрәт кузгатырга тырышу максатыннан килә. Шунныктан, — диелә язуда, — комитет бу шигырьләрдә җәза бирү турындагы уложениенең 1034 статьясының 3 нче пунктында каралган җинаять билгеләре бар дип таба».

Шагыйрьнең «Хөррият хакында» шигырен цензура турыдан-туры патша строена каршы юнәлтелгән әсәр дип бәяли.

Патша цензурасына Г. Тукайның «Тавыш» хакында» дигән шигыре дә ошамый. «Бу шигырьдә, — ди ул, — эшчеләр сыйныфының авыр тормышы һәм шул тормышны үзгәртү чаралары турында сөйләнә». Эшчеләрне патша хөкүмәтенә каршы көрәшкә чакыру идеясе белән сугарылган булганлыктан, комитет бу шигырьне җинаятьле бер әсәр дип таный.

Комитетның Казан суд палатасы прокурорына җибәргән кәгазендә Г. Тукайның тагын бер шигыре — «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?»е искә алына. Цензура өчен түбәндәге юллар аеруча куркыныч булып күренгән:

Ни хурлыклар,
Ни зилләтләр
Күрмәдек без
Бу милләттән;
Күрми издә
Мескен безне
Күзендә булкан
гыйлләттән.

Шик юк ки, шагыйрь биредә татар халкының самодержавие хөкүмәтеннән, аның милли-колониаль политикасыннан күргән «хурлыклары» турында яза. Шунлыктан, патша цензурасы Тукайның бу шигырен «җинаятьле фикерләрне чагылдыра торган» әсәрләр рәтенә кертә.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып, Казан вакытлы комитеты суд палатасы прокурорыннан түбәндәгеләрне сорый: «Беренчедән, суд карамагына исеме күрсәтелгән җыентыкка арест салу турындагы (мәсьәләне) һәм, икенчедән, җыентыкның авторы Габдулла Тукаевны законда каралган статьялар буенча суд җаваплылыгына тарту турындагы (мәсьәләне) куяргa».

Бу «эш»кә теркәлгән кәгазьләр арасында Г. Тукай җыентыгына кергән 6 шигырьнең русчага тулы тәрҗемәләре бар. Цензура игътибар иткән ул шигырьләр түбәндәгеләр: «Ислахчыларга», «Китмибез», «Иттифак хакында», «Хөррият хакында», «Тавыш» хакында» һәм «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?». Шигырьләрне рус теленә комитет члены Н. Катанов тәрҗемә иткән.

Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитет председателе М. Пинегинның Матбугат эшләре буенча баш идарәгә 1911 елның 18 декабрендә җибәргән икенче кәгазе дә игътибарга лаек. Анда Казан вакытлы комитетының Г. Тукай шигырьләр җыентыгына арест салу турындагы карары белән Казан суд палатасының килешмәве һәм ул карарны расламавы хәбәр ителә. Баш идарә исә, күрәсең, Казан суд палатасы карарыннан бик үк риза булмаган. 1912 елның 5 апрелендә Баш идарә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетына түбәндәге сорау кәгазе җибәрә:

«Кирәкле табылганлыктан, Матбугат эшләре буенча баш идарә Матбугат эшләре буенча Казан комитетыннан Баш идарәгә шул комитетның 1911 елның 28 ноябрендә 1869 номер белән «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле татар телендәге брошюрага арест салу турындагы язуының копиясен җибәрүне сорый».

Казан комитеты бу сорауга ашыгыч рәвештә җавап бирә һәм шул ук җавап кәгазенә теркәп, соралган документларның копиясен җибәрә. Бу документлар, шулай ук, 260 номерлы «эш» папкасына тегелгәннәр.

Югарыда китерелгән архив документларының әһәмияте шунда: алар патша цензурасының Г. Тукайны, беренче нәүбәттә, политик эчтәлекле, революцион рух белән сугарылган шигырьләре өчен, социаль һәм милли изелү астында яшәүче татар хезмәт ияләрен азатлык яулап алырга чакырган шигырьләре өчен эзәрлекләвен ачыктан-ачык күрсәтеп торалар.

Х. ХӘСӘНОВ.

# К. БАСЫЙРОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

*(Тууына 60 ел тулу уңае белән)*

Егерменче еллар ахырында әдәбият мәйданына килеп, шактый кыска вакыт эчендә үзенчәлекле прозаик һәм талантлы тәрҗемәче булып танылган Кәшфи Басыйровның (Басыйров Кәшшаф Хәбир улы) тууына 60 ел тулды.

Кәшфи Басыйров 1906 елның 17 апрелендә Башкортстанның Бәләбәй районы Мәтәү-баш авылында туган. 1940 елның 27 апрелендә язган автобиографиясендә ул: «11 яшьтән 16 га кадәр (1917—1921 еллар) Бәләбәй шәһәрендәге алты еллык рус-татар мәктәбендә укыдым... 16 яшьтән 21 гә кадәр (1922—1927 еллар) Бәләбәй педагогия техникумында укыдым...» ди. Аннан соң Дүртөйледә, Кукмара һәм Казанда укытучы булып эшләвен әйтә. 1934 елның көзеннән алып ул Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият секторында корректор, техредактор, тәрҗемәче булып эшли. 1942 елның 13 январенда армия сафларына алына һәм 1943 елның 16 январенда фашистларга каршы көрәштә һәлак була...



Шушы кыска гына иҗат гомерендә К. Басыйров татар совет әдәбиятына шактый өлеш кертеп калдыра алды. Аның «Сәлимҗан», «Алар онытылмыйлар», «Авылда» исемле беренче хикәяләре 1925 елда «Белем» журналында басылып чыга. 1927 елда «Безнең юл» журналында «Минем сөюем» дигән зур хикәясе басыла. Утызынчы елларда Кәшфи Басыйровның «Ликвидаторлар», «Танышлар», «Секретарь», «Күрше хатыны Саша», «Көзге юллар буйлап» һәм башка хикәяләре «Совет әдәбияты», «Азат хатын» журналларында басыла. Әмма бу әсәрләр, озак еллар буена, хәзерге укучыларга билгесез булып кала килделәр. Бары тик 1958 елда гына К. Басыйров хикәяләре аерым китап булып чыкты. Ул хикәяләрдә коллективлашу еллары вакыйгалары да, хезмәткә социалистик мөнәсәбәт, семья-мәхәббәт мәсьәләләре дә күтәрелә һәм аларның һәркайсында авторның үз геройларына самими-җылы мөнәсәбәте ачык сизелеп тора. Аларда үз чорының сулышы көчле, алар шул чорга хас вакыйгалар һәм күренешләрне җанлы сурәтләүләре белән кыйммәтле.

Билгеле булганча, 30 елларның икенче яртысында безнең әдәбиятта да темаларның ваклануы, заманның катлаулы мәсьәләләреннән читкә китү һәм әһәмиятсез вакыйгаларга зуррак игътибар бирү күренешләре булып алды. Ләкин ни генә булмасын, бу еллардагы татар әдәбиятында да үзәк һәм хәлиткеч урынны геройларның рухи тормышына тирән үтеп кергән, совет кешеләренең патриотизмын, социализм төзү өчен көрәшүчеләрне сурәтләгән әсәрләр алып торды. Совет әдәбиятының алдынгы, уңай геройларының характер көчен билгеләүдә аларның хезмәткә һәм чынбарлыкка актив мөнәсәбәте төп үлчәү иде. Тормышка, кешеләргә, хезмәткә актив мөнәсәбәт, илдәге бөтен вакыйгалар өчен үзенне җаваплы итеп тою, чын хуҗа булу хисе — болар барысы да утызынчы еллар әдәбиятындагы уңай геройларның төп сыйфатларын билгеләделәр.

Бу сыйфатлар К. Басыйровның да күпчелек хикәяләре өчен хас иде. «Көзге юллар буйлап» дигән хикәяне генә алыйк. Бу хикәядә сурәтләнгән врач Бану табигыйлеге, тормышка актив мөнәсәбәте, кешеләргә чын күңелдән яхшылык эшләргә омтылуы белән укучыны үзенә тарта. Нәкъ менә активлыгы һәм оптимизмы, күркәмлеге һәм кешелеклелеге, тагын да дөресрәге — сәнгатьчә ышандыручанлык көче белән, Бану образы бу чордагы татар әдәбиятында сурәтләнгән башка хатын-кызлар образлары арасында үзенә лаеклы урын алырга хаклы. З. Мансур бик дөрес билгеләгәнчә, үз эшенә бик таләпчән бу язучы иҗатында иң характерлы момент — «туып килә торган яңа кеше образын чагылдыру» иде.

К. Басыйров тәрҗемә өлкәсендә аеруча күп эшләде. Ул тәрҗемә итеп чыгарган әсәрләр арасында — М. Ю. Лермонтовның «Безнең заман герое», Н. В. Гогольнең «Үле җаннар»ы, К. Паустовскийның «Колхида»сы, прогрессив немец язучысы В. Бредельнең «Сыналу»ы (Г. Хәбиб белән бергә тәрҗемә иткән), В. Дуровның «Минем җәнлекләрем» дигән китабы, В. Г. Короленко, А. П. Чехов, Ю. Либединский, башка язучыларның күп кенә хикәяләре бар. Бу әсәрләрнең барысы да татар теленә беренче тапкыр К. Басыйров тарафыннан тәрҗемә ителгәннәр һәм хәзер дә тәрҗемә сәнгатенең матур үрнәкләреннән саналалар. Менә шуның өчен дә С. Фәйзуллин: «К. Басыйр тәрҗемәләренең төп кыйммәте шунда — аларны укыганда азапланмыйча, ватылмыйча, матур оригинал укыгандай ләззәт белән укыйсың», — дип язуы белән бик хаклы.

Ләкин татар әдәбиятында хикәя жанрын үстерүгә шактый көч куйган һәм тәрҗемә сәнгатен күтәрү өлкәсендә дә зур хезмәт күрсәткән К. Басыйровның иҗат мирасы әлегә кадәр өйрәнелмәгән килеш ята. Бүгенге укучылар аның югарыда телгә алынган «Танышлар» исемле китабын һәм бу китапка А. Яхинның рецензиясен, китапның авторы турында С. Фәйзуллин белән З. Мансур мәкаләләрен генә беләләр. К. Басыйровның иҗат мирасы безнең әдәбият тарихында үзенә лаеклы урынны алырга тиеш. Әйтергә кирәк, хәзер инде моның өчен кайбер мөмкинлекләр дә бар. Күптән түгел генә язучының тормыш иптәше Җинан ханым Фәттахова К. Басыйровның шәхси архивында сакланган кайбер әсәрләрен СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының кульязмалар фондына тапшырды. Болар арасында К. Басыйровның әлегә кадәр беркайда да басылмаган «Укытучы» исемле зур күләмле повесте, төрле еллардагы хатлары, журналларда һәм әдәби җыентыкларда чыккан әсәрләренең кульязмалары һәм беренче басмалары, мәрхүмнең үз кулы белән язган автобиографиясе, көндәлек язмаларыннан өзекләр бар. Болар киләчәктә К. Басыйровның мирасын тулырак чыгарырга ярдәм итәчәкләр.

...Әйе, яшьли һәлак булган талантлы язучы һәм тәрҗемәче Кәшфи Басыйровка хәзер 60 яшь тулыр иде. Ул күп әсәрләр тудырган булыр иде. Ләкин кыска гына гомерендә иҗат иткән әсәрләре белән дә ул безнең белән бер сафта. Бүген без аны зур хөрмәт белән искә алабыз.

*НУР ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.*

## Беренче укыган шагыйрем

*Башкорт язучысы Б. Бикбай «Тере чишмәләр» исемле автобиографик повесть өстендә эшли. Укучыларга әнә шул повестьтан Г. Тукайга багышланган бер өзек тәкъдим итәбез.*

...Безнең авылда мәктәп юк иде. Азмаз укый-яза белә башлагач, мине татар Морапталы мәктәбенә бирделәр. Билгеле, укымышлы гаиләдән чыккан малай булганлыктан, хәлфәгә: «Ите сиңа, сөяге миңа», дип әйтеп торучы булмады. Мин авылның алдынгырак саналган икенче мәхәллә мәктәбенә туры килдем. Бирерә безгә, яңа укырга төшкән малайларга, сабакны: «Арба бата, ат тарта. Балык башы, балта сабы...» дип укыттылар. Ә югарырак сыйныф малайлары хисап, география, тарих дәресләре дә үтә иде. Ул малайлар миңа зур галимнәрдер инде кебек тоелды. Икенче мәхәлләдә — таш мәчет мәктәбендә — эшләр алай түгел икән. Безнең зуррак шәкертләр аларның мәдрәсәсе турында менә болай дип көлә иде:

«Чәйниләр монда жирәнгеч әллә нинди мөһмәлат,
Яшь гомерләр мөһмәлат чәйнәп була монда һәлак.
Кайсысы «кәптеркү», ди, һәм кайсысы «каптырку», ди;
Чорт ява знат нәрсә, ди, «синтерсү», ди, «саттырсу», ди.
Кыш көне шул мөһмәлатне ач төя төсле күшәп,
Яз көне туктый күшәүдән һәр күсәк углы күсәк.
Астына мендәр өйгән — күрдем түрендә хәлфәсен,
Ул кырын салган, начар, очлы вә кыршылган фәсен.
Килбәте булгач кабахәт, уйладым — иблистер ул;
Бу сасы ис, кем белә, шуннан чәчелгән истер ул».

Соңыннан белдем, бу — Габдулла Тукайның «Авыл мәдрәсәсе» һәм минем иң беренче ишеткән шигырем булган икән. Шулай ук зур малайлар, тәнәфес араларында, Тукайны:

«Күп яттык без Мәдрәсәдә,
Анламадык Бернәрсә дә;
Селкенмәдек
Таш төсле без,
Жилбер-жилбер
Жил бәрсә дә...» —

дип, махсус бер көй белән, күмәкләп такмаклый торганнар иде.

Мине Шәмсетдин исемле бер агайга, дегет сатучыга, фатирга куйдылар. Аның Гайнетдин дигән улы бар. Икебез дә бер чамарак яшьтәге малайларбыз. Тиз иләшеп киттек. Ул мине, башка малайлар кебек, «башкорт» дип читләми.

Без бер көнне, букчаларыбызны ниндидер китаплар белән тутырып, иртүк мәктәпкә киттек.

Мәктәп яңадан салынса да, парта дигән нәрсә юк иде. Безне рәтләргә тезелгән бер катлы шүрлекләр кебек өстәлләр артына, идәнгә утырттылар. Уңайсызланмадык.

Барлык сыйныфлар да зур гына ике бүлмәгә сыйган. Бар сыйныфлар да кычкырып укыйлар. Тавыш гөжләп тора, хәтта колак чыңлый. Иркенлеккә, ялан тынлыгына иләшкән малайга, миңа, бәлки, гүләп утырган телеграф баганасына бәйләп куелган сыман тоелгандыр. Шулай да кыерсыну озакка сузылмады, үзем килеп кергән бу сәер яңалыкка күнектем, укулар жайлана төшкәндәй булып китте. Бу, бәлки, кечкенәдән китаплар күреп үскәнем өчен шулай булгандыр, ә менә Гайнетдин шактый жәфа чикте. Аеруча, яттан бикләргә биргән шигырьләрне авыр үзләштерде ул.

Ярлы гына көн итсә дә, Шәмсетдин агай тормышка чат ябышып яткан бер кеше иде. Ул, һәр нәрсәдән файда күрергә яратучы, безнең укуларыбыз барышы белән дә кызыксынмый калмый иде. Кичләрен, аштан соң, агай тыңлатып карый, янәсе, бу малайлар юкка гына көн уздырып, чабата туздырып йөрмиләрме? Тыңлаткан чакта Гайнетдин, күбесенчә, ык-мык абынып кала, ә мин ятлаган шигырьләремне чак ишетелерлек тавыш белән сөйли башлыйм.

— Кычкырыбрак сөйлә, ишетмим, — ди агай.

Мин кычкырыбрак яңадан тотынам:

**«Әйт әле, Күбәләк,**
**Сөйләшик бергәләп;**
**Бу кадәр күп очып,**
**Армыйсың син ничек?»**

Көн саен кабатлана мондый сынаулар. Без «Ак бабай», «Иртә», «Карлыгач», «Ата белән бала» һәм башка шигырьләрне яттан сөйләп чыгабыз. Шунысы гаҗәп — ул шигырьләрнең күбесе әле дә хәтердә калган. Шәмсетдин агай хезмәткә, намуслылыкка өндәгән бу мәгънәле шигырьләрне, начар сөйләвебезгә карамастан, башын басып, бирелеп тыңлап утыра. Хәтта ул безне тыңламыйдыр да, йокыга талгандыр кебек тоела башлый. Сөйләүләр беткәч, башын күтәрә дә, моңсу күзләрен тутырып карап, үз-үзенә сөйләнгән шикелле, күкрәк тавышы белән:

— Яхшы, бик яхшы. Дөрес әйткән безнең Габдулла... Афарин, Баязитдин, откыр бала икәнсең. Бәлки, үскәч, син дә Тукай кебек булырсың әле... Ә менә минем Гайнетдин шул дегетче малае булып калудан уза алмас инде... — ди.

Картның мактавы мине уңайсызландыра. Әтән генә кинәнсәм дә, Гайнетдинне кимсетүе өчен кыенсынам. Эх, чыннан да шагыйрь булсаң иде! Балалык хыялы нинди дә киң канатлы, ә? Нигә мондый ярсулы ашкыну тойгылары кешедә гомер буена сакланмый икән?..

Габдулла Тукайның күпләргә таныш бер рәсеме бар. Әле каты чирли башлаганчы алдырган рәсемедер. Ул — тулы битле, чәче житек, түбә өстендә генә кара түбәтәй, ак якалы изүеннән эре шакмаклы галстугы пиджак тышына чыгып тора. Аның маңгае киң, күзләре ачык һәм мөлаем. Мин еш кына китап битен ачам да шул рәсемгә озак төбәлеп карап торам. Кайчакта, алдыма кечкенә көзге куеп, башыма Гайнетдиннең түбәтәен киеп алам да әле суратка, әле көзгедәге үз сыныма карап утырам. Кызык. Төстә дә безнең ниндидер уртаклыгыбыз бар кебек... Чыннан да бар бугай: аның сул күзе кечерәк, борыны туры, колаклары зур. Минем дә шулай түгелме соң? Эчемдә ниндидер шайтан: «Әйе», дип куя. Бәлки, бөтенләй охшашлыгыбыз да юктыр әле. Аның үлгәненә дүрт ел, ә мин — сигез яшьлек кенә малай. Чик белмәс балалык хыялым гына безне шулай ясый торгандыр... Кыскасы, шул чактан ук беренче укыган һәм гомергә яраткан шагыйрем булып калды бөек Тукай. Әгәр ул вакытсыз үлмәсә, гәрчә хәзерге минем яшемә генә дөньяда торса да, нинди гаҗәеп шигъри могҗизалар күрсәтер иде!.. Болай да мин аңа бик күп бурычлы. Хәер, мин генәмени, яшь башкорт совет әдәбияты да аның исеме алдында хөрмәт белән баш ия. Без, башкорт язучыларыннан бер төркем, 1961 елда шагыйрьнең туган авылында булып, аның йорт-музеен карадык. Шунда мин музейның истәлекләр кенәгәсенә: «Әгәр бөек Габдулла Тукай булмаса, бәлки, кечкенә мин дә булмас идем!» дип язып калдырдым. Бу юкка гына түгел, әлбәттә. Бу сүзләрдә чын йөрәк рәхмәте дә, бөек шагыйрь белән горурлану тойгысы да ята.

**БАЯЗИТ БИКБАЙ.**

# Ул минем туган абыем кебек иде

**И туган тел, и матур тел,**
**Әткәм-әнкәмнең теле!**
**Дөньяда күп нәрсә белдем.**
**Син туган тел аркылы.**

Әле генә телем ачылып килгән чагымнан көйләп йөргән көем бу минем. Әтием-әнием әйтүе буенча, өч яшемдә үк, бәйрәм көннәрендә хатын-кызлар җыелышып, шул көйгә мине җырлата торган булганнар.

Сигез яшемә житкәч, Габдулла абыйның күп шигырьләрен сәхнәгә менеп

жырлаганнарымны үзем дә яхшы хәтерлим. Бу бик табигый да, чөнки Габдулла абый минем әтием мәдрәсәсендә күп еллар укыган. Аннары, татар культурасы тарихында беренче буларак, газета-журналлар да безнең йортта чыга башлаганнар, һәм бу эшне башлап җибәрүчеләр минем бертуган абыем Камил белән халык шагыйре Габдулла Тукай булганнар. Тукай шул газета-журналлар аша шагыйрь булып халыкка танылган.

Бу исемнәрнең икесе дә безнең өчен Габдулла яки Камил түгел, бары тик абый гына иде.

Габдулла абый безнең өйдә үзен бик иркен тоткан. Җырлаган да ул, биегән дә безнең өйдә. Ә минем абыйларым җырны, биюне, кыскача әйткәндә, артистлык эшен бик ярата торган булганнар.

Һәркөн диярлек безнең өйдә әдәбият һәм сәнгать кичәләре үткәрелә торган булган. Ул кичәләргә Габдулла абый да еш катнашкан. Габдулла Тукайның һәр яңа шигырен һәм мәкаләсен без, иң беренче кешеләр булып, тыңлаганбыз, укыганбыз, көйгә салып җырлаганбыз.

1907 елның көзендә Габдулла абый Казанга китә, ә Камил абый ул елларны Россиянең төрле шәһәрләрендә концертлар биреп йөри.

Габдулла абыйны мин үзем хәтерләмим — бик нәни булганмын. Шулай да үз-үземне белә башлаганнан бирле аның исемен еш ишеткәнгә, аның турында семьяда һәр көн сүз булганга, аның шигырьләре өзлексез укылып торганга, мин Тукай абый белән даими сөйләшеп, киңәшеп үскән кебек тоям үземне.

Беркөнне Камил абый белән Габдулла абый рус җырчысы Таиса концертын тыңлап кайтканнар икән дә, шуннан соң: «Бу нәни кызның тавышы бик матур, җырчы булыр ул», дип, Габдулла абый миңа Таиса исеме таккан. Таиса исеме, үсеп буйга җиткәнче, гел миңа ияреп йөрде. Шул кушаматым белән 1923 елда Казанга килдем. Театр техникумына укырга кергәндә дә, шул исемем белән дәшәләр иде әле. Бергә укучы студентлар «Тая-Мая» дип шаярта башлагач, мин аларга чын исемемне әйтергә куша идем. Казанга укырга килгәч, Габдулла абыйның кабренә барып елаганым хәтердә. Шул чакта нәни вакытта булган күп кенә вакыйгалар күз алдына килеп бастылар.

Дәү әниебез безне, бала-чагаларны, үз янына җыеп, аның шигырьләрен, хикәяләрен безгә сөйли торган иде. Ә без ул сөйләгән «Су анасы», «Таз», «Шүрәле» кебек әсәрләрне бик тиз ятлап ала идек.

1913 елны миңа сигезенче яшь иде. Беркөн шулай әтием бүлмәсенә керсәм (бу бүлмә заманында Габдулла абый эшли торган бүлмә булган), аның күзләрендә яшь бөртекләре күреп, гаҗәпләнеп калдым. Мин элек бер дә әтиемнең елаганын күргәнем юк иде.

— Әтием нигә елыйсың? — дип сорадым да, җавап та көтмәстән, аңа кушылып үзем дә елап җибәрдем.

— Елама кызым, үзең соң нигә елыйсың? — диде әтием.

— Син елаганга елыйм, — дидем мин.

— Казаннан зур кайгылы хәбәр килде. Габдулла абыегыз үлгән, — диде әтием һәм кульъяулыгы чыгарып күзләрен сөртеп алды.

Безнең семья өчен чын-чынлап зур кайгы иде Габдулла абыйның үлеме. Әнием белән җиңгәм Габдулла абыйны күмәргә Казанга киттеләр. Бик табигый, мин, кечкенәлегем аркасында, бу зур кайгыны аңлап җиткермәдем.

— Әтием! Габдулла абыйны Казаннан алып кайтырлармы? Мин аның шигырьләрен үзенә укып күрсәтер идем, — дип сөйләнгәнем хәтердә.

Аннары тагын шунысы да истә: мич капкачын ачып, самовар морҗасы аша: «Гариф абый! Габдулла абыйны Казаннан алып кайт!» дип, сузып-сузып кычкыра идем. Янәсе, тавыш төтен белән еракка китә дә, Габдулла абыйлар ишетеп, Җаекка кайталар. Авыз-борыннарым корымга буялганын күреп, беркөнне туганым апа «тагы кычкырган бу» дип үземне орышты...

...Кабер калкулыгын чәчәкләр белән бизи-бизи, аның шигырьләрен акрын тавыш белән көйли-көйли, Габдулла абый янында озак утырдым мин ул көнне...

* * *

Әнием сөйләве буенча, Габдулла абыйның безнең семья белән аралаша башлавы шулай булган:

Әтием Кече Кайбыч авылында туган. Ул кечкенәдән үк ятим калган, кардәш-белешләре кулында бер өйдән, бер өйгә күчеп үскән.

Бабамны авыл халкы бик үз итә торган булган. Шуңа күрә минем әтиемә дә җәбер-золым күрсәтмәгәннәр, үзара акча җыеп укытканнар.

Үзе шулай ятим үскәнгә, әтием дә һәр ятимне, һәр кимсетелгәнне якын күрә, андыйларга кулыннан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыша иде. Урамда берәр алжыган картны, дәрвиш кешене күрсә, аны үзенә китереп ашата, эчертә һәм мөмкин кадәрле кием-салымын да биреп чыгара торган иде.

Көннәрдән бер көнне әтием, кулыннан житәкләп, өйгә бер яшь бала алып керә. Баланың кутырланган кулларына, таланып беткән аяк киемнәренә, ертык чалбарына, бигрәк тә аның акыллы соры күзләренә күзе төшкәч, әнием дә баланы якты чырай белән каршы ала. Баланы әле генә өлгергән мунчага кертеп юындыра. Әтиемнең иске булса да бер әчке күлмәк-ыштанын әмәллләп киертә, чалбарын ямап бирә. Баланың кулындагы кутырларына да май сөртә.

Менә шул көннән алып кечкенә Апуш көн саен безгә килә торган булып китә. Килергә сәбәп һәрвакытта табылып торган: я әтиемнең китапларына кем туган, кем өйләнгәнен язарга кирәк, я мәдрәсәдә биргән сабакларга өстәп төрле дәресләр укырга кирәк һ. б. лар, һ. б. лар.

Тукайның атасы Гариф мулла әтием Кышкарда укыган вакытта аның сабакташы булган. Әтиемнең Габдулланы якын итүендә моның да роле булгандыр, әлбәттә. Ул дәрес вакытларында Габдулла абыйны хәтта үз янына утырта торган булган...

* * *

1957 елда Кушлавыч авылында сөекле шагыйребезгә һәйкәл куелды. Һәйкәл ачылган көндә мине дә кунак итеп шунда чакырдылар. Анда мин Габдулла абыйга багышлап язган шигыремне укыдым. Менә ул шигырьдән бер өзек:

**Халкым сөйде үз шагыйре итеп,**
**Онытa алмый сине Уралың.**
**Ятим иттең, Тукай, бик яшь китеп,**
**Ләкин калды илдә җырларың.**

Галия **КАЙБИЦКАЯ**,
Татарстанның халык артисткасы.

# Тукай һәм Сәйдәш

Тукай һәм Сәйдәш, Сәйдәш һәм Тукай. Бу ике олы кешебезнең исемнәре культурабыз тарихында янәшә торалар. Халкыбыз бу ике зур талант иясен бердәй хөрмәт белән искә ала. Бу бик табигый да. Икесенең дә иҗат чыганагы уртак — халык тормышы, халык күңеле, халык моңы, халык омтылышлары. Алар икесе дә халыкның үз уллары иде. Аннары шунысы да: Сәйдәш музыкасының, көйләренең тирән халыкчанлык рухы белән сугарылган булуларында, бәлки, Тукайның турыдан-туры йогынтысы да булгандыр. Чөнки алар бер-берсен күреп тә беләләр иде. Яшьләрендә булган зур аермага карамастан (бу вакыт Салихка 12, Тукайга 26 яшь), бер-берсен бик хөрмәт итәләр иде. Тик бу дуслык мөнәсәбәтенең тагы да үсүенә шагыйрьнең вакытсыз вафат булуы мөмкинлек бирмәде.

Шулай да кыска гына вакыт эчендә алар берничә тапкыр очрашып, бер-берсенә мөнәсәбәтләрен белдерә алдылар. Башлап танышу һәм аннан соңгы очрашулар бездә — минем өемдә булды. Чөнки Салих, минем семья членнарының берсе булып, минем тәрбиямдә яши торган бала иде. Ә Тукай белән без күп еллар «Болгар» номерларында бер коридорда, янәшә бүлмәдә торып, шактый үзләшеп беткән идек инде. Без бер-беребезгә, ишек кагып, рөхсәт сорап тормыйча, кереп-чыгып йөри идек. Җәй көннәрендә бакчаларга, су керергә бергәләп бара идек. Хәтта «Болгар»-ның өске катындагы кечкенә залда ашапэчүебез дә күп вакыт бергә иде.

Тукай белән булган безнең бу дуслык мөнәсәбәте мин өйләнеп, аерым квартирада тора башлагач та дәвам итте. Ул һәр көн диярлек миңа килә, мин дә еш кына аңа бара идем.

Шагыйрьнең безнең квартирага беренче килүендә үк, мин Салихны:

— Менә бу кеше син яттан белә торган «Туган тел», «Шаян песи», «Алтын тарак» шигырьләрен уйлап чыгарып язган Габдулла Тукай абыең була инде, — дип, аның белән таныштырдым.

Тукай белән танышуына Салих бик сөенде, аның шигырьләрен тагын да тырышыбрак укый, өйрәнә башлады. Башта аның белән бик оялып кына сөйләшкән булса да, соңрак аңа иялэште. Хәтта:

— Габдулла абый, тагын нинди яңа шигырь яздыгыз? — дип сораша ук башлады.

Тукай Салихка бала итеп кенә карамый, аның белән кул биреп күрешә, янына утырып көлке-мәзәк сүзләр сөйли иде. Аннары рояль янына килә дә:

— Яле, егетем, үзең тагын нинди көйләр үзләштердең, уйнап җибәр әле, — дип, Салихны чакыра торган иде. Салих та кыстатып тормый, янарак өйрәнгән көйләрен уйнап җибәрә, ә Тукай үзенә ошаган көйләрне кат-кат уйната, кайчакларда аңа кушылып эчтән генә көйли иде.

Минем шул аеруча истә калган: вакыт-вакыт Габдулла үзе дә Салих янында балаларча булып китә, бала-чага уеннары турында сораштыра башлый, аның белән уйнарга ук керешә иде.

— Кузна уйный беләсеңме? — дип сорый Габдулла.

— Белмичә ни, беләм.

— Кузналарың күпме, сагаң төз сугамы?

— Сага бит, Тукай абый, кулың төз бәрсә генә төз суга, төз бәрмәсәң, читкә оча...

Тукай бу сүзләрдән соң бер көлеп ала да кинәт җитдиләнеп китә.

— Юк, Салих энем, читкә оча дип оттырырга ярамый, төз бәрергә тырыш син. Кузнадан да бигрәк менә бу телләргә төз бәр,— ди ул аннары, рояль клавишларына күрсәтеп...

Тукай һәм Сәйдәш шул вакытта ук ниндидер күзгә күренми торган җепләр белән бер-берсенә бәйләнгән булганнардыр кебек тоела миңа.

**Шиһап ӘХМЕРОВ,**
*пенсионер.*

# Минһаҗ кем иде?..

Озак еллар буена мин Казанда укытучы булып эшләдем. Мин укыта торган мәктәп Яңа бистәдә, Фатих Әмирхан яшәгән йорттан ерак түгел иде. Без аның белән еш кына очраша, сөйләшә торган идек.

Шундый очрашуларның берсендә Фатих Әмирхан миңа «Болгар» номерына, Тукай янына кереп чыгарга кушты. Тукай Хвалынск, Кулатки мишәрләре тормышы белән кызыксынган да Фатих Әмирхан аңа минем Хвалынск мишәре икәнлегемне әйткән икән.

Рөхсәт сорап, Тукай торган бүлмәгә кердем.

— Сез чакырган Хвалын мишәре мин булам, — дидем.

— Мишәр, ишепме ишәр, — дип шаяртып, Тукай миңа кул бирде.

Бүлмәсе зур түгел иде, көньякка караган бер тәрәзә, кечерәк кенә бер өстәл, өч урындык, гади генә бер кровать. Шагыйрь бүлмәсендә бар булган җиһаз шул иде.

Тукай миңа урын тәкъдим итте дә:

— Укытулар беткәч, Хвалынга кайтып килмисеңме соң? — дип сорады. — «Галия» мәктәбен салырга һинди Минһаҗның Хвалын тавы башына күпме таш ташытканын белеп кил әле.

Аннары бераз дәшми торды да өстәп куйды:

— Әллә кайларга канат җәйгән Баһави, Габделмән ишаннар кебек ишәкләр турында да белеп килергә онытма, — диде.

Тукай кызыксынган Минһаҗ Кулатки янындагы Яңа Зимница авылында торучы ишан малае булып, ул үзе дә ишан булырга әзерләнә иде. Минһаҗ: «Мәктәп салдырам», дип, халыкны алдап, акча җыя. Ләкин мәктәп салдырмый, әллә ничә йөк таш ташыту белән генә чикләнә. Мәктәп салдыру урынына, Казан миллионеры Апанаевлар кызына өйләнә дә, Кабан күле аръягына зур таш өйләр салдыра.

Мин авылга кайтып килгәч, Минһаҗ турында ишеткәннәремне Тукайга сөйләдем. Озак та үтмәде, Минһаҗ турында Тукайның шигыре чыкты:

**«Таш ташыйлар: анда Минһаҗ «Галия»**
**нигезен сала.**
**Туй ясыйлар: монда Минһаҗ гаилә нигезен**
**сала.**
**Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр**
**соңгысы;**
**Шикләнәм мин, әллә ник, булмас кеби**
**әүвәлгесе».**

Урта Терешка авылы ишаны Габделмән дә читтә калмады. Аның комсызлыгы турында Тукай:

**«Безнең ишан Габделмән,**
**Ашыйдыр ул мең пилмән», —**

дип такмак чыгарды.

**Заман БИКБАЕВ,**
*карт коммунист, персональ пенсионер.*




Театр сәнгате турында сөйләшәбез

# ТАМАШАЧЫ СҮЗЕ

Театр миңа кече яшьтән үк бик якын. Һич онытасым юк. Бөек Ватан сугышы алдыннан, туган-үскән авылым Каенлыкта (Буа районы) республика күчмә театры М. Әблиевның «Шәмсекамәр» пьесасын күрсәтте. Зал халык белән шыгырым тулы. Без бала-чаганы клубка кертмиләр. Әтәләнеп йөри торгач, җае чыкты. Безне динамо әйләндерергә залга керттеләр. (Ул вакытта сәхнә кул динамосы белән яктыртыла иде). Шулай итеп, маңгайдан аккан тирне сөртә-сөртә, мин беренче мәртәбә профессиональ спектакль карадым. Иртәгесен артистларны күрше авылга илтергә олаучы кирәк булгач та, чәчрәп мин чыктым. Сикелтәле чана юлларыннан артистлар белән сөйләшә-сөйләшә баруы да минем балачагымның иң матур истәлеге булып хәтергә сеңеп калган.

Ул көннәрдән алып халыкның театр сәнгатенә булган мәхәббәте никадәр үсте! Без артистларны күтәреп алабыз, аларның уены уңышлы булса, чиксез сөенәбез, ниндидер сәбәп белән уңышсыз чыкса, көенәбез.

Тамашачы буларак та, дөресрәге, «болельщик» буларак та, «Казан утлары» журналының 1965 ел 11 санында басылган И. Иляллованың «Заман һәм театр» исемле дискуссион мәкаләсе минем театр сәнгатенә һәм драматургиягә карата күптәннән җыелып килгән фикерләремне кузгатып җибәрде. Минем карашымча, татар театрында элек-электән ике линия яшәп килде. Беренчесе, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ш. Камал линиясе. Бу линиядә реалистик алым белән язылган әсәрләр иде һәм аларда музыка-җыр бөтенләй юк диярлек. Икенчесе, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш линиясе. Бу линиягә кергән әсәрләрдә җыр-музыка зур урын алды. Шунысы характерлы, мондый спектакльләр тамашачыда аеруча зур уңыш казанды.

Татар опера театры барлыкка килгәнче булган чорда мондый музыкаль драма әсәрләренең уңышы бик аңлашыла да.

Әйтәсе килгән фикер шул: драма театры, заман таләпләре үзгәрүгә карамастан, һаман да шушы элекке уңышны кулыннан ычкындырмаска тырыша. Ләкин, турыдан-туры әйтергә кирәк, ул уңыш инде ычкынды. Моның беренче сәбәбе, минемчә, заман таләбе үзгәрү булса, икенчедән, театрда хәзер С. Айдаров кебек оста артист та булган җырчылар юк. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә. Мәшһүр җырчы һәм сәхнә остасы С. Айдаровның «Галиябану»дагы Хәлилен, «Зәңгәр шәл»дәге Булатын, «Таһир-Зөһрә»дәге Таһирын, «Наемщикта»гы Батырҗанын тамашачылар әле дә сагыналар. Аңа партнер булып уйнаган Галия Кайбицкаяның Галиябануын, Мәйсәрәсен, Зөһрәсен, Гөлйөземен дә халкыбыз оныта алмый.

Татар дәүләт академия театрында хәзер мондый музыкаль геройларны уйнаучы оста артист та булган җырчылар юк. Шуңа күрә хәзер театр музыкаль геройларны уйнау өчен җырчыларны татар опера театрыннан чакыра. Инде төп җырчы көчләр опера театрында икән, минемчә, мондый музыкаль әсәрләрне оперетта жанрына күчереп, опера театрында кую кызыклы булыр иде һәм бу юнәлештә эш алып барырга бик кирәктер.

Музыкаль драма әсәрләрен оперетта жанрына күчерү турында сүз бара икән, кайбер драматургларның һаман да драма әсәрләренә чамадан тыш җыр-музыка кертүләре һич тә аңлашылмый. Шундыйлардан Хәй Вахитның һәм Аяз Гыйләҗевның пьесаларын күрсәтергә була. Хәтта бу авторлар пьесаларның исемен дә җырдан алып куялар. («Көзге ачы җилләрдә», «Кайда соң син»). Шунысын да әйтергә кирәк, пьеса «Көзге ачы җилләрдә» дип аталгач, тамашачы анда шул җыр туган революция елларындагы вакыйгаларны карарга килә. Ләкин исеме җисеменә туры килмәгән спектакльне карап, тамашачы алдана.

Ильтани Илялова мәкаләсендә бүгенге драматургия белән канәгатьләнү сизелә. Ул бөтен гаепне театр өстенә генә аударырга тырыша. Минем бу караш белән килешәсем килми. Чөнки аның тарафыннан саналып кителгән «Ай тотылган төндә» борынгы заманнарны, «Һиҗрәт» 20 елларны чагылдыра, хәтта «Бертуган Таһировлар», «Карлыгач канат кага» әсәрләре дә 50 елларда гына типик булган вакыйгаларны чагылдыра. Мәкаләдә заман һәм театр мәсьәләсе күтәрелгән икән, ул вакытта кайда соң бүгенге көннең чын сулышын чагылдырган тулы канлы әсәрләр?

Миңа шәһәр һәм авыл тормышын чагылдырган драма әсәрләрен байтак карарга туры килде. Ләкин алар бүгенге тормышны тулы чагылдырмыйлар, тамашачыда эз калдырмыйлар. Шуна күрә алар кыска гомерле булалар. Драматурглар тамашачылар алдында һаман да зур бурычлы булып калалар.

И. Илялова үзенең мәкаләсендә театрның бүгенге авыр хәлдә калуын баш режиссер булмауга кайтарып калдыра. Баш режиссер ни өчен юк соң? Ул моңа җавап бирми. Минемчә, баш режиссерны булдыруда таякның юан башы Культура министрлыгына һәм театр дирекциясенә төшә. Мин гел күзәтеп барам, бу турыда сүз еллар буе бара, ә эш сүздән ары киткәне юк. Бәлки баш режиссерның читтән килгәнен көтмәскә, ә кыю рәвештә яшь көчләрне күтәрергә кирәктер. Матур-матур спектакльләр куйган Празат Исәнбәт, Рәфкать Бикчәнтәев кебек яшь талантлар бу авыр йөкне тарта алырлар иде.

Аннары, артистларның тамашачылар белән элемтәсе дә һич җитәрлек түгел әле. Артистлар тамашачылар белән еш очрашсалар, тамашачыларның фикерләрен системалы иштеп торсалар, бу, үз чиратында, театр сәнгатенең үсешенә зур йогынты ясар иде. Югыйсә, бездә тамашачы сәхнәдәге артистның уенына сокланса яки эче пошса, күршесеннән бу артистның фамилиясен сорый. Ләкин күршесе дә аңа җавап бирә алмый. Бу — артистларның тамашачылар белән бәйләнешләре булмаудан килә дип уйлыйм.

Минем күп кенә шәһәрләрдә (Мәскәү, Горький, Куйбышев, Саратов һ. б.) спектакльләр караганым бар. Ул спектакльләрдә тамашачының яраткан артистлары сәхнәдә күренү белән үк зур алкышлар башлана. Бу артистларның тамашачыга якын торуын һәм аларда мәхәббәт казануларын күрсәтә. Мондый артистлар безнең үзебездә дә бар, ләкин аларны тамашачы белән якыннан таныштыру җитми. Моның юллары күп төрле. Элеграк кулланылганча, артистларның бенефис спектакльләрен куюны оештыру хәзер дә кирәк түгел микән? Артистларның иҗади отчетларын практикага кертү, радио һәм телевидение аша аерым артистларга багышланган тапшырулар оештыру да бик файдалы булыр иде. Бу өлкәдә шулай ук ВТОның Татарстан бүлекчәсе дә күп эшләр эшли ала.

Тиздән җәмәгатьчелек Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының 60 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк. Шундый данлыклы юбилей алдыннан театрыбызны тагын да югарырак баскычка күрәсебез килә. Безнең драматургларыбыз да бүгенге тормышны тулы канлы итеп чагылдырган, берсеннән-берсе матур әсәрләр бирерләр дип ышанабыз.

*ӘГЪЗАМ ҖӘЛӘЛИЕВ,*
*Биектау районының Киров исемендәге колхоз председателе.*

# «КАЗАН УТЛАРЫ»Н БАЛКЫТУЧЫЛАР

Үткән елның икенче яртысында, «Союзпечать» работникларына һәм җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыларга мөрәҗәгать итеп, журнал редакциясе аларның «Казан утлары»н таратуда актив катнашуларын үтенгән һәм иң күп журнал тараткан кешеләргә бүләкләр бирелачәген хәбәр иткән иде. «Союзпечать» органнарында эшләүче иптәшләр дә, матбугат таратучылар да, редакция үтенечен искә алып, «Казан утлары»н таратуда бик тырышып эшләделәр һәм менә шул тырышлыкның нәтиҗәсе: 1965 елда журнал 20 000 дана тираж белән чыккан булса, бу ел ул 37 000 дана басыла.

Шушы елның 18 январенда редакция, Казандагы «Союзпечать» оешмалары работникларын һәм җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыларны җыеп, узган подписка сезонына йомгак ясады. Җыелышта «Союзпечать» работниклары һәм матбугат таратучылар үзләренең эш тәҗрибәләре турында сөйләделәр. Аннары «Казан утлары»н таратуда аеруча актив катнашкан иптәшләргә бүләкләр тапшырылды. Беренче бүләк (транзисторлы радиоалгыч) Казан заводларының берсендә өлкән инженер булып эшләүче Мәлик Мөхәммәтҗановна, икенче бүләк — Т. Айдельдиновка, өченче бүләк — Э. Зәйнуллинга бирелде. «Союзпечать» работникларыннан В. Иванов, Фәйзрахманова, Әбдрәшитова, Суркова, Орлова, матбугат таратучылардан Гудкова, Тихонова, Баталов, Баталова һәм Фатыйховларга да истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Журналны таратуда республикабыз районнарында эшләүче «Союзпечать» работниклары һәм матбугат таратучылар да бик актив катнашканнар иде. Райкомнардан алынган мәгълүматлардан чыгып, редакция республикабыз районнарындагы актив матбугат таратучылардан:

Ә. Азизова (Буа районы, Шәйморза станциясе),
Х. Әхмәтов (Мөслим районы, Т. Табын авылы),
Х. Султанбеков (Әгерҗе),
Р. Галиева (Әгерҗе районы, Кодаш авылы),
А. Төхфәтуллина (Әгерҗе районы, Тирсә авылы),
М. Гисмәтова (Бөгелмә районы, Карабаш поселогы),
Х. Вәлиев (Кама тамагы районы, Карамалы авылы),
А. Кәлимуллин (Алабуга районы, Бондюг поселогы),
М. Садыйков (Алабуга шәһәре),
Галиева (Алабуга районы, Юраш станциясе),
Ф. Гарипов, Ф. Мәрданова (Куйбышев районы, Урта Йорткүл авылы),
Ф. Сөләйманова (Куйбышев районы, Иске Рәҗәп авылы),
Х. Хаҗиева (Азнакай районы, Тымытык авылы),
Г. Мөхитова (Азнакай районы, Чалпы авылы),
Р. Хәйдәров (Азнакай районы, Урманай авылы),
З. Җәләлиева (Кукмара районы, Кукка авылы),
М. Фәйзрахманов (Кукмара поселогы),
Ф. Садыйкова (Чирмешән районы, Лашман авылы),
М. Минһаҗов (Чирмешән районы, Иске Кәди авылы),
Ф. Әхсәнова (Лениногорск районы, «Уңыш» колхозы),
У. Фатхуллин (Лениногорск шәһәре),
Р. Закирова (Апас районы, Чәчкаб авылы),
Х. Хафизова (Апас районы, Кушман авылы),

З. Сәлимова (Актаныш районы, Иске Курмаш авылы),
Х. Хәсәнҗанова (Актаныш районы, Иске Сәфәр авылы),
Д. Галимова (Актаныш районы, Иске Богады авылы),
Р. Мәҗитова (Сарман районы, Минзәләбаш авылы),
Л. Шакиров (Сарман районы, «Нәркәй» совхозы),
З. Хәсәншина (Мамадыш районы, «Кызыл флаг» колхозы),
Р. Котдусова (Мамадыш районы, Түбән Тәкәнеш авылы),
Н. Нуруллина (Әлмәт районы, Түбән Мактама авылы),
Р. Нуретдинова (Әлмәт шәһәре),
С. Фәретдинова (Әлмәт районы, Кама Исмәгыйле авылы),
М. Харрасова (Әлмәт районы, Бишмунча авылы),
З. Гәрәева (Әлмәт районы, Сөләй авылы),
Х. Закирова (Әлмәт шәһәре)
иптәшләргә дә истәлекле бүләкләр җибәрде.

Журнал редакциясе «Казан утлары»н таратуда катнашкан барлык иптәшләргә чын күңелдән рәхмәт белдерә һәм алар киләчәктә дә бу эшне дәвам иттерерләр дип ышанып кала.

## „КАЗАН УТЛАРЫ“ ЖУРНАЛЫНЫҢ РЕСПУБЛИКАЛАР ҺӘМ ӨЛКӘЛӘРДӘ ТАРАЛУЫ[1]

| Тәртип №№ | Республикалар, өлкәләр | 1965 елда | 1966 елда | Тәртип №№ | Республикалар, өлкәләр | 1965 елда | 1966 елда |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Бөтен Союз буенча | 19246 | 37100 | 19. | Красноярск | 122 | 137 |
| 2. | Татарстан | 8781 | 13000 | 20. | Чувашия | 68 | 101 |
| 3. | Башкортстан | 4217 | 9689 | 21. | Төркмәнстан | 67 | 142 |
| 4. | Пермь | 870 | 1422 | 22. | Курган | 66 | 136 |
| 5. | Казагыстан | 748 | 1480 | 23. | Мәскәү | 65 | 50 |
| 6. | Свердловск | 712 | 1120 | 24. | Сахалин | 59 | 74 |
| 7. | Үзбәкстан | 496 | 1102 | 25. | Пенза | 50 | 150 |
| 8. | Оренбург | 417 | 873 | 26. | Горький | 46 | 178 |
| 9. | Кемерово | 354 | 557 | 27. | Астрахань | 42 | 91 |
| 10. | Чиләбе | 347 | 566 | 28. | Новосибирск | 42 | 64 |
| 11. | Таҗикстан | 321 | 551 | 29. | Саратов | 36 | 48 |
| 12. | Кыргызстан | 224 | 374 | 30. | Томск | 35 | 37 |
| 13. | Ульяновск | 218 | 701 | 31. | Иркутск | 24 | 45 |
| 14. | Киров | 77 | 144 | 32. | Омск | 11 | 188 |
| 15. | Куйбышев | 161 | 443 | 33. | Тула | 11 | 19 |
| 16. | Төмән | 158 | 253 | 34. | Бурятия | 11 | 36 |
| 17. | Украина | 133 | 81 | 35. | Мордовия | 9 | 31 |
| 18. | Удмуртия | 122 | 276 | 36. | Ленинград | 7 | 54 |

[1] Таблицада журнал аеруча күп тарала торган республикалар һәм өлкәләр генә күрсәтелде.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМЫЙ

### БЕР ГОРУРЛЫК ХИСЕ

Без әле һаман булып узган бәйрәм тантанасы тәэсирендә яшибез; күңелләрдә — зур горурлык хисе, ә телләрдә — Сибгат Хәкимнең мәгълүм юллары:

Бер горурлык хисе яна миндә,
Әчтән бәреп яна битләрдә.
Сөйләр идем аны дөньядагы
Барлык-барлык парламентларда...

Ватаныбыз халыклары, прогрессив кешелек дөньясы, киң күләмдә, зур итеп, герой шагыйребез Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеен бәйрәм иттеләр. Муса Җәлил юбилее уңае белән үткәрелгән чараларны санап кына чыгу өчен дә күп вакыт, зур урын кирәк булыр иде. Белмим, Татарстанда бу бәйрәмне билгеләп үтмәгән бер генә шәһәр яки район, бер генә колхоз яки авыл, бер генә предприятие яки уку йорты калдымы икән? Мөгаен, юктыр.

Юбилей алдыннан һәм юбилей көннәрендә республика газета-журналларының күп саннары тулысынча Муса Җәлилгә багышланып чыкты. «Газетабызның бу саны патриот шагыйрь Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеена багышлана», «Журналыбызның бу саны Муса Җәлилгә багышлана» кебек белдерүләр гадәти бер хәлгә әйләнде.

Сәгыйт Алиш, Чыңгыз Айтматов, Анна Ахматова, Баязит Бикбай, Петрусь Бровка, Ким Васин, Антанас Венцлова, Олесь Гончар, Гафур Голәм, Михаил Дудин, Мирза Ибраһимов, Давид Кугультинов, Сәйфи Кудаш, Кайсын Кулиев, Мостай Кәрим, Георгий Леонидзе, Семен Липкин, Марк Лисянский, Макс Майн, Эдуардас Межелайтис, Жубан Молдагалиев, Рәсүл Рза, Сөләйман Рөстәм, Константин Симонов, Сергей Смирнов, Николай Тихонов, Мирза Турсун-заде, Василий Федоров, Степан Щипачев, Камчы Жунусов, Камил Яшен кебек күренекле каләм осталары үзәк һәм республика матбугатында, юбилей кичәләрендә сөекле шагыйребез турында да, аны тәрбияләгән татар әдәбияты, Мусадай лачынны үстергән халкыбыз турында да күп мактау сүзләре әйттеләр.

«Литературная Россия»нең 11 февральдә чыккан санының 4 бите герой шагыйрьгә багышланган иде. «Правда», «Известия», «Литературная газета», «Комсомольская правда» һәм башка үзәк газеталарның 15 февральдә чыккан саннарында Муса Җәлил шигырьләре, аның иҗатына багышланган мәкаләләр басылды.

Үзәк журналларның февраль санында герой шагыйребез турында материаллар бар. «Москва», «Молодая гвардия», «Дружба народов», «Волга», «Юность» кебек журналларда Муса Җәлилнең 60 еллык юбилее шактый киң һәм тулы яктыртылды.

### ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ...

Шәһәр һәм поселоклардагы Җәлил исемендәге урамнарны, культура сарайларын һәм клубларны, уку йортларын һәм кинотеатрларны, колхозларны һәм совхозларны, пионер дружиналарын киң илебезнең теләсә кайсы почмагында очратырга мөмкин. Юбилей уңае белән Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең якты истәлеген мәңгеләштерү өчен тагын күп нәрсә эшләнде.

* * *

15 февраль көнне Казан шәһәренең 85 мәктәп укучылары, тантаналы шартларда, Муса Җәлил музеен ачтылар. Музейда герой шагыйрьнең иҗатына һәм тормыш юлына бәйләнешле күп кенә кызыклы материаллар тупланган. Яшь скульптор Сысоев укучыларга үзе эшләгән Муса Җәлил бюстын бүләк итте.

* * *

15 февральдә герой-шагыйрь исемен йөрткән нефтьчеләр поселогында Муса Җәлил музее ачылды. Музейда шагыйрь тормышына бәйләнешле рәсемнәр, истәлекләр, «Моабит дәфтәре»нең фотокопиясе һәм күп санда башка экспонатлар бар.

Музейны ачу тантанасында КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре М. Сабиров, «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары У. Закиров, «Әлкинефть» идарәсе җитәкчеләре, алдынгы нефтьчеләр, Әлмәт язучылары катнашты.

Җәлил поселогы пионерлары шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым, бельгияле Тиммерманс һәм Муса Җәлилне күреп белгән кешеләр белән элемтәгә керәчәкләрен белдерделәр.

* * *

Юбилей көннәрендә Оренбургтагы ике бинага мемориаль такта куелды. Аларның берсе — Муса укыган элекке мәдрәсә, икенчесе — комсомолның Оренбург губерна комитеты бинасы.

* * *

Кириши — нефтьчеләр һәм химиклар шәһәре, Волхов елгасы ярына салынган яңа шәһәр. Шәһәр советы башкарма комитеты карары белән Киришидагы икенче урта мәктәпкә Муса Җәлил исеме бирелде.

* * *

Югославиянең «Ульяник» судноляр төзү верфында Советлар Союзы өчен эшләнгән тагын бер теплоход суга төшерелде. Иң яхшы приборлар белән җиһазландырылган 12 мең тонна йөк сыйдырышлы океан гигантына Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исеме бирелгән.

«Муса Җәлил» исемендәге теплоходның капитан ярдәмчесе И. Кашаев, Татарстан язучылар союзына җибәргән хатында, болай дип яза: «Безнең судно моряклары герой шагыйрьне беләләр, яраталар. Судно экипажы Муса Җәлил исемен намус һәм горурлык белән йөртергә сүз бирә».

## ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

Татарстан дәүләт музее татар халкының бөек улы Муса Җәлил поэзиясен, аның героик тормышын өйрәнү һәм пропагандалау буенча зур эш башкара. Юбилей уңае белән, музейда зур күргәзмә ачылды. Андагы экспонатлар Җәлилнең иҗат һәм тормыш юлы турында гына түгел, ә бәлки герой шагыйрьнең үлемсезлеге, аның әсәрләренең Советлар Союзында, шулай ук чит илләрдә киң танылуы хакында да сөйли. Экспозициянең бер бүлеге «Җәлил турында совет язучылары» дип исемләнгән. Күренекле совет язучыларының күргәзмәгә җибәргән хатларында Муса Җәлилнең гражданлык һәм шагыйрьлек батырлыгына тирән соклану, мәхәббәт һәм хөрмәт сизелеп тора.

* * *

Мәскәүнең матур әдәбият нәшрияты, 100 000 тираж белән, Муса Җәлилнең сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды. Сөекле шагыйребезнең иң яхшы әсәрләре тупланган бу җыентык «Яшьлек», «Окоптан хатлар», «Соңгы җыр» дигән өч бүлектән тора. Муса Җәлил әсәрләрен тәрҗемә итүдә П. Антокольский, А. Ахматова, Э. Багрицкий, С. Липкин, С. Маршак, Р. Моран, И. Сельвинский, И. Френкель кебек танылган шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр катнашкан. Җыентыкка кереш сүзне Ю. Корольков язган, төзүчесе В. Ганиев.

* * *

Юбилей көннәрендә укучылар тагын бер кадерле бүләк алдылар. Татарстан китап нәшрияты татар, рус һәм немец телләрендә «Муса Җәлил» дип исемләнгән фотоальбом чыгарды. Альбомдагы фотоматериаллар һәм текстлар Муса Җәлилнең якты тормышы һәм гүзәл көрәше белән таныштыралар, аның көрәштәш дуслары — җәлилчеләр турында яңа мәгълүмат бирәләр.

* * *

Муса Җәлилнең 60 еллыгына Мәскәүнең «Знание» нәшрияты «Батырлык поэзиясе» исемле китап чыгарды. Хезмәтнең авторы — Рафаэль Мостафин. 80 меңнән артык тираж белән басылган бу китапта Муса Җәлилнең иҗаты, тормышы һәм героик көрәше турында сөйләнелә.

* * *

КПССның Татарстан өлкә комитетының газета-журналлар нәшрияты «Муса Җәлил» исемле брошюра чыгарды. Биш мең тираж белән рус телендә басылган бу брошюрага Гази Кашшаф тарафыннан герой шагыйрьнең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында язылган мәкалә, шагыйрьнең автобиографиясе, хатлары, Җәлил иҗатына караган әдәбиятның кыскача библиографиясе кертелгән.

* * *

Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең «Хат ташучы» исемле поэмасын, зур тираж белән, аерым китап итеп чыгарды. Укучылар тарафыннан яратып укыла торган бу поэма матур, төсле рәсемнәр белән иллюстрацияләнгән.

* * *

Юбилей көннәрендә Казанның барлык театрларында диярлек Муса Җәлилгә багышланган спектакльләр барды.

Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры Нәкый Исәнбәт әсәре буенча эшләнгән «Муса Җәлил» спектаклен сәхнәгә чыгарды. Муса ролен Ф. Халитов һәм Р. Таҗетдинов башкарды. Спектакльнең режиссеры П. Исәнбәт, художнигы М. Сутюшев.

В. И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры, Муса Җәлил юбилеена багышлап, «Онытма, синең хакка» исемле музыкаль-поэтик спектакль әзерләде. Пьесаның авторлары — Р. Кутуй һәм А. Бикчәнтәев, сәхнәгә куючы — театрның баш режиссеры Н. Орлов.

Юбилей көннәрендә Татар дәүләт опера һәм балет театрында, зур уңыш белән, Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсы барды.

* * *

Татарстан радиосы һәм телевидениесе дә, герой шагыйрьгә багышлап, бик кызыклы һәм эчтәлекле тапшырулар оештырды. Тамашачылар, радио тыңлаучылар «Муса Җәлил турында яңа документлар», «Муса абый», «Серле йомгакны сүткәндә», «Үлмәс җыр», «Муса», «Азатлык җырлары» исемле тапшыруларны аеруча яратып карадылар һәм тыңладылар.

* * *

18—19 февральләрдә университетның Актлар залында Татарстан язучылар союзы идарәсе, СССР Фәннәр академиясенең Ка-

зан тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты патриот шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулуга багышланган фәнни конференция үткәрделәр. Конференцияне, Муса Җәлилнең бай поэтик мирасы турында кереш сүз сөйләп, философия фәннәре докторы, профессор М. И. Абдрахманов ачып җибәрде. Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә багышланган докладлар белән тәнкыйтьчеләр Г. Кашшаф һәм Р. Мостафин, университет доцентлары һәм укытучылары З. Мәҗитов, В. Хаков, Р. Низамов, СССР Фәннәр академиясе Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни сотрудниклары Б. Гыйззәт, А. Әхмәдуллин, В. Воздвиженский, Ш. Ханбекова, Ә. Кәримуллин, СССР Фәннәр академиясенең Уфа тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни сотрудингы К. Әхмәтҗанов, Башкорт дәүләт университеты доценты Ә. Нигъмәтуллин, мари язучысы К. Васин, Чувашстан АССР Министрлар Советы каршындагы тел, әдәбият, тарих һәм экономика институтының әдәбият секторы мөдире В. Долгов, Казан шәһәренең 26 мәктәп директоры М. Мөхәммәтов иптәшләр чыгыш ясады.

Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулуга багышланган тантанага илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән, шулай ук чит илләрдән кунаклар килде. Алар арасында Җәлилнең көрәштәш дуслары бельгияле Андре Тиммерманс, Гараф Фәхретдинов, Рушат Хисаметдинов, Фәрит Солтанбековлар бар иде. Фәнни конференциядә Мусаның көрәштәшләре һәм замандашлары герой шагыйрь турында кызыклы истәлекләр сөйләделәр.

* * *

Шагыйрьнең 60 еллыгын каршылап, СССР Элемтә министрлыгы Муса Җәлилгә багышланган почта маркасы чыгарды. Художник Ю. Лукьянов тарафыннан эшләнгән бу маркада Муса Җәлилнең портреты, арттарак — РСФСРның һәм ТАССРның халык художнигы Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» исемле мәгълүм картинасыннан репродукция бирелгән.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

Без, никадәр генә тырышсак та, укучыларыбызны Муса Җәлилгә багышлап үткәрелгән тантаналы кичәләрнең барысы белән дә таныштырып чыга алмас идек. Алар бик күп, алар йөзләрчә. Шуңа күрә күп санлы ул җыелышларның кайберләре турында кыскача мәгълүмат бирү белән генә чикләнергә мәҗбүрбез.

Юбилей тантаналары Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында башланды. Шушы авылда Муса дөньяга килгән, шунда үскән, шул авылда «Кызыл чәчәк» исемле беренче пионер оешмасы төзегән. Мостафада әле бүген дә Җәлилне якыннан белүчеләр күп. 13 февраль көнне дала уртасындагы бу авылга Оренбург өлкәсе партия һәм совет органнарының вәкилләре, Татарстан, Башкортстан, Чувашстан һәм Мәскәү язучылары, Мусаның туганнары килеп төште. Шагыйрь һәйкәле янындагы тантаналы митингны Шарлык район Советы башкарма комитеты председателе С. Бахтияров ачып җибәрә. А. Коптяева, Г. Минский, Н. Нәҗми, П. Хузангай мостафалыларга рус, татар, башкорт һәм чуваш халыкларының кайнар туганлык сәламнәрен тапшыралар. Шуннан тантана авыл клубына күчә. Х. Туфан, Н. Нәҗми, Г. Латыйп, Ә. Юныс, С. Шакир Мусага багышлап язган шигырьләрен укыйлар. Мусаның туганнары — абыйсы Ибраһим, сеңелесе Хәдичә шагыйрь турында җылы истәлекләр сөйлиләр.

* * *

Өлкә хезмәт ияләренең герой шагыйрьне искә алуга багышланган тантаналы җыелышы Оренбург шәһәрендә уздырылды. Муса Җәлил турындагы докладны Язучылар союзының өлкә бүлеге секретаре Б. Бурлак ясады. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән әдипләр Муса турында дулкынландыргыч речьләр белән чыктылар. Ахырдан, сәнгать осталары һәм һәвәскәрләр көче белән, зур концерт бирелде.

* * *

«Кыргыз укучылары Муса Җәлил әсәрләрен яратып укыйлар. Татарлар безнең Муса Җәлилебез дисәләр, кыргызлар да аны безнең Муса Җәлилебез диләр... Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән, республикабыз китапханәләрендә, уку йортларында һәм колхоз клубларында кичәләр, конференцияләр үткәрелде...

Коммунизм төзүче совет кешеләре Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил исемен йөрәк түрләрендә мәңге саклар лар»,— дип яза Камчы Җунуссв «Социалистик Татарстан»га җибәргән телеграммасында.

* * *

Җәлил — үзбәк халкының да яраткан шагыйре. Аның тууына 60 ел тулу көне Үзбәкстанда киң күләмдә билгеләп үтелгән. Юбилей алдыннан «Моабит дәфтәре»нең икенче басмасы чыккан, «Шәрык йолдызы» һәм «Звезда Востока» журналларында Җәлилнең героик тормышын һәм иҗат эшчәнлеген яктырткан материаллар басыла, республика газеталары әдәби сәхифәләр бирәләр, китапханәләрдә һәм клубларда әдәби кичәләр һәм конференцияләр үткәрелә.

21 февраль көнне республика җәмәгатьчелегенең М. Җәлилгә багышланган тантаналы җыелышы уздырыла. Җыелышны Үзбәкстан язучылар союзы идарәсенең председателе Камил Яшен ача. Муса Җәлилнең героик көрәше һәм иҗаты турында «Шәрык йолдызы» журналының җаваплы редакторы Хәмит Голәм сөйли.

* * *

«Кадерле иптәшләр! — дип язалар Киевтә Муса Җәлил тантанасына катнашучылар.— Совет иле һәм аның чит илләрдәге дуслары татар халкының бөек улы геройшагыйрь Муса Җәлилне искә алганда, без, данлы туганыбызның тууына 60 ел тулуга

багышланган тантаналы кичәгә җыелган украин язучылары, сезгә, Мусаның якташларына, кайнар мәхәббәт һәм дуслык сүзләре белән мөрәҗәгать итәбез. Без Җәлилне Прометей туганы дип атыйбыз. Аның исеме Фучик, Галан, Вапцаровның үлмәс исемнәре белән бер рәттә тора. Мусаның иҗаты, тормышы, батырлыгы — геройлыкның, туган илгә, Ленин идеяләренә бирелгәнлекнең мәңгелек үрнәге.

Ялкынлы интернационалист Муса Кобзарьның туган илен яратты, һәм украин халкы аңа шундый ук эчкерсез ярату белән җавап бирә. Җәлил поэзиясенең ялкыны гел дөрләп торсын, аның тормышы халыкта җыр булып яңгырасын!».

* * *

Патриот-шагыйрь Муса Җәлил юбилее уңае белән, Әлмәт язучылары күп тапкырлар нефть предприятиеләрендә, мәктәпләрдә булдылар. Ә. Маликов, Г. Ахунов, Г. Афзал Бигәш авылындагы сигезьеллык мәктәп коллективы алдында чыгыш ясадылар. Алар Муса Җәлилнең иҗат һәм тормыш юлы, аның батырлыгы турында сөйләделәр, герой шагыйрьгә багышланган әсәрләрен укыдылар.

12 февральдә шәһәр оешмалары һәм Язучылар союзының Әлмәт бүлеге Техника йорты бинасында патриот шагыйрьгә багышланган зур әдәби-музыкаль кичә үткәрделәр. Фойеда Муса Җәлилнең һәм татар совет язучыларының китапларын сату оештырылды. Шундый ук кичә 14 февральдә Горький исемендәге шәһәр клубында да булып узды.

* * *

Юбилей тантаналарының иң зурысы, әлбәттә, Казанда булды. 19 февраль көнне шәһәребез хезмәт ияләре, республиканың һәм илебезнең төрле районнарыннан килгән кунаклар Татар дәүләт опера һәм балет театрына — Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты патриот шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулуга багышланган тантаналы юбилей кичәсенә җыелдылар. Президиумда Андре Тиммерманс һәм аның тормыш иптәше Жанна, Җәлилнең тормыш иптәше Әминә ханым һәм кызы Чулпан, Мусаның туганнары һәм немец подпольесындагы көрәштәшләре, каләмдәш дуслары, тугандаш республикалардан һәм өлкәләрдән шушы тантанага килгән күренекле әдипләр... Советлар Союзы гимны яңгырый. Тантананы, кыскача кереш сүз белән, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Батыев ача. Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе Мирсәй Әмир сөйли. Тантаналы җыелышта чыгыш ясаган иптәшләрдән РСФСР Культура министры Н. Кузнецов, РСФСР Язучылар союзы секретаре В. Федоров, Башкортстанның халык шагыйре М. Кәрим, казакъ шагыйре Җ. Молдагалиев, Оренбург язучысы А. Рыбин, Чувашстанның халык шагыйре П. Хузангай, балкар шагыйре К. Кулиев, бельгияле А. Тиммерманс М. Җәлил исеменә, татар халкы һәм татар әдәбияты исеменә күп җылы сүзләр, изге теләкләр әйттеләр.

Шул ук кичәдә А. Тиммерманска, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәр»н коткарып калуда күрсәткән батырлыгы һәм кыюлыгы өчен, «Батырлык өчен» медале тапшырылды.

Тантаналы кичәнең икенче бүлегендә, сәнгать осталары көче белән, зур концерт бирелде.

* * *

Мәскәүдә Җәлил юбилеена багышланган тантана 21 февральдә Чайковский исемендәге Концерт залында үткәрелде. Кичәне юбилей комиссиясенең председателе К. Симонов ачты. Татарстан АССР Культура министры Б. Гыйззәтуллин Муса Җәлил турында доклад ясады. Ленин премиясе лауреаты Э. Межелайтис, аннан соң Х. Туфан, П. Хузангай, әрмән шагыйрәсе С. Капутикян, К. Кулиев, Мәскәү шагыйре Р. Рождественский, башка чыгыш ясаучылар Җәлил поэзиясенең үлемсезлеге, бөеклеге турында сөйләделәр.

Муса турындагы истәлекләр белән шагыйрьнең көрәштәшләре чыкты.

## ҖИР ШАРЫ ӨСТЕНДӘ ҖӘЛИЛ ТАВЫШЫ

«Социалистик Татарстан» газетасының 13 февральдә М. Җәлилгә багышлап чыгарган санында басылган «Шагыйрь һәм заман» исемле мәкаләсендә Н. Юзиев болай язган иде:

«...Җәлил хәзер вакыт һәм заман сынавын да, милләт һәм дәүләт чикләрен дә бик иркен үтә, чорыбызның, халкыбызның намусы буларак, көрәшче шагыйрь буларак дөнья гизә. Моабит циклы, оста һәм талантлы очучы тарафыннан идарә ителгән ракета шикелле, шагыйрьне әдәбиятның бөтен дөнья орбитасына алып чыкты. Дөнья әдәбияты понарамасында хәзер инде Җәлилне һәм татар әдәбиятын читләтеп узу мөмкин түгелдер».

М. Җәлил әсәрләренең чит илләрдә күпме таралуын күрсәткән мәкаләләре белән Ә. Кәримуллин да югарыда әйтелгән фикерләрнең дөрес булуын раслады.

Эрих Мильштат, Леон Небенцаль, Франц Лешнитцер кебек немец әдипләренең республика матбугатында басылган мәкаләләре дә шул фикерне куәтли, шул фикерне раслый.

Ниһаять, Германиянең төрле шәһәрләрендә Җәлил юбилеена багышланган кичәләр үткәрелә икән (Г. Кашшаф. Немец халкы Мусаны зурлый. «Социалистик Татарстан» газетасы. 1966 ел. 20 февраль), бу да Җәлил иҗатының, татар әдәбиятының бөтен дөнья аренасына чыгуы турында сөйли.

Әйе, җир шары өстендә Җәлил тавышы ишетелә.

## Алдагы саннарда:

**А. Гыйләҗев. Берәү.** Повесть.

**Г. Гобәй. Корьән серләре.** Публицистик повесть. Дәвамы.

**С. Баттал. Чирмешән якларында.** Шигъри роман. Ахыры.

**Х. Камал. Әнкәй истәлеге.** Шигырь.

Яшь шагыйрьләр һәм язучылар иҗаты.

**Г. Рябков. Театр яшьтәше.** РСФСРның халык артисткасы Галия Булатова турында очерк.

**С. Шакир.** Х. Мөҗәй турында яңа документлар.

**1965 әдәби ел йомгаклары материаллары.**

Г. Кариевның тууына 80 ел тулуга багышланган мәкалә һәм истәлекләр.

**Ш. Маннур. Түгәрәк өстәл тирәсенә.**

**Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.**

**Рецензияләр.**

**Сатира һәм юмор әсәрләре.**

**Хатлар.**


**Җырлар.**

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев.**

Производствога бирелде 15/II-1966 ел. Басарга кул куелды 23/III-1966 ел. ПФ 07021. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 36500 экз. Заказ Н-247.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.



# ТУГАН ЯК

М. МОЗАФФАРОВ музыкасы

М. МАЗУНОВ сүзләре

Кешене иленнән, йортыннан аерып
Йөреткән юллар бар. Җиллар бар
Хәтердән җуелып, йөрәктән уелып
Онытылып калган күп җирләр бар
Ә сине, ә сине, ә сине, туган як,
Бар микән сагынмый торган чак!

Күрдем мин гомеремдә бик гүзәл якларны,
Яраткан җырларын ятладым.
Белмимен, никтер мин бер киткәч шул якка
Яңадан әйләнеп кайтмадым.
Тик сине, тик сине, тик сине, туган як,
Күңелемдә һәрвакыт сакладым.

Анда да тормышны гөл итеп бизәргә
Хуш исле чәчәкләр аттылар.
Хезмәттә сусасаң, суларын эчәргә
Шифалы чишмәләр актылар.
Тик сиңа, тик сиңа, тик сиңа, туган як,
Иң кайнар хисләрем тарттылар.

Шул икән иң изге бу туган туфракка
Мәңгелек мәхәббәт ялкыны.
Шул икән кейдерә, еракта торганда,
Иң нечкә сагыну аркылы.
Шуңадыр, шуңадыр, шуңадыр, ахрысы,
Йөрәгем һәрвакыт ярсулы!

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ